ISSN 0206—4189

# Казан утлары

2.1999



# JAZUCЬLARЬBЬZ CIT ILLƏRDƏ



Jazucьlarnьn̡ Helsinkidə ytkərelgən xalьqara kongressьnda qatnaşqan Tatar Pen-yzəqe əgzalarьnnan ber tərkem. Un̡nan sulga: **Marsel Gəlief, Mədərris Wəlief, Məsəgit Xəbibullin, Tufan Min̡nullin, Rkail Zəjdulla, Təlgət Barief, Razil Wəlief, Əxət Muşinskij, Waxit Junьs** *(1998 jьl).*



Şagir **Gərəj Rəxim** Misьrda «Isə Bolgar çillərə» fil'mьn təşery waqьtьnda *(1998 jьl).*

# Казан утлары
# Qazan utlarь

1999

**2**

**(916)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Хәлим Гайнуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Нажар Нәҗми,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Шамил МАННАП. Мин дә килдем, дөнья күрдем... *Шигырьләр* ..... 5
Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Агыйделнең аръягында... *Роман-кыйсса* ..... 11
ЗӨЛФӘТ. Җирнең йөрәгенә юллар якын. *Шигырьләр* ..... 68
Гариф АХУНОВ. Тимерханның эзләнүләре. *Документаль повесть* ..... 74
Җәүдәт ДӘРЗАМАН. Моннар фәрештәсе. *Поэма* ..... 104
Әхмәт ГАДЕЛ. Өзелгән кыллар. *Хикәя* ..... 109
Роза ХАФИЗОВА. Парчалар ..... 115
Госман САДӘ. Сүзем—ялкыным. *Шигырьләр. (Н. Гамбәрнең кереш сүзе белән)* ..... 119

**ФӘНЗАМАН БАТТАЛГА 60 ЯШЬ**

Фәнзаман БАТТАЛ. Сатирик хикәяләр. *(Ш. Маннапның кереш сүзе белән)* ..... 127

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Равил БОХАРАЙ, Гәрәй РӘХИМ. Татарның үз миссиясе бар ..... 140
Марсель ЗАРИПОВ. Генерал булу рәхәтме? ..... 144

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Тәүфикъ ӘЙДИ, Рафаэль СИБАТ. Туксанынчы еллар әдәбияты. *(Анкетага җаваплар)* ..... 156

**ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ**

Чулпан ЗАРИПОВА. Сәгыйть Рәмиев һәм Гаяз Исхакый ..... 162

**ФӘН ҺӘМ ДИН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Пәйгамбәр ..... 170

**ХӘТЕР**

Фуат МАННАПОВ. Бабаемның тормыш фәлсәфәсе: кеше хакы. *Истәлек. (Ә.Еники кереш сүзе белән)* ..... 179

**ФЛҮН МУСИНГА 60 ЯШЬ**

Назыйм ХАНЗАФАРОВ. Танылган галим ..... 185

**ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ**

Илһам ФӘЙЗРАХМАНОВ. Пародияләр ..... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190
Тышлыктагы сурәтләр ..... 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": "За рекой Белая"—роман З. ЗАЙНУЛЛИНА (окончание); документальная повесть Г. АХУНОВА "Тимерхан разыскивает..."; рассказ А. АДЕЛЯ "Оборванные струны"; этюды Р. ХАФИЗОВОЙ; поэма З. ДАРЗАМАНА; стихи Ш. МАННАПОВА, ЗУЛЬФАТА, Г. САДЭ.
"К 60- летию Фанзамана Баттала": предисловие Ш. МАННАПОВА и сатирические рассказы юбиляра.
"Публицистика": "У татар есть своя миссия" (беседа Г. РАХИМА с Р. БУХАРАЕВЫМ); окончание очерка М. ЗАРИПОВА "Легко ли быть генералом?"
"Литературная критика": "Татарская литература 90-х годов"—размышления Т. АЙДИ и Р. СИБАТА.
"История литературы": статья Ч. ЗАРИПОВОЙ "С. Рамиев и Г. Исхаки".
"Наука и религия": статья А. ТИМЕРГАЛИНА "Пророк".
"Память": Фуат МАННАПОВ. "Жизненная философия деда" (воспоминания).
"К 60-летию Флюна Мусина": статья Н. ХАНЗАФАРОВА "Известный ученый".
Юмор и сатира.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Белый волк"—фоторепродукция из картины Р. Миннебаева; писатель Фанзаман Баттал.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": "Over the White river" Z. ZAINULLIN'S novel; documentary story of G. AKHUNOV "Timerkhan searchs for..." A. ADEL'S story "The torn strings"; R. KHAFIZOVA'S etudes; Z. DARZAMAN'S poem; the verses of SH. MANNAPOV, ZULFAT, G. SADE.
"Commemorating the 60th Anniversary of Fanzaman Battal": the preface of SH. MANNAPOV and BATTAL'S satirical stories.
"Publicism": "Tatars have their mission" (the conversation of G. Rakhim with R. Bukharaev), the finishing of M. ZARIPOV'S essay "Is it easily to be general?"
" Literary criticism ": "Tartar literature of 90 years"-reflection of T. AIDI and R. SIBAT.
"History": CH. ZARIPOVA'S article "S. Ramiev and G. Iskhaky".
"Science and religion": A.TIMERGALIN'S article "The prophet".
"Memory": Fuat Mannapov "The philosophy of life of grandfather" (reminiscencer).
"Commemorating the 60th Anniversary of Flun Musin": N. KHANZAFAROVA'S article "The famous scientist".
Humour and satire.
The diary of social and cultural life.
In our covers: "The white wolf" the fotoreproduction from R. Minnebaev's picture; the writer Fanzaman Battal.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 2.02.99 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70Х108 1/16
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9019 Заказ 3-43
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1999 ел.

# ШИГЪРИЯТ



Шамил
Маннап

## МИН ДӘ КИЛДЕМ, ДӨНЬЯ КҮРДЕМ...

ГОМЕР ТУРЫНДА УЙЛАР

### Кабатлана калса...

*Ай-һай, дөнья, туйдым синнән,*
*Син дә туйгансың миннән;*
*Шушы яшьләремә җитеп,*
*Ни рәхәт күрдем синнән...*

Эти яраткан җыр.

**"Нигә икән һәр җан иясенә**
**Тик бер генә гомер бирелгән?**
**Кышлардан соң язлар килгән кебек,**
**Кабатланса иде гомерләр..."—**

**Әй, дусларым, шулай дисез дә бит,**
**Бармы икән моның кирәге?**
**Үз гомрендә узган сиратларны**
**Икенче кат узар өчен тагы**
**Түзәр микән адәм йөрәге?**
**Ничек булыр алдан күреп тору**
**Кабатланып узар юлыңны?**
**Хәтта кайчан үлеп китәсеңне**
**Кызыкмы ул белеп торуы?**

**Юк!**
**Күрәчәгең алдан күреп торсаң,**
**Башың чыкмас кайгы-газаптан.**
**Ни дисәң дә, Ходай бу дөньяны**
**Бик тә камил—серле яраткан.**
**Шөкер итеп кенә яшисе дә**
**Якты бу дөньяга килгәнгә,**
**Юк шул, дөнья камил булганда да,**
**Камиллектән ерак бу бәндә.**
**Җирдә яшәү тик бер бирелгәнен**
**Белгән хәлдә, никтер каныгып,**
**Кеше җанын, йә үзенең җанын**
**Кыючылар тора табылып...**

Кышлардан соң язлар килгән кебек,
Кабатлана калса гомерләр,
Нишләмәс бу бәндә?!—
Ярый әле
Тик бер гомер аңа бирелгән...

* * *

Кадерен белү кирәк
очраклылык
дип аталган гаҗәп мизгелнең.
Танып ал да, кадерен белеп кал син
рухың нурландырган тиңеңнең.

Кешеләр бит күк җисеме кебек,—
очышлары үзгә һәркемнең.
Бер-берсеннән якын тоела гына
галәмдәге йолдыз төркеме.

Үз йолдызың янәшәңдә чакта
нурларыннан аның балкып кал,
күк капусы ачылгандагыдай—
кирәк сүзең әйтеп, язып кал!
Шул сүз бәлки тарту көче булып,
язмышыгыз бәйләр гомергә.
Айрылсагыз, насыйп булыр микән
тагын шулай
бер-берегезгә якын килергә?..

Тугрылыкка, мәхәббәткә мисал—
Җир әйләнә Кояш тирәли.
Нинди генә якты йолдызлар да
алар арасына кералмый.

Әйләнә Җир чәчәк-гөлләр тотып,
балаларын кысып куйнына,
Кояш белән Җирнең мәхәббәте
нинди могҗизалар тудыра!

... Башын иеп килсә, кире какма
рухың нурландырыр тиңеңне.
Кадерен белү кирәк—очраклылык
дип аталган гаҗәп мизгелнең!

## Сайрар кошка кунып сайрау өчен...

"Аны бит мин җырчы иттем!"—диеп,
Сөйләп йөрисең ди, имеш, син.
Синең өчен җырламадым түгел,
Һич таналмыйм аны, нишлисең.
Нишлисең бит, кунып сайрау өчен
Кошларга да кирәк тал-тирәк.
Оясында җайлы була икән,
Сандугачның җыры ямьлерәк.

Әй син, зифа талым, мин дә сиңа
Кунган идем, сөеп, ышанып.
Тик оямны тормыш давылыннан
Саклый алмады шул кочагың.
Канат чыгармаган кошчыкларым
Очарга дип юкка талпынды,
Ятим калды алар... Җырларыма
Шатлык урынына зар тулды.
Үземнең дә очар канатымны
Каердылар давыл җилләре.
Ярый әле халкым күреп алып,
"Таян!.."—диеп, куйды иңнәрен.

Әйе, сайрар кошка сайрау өчен
Ышанычлы терәк бик кирәк.
Тал-тирәге үз иткәндә,
аның
Җырлары да була ямьлерәк.
Ә син миңа шундый кирәк чакта
Таянырлык терәк булдыңмы?
Юк, син мине җырчың итәлмәдең...
Зарлы иттең бары җырымны!.

* * *

*Болай, шаярып кына...*

Иркәм миңа: "Җаным..."—дия иде,
Танышлыкның тәүге таңында.
Инде хәзер: "Җаның алырмын!"—ди,
Хуҗа булып алгач җаныма.

Мин: "Фәрештәм..."—дия идем аңа,
Булганмындыр күктә-гарештә.
Инде белдем: чынлап фәрештә ул,
Әмма җан алучы фәрештә.

* * *

Адәм ул фәрештә түгел,
Оҗмах түгел дөнья йорты.
Табып була һәркайсыннан
Яхшылыкны, начарлыкны.

Бер үк чәчәктән ләбаса
Елан зәһәр агу җыя,
Бал җыя умарта корты.
Бер үк җирдә җимеш бирә
Алмагач һәм эт шомырты.

Син дә үз аслыңа күрә,
Табарсың минем күңелдән
Яхшылык йә начарлыкны...

## “Хуҗалар тавы”

Туган ягымда бар бер тау—
“Хуҗалар тавы”.
Ерак-еракка таралган
Бу тауның даны.

Болгар-йортка ябырылганда
Дошманнар явы,
Хуҗаларга терәк булган
“Хуҗалар тавы”.

Ир-егетләр һәлак булгач,
Илнең кызлары
Яуга чыккан—кальга иткән
“Хуҗалар тавы”н.

Дошман явын тончыктырган
Шәһитләр каны.
Тау өстендә—янә бер тау—
Ул—“Кызлар тавы”.

Шул кызларның күз-яшьләре—
Чишмә сулары.
Изге чишмә диеп халык
Атаган аны.

Ошбу таудан һич өзелми
Халык сукмагы.
Кочак җәеп каршы ала
“Хуҗалар тавы”.

Илемнең чын хуҗаларын
Таный ул, таный.
Изге чишмә суы белән
Халкымның рухын дәвалый
“Хуҗалар тавы”,
“Хуҗалар тавы...”

* * *

Нигә әле тәрәзәңә килеп,
Төнге күккә һаман карыйсың?
Җем-җем итеп торган галәмнәрдән
Үз йолдызың әллә таныймсың?

Таныйсыңдыр.
Яшьлегеңдә аны
Чөеп аткан идең үзеңнән.
Кем уйлаган шул чөелү көче
Күтәрәсен галәм түренә.

Чакырсаң да, инде соңга калдың,
Имин килеш кайту юк аннан.
Азмы йолдыз Җирне кочам, диеп,
Сузылганда сызылып югалган...

Пышылдыйсың:
“Янәшәмдә чакта
Күрмәгәнмен нурлы җаныңны.
Яннарыма кабат кайталмасаң,
Үз яныңа тартып ал мине!..”

Җем-җем иткән йолдыз әйтә сыман:
“Без генәме соңлап үкенгән.
Беребез—анда,
Беребез монда килеш,
Без янарга хөкем ителгән.
Без янарга хөкем ителгән...”

## Мин дә килдем, дөнья күрдем...

Көзгегә карарга куркам,—
Көзге турыдан яра:
“Тормыш көзең җитә,—ди ул,—
Чәчләрең дә чалара.
Элек йөзеңне нурлаган
Елмаю сызыкларың—
Инде хәзер хасил иткән
Картлык җыерчыкларын.
Төшенгәнсеңдер,
Дөньяда
Син—бары кунак, җаным...”

—Фәйләсүф көзге, әйтсәңче,
Ник туа Җирдә кеше?

“Ходай яраткан Адәмне
Дөньяда сынар өчен.
Бәлки күрсәтим дигәндер
Ул үзенең иҗатын,
Адәмгә гыйбрәт булырлык
Мәңгелек могҗизасын?

Иксез-чиксез Галактика—
Илаһи иҗат эше.
Җир тормышы—шул иҗатның
Нәни бер чагылышы.

Адәмгә дә рухын өргән,
Иҗат итәрсең!..—диеп,
Эшең калыр, ә син үзең
Соңра... китәрсең...—диеп.

Фанилыкка килгән җаның
Китәр бакыйлыгына.
Килү-китүнең арасы—
Яшәү дигән могҗиза...”

Аһ, көзге, гомер уза!..

## Яшь гомеркәй сыман...

**Табигатьнең яшь һәм дәртле чагы,**
**Яшь вакыты кебек Җирнең дә.**
**Әй, бу җәйләр!**
**Җәйрәп яткан ямьнәр—**
**Бөтенесе Кояш иркендә.**

**Бу фасылда Кояш кызлар кебек**
**Көлеп карый Җирен сөйгәнгә.**
**Җир вә Күкнең кавышу вакытлары,**
**Җимеш бирер өчен көзләрдә.**

**Җир вә Күкнең гыйшкы йөрәгенә**
**Күчкән бугай җиткән кызларның.**
**Кайсы бәхетлеләр татыр икән**
**Шул кызларның чишмә суларын...**

**Инеш буйларында—сылу кызлар,**
**Суларында казлар коена.**
**Яшь гомеркәй сыман ямьле җәйләр**
**Мәңге узмас кебек тоела...**

## Дулкын сагышы

*Бер болганмый су да тынмый,*
*Болганмый булмый, булмый...*

Халык җырыннан.

**Елга ага, дулкыннарын кага**
**Үзен тотып торган ярларга.**
**Аһлап ишелә ярлар, гүя алар:**
**“Каты какма!..”—диеп,**
**Дулкыннарга шулай ялвара.**

**Ярсыр өчен җилләр булышса да,**
**Булышмый шул**
**Ярга килеп гафу сорарга.**
**Шуңа микән кала агымсуга**
**Үкенүдән ямансуларга...**

**Аһ, болганмый, дулкынланмый гына**
**Буламыни озын юлларда?!**
**Ерактагы диңгезләргә чаклы**
**Кирәк ласа барып чыгарга.**

**Үзенең ярын үзе ишә елга,**
**Шунсыз бит ул ага алмыйдыр.**
**Ярдан башка яши алмаганын**
**Койган җиренә җиткәч аңлыйдыр...**

*1997—1998*

## Чәчмә әсәрләр

# Зәки Зәйнуллин

# АГЫЙДЕЛНЕҢ АРЪЯГЫНДА...

РОМАН-КЫЙССА

* * *

Хәйдәргали хәлфә белән ярлы малае Лотфулла дүрт ел бергә утырып урысча укыдылар. Хәйдәргали абый "Учител малайларына уйнарга иптәшлеккә" житәкләп еш кына үзенең улы Мирсәетне дә алып килә. Терекөмеш кебек тиктормас, хәрәкәтчән, уенга бик тә хирыс бер малай кисәге булып чыкты бәләкәй Мирсәет. Хәйдәргали хәлфә остазына, Учител Мирсәет Бийишевкә зур хөрмәт күрсәтеп улына аның исемен кушкан иде. Инде кече Мирсәет туганнан соң Эстәрлебашта Мирсәетләр икәүләр.

Дулкынланып үсә торган коңгырт чәчле, зәңгәр күзле, кечкенә гәүдәле бу үткен малайны күрше-күлән дә, таныш-белешләр дә, белгән-күргән дә Бәләкәч Мирсәет дип кенә йөртәләр. Ә Зур Мирсәетнең Эстәрлебаш авылы өчен исеме Учител Мирсәет, яисә Учител генә инде.

Әтисенә тотынып килгән Бәләкәч Мирсәет беренче көнендә үк ике малай белән "сугышлы уйнаганда" үзеннән яшь ярымга зуррак Учител улы Гомәрне "бәргәләп"тә алган. Абзасына "эләккәнне" тиз шәйләп алган һәм ярыйсы ук "шүрләгән" Вәлиәхмәт туңкаеп идәнгә яткан да, ике куллап күзләрен томалап "качкан". Янәсе ул "күрми дә, белми дә"...

Шул беренче көннән үк Бәләкәч Мирсәет ике малай өстеннән дә "башлык" итә башлый. Хатынының аптырап, зур ризасызлык белән сөйләгәнен Учител Мирсәет дәшми-тынмый тыңлаган һәм... үзенең адашының холык-фигылен караштыргалап, үзенә сиздерми генә "чамалый башлаган". Байтак хәлләрне күреп күз алдыннан уздыргач, әйткән Хәйдәргали хәлфәгә:

—Син мине яхшы гына иттереп тыңлале, Хәйдәргали абзый. Беләсенме нәрсә?

—Нәрсә, энем?!

—Синең бу малаеңның холык-фигылен мин караштырып йөредем-йөредем дә, бик кызык бер фикергә килдем бит әле...

—Әй, энем Мирсәет! Монауы орчык буе малайның нәрсәен карагансыңдыр инде, белмим мин. Аңа карап нинди фикер тусын инде тагын?! Кит! Азрак кына үсә төшсен инде, ичмасам!

—Алай түгел шул, Хәйдәргали абзый! Беренчедән, бу малай бөтенләй елый белми. Егылса да, сутышса да еламый. Чана шуалар иде өчәүләшеп. Шунда менә күрше Ваһап абзыйның Хәйруллясы белән сугышты. Мин шуларның сугышканын күренмичә генә, тәрәзә аша карап тордым. Минем малайлар курыкканнар, катнашмыйлар. Хәйрулла карга китереп тәгәрәтеп ега малаеңны, биргәли. Шуннан китә башлый. Мирсәет шунда ук егылган жиреннән сикереп тора да, тагын барып ябыша Хәйруллага. Хәйрулла

Ахыры. Башы 1 санда.

моны алып барып көрткә илтеп тыга. Тагын биргәли. Бу әллә ничек кенә иттереп ычкынып китә дә, сикереп тә тора, тагын тотына тегеләргә ыргылырга. Тегесе екканчы биргәләп тә ала. Башындагы, битендәге карларны сыпырып та тормый. Азактан белдем, теге малай боларның шуа торган чаналарын алырга маташкан икән. Сугышуы сугышу—чананы бирмәде барыбер. Туктадылар сугышудан. Икесе дә хәл алалар. “Китә инде хәзер Мирсәет!”—дип уйлыйм мин. Никтер эчемнән генә моның киткәнен теләмим үзем. Шуннан әтәч кебекләр иттереп сикереп Хәйрулланың өстенә кунды да, муеныннан борып көрткә екты. Өстенә менеп атланды да, акыртырга тотынды тегене. Илләмә биргәләде инде. Башы белән карга тыга, авызына кар тутыра. Шуннан Ваһап абзыйның хатыны чыгып, колагыннан өстерәп, малае өстеннән төшерде Мирсәетне. Хәйри торды да, үзләренә йөгереп кереп тә китте. Хәзерге көннәрдә Мирсәет чана шуарга чыкса, Хәйрулла юкка чыга да куя таудан.

—Сугышырга баш кирәкми инде аңарга. Анысы шулай. Ул бала өйдә дә шундый—суксаң да еламый. Яхшы гына әләккәне дә бар үзенә. Юк, еламый. Туп-туры күзгә карап тик тора, суксаң. Икенчегә сугарга кул күтәрелми инде, шулай итеп карагач.

—Мин сиңа сөйләп бетермәдем бит әле...

—Шулаймы?! Гафу туган, гафу!

—Бу бала үсеп житкәч гади генә кеше булмаячак. Барлык жирдә, барлык эштә башлап йөри торган егет булачак бу малаең синең. Чөнки уенда да, шаярганда да, эштә дә—һәрчак алда йөри бу. Үзе дә шуны ярата. Ай-һай, башка кешегә буйсына белмәс, ахрысы, бу малай...

—Ат карагы чыкмаса ярый инде.

Хәйдәргали хәлфә кулын селтәп көлде.

—Юкка көләсең син. Шундыйга тартымрак булуы да бар. Ат караклары, үзең күреп торасың, барысы да тәвәккәл егетләр...

—Ходай сакласын диген, энем. Ходай сакласын. Ул ат каракларының берсе дә үз үлеменә барып житә алмыйлар бит. Тәвәккәл булсалар да. Ярты юлларында үтереп бетереп торалар, йә ияр өстендә бирәләр жаннарын, яисә авыл урамында халыктан кыйналып үләләр. Ат урлаганда тотылып.

—Бик ныклы иттереп укытып, белем бирергә кирәк бу малайга, дип уйлыйм мин.

—Кулдан килерлек булса, укытырга тырышырбыз инде аны. Тик үзе нинди булыр бит. Ярый ла тырыш булса уку ягына...

Хәйдәргали хәлфә белән бәләкәй Лотфулла дуслашып китеп, икәү бергә арифметика, география, урыс тарихын урысчалатып өйрәнделәр. Көннәрдән бер көнне Мирсәет Учител үзенең укучыларына урыс китапларында булмаган фажигале тарихны сөйләде. Ул урысларның 1552 елда Казан каласын алу тарихы иде...

Зур бүлмә эчендә “чылт” иткән тавыш та юк. Төрле зурлыктагы, төрлечә киенгән, төрле төстәге татар малайлары Казан тарихын, үзләренең борынгы бабайларының фажигасен тыңлыйлар. Хәзерге мизгелдә алар өчен авыл урамнарында чана шуу да, жиргә төшәргә тырышкан карларны бөтерә-бөтерә уйнатып өертеп, аларны читән, коймa, абзар-кура, йорт ышыкларына китереп сырынтылар иттереп өеп йөргән эшкуар жил дә, бүген танда жан тәслим кылган, әллә кайдагы чит патшалыкның Шипка дигән кальгасы янында кулын калдырып кайткан Чулак Гыйльфан бабай кайгысы да юк. Малайлар башында тик Казан каласы кайгысы гына.

—... Урыслар Казан каласының биек, калын, ике катлы диварларын өч айдан артык камап торганнар. Урыс гаскәренең саны 150 меңнән артык булган. Ә Казан каласын саклаучы сугышчыларның саны 30 мең чамасы гына булган. Урысларның патшалары бик тә явыз, бик тә усал, бик тә рәхимсез кеше булган. Каршы әйтсәләр, яисә берәр гамәле белән ошамаса, үзенең урыс боярларын да тереләй көенә этләреннән талаткан. Исеме Иван, кушаматы Явыз булган ул патшаның. Казанны басып алырга

килгәч, Казансу елгасының Иделгә койган жирендә чатыр корып, шуннан Казанны алу белән житәкчелек иткән. Казанны ала алмагач, Аурупадан туп һәм дары белгече Бутлер дигән инглизнеме шунда, немецнеме— шуны бик зур акча түләп китергән. Шул Бутлер белән өч меңгә якын чит ил белгечләре ялланып килгәннәр. Барысы да башкисәр сугышчылар булган. Жир асты юллары казып өч урыннан шул Бутлер Казан каласы диварлары астына барып житкән. Диварларны өч урында шартлаткан. Диварлар бик каты жимерелгәннәр. Шул урыннардан ач, канга сусаган урыс сугышчылары ябырылып, кара саранча болыты кебек кала эченә ыргылганнар. Ә Казан каласы бик бай кала булган. Безнең бабайларыбызда алтын-көмеш акчалар, хатын-кызларның бизәнү өчен асыл ташлардан ясалган әйберләре, затлыдан-затлы киемнәре бик күпләп булган. Кала эченә бәреп кергән урыслар кем узардан шул байлыкны талау өчен йортларга, урамнарга таралганнар, сугышуны кирәк дип тә уйламаганнар. Безнең тере калган сугышчан бабайларыбыз бергә жыйналып тагын оешып алганнар да, өр яңадан һөжүм оештырып урысларга ташланганнар. Аларны кисә, тураклый башлаганнар. Куеннарына алтын-көмешләр тутырган, кулларына затлы киемнәр күтәргән урыслар, куркуларыннан сөрән сала-сала кире чыгу юлына йөгерә-кача башлаганнар. Качып өлгерә алмаганнары биек диварларның тышкы ягына сикереп аяк-кулларын сындырып бетергәннәр. Күпләре үлгән булып кыйланып, кала урамнарында тәгәрәп ятканнар. Безнең сугышчы батырларыбыз урысларны тоташлары белән Казан каласыннан куып чыгарганнар. Юан-юан бүрәнәләр тезеп кала диварларын яңадан күтәрә башлаганнар...

Урысларның каладан качып чыккан гаскәр башлыклары патшаның чатырында жыйналганнар. Барысы да куркышып басып торалар икән. Шулар арасында үзенең татарларын сатып урыска хезмәт итүен кәсепкә әйләндергән Шаһ Гали белән Камай морза да бар икән. Куркудан коты алынган Иван һөжүмне туктатабыз, Мәскәүгә кайтып китәбез, без бу татарларны беркайчан да жиңә алмаячакбыз, дип акырып-акырып елый икән. Тәхетендә утырган килеш. Шул чакта сатлык Шаһ Гали алга чыгып әйткән:

—Син патшасың! Ак атка атлан да чык, гаскәргә күрен. Менгән атың белән Казан кирмәненә карап бар. Сугышчылар күрсеннәр—патша исән, патша бар, патша сугышка чакыра! Казанны алу белән идарә итә...

Иван патша моңа каршы ризасызлык белдергән, башын селкегән. Кулы белән ишарә ясап, чатыр эченнән барлык кешеләргә чыгып китәргә боерык биргән. Шул чакта урыс попларының иң зурысы янында басып торган үзенең ике попына нәрсәдер пышылдап әйткән. Алдан сөйләшеп куелган буенча, шул ике поп, куркуыннан калтырап утырган патша янына килеп, аның карышуына әһәмият итеп тормыйча, икесе ике ягыннан, кулларыннан тотканнар да, чатырдан алып чыкканнар. Чатыр янында патша өчен инде иярле ат әзерләп куелган булган. Куркуыннан Иван патшаның атка атланырлык та көч-куәте калмаган булган. Ике урыс сугышчысы аны күтәреп атка атландырганнар. Иң зур поплары атның йөгәненнән житәкләп, теге ике поп атның ике ягыннан, өзәнгеләр яныннан атлап, патша сикереп төшеп качмасын дип саклап барганнар. Алып киткәннәр Иван патшаларын Казан кирмәне ягына каратып. Иван патшага ияреп барып барлык урыс гаскәрен өр-яңадан кузгатканнар. Урыслар тагын яна һөжүмгә күчкәннәр...

Урыслар алганнар Казан каласын. Иң соңгылардан булып Кол Шәриф исемле барлык руханилар башлыгы, Сәетебез һәлак булган. Ул үзенең шәкертләре белән, мөритләре белән соңгы сугышын Хан мәчете башында башкарган. Урыслар аны сөңгеләренә күтәреп мәчет башыннан ыргытканнар...

Бүлмә тып-тын. Малайлар тавышсыз гына елыйлар иде...

—... Явыз Иван боерыгы белән Казан каласы эчендәге барлык ир токымын, имчәк баласы булган малайлардан алып, карт бабайларга кадәр—

барысын да суеп бетергәннәр. Казансу елгасы мәет белән тулып, ярларыннан чыккан, Казан урамнарында адәм каны шарлавыклар ясап, елгалар булып аккан. Әсир төшкән, җәрәхәтле сугышчыларны урыслар куып Идел ярына алып килгәннәр. Су өстендәге бүрәнәләргә тезеп утыртып, су астында аякларын бер-берсенә тарттырып, нык иттереп бәйләп куйганнар. Шул бүрәнәләрне этеп Идел агымына чыгарып җибәргәннәр. Гәүдә авырлыгыннан бүрәнәләр әйләнгәннәр. Башлары су эченә кереп безнең шул сугышчыларыбыз тончыгып үлгәннәр. Су өстендә бәйләнгән аяклары гына күренеп торганнар; шул бүрәнәләр Идел агымы белән Самара, Сембер, Сарытау, Сары Чин, Әстерхан калалары якларына акканнар. Салларга дар агачлары ясап утыртып, урыслар һәр салга 20—30 ар татарны асканнар. Салларны да Идел белән түбән таба агызганнар. Дарлар астында карга-козгыннарга азык итеп әрдәнә-әрдәнә иттереп безнең сугышчыларның гәүдәләрен тураклап ташлаганнар...

Безнең хатын-кызларыбызны, кыз балаларны урыс сугышчылары үзләренә кол итеп бүлешеп алганнар...

Казан каласы, Казан дәүләте юк ителгән. Ханлыкның байлыгын күп санлы кораблар белән, олаулар белән Мәскәүгә алып кайтып киткәннәр. Бик тә бай булган Казан китапханәсен урамнарга чыгарып өеп ут төртеп яндырганнар.

Бүлмә эчендәге тынлыкны тик Лотфи мәхдүмнең сулкылдап куйгалаганы гына боза. Малайларның Казан каласын урыслар алуы турында беренче мәртәбә ишетүләре иде...

Эчке киеренкелектән кызарып чыккан Мирсәет Учител кесәсеннән кульяулыгын чыгарып битен, күзләрен, җилкәсен, муеннарын сөртеп алды. Тирләп чыккан иде ул. Тавыш-тынсыз яшь түккән малайларның күзләренә карап чыкты. Дулкынлануын басарга тырышып әйтте:

—Балалар! Сез чын татар балаларысыз! Казан фаҗигасе һәрчак сезнең йөрәгегездә, исегездә булсын. Без, татарларның, урыслардан биш йөз елга элек үзебезнең дәүләтебез булган. Без алардан дүрт гасыр элегрәк яза белгәнбез. Ниндидер гөнаһларыбыз өчен, бик күп иттереп байлык артыннан куган өчен Ходай Тәгалә безне урыска буйсындырган. Шулай иттереп, безгә, татар мөселманга тиешле җәзаны биргән...

Ходайның кодрәте киң! Килер бер заман—котылырбыз урыс коллыгыннан. Өр-яңадан үзебезнең дәүләтебезне төзербез. Без татарга хәзер белемле, затлы, иманлы, гыйлемле, батыр йөрәкле шәхесләр кирәк. Бу инде менә шушы сез укыган урыс ышкулын ачарга башы житкән, ярдәме тигән Шиһабетдин Мәржани хәзрәтләренең васыятедер. Ул әйтеп калдырганча, без татарга урыс теле дә бик кирәк. Үзебезнең ирегебез өчен. Җир шарында ниләр булганын без татарлар бүгенге көнне урыс теле аркылы гына белә алабыз, дигән ул.

Хәйбулла да, Лотфи да мәхдүмнәр булсалар да, Лотфулла да ярлы балта остасы малае гына булса да—сез барыгыз да татар балаларысыз. Максатыгыз да бер—татарның азатлыгы өчен яшәү, кирәк икән көрәшү дә шуның өчен. Сез барыгыз да татар халкы өчен яшәргә, эш итәргә фарызсыз. Шуны онытмагыз укыганда да, яшәешегездә дә...

Шул көннән башлап мәхдүмнәр Лотфулланың каталары эчен юешләүдән туктадылар.

Җәй көннәрендә Мирсәет Бийишев хатынын, ике малаен алып Казан каласына кайтып китә. Кунакка һәм туган-тумачасын күрергә, яраткан Казанында аз гына булса да яшәп алырга дип. Анда аны инде картаеп бетеп барган әтисе-әнисе, өч абыйсы, ике апасы, тагын да өч энесе һәм бер сеңлесе көтеп алалар. Сагынып-сагынып. Ә Эстәрлебашта, Чуаш Ягына тауга күтәрелгән сукмакның сул ягында, башын такта белән япкан кечкенә өйгә күз-колак булып күрше Гыйбәтулла бабай кала. Хуҗалар юл сәфәренә чыгып киткән көнне үк карт, Мирсәетнең яраткан йөнтәс Бохара песиен күтәреп кичләтеп кенә карчыгы янына кайтып керә:

—Тот, карчык, бу мәхлук жан иясен. Кәжә сөтеннән өлеш чыгар. Ә монысын инде Мирсәет улым бирде. Тот песи белән бергә!

Карчыгына ул өч тәңкә дә илле тиен көмеш акча тоттырды.

—Песи караганның, өен саклаганның хакы бу! Чәй ал! Бөртеклесен. Кытай чәе булсын. Шакир мәгъзүм кибетеннән ал. Анарда арзанрак. Күптән чын чәй эчкән юк. Шунардандыр дип уйлыйм—берәр нәрсә уйлый башласам, күзләр әлже-мәлже килеп тик торалар. Күрәләр үзләре күрүен, тик анлатып күрмиләр. Башка барып житми тиз генә күзгә күренгән нәстәләр. Эчкән чәй мәтрүшкә дә, кура жиләге яфрагы, аннан жыен юк-бар үлән шунда. Куе иттереп, сөтләп ясарсың, Ходай кушып...

Картның карчыгы, күгәргән юка иреннәрен кыймылдатып укынырга тотына:

—Писмиллахи-и иррәкмә-ән иррәк-ки-имм! Пиргәненә мең шөкер, кода-айкай-йы-ым минем...

Гыйбәтулла картның карчыгы күрше Тәтербаш исемле чуаш авылыннан иде. Ул авыл Димгә барып коя торган Тәтер елгасы башланган урынга утырган. Гыйбәт карт егет чагында шул авылның бае саналган Пәдер чуашка ялланып эшләгән. Кышкы суыклар якынлашып килгән караңгы бер көзге төндә изүенә, башына бик күп тәңкәләр таккан чуашларның зәңгәр күзле, кара чәчле, чабаталы Марфа исемле кызларын житәкләп Эстәрлегә алып кайтып киткән Гыйбәт. Айга якын авылдагы бер кешегә дә күрсәтмәгәннәр, өй эчендә генә яшәткәннәр чуаш кызын. Ай узуга өйгә абыстай чакырып китереп, чуаш кызын мөселман иттереп догалар укып, исемен үзгәртеп Мәхфия дип кушканнар. Инде кырык елдан артык бергә гомер кичерсәләр дә, ни сәбәптәндер балалары булмады. Марфа-Мәхфия урысларның чиркәвенә дә, чуашларның урманда урыс попыннан яшереп ясаган түмәр тәнреләренә дә барып табынып карады, файдасы тимәде. Инде картлыклары килеп житкәч: "Улсыз пер жылаган, уллы мең жылаган!"—дип үзен дә, картын да юатып яши Мәхфия карчык. Корбан, гает бәйрәмнәрендә ап-ак яулыклар бәйләп, пөхтә, матур иттереп, мөселманча бар жиренә дә житкереп киенеп, йорттан-йортка бәйрәм ашларына йөри. Кунак ашы—кара каршы, дигәнне онытмыйча үзе дә чакыра. Бер генә тамчы да чын татар хатыннарыннан артта калмыйча барлык татар ашларын пешерә белә. Үзенең дә күңелен күтәреп, жыелган мөселман хатыннарын да моңсуландырып, борынын аз гына тынкышландыргандай иттереп, мәкам белән коръән сүрәләрен дә укый белә Мәхфия карчык. Ә аннан инде, кирәкле вакыты житкәч, елына бер мәртәбә жаны сөйгән карты сагында Чуаш сукмагы белән каршы тауга үрмәли. Киеме дә мөселманча, үзе инде чын коеп куйган мөселман карчыгы Мәхфия булган чуаш Марфасы. Икәүләшеп, бер-берсенә тауга менәргә ярдәм итешеп тау башына менеп житәләр. Эстәрлебашка йөзләре белән борылып, Кыйбла тарафына карап дога укыйлар. Ул дога һәрчак "Әлхәм" була. Аннан соң шул сукмак белән кабаланмый гына кояш баешы ягына сузылып киткән чуаш юлына чыгалар. Тирә-яктагы яланнарга, якындагы һәм еракта күгелжемләнеп күренгән тауларга, күк йөзендәге әллә кайларга агылган күчмә ак болытларга карап соклана-соклана, Ходай Тәгаләнең ике жан иясе чуаш авылы Тәтербашка алып барган борынгы юл белән теркелдәп атлыйлар. Икесенең дә кулларында чикләвек агачыннан ясалган, кул тоткан жирләре шомарып матурланган таяклар, аякларында өр яңа, тик башлары азрак очлырак, чуашчарак иттереп ясалган чабаталар. Бу чабаталар чуаш бәйрәме өчен махсус ясалганнар. Гыйбәт карт тарафыннан.

Чуашларның Тәтербаш исемле авылларына барып житкәч, Гыйбәт карт авылга килеп житәрәк инде "чуашлана" башлаган карчыгын туптуры бажасы йортына алып килә. Ул йортта Мәх... э-э... Марфаның бертуган сеңлесе Мәтрунә яши. Керү белән сәлам бирә:

—Әссәлам-мәгаләйкүм, чуаш агай-энеләр.

Мәтрүнәнең ире Микалай мөешләренә эленгән, корымнан танылмый да торган "тегә урыс тәресенә" карап торуны кирәк дип тә тапмый. Ике

кулын алга сузып, татар бажае белән мөселманнарча гына күрешә:

—Вакалыйкем сәлам, бажакай! Әйдүк киләсең пезгә! Зур кунак пулып киләсең! Түрдән узыгыс!..

Шул көнне үк, кичен, күз бәйләнә башлаган вакытта чуаш авылыннан Тәтер елгасы агышы белән чакрым ярымдагы урман акланында чуашларның борынгы бәйрәмнәре була. Йорт башыннан биш тиенләп җыйналган акчаны, рясасының тирән кесәсенә шалтыратып тутырган озын чәчле урыс попы отец Константин, Тәтербаштан унсигез чакрымдагы урыс авылы Карамалкага "кызына кунакка" чыгып киткән. Киткәненә ике көн икән инде. Чуашларның бүгенге бәйрәмнәрен ул күрми дә, белми дә. Попның ул бәйрәмдә "бер генә дә катнашы юк" һәм "Слава Богу!" булмас та! Шунлыктан поп чуашларның борынгы бәйрәме хакында Эстәрлетамак архиреена хәбәр итеп тә тормый. Беренчедән, нигә дип инде аны борчырга? Икенчедән, чуашларның ул бәйрәмен Христос белән Аллаһ бергә тотынсалар да туктата алмаячаклар. Хәер, Аллаһ андый ыгы-зыгыга тыгылмый да ул! Татарларның Аллаһлары даже Сабантуйны да туктатырга болашканы юк. Мөселман Алласының күнеле урысның Богына караганда киңрәк тә, мәрхәмәтлерәк тә! Башка халыклар диненә кысылмый. Гөнаһ булса да, отец Константин шулайрак иттереп уй йөртә белә.

Аннан соң чуаш авылының сиксән җиде йортыннан бишәр тиенләп җыйган өч тәнкә дә сиксән тиен акча матур тавышлар чыгарып попның кесәсендә чылтыр-чалтыр киләләр. Ул акча попадья өчен. Ә инде илле биш тиене, шалтырамасын өчен кульяулыкка кысып төрелгәне, попның рясасының яшерен иттереп салынган әллә кайдагы, эчтәге кесәсенә тыгып куелган. Попадьяга поп әйтәчәк: "Тиешле биш тиеннәрне чуашларның кайберләре бирмәгәннәр! Ә теге илле биш тиен "кирәге чыккан чакта, эһ-һем, эһһ-һем!... акча кайчан да кирәк бит инде... хи-хи-хи...

Попадьяга да авылда эш килеп чыга. Җәй буена кем биш тиенне түләмәгәнне белергә тырышып, попадья зур сәясәт-сөйләшүләр алып барачак.

Ә Гыйбәт карт белән Мәхфия карчык бажайларына барып кергәч, "бәйрәмчәрәк иттереп", чуашча кием алмаштыралар. Мәхфия карчык, кыз чагыннан калган, суккан киндердән теккән, чиккән чуаш күлмәген кия, чуаш алъяпкычын бәйли. Тоташ тәңкәләр белән капланган очлы башлыгын кия. Муены, күкрәкләре тоташ тәңкәләр белән капланган була. Ире, чиккән Казан түбәтәен салып, шушы бәйрәм өчен дип айга якын кырдырмаган башындагы агарып беткән чәчләрен сыпыргалап куя. Бу инде җиткән чәч белән булса да чуашка аз гына ошарга тырышуы. Камзулын, ап-ак терсәкләре ямалган булса да, әле яңадан саналган күлмәген, буйлы, ярыйсы гына төпле ыштанын салып түрә дә, мич башына, "билгеле урынга" яшереп куя. Шуннан соң гәүдәгә бер чамалырак булган бажасының чуаш киемнәренә киенә. Күлмәк-ыштан чуаш киндереннән. Тәнеңнең берәр урыны кычытса, кулны күлмәк-ыштан эченә кертеп тыгасы юк—кул белән киндер күлмәкнең, яисә киндер ыштанның кирәкле җиреннән генә тотасың да, тәнне ышкыйсың. Кычыту хәзер үк бетә. Ә аякларга теэдән югары итеп, тирәләп уратып тагын киндер ыштыр урыйсың да, чуаш чабатасы киясең. Киенеп килгән чабаталар авылга кергәндә чуашлар карасын өчен генә. Ә чын чуаш чабатасын бажай бирә. Башы чабатаның чуртан балык башына ошап алга очлаеп тора. Сүстән өчләп ишкән озын киндерәсен аягыңның балтыры тирәсендә ун-унбиш тапкыр уратасың, тездән югарыга чыгарып тагын өч тапкыр урыйсың. Шуннан соң гына тышкы якка чыгарып очларын бәйлисең. Чыгып торган очларын киндерәгә кыстырасың. Куян колагы кебек тырпаеп чыгып тормасыннар. Югыйсә чуашча биегәндә сүтелеп китүләре дә бар бит әле аларның. Чуаш чабатасының борыны да очлы булу өстенә, юкәсе дә киңрәк була. Озын, киндер, чиккән күлмәкне дүрттән үргән, чәнти бармактан азрак нечкәрәк сүс бау белән буасың. Шуннан инде киндер

ыштанның тирән ике кесәсенә дә вак акча саласың. Бик күптән булмаса да, һәр кесәдә унлап, унбишләп булырга тиеш. Биегәндә чылтыр-чылтыр килеп тавышлар чыгарып торсын өчен. Гыйбәт карт шуның өстенә чуаш бажасы биргән кыргый чия тамырыннан ясаган чуаш трөпкәсен дә каба. Чуаш бажасында да бар андый трөпкә. Тәмәкесе дә аныкы. Чия яфрагы кушып эшләнгән. Трөпкәне каба кабуын Гыйбәт карт. Тик акланга барып гөнаһның зуррагына тотынганчы кабызмый. Барлык булган, булмаган тәвәккәллеген җыйнап, үзен тәвәккәл булырга юмалый-юмалый шул гөнаһны кыларга хәзерләнә карт солдат. Ак падишаһ хезмәтеннән алып кайткан урыс гадәте буенча, елына бер мәртәбә, чуашлар бәйрәмендә, Гыйбәт карт (эченнән генә аны "чуаш туе" дип йөртә)... аягыннан тәгәрәгәнче ... хәмер эчә. Шуның өчен дип алып килә дә инде аны чуаштан мөселман булган Мәхфиясе. Шулай булса да бәйрәм барган чакта Гыйбәт карт карчыгына тик Марфуга дип кенә эндәшә. Мөселман дине буенча булган аз-маз белеме (малай чагында дин дәресләрен үзләштерә алмыйча байтак "тал чыбыгы ашаган" шәкерт иде ул заманында!) булган карт төлке—Гыйбәт карт болайрак иттеребрәк фикер йөртә: "Теге дөньяга баргач сорасалар, нигә Марфаң белән чуаш бәйрәмнәренә барып гөнаһлы булдың, нигә анда хәмер эчтең, дип? Болайрак китеребрәк җаваплармын инде мин аларга: "Ул Мәхфия дигән карчык чуашларның Марфасы иде. Минем тырышлыгым белән мөселман хатыны Мәхфия булды ул. Вә һәм дә ул Мәхфиянең чуаш Марфасына бер генә тамчы да катнашлыгы юк!—диярмен. Тәмугка үземне тыксалар тыгарлар, тик карчыкны коткарып калырга тырышырга кирәк булыр..."

Чуаш бәйрәме бик тә күңелле уза. Үзләре ясаган хәмерне чуашлар башта уймактан гына эчәләр. Шулай эчсәң, "башка тиз китә" икән! Чыннан да шулай икән—чуашның белмәгәне юк! Башта уймак бераү генә була. Аннан икәү, аннан өчәү булып китә. Тиз-тиз йөри башлыйлар уймаклар. "Башка барып җитә башлагач", ярыйсы гына зурлыктагы балчык савыт килеп чыга. Аны чуашлар "урыс крушкасы" диләр. Кулдан-кулга китә теге шайтан... Уймактан эчеп шаулый башлаган башларын тагын да ныграк шаулатып, җилкенсенә башлаган күңелләрне тагын да ныграк җилкендереп "урыс крушка"лары чуашларның зур кулларында уйнап-уйнап йөриләр. Бушап, кире көрәгәчегә кайталар. Шуннан бераз вакыт узгач, чуашлар урыннарыннан кузгалып тора башлыйлар, акланга чыгалар. Араларында әле кыеш-мыеш басканнары юклар, күренмиләр. Тик инде йөзләр кызара башлаганнар, хатыннары да ирләренә якынрак елышып баса башлаган. Җайлап кына кузгалган кебек булса да, китә бию, китә җыр. Кайсысы өстенлек алганны әйтүе дә кыен. Җырлаганы да бии, биегәне дә җырлый. Чуашлар кызганнан кыза баралар. Тагын "урыс крушкасы" белән теге "кыздыра торганны" өстәп куялар. Шуннан бер мәлне акланны яңгыратып кем узардан тотыналар акырырга. Чуашчалап түгел, татарчалап. Килгән кунакны хөрмәт итеп:

—Ыстапан дәдәй! Ычтапан дәдәй! Кая пезнең сыпыскы-ы!

Хәмер башларына ныграк йөгергән саен чуашларның татарчалап кычкырганнары көчәйгәннән-көчәя генә. Кунак хөрмәтенә кычкырудан башка чуашларда тагын да бер хәйлә бар. Урман тәңреләре хәмерне дә чуашлар үзләре түгел, ә татарлар эчә дип уйласын! Татарга сылтасаң да ярый ул! Татар түзә ул!

—Хәмер эчкәннәр пес чуашлар түгел! Татарлар эчә хәмерне! Татарла-ар! Менә пит Кибәт бабай үсе утыра-а! Менә пит! Татар пит инде ул! Татар!

Эчкечелекне "татарга сылтап бетергәч", чуашларга тагын "Ыстапаннары" искә килеп төшә:

—Ыстапа-ан дәдә-әй! Син кайда-ауу?! Песнең сыпыскы кайда-а? Тау-а-ай!

Кычкырып чакырулар тоташ бер гүләүгә әверелгәч, Чәпүшкә чишмәсе ягыннан нечкә генә, чыйнаганга охшаган тавыш ишетелә башлый.

Жыр дисәң ачык кына көе сизелми үзенең, моң дияр идең—чуашта моң булмый бит инде. Тик әллә нинди генә бер уен коралының чыйнап-чыйнап чуаш көен уйнаганы ишетелә башлый. Озакламый күңелле генә иттереп уйнаучы агачлар арасында үзе пәйдә була да, акланга чыга башлый. Шулай итеп, бирегә тунын, бүреген йөнтәс яклары белән тышка әйләндереп кигән, чуашның кызыл путасы белән кат-кат урап билен буган, аякларына өр яңа, очлы башлы чуаш чабаталары кигән, ике кулына печтерелмәгән карт үгезнең тын тутырылган "янчыгын" тоткан бер карт чуаш атлый. Янчыкның бер очына баш бармак юанлыгындагы агач төрбә беркетелгән. Төрбәнең икенче нечкәрәк ягы картның авызында. Шуңа өреп, карт бертуктаусыз "янчык" эченә тын тутыра. Янчыкның алгы өлешенә каен агачыннан бик әйбәт иттереп шомартылып ясалган берничә тишекле курай беркетелгән. Карт чуаш бармаклары белән шул курай тишекләренә басып-ачып, янчык эчендәге һаваны курай тишекләреннән чыгарып чуашча сызгырта, чуашча гыжылдата һәм чуашча җырлата иде.

Акланны тутырып утырган чуашлар тып-тын булып сыбызгы җырын тынлыйлар. Ник бер чуаш шауласын!

Карт чуаш акланның кыры белән атлап китте. Аның артыннан кечкенә чуаш кызчыклары иярделәр. Аларга буй җиткергән кызлар, яңарак кына килен булып төшкән киленчәкләр, балаларын күтәргән, житәкләгән ир хатыннары, аннан соң вак-төяк малай-шалай, егет-җилән, яшь ирләр, ир урталары һәм иң арттан карт чуаш карчыклары, карт чуашлар иярделәр. Чуашның саламнан үргән тирән эшләпәсен киеп "чуаш карты" булган Гыйбәт бабай да шул "карт чуашлар" исәбенә кереп атлый.

Салмак кына атлап акланны бер мәртәбә әйләнеп чыккач, Ыстапан сыбызгычы уң кулын һавага күтәрде дә, өстән аска каратып селтәде. Шул ук мизгелдә аклан һавасы дертләп куйды. Әллә кайларда, урман эчендә куркып уянган каргалар каркылдашып очтылар. Урман артындагы тауның таз, кырчынлы башы селкенеп куйгандай булды. Акланда чуашча җыр башланды:

Инеш аша басма салдым,
Нечкә таллардан үреп лә,
Нечкә таллардан үреп.

Ничәмә-ничә еллар инде чуаштан татарга әйләнгән хатыны кул астында Гыйбәт карт та чуашча җырларга ярыйсы гына өйрәнгән иде инде. Көйләрен дә белә чуаш җырларының, сүзләрен дә чуашча әйттереп җырлый...

Атлап чыккан чакта басмам,
Сыгыла да бөгелә лә,
Бөгелә лә сыгыла;
Мине көтеп торган ярым,
Муеныма сарыла ла,
Муеныма сарыла-а.

Зур акланны тирәләп йөреп байтак җырлагач, чуашлар акланга чәчелеп утырыша башлыйлар. Туган-тумача, агай-эне, якын дус-иш бергәрәк җыйналып, түгәрәк ясап утырышалар. Бала-чага, кыз-кыркынны, балигъ булып бетмәгәннәрне аклан уртасына җыеп, тезеп утырталар да, аларны ылкынганчы ашаталар. Ашап туенгач, уйнап-көлеп күңел ачу өчен аларга аклан уртасы бирелә.

Ә аклан читенә утырышкан чуаш табыннары, уймактан эчүне оныгып, балчык "урыс крушкаларына", кырлы стаканнарга тотыналар. Байтак вакыт узып, инде ныклап кызгач, һәр елны берәр чуаш сөрән салып акырырга тотына:

—Кая песнең үсепеснең чуаш татарыбыс! "Ыстаканны" әйттерсен! "Ыстаканны!" Җырласын пескә-ә!

Аклан "гү" килә:

—Кая песнең Кибә-әт?! "Ыстаканны" җырласын! Ыстаканны-ы!

Чуашлар бөтен акланнары белән Гыйбәт картның җырлавын телиләр. Ул да көттереп тормый, "тегенең" белән мөлдерәмә иттереп тутырылган кырлы стаканын баш өстенә күтәреп, ачыграк урынга чыга. Уеннар, шау-шу туктала: "Үсепеснең чуаш татары җырлый пи-ит!"

Гыйбәт карт уң кулына тоткан тулы стаканын азрак һавада чайкый биреп, сул кулын биленә салып, ел саен бер үк җырны әйттерә. Тик җырның ниндие бит—чуашлар турында һәм аларның иң яраткан җыры ул! Тавышы азрак карлыкканрак кебек булса да, моңы бар иде чуаш татарының:

Чуашларның исемнәре-е
Пәдрий белән Ычтапа-ан;
Үзем җырлап, үзем эчә-әм,
Үземә тигән ыстака-ан...

Аклан тулы чуашлар куанычыннан аның тирәләп үскән карт имәннәр дә дер селкенеп шаулый кебек иде:

—Үсепеснең чуаш татары-ы-ы! Үсепеснең ыстака-а-ан!!! Эчәпе-ес... беткәнче-е!..

Табыннар тагын да ныграк кыза. Дөнья нужалары нужа булуларыннан туктап, чүпкә әйләнәләр. Чуашлар гөрлиләр, эчәләр, җырлыйлар, җылыйлар, кочаклашалар, үбешәләр... Кыска-кыска гына, тиз-тиз генә иттереп тәпәләшеп тә алалар. Тагын утыралар табыннарга, тагын гөрлиләр, тагын җырлыйлар, бииләр...

Икенче көнне кояш белән бергә шул акланда уянып китә Гыйбәт карт. Башы авылларындагы Гобәйдулла Көрпә коесындагы агач бадия кебек авыр һәм "авырта баш" дигән сүзләр белән генә аңлату җитмәслек итеп авырта. Ярылган, ахрысы—чатнап, чатнап сызлап авырта. Кисеп ташлар идең—яшисе бар! Авызы кипкән, теле авыз эчендә өскә күтәрелеп, аңкауга ябышкан. Куптарып алырлык түгел. Ыңгырашып Мар...э-э-э... Мәхфиясен чакырырга да әмәле юк. Үлә башлавы шулдыр инде, күрәсең?! Шулай да сул кулын кузгата ала. Янында татар иренең уянганын көтеп утырган Мәхфиясенең җылы ботын сәрмәп таба. Татарчалый:

—Си...си...н...ме, карчы...-ы-ыккк?!

—Мин картым, мин. Ычкындырма кулыңны тоткан җиреңнән. Хәзер хәл керер. Тот шушыны, кой авызыңа. Йотылыр, иншалла!

Ыстакан туп-тулы "теге" икән. Йа, Ходай! Нинди генә гөнаһлар эшләтми бу шайтан сидеге! Үзең ярлыкагыл инде?!

—Ы-ы-ы-ыh-hа-hа-а!!!

—Эч. Эч! Аннан соң чишмәдә юынырсың. Эч! Инде аягыңа бассаң, Ходай кушып, кайтыр юлга чыгарбыз. Еллыгыңны алдың, булды!

1856 елны Кырым сугышында дошман Севастопольне штурмлап алгач, яшь солдат Гыйбәдулла Исмәгыйлов Севастопольдән Керчь каласына кадәр җәяүләп кача. Шул Керчь каласына житкәч, "Севастопольне югалту кайгысыннан", урыс солдатлары аны тәгәрәгәнче хәмер эчертеп исертеп йоклаталар. Шул урыс солдаты хезмәтеннән калган начар гадәте бар Гыйбәт картның—елына бер мәртәбә ул "туйганчы" хәмер эчәргә тиеш. Шул эчеп тәгәрәү кирәк аңарга. Шулай эшләмәсә, ел буена туктамастан тиктомалга башы авырта...

Кешегә Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән бик тә гаҗәп нәстә бит ул баш! Хуҗасы нәрсәләр генә майтармасын, нинди генә ялгышлар эшләп куймасын (гөнаһлар дияргә Гыйбәт картның теле әйләнеп бетми), баш һәрчак үзенең хуҗасын ап-ак иттереп пакьлап, гаебен җиңеләйтеп, ә күп чакта бөтенләй юкка ук чыгарып та куя. Елына бер мәртәбә чуашларның Тәтербаш авылында хәмер эчеп тәгәрәп ятса да, Гыйбәт карт үзенең мөселманлыгын югалттым дип санамый. Башы аның болайрак уйлый: "Мин бит инде урыс кулы астына эләгеп, кеше кешесе булып, солдат хезмәте узганда, Рәсәйнең ак патшасы карамагында булдым. Теге, тырышып йөгерә торган дуңгызның итен дә ашарга туры килде. Урыстан

булган дус салдатлар белән... хәмерен дә эчкәләдек инде. Кая барасың эчмичә?! Ул эшләр бит инде барысын да патша галиҗәнабләренең әмерен үтәп башкарылдылар. Шунлыктан ул кылынган (баш һаман да "гөнаһлар" дими!) гамәлләр, кырынрак эшләр патша кушуы буенча эшләнгән булгач... әнә шул урыс патшасыннан сорасыннар теге дөньяда. Аннан соң патша хәзрәтләре урыстан булса да Ходайга якынрактыр инде. Аны бит инде безнең өстән... Ходай Тәгалә үзе куйган! Патша—патша бит инде ул! Салдат кына түгел!.."

Ә инде чуаш авылына килеп, акланда хәмер эчеп тәгәрәп ятканлыгы турында Гыйбәт картның башы болайрак иттереп фикер йөртә: "Йа, Ходай! Бер ел эчендә өч йөз илледән артык көннәрең бар. Аларның төгәл исәбен белеп тә бетермим инде. Мин колың, теге христиан динендәге чуаш Марфаны хатынлыкка алып, менә дигән мөселман хатыны Мәхфия ясадым аңардан. Зур изгелек кылдым ислам дине өчен. Әй-йе бит?! Әй-йе! Шул изгелекнең әҗере итеп бер генә көн шушы элекке чуаш хатынының янында мин дә алар чуашы булып кыйланып алыйм инде. Ул хатынның күңелен күрү миңа фарыздыр бит инде. Шунлыктан ярлыкагыл инде ... минем елына бер көн чуаш булганымны?!"

"Урыс крушкасына" салган "шайтан коткысын" күтәреп эчеп куя да, Мәхфиясенә ияреп, ярылган башын бик нык селкетмәс өчен каты иттереп басмаска тырышып кайту юлына чыга башлый. Алар кайтырга чыкканда әле бер генә чуаш та уянмаган, урыныннан кузгалмаган була.

Кайтып китәләр болар җайлап кына атлап. Чуаш авылы Тәтербашны чыгу белән сөзәк кенә озын үр башлана. Үргә каршы атлый-атлый Гыйбәт уфылдап куя. Доганың башындагы сүзләрен әйтмичә генә берничә сүзен әйтеп куя:

—Әлхәмделилләһи раббил галәмин...

Карты "төшереп калдырган" дога сүзләрен арттан килгән чуаштан мөселман булган карчыгы "җыя килә":

—Әгүзе билләһи миннәшәйтан иррәҗим, бисмилләһи иррахман иррахи-им...

—... иййәкә нәгбүду, иййәкә нәстәгыйн...

Карчыгы шул дога сүзләре алдында булганнарны өстәп килә:

—... мәлики йәүмитди-ин...

Ике мөселман җаны шулай, "кичә чуаш булганнарыннан" дога укып, арына-арына хәмер эчеп гөнаһланган җаннарын "изге мөселман юлына алып чыга башлыйлар." Кичәге гөнаһларын юл буена сибеп, коеп, догалар укый-укый мөселман авылы ягына карап юл тоталар. Бускын дигән чокыр янына житкәч, борынгы, иске ташландык юл белән уңга борылып, Ак Чагыл тавы ягына кереп китәләр. Борынгылардан калган истәлекләр буенча, шушы юл белән атаклы ат карагы Камчы Бакый Ырынбур ягында әби патша гаскәрләреннән җиңелгән Пүгач патшаның калдык сугышчыларын Ак Чагыл янындагы Бускын чокырына алып килеп яшергән, имеш. Исеме дә шуннан башлап аталмыш. "Бускын Чокыры..."

Ике картаеп килгән җан Ак Чагыл тау астында, ак ташлар арасыннан ургылып чыккан чишмә янында туктыйлар. Алмашлап тәһарәт алалар да, яшел чирәмне намазлык итеп, кыйбла тарафка карап намазга басалар.

Гыйбәт бабай азан әйтә, карчыгын намазга чакыра. Әби картыннан бер адымга сулда, ике адымга артта урын ала. Картның азан әйткәнен иреннәрен кымтап, сүзсез генә тыңлый. Картына кушылмый. Чөнки хатын-кызга азан әйтү дөрес булмас. Гыйбәтнең тавышы ялан-кырларны яңгырата:

—Алла-а-һу әкбә-ә-р!!!

Дүрт тапкыр кабатлаганнан соң ике мәртәбә:

—Әшһәдү әллә иләһә иллалаһ!—яңгырый.

Азан әйтелеп беткәч икәүләшеп намазга керешәләр...

Намаз тәмам булганнан соң челтерәп аккан чишмә тавышын, сайрар кошлар, агачлар шавын, үләннәрдә кыштырдаган бөҗәкләрне тыңлап

ике жан бик озак итеп үлән өстендә утырдылар. Берничә тапкыр учлап чишмә суын эчтеләр, хәмер исеннән арындылар. Кичә кичен, төнен, иртәсен хәмер эчеп, чуашча җырлап-биеп гөнаһлы булган жаннарына ял бирделәр, Ходайдан үзләрен ярлыкаун үтенделәр. Тирә-яктагы гүзәл табигатьнең ирегендә утырып, аның хозурына буйсынып тынычлан-ганнан тынычлана бардылар. Карты узган тәүлеккә нәтиҗә ясагандай сөйләнеп китә:

—Шула-ай, Мәхфиякәй! Чуаш булса да, синең туып үскән авылың бит инде Тәтербаш. Синең бала чактан ук күреп үскән чуаш ту... бәйрәмнең бит инде-е...

Карчык та картының үзеннән ниндирәк сүзләр көткәнен яхшы белә. Болайлар иттереп "кунакка йөрүләре" беренче генә ел түгел.

—Рәхмәтләр яусын инде сиңа, Гыйбәтуллакай! Күрдең, бәйрәм иттердең минем чуаш күңелемне. Инде тагын бер елга мин сиңа мөселман хатыны да, татар хатыны да булырмын. Киләсе елга килмәбез, булмаса.

—Әһә! Шулай дисеңме? Килмәбез, дисеңме?!

—Гөнаһтыр инде болай бәйрәм итү Ходаебыз алдында?

Карты уйланып, дәшмичә азрак утыра. Аннан соң үрелеп карчыгының ак яулык кырыннан чыгыбрак торган чал чәчләрен яратып сыйпый. Карчык аның сыйпаган кулына ике кулы белән ябешә дә, аны үбәргә тотына.

—Йә, йә, син нәстә инде тагын?!—ди карт йомшарган тавыш белән.—Ярамый алай, тукта. Мин бит сиңа, кул үптерергә урыс пупы түгел. Ирең мин синең...

Исенә төшә:

—Киләсе елларга хәтлек яшисе бар бит әле, карчык. Килүкилмәүләр—Ходай кулында. Тереклек итүдән тора. Вакыты житкәч күз күрер—килербезме, килмәбезме...

Урыныннан авыр гына итеп кузгала да, кулын биреп карчыгына торырга ярдәм итә. Киләсе елга да киләсен белеп сөйли карт төлке.

—Әйдә, карчык, атлыйк авылга. Ходай үзе ярлыкасын инде безне. Әллә ни зур гөнаһларыбыз юк-юклыкка Аллага шөкер! Вак-төякләрен намаз укып Ходайдан ярлыкау сорарбыз дип уйлыйм инде мин...

Ярлылык белән нужа баскан тормышта яшәүче ике жан бер-берсен саклап, кулларыннан килгәнчә ярдәмләшеп гомер итәләр. Менә хәзер дә үлән каплаган борынгы ташландык юл белән авылга карап тау түбән атлыйлар. Карты аз гына алдан, үзе генә белгән уйларга уралып атлый. Тик ул уйларны хатыны Мәхфия белергә тиешле түгел шул...

Ырынбур каласында сыңар аяклы табиб Власов Николай дигән бер кеше яши. Алар Севастополь каласында төреккә, француз белән инглизгә каршы бергә сугыштылар. Гыйбәтулла аның тездән түбән өзгән аягын чалбар каешы белән кысып бәйләп канын туктатты. Шуннан соң чигенгән чакта, өч чакрым араны һушын жуйган Николайны күтәреп барды Гыйбәт солдат. Шул кылган батырлыгы өчен Гыйбәтуллага урыс тәресе тагырга иттеләр. Күкрәгенә. Әфисәрне коткарып, күтәреп алып чыккан өчен. Тәре тагылырга тиеш булган күкрәген ике куллап каплады да, каршысында тәре тотып торган полк командиры полковник Никитинга әйтте Гыйбәтулла:

—Нилжә крис адивайт мөселманга. Аллах ни вилит. Динга нужна.

Полковник көлеп жибәрде. Тәре урынына түгәрәк медаль гына такты Гыйбәтнең тәгәрмәч кебек түгәрәк тә, киң дә күкрәгенә. Шуңа өстәп биш тәңкә акча тоттырды. Тәре булмыйча, түгәрәк бер нәмәрсә генә булса да тakканы юк Гыйбәтнең урыс медален түшенә. Мөселман жаны кабул итми. Ырынбурдан пар ат белән килеп үзе тапты Власов Гыйбәтулланы. Сугыш беткәнгә жиде ел дигәндә. Гыйбәтулланың тартынып кына сөйләгәнен тыңлады да, үзе белән Ырынбурга алып китте. Бик яхшы хастәханәсе бар икән Власовның. Тикшерде ныклап һәм әйтте Гыйбәткә:

—Бала ясый алмаячаксың, дус кеше. Орлык ясый торган жирләрең суык тигәннән эшләмиләр. Балаларыгыз булмаячак.

Ни эшләсен Гыйбәтулла?! Башны ташка орып булмый. Яшәргә генә кала, Ходай тарафыннан бирелгән язмышыңа буйсынып...

Гыйбәт карт чуашларның елга бер урманда үткәрелә торган борынгы бәйрәмен һәрчак менә шулай уздыра. Үзенекеннән бигрәк чуаштан чыккан хатыны Мәхфиянең күңелен күрергә тырыша ул. Елына бер тапкыр чуаштан чыккан Марфаны хәмер эчертеп, туйганчы җырлата, тыпыр-тыпыр китереп биергә дә рөхсәт итә, чуашча туйганчы сөйләштерә һәм икенче көнне Мәхфиясен мөселман авылына алып кайтып китә. Рәхәт күп булмый ул!

* * *

Урам чирәмендә шара сугып уйнаган малайлар яныннан Таз Бакыйр дип йөретелмеш егет ат белән узып китте. Малайларны котыртып узды:

—Йөгерегез, малайлар. Анда мәчет янында Акмулла бабай килгән. Китап, кәнфит тарата. Үзе җырлый, үзе курайда, кубызда уйный. Минем вакыт юк, тегермәнгә барасым бар. Югыйсә, китми идем мин аннан...

Малайларда шара сугу кайгылары китте. Кемузардан таякларын ташламыйча мәчет ягына йөгерделәр. Алар хәлләре-тыннары бетеп барып җиткәндә, мәчет янында байтак халык җыйналган иде инде. Кысыла, төртелә алгарак үттеләр. Алмачуар бия җигелгән арба тирәләп уратып кешеләр басканнар. Иң алда, Алланың кашка тәкәсе булып, малайлар өерелешкәннәр инде. Байтак кына егетләр, ир урталары һәм авыл картлары да барлар. Хатын-кыз берничә генә. Алары да аерым бер кечкенә төркем булып, шәл читләре белән битләрен каплап басканнар. Малайлар барып җиткәндә арба яныннан сузып-сузып курай моңы ишетелә иде.

Лотфулла иң алга чыгып басты. Арбага азрак арты белән терәлгәндәй итеп баскан, өстенә ак чапан кигән, башына чалма ураган, бите, куллары кояшта янып каралган, яртылаш чаларган кырма сакал-мыеклы, алтмыш яшьләр чамасындагы бер карт икән курай гыжылдатучы. Басып торучыларны курай моңы тулысынча биләп алган, гүя инде аларны ак кылганнар баскан монсу далага, урман-яланнарга, тауларга, кыя ташлар арасына алып киткән. Башына солы салган капчык кидерелгән алмачуар бия коерыгын сирәк-мирәк кенә селкеткәләп тыныч кына басып тора. Солы чәйни. Дирбияләр бар да каештан. Шлея-йөгәннәр җиз белән бик матур иттереп бизәкләнгәннәр. Дуга сарыга буялган һәм шуның өстенә яшелдән матур иттереп төрле яфраклар төшерелгәннәр. Арбаның тәҗесе чәнти бармактан аз гына нечкәрәк тимерчыбыктан ясалган. Тәгәрмәчләр нык күренәләр, күчәннәре сумалага катырылганнар. Ә тәгәрмәчләр үзләре яхшы тимер белән бик оста иттереп кыршауланганнар. Арба астында, дүрт тәгәрмәч арасында ике катлы иттереп тартмалар ясап куелган. Тартмаларның тоткалары асылынмалы иттереп сары җиздән эшләнгәннәр. Арба үзе тоташы белән яшел төскә буялган. Ә тартмалар ак төстәләр. Аты—яхшы тәрбия күргән көр алмачуар бия. Өстендә дә, хәтта аяк бәкәлләренә кадәр бер генә җирендә дә пычракның әсәре дә юк. Бабай курайда уйнавын туктатты да, үзен уратып баскан халыкны барлагандай карап чыкты. Күзләре бик тә нурлы иде картның. Тамагын аз-аз гына кыргалап торды да, бик көчледән булмаса да, үтә дә моңлы тавыш белән җырлап җибәрде:

Кара да-а гына-а урма-а-ан, караңгы тө-өн,—
Яхшы атла-ар кирәк үтәргә...

.........................

Мәчет урамында җырның соңгы авазлары тынып бетмәде, курай моңы "Карурманны" дәвам итеп алып китте. Курай туктауга бабай шигырь сөйләде һәм шуның белән чыгышларын тәмамлап куйды. Чем кара күзләре

тулы нур, мәрхәмәт, жыр һәм шигырь иде бабайның. Лотфулла чамалап алды—берничә малайның кулында китаплар бар иде. Димәк, алар килеп житкәнче бабай инде китаплар тараткан. Үзенең китапсыз калганына Лотфулланың кәефе китә башлады. Бабай арбасыннан сөяннән ясаган шома агачны алып икегә аерып ачты да, шуның эченә кураен салып ябып куйды. Агачның эче курай урнаштырыр өчен чокып ясалган һәм йомшак соргылт чүпрәк белән капланган икән. Савытны ябып, ике башыннан дүрттән үргән сүс баулар белән бәйләп куйды. Арбасы астыннан бер тартманы тартып алып ачты да, курай салган сөянне шул тартмага салып, кире урнына этәреп урнаштырып куйды.

—Ярар авылдашлар, мин кузгалыйм инде. Мөхәммәт Шакир хәзрәтне дә күрәсем бар иде. Иншалла, сезнең белән тагын күрешергә язсын.

Шул чак Лотфулла үзенең кычкырып сораганын сизми дә калды:

—Акмулла бабай! Миңа да китап бир әле?!

Акмулла арба үрәчәсеннән дилбегәсен чишә башлаган жиреннән туктап калды. Сәерсенгән караш белән тавыш килгән якка борылып карады һәм ялан аяклы, башына кара кәләпүш, ямаулы чалбар һәм иске генә күлмәк кигән, кулына шара суга торган кәкре башлы таяк тоткан малайны күреп алды. Малай картның сөйкемле, жылы карашы үзенә табан тартканнан алга атлап куйды.

—Кита-ап бир инде, Акмулла бабай?!

Малайның үтенүе, сусап үлер дәрәжәгә житкән кешенең су сораганы кебегрәк тоелды Акмуллага. Шул кадәр үтенеп китап сораган сабыйны күрү карт остаз өчен зур шатлык иде.

—Укый беләсеңмени? Бик бәләкәйсең бит әле.

—Мин биш яшьтән үк укый беләм инде.

—Кем улы син?

—Зәйнетдин Балта улы.

Акмулла Зәйнетдин Балтаны белми иде, ахрысы. Сорады:

—Әтиең балта остасымыни?

—Әй-йе.

—Ә... ни... картәтиең бармы соң?

—Бар.

—Исеме ничек картәтиеңнең?

—Картәти минем Әбеннәгыйм исемле. Кучер ул.

Акмулланың йөзе яктырып, тагын да ныграк нурланып китте.

—Ә-ә-ә! Әбеннәгыйм синең бабаңмыни инде-е? Картәтиең диюеем! Харис тарханны йөреткән кучерме?

Малай, бабасы Әбеннәгыймнең һәр чак мактап сөйләгәненнән, Харис тарханның кем икәнен яхшы белә иде.

—Әй-йе. Хәзер ул Мөхәммәт Шакир хәзрәтнең кучере инде.

—Шулаймыни-и! Мин бит синең бабаң Әбеннәгыйм белән дүрт елга якын мәдрәсәдә бергә ятып укыдым. Шул дүрт елдан уза алмады ул. Укырга, язарга өйрәнде дә, тайды мәдрәсәдән. Ат жене кагылган малай иде ул тумыштан ук. Әй-йе. Илләмә дә талчыбыкны күп ашады инде укымыйча. Хи-хи. Хәлфәбез Зәки Шәмсетдин колагын бора торганые аның. Сукыр шагыйрь иде мәрхүм. Тик Әбеннәгыймне барыбер укыта алмадылар. Картәтие аны укытыр өчен әллә күпмеләр мәдрәсәдә кунып та ятты. Юк. Чынлап менә ат жене кагылган малай иде шул ул.

Ала-ай! Әбеннәгыймнең оныгы булып чыктың бит әле син! Кызык! Кая эзләп карыйм инде алай булгач сиңа бирәр китап. Беткән кебек иде бит әле?! Ул өстәге каттан бер тартманы ачты да, ике китап китереп чыгарды. Сул кулы белән китапларны Лотфуллага сузды. Малай китапка үрелә генә башлаган иде, сул кул янында уң кул пәйда булды. Уч төбендә зур гына сары төстәге шикәр кисәге ята иде. Малай сәерсенеп бабайга күтәрелеп карады. Акмулланың күзләре тулы көлү, шуклык иде.

—Икесе бер кешегә бирелми. Йә шикәрне генә аласың, йә китапны гына..

Лотфулла, уйлап тормастан, ике куллап китапларга ябышты.

—Сөбханалла!—диде Акмулла бабай.—Асыл малай икәнсең. Тот инде болай булгач шикәрне дә. Тот!

—Рәхмәтләр яусын сиңа, Акмулла бабай, китапларың өчен! Китап булгач җитте, шикәр кирәкми дә миңа. Исән-имин йөре, юлларыңда авырлыклар күрмә. Ходай сакласын сине.

—Амин, шулай булсын, улым. Рәхмәт яхшы сүзеңә. Тагын бирер идем дә—бетте китаплар. Бер унлап кына урыс китаплары калды. Аларны син укый белмәссең шул, бирсәм дә...

Лотфулла кыяр-кыймас кына иттереп әйтте:

—Урысча укый беләм мин...

Дилбегәсенә үрелә башлаган Акмулла кискен хәрәкәт ясап малайга табан борылды:

—Синме-е? Урысчамы-ы?

—Ы-ы! Мирсәет Бийишев абыйда кышын укыйм мин. Туктамыйча, тотлыкмыйча укый беләм.

—Син ничекләр барып эләгә алдың ул ышкулга. Анда бит бай малайлары, хәлфәнекеләр генә укыйлар. Аларның да теләгән берсе түгел.

—Мин Чибәр апага малайларын карашам, идән себерәм, бәрәңге әрчим, йомышка йөрим, кар көрим. Шуның өчен миңа Мирсәет абый ишек төбендәге өстәл артында утырып дәрес тыңларга рөхсәт итте.

—Әрифмитикәне дә беләсеңме?

—Кушуны, алуны—яхшы беләм. Дробь дигәнне, тапкырлауны, бүлүне әле өйрәнеп бетермәдек. Працинт дигәнне дә беләм...

—Сөбханалла! Сөбханалла! Менә, ичмасам, бу бүләк дигәч тә бүләк миңа.

Икенче тартмасын ачты да шуннан ике китап алды. Берсен Лотфуллага тоттырды:

—Яле, алай беләм дип мактангач, укып күрсәт миңа шушы китаптан!

Лотфулла сакланып кына китапны кулына алды. Катыргы тышлыгын ачып, беренче биттә язылган китапның исемен карады. Иреннәрен кыймылдатып укыды. Арбаны уратып алган кешеләр тавыш-тын чыгармыйча бу могҗизага исләре китеп карап тора иделәр.

—Йә,йә, кычкырып укы!—дип түземсезлеген күрсәтте бабай.—Укы!

—Ма-а амин Си-ибиряк. Разсказы.

Арба тирәсе тып-тын булды. Акмулла нәрсә дип тә әйтергә белмичә арбаны уратып баскан кешеләргә аптырап карады. Аның карашы тулы: "Сез аңладыгызмы? Бу малай бит урысча укый белә!"—дигән тантана иде.

Икенче китапны сузды:

—Монысын укы инде!

Лотфулла икенче китапка батыррак тотынды. Тышлыгыннан укыды:

—А.В.Гоголь. Тарас Бульба.

Акмулла Лотфулланы ике куллап кочаклап аркасыннан шапылдатып сөйде.

—Рәхмәт, улым, сиңа! Рәхмәт! Бик зурладың мине, бик шатландырдың. Укы, кеше бул! Без, татарлар өчен урыс укуы бик тә кирәк. Мин киләсе килүдә кереп күреп чыгармын әле ышкулыгызны. Әле ябылган җәйгә дип. Ишетеп кенә беләм Эстәрлебашта урыс ышкулы барлыгын, тик күрергә туры килмәде моңарчы. Иншалла, насыйп булса күрермен...

Акмулла бабайның шатлыктан күзләре яшьләнде. Кулының сырты белән ике күзен сөртте дә кузгалу исәбе белән тагын дилбегәсен чишә башлады. Тик бу юлысы да кузгалып китә алмады. Арба артыннан олпат гәүдәле бер карт килеп чыкты да, көрәктәй зур кулы белән Акмулланың аркасына учын җәеп китереп сукты:

—Мифтахетди-ин! Син бит бу, шайтан тамыры-ы!

Акмулла тиз итеп артына борылып карады. Китте авызы ерылып:

—Бәрәкалла-а! Бәрәкалла! Син бит бу Исмәгыйль! И-и! Бирсә бирә

ул Хода-ай! Иртәннән бирле куаныч артыннан куаныч бүген мина. И-и! Бар икәнсе-ең, исән-имин икәнсе-ең?!

Исмәгыйль бабай да куанычыннан кулларын куярга урын таба алмый басып тора иде.

—Кая кочаклыйм әле үзенне, сабакташ!—диде ул, сул кулында тоткан берничә пар яңа чабатасын жиргә куя-куя.—Инде егерме еллап бардыр сине күрмәгәнгә. Барды-ыр! Тукайларга килеп кенә кунак буласың да, вәссәлам! Китеп тә барасың. Мин бит мәгъзүмнәрдән барып сине киттеме, юкмы дип сорашып йөри алмыйм. Безгә кереп тә тормыйсың. Үзең яшьлектәге дус бит әле син. Ә?!

Икесе дә ике куллап, мөселманча кочаклашып исәнләштеләр. Шапшоп китереп аркаларына суккалап алдылар. Кулбашларыннан ике куллап тотып, азрак артка табан этеп бер-берсен жентекләп карадылар да, тагын кочаклаштылар.

—Картаймыйсың әле, шәпсең!—диде Исмәгыйль бабай, шатлык тулы күзләре белән яшьлек дусты Мифтахетдингә карап.—Менә мин бирешә башладым соңгы елларда-а...

—Алай димә син, Исмәгыйль! Алай димә-ә! Яшик әле! Ходай кушса, минем әле тагын бер егерме еллар чамасы яшисе килә. Эшләрем бик күп! Әтиең Ярмөхәммәт абзый исәнме әле? Хәерниса түти ничегрәк?

—Әни китте бит. Бу елның көзендә биш ел тула инде. Әти исәнсау әлегә. Нык картайды инде. Бик еш искә ала башлады сине. Шелтәли: "Күренми дә башлады, кайсактан яралган нәмәстәкәй, ди сине. "Ай-һай курайда моңлы иттереп уйный торган иде, Мифтахетдин!"—дип искә ала. курай тыңлыйсы килә дигәч, Сарайса авылы башкорты Исәнгужа агайны алып кергән идем базар көнне. Теге уйнаган иде, ошатмады. Шулай да үзенә сиздермәде ошатмаганны. Мифтахетдингә житкерәлми, ди. Синең курайны, жырлаганыңны тагын бер генә тыңлап карарга кирәк иде дип искә алды әле, узган базар көнне генә...

—Йөриме болай?

—Юу-ук инде-е! Кая ди ул йөрү. Ишек алдына алып чыгып кояшка утыртып куя хатын. Шул чыкканы. Бик йончыды. Бу ел көзгә туксанны тутыра бит инде. Гажәп бит әй. Теге әллә кайчан булган Напалиун сугышына безнең бабайларның киткәне хәтерендә әле аның. Ул сугышлар инде әллә кайдагы хан заманында ук булганнар бит...

Сөйләүдән туктады да, шәкерт заманындагы дусты Мифтахетдиннең кулбашын уң кулыннан ычкындырмыйча әйтте:

—Әйдә, бор атыңны! Югары оч ягына! Күп сорамыйм, берне генә булса да бездә кунып, кунак булып кит. Күп сорамыйм. Әтинең дә күңеле булыр. Бик ярата иде ул сине. Әйдә, дус!

Акмулла Таш күпер ягына карап алды да, нәрсәдер әйтмәкче булды. Исмәгыйль дусты аны сүзсез аңлады:

—Юк инде, дус кеше! Тукай бабай нәселенә калган вакытың да житәр. Яшьлек дусларыңны оныткан өчен Ходай Тәгалә жәзасын кызганып тормас. Әйдә дигәч, әйдә!

Дилбегәне чишеп алды да, суккалап атны бора башлады:

—Э-эй, Мифтахетди-ин! Исеңдәме, син, мин, хәлфәбез Шәмсетдин Зәки белән Бакыр Чагыл тау якларына сәхрәгә чыга торган идек. Сез бер-берегезгә шигырьләр сөйлисез, жырулар әйтәсез. Бакыр Чагыл тау башына менеп искән жил тавышын тыңлыйсыз. Ә мин сезгә ашарга пешерәм, чәй кайнатам. Мәтрүшкәләп, кара карлыган яфраклары белән. Илләмә дә сагындыра инде шунда чыгып йөрегәннәр...

Икесе дә битләрен сыпырып, Мәккә Шәрифтән кайтып килгәндә Таганрог каласында вафат булып, шунда жирләнгән остазлары суфый шагыйрь Шәмсетдин Зәкине исләренә алдылар. Исмәгыйль тагын дилбегәне кулына алды. Әйтте:

—Урыны ожмахта булсын остазыбыз Зәкинең. Әйдә, дус!

Арбаны боргач кына исенә төште—жирдә яткан чабаталарны алып

арбага салды. Акмулланың да исенә төште. Арба янында китаплар күтәреп басып торган Лотфулланы аркасыннан сөйде:

—Укырга тырыш, улым! Ходайдан ярдәм сора! Ул ташламаса, бар эшең дә уңышлы булыр.

Дусты янына арбага менеп утырды. Исмәгыйль бабай яшьлек дусты Мифтахетдинне, инде Акмулла дип данлыклы исеме чыккан татар, казакъ халыкларының атаклы шагыйре Акмулланы авылның Югары Очында, Бикмәт тавы янында урнашкан үз йортына кунак итәргә, туксан яшенә житкән атасы Ярмөхәммәтне куандырырга алып кайтып китте.

* * *

Күзгә карангы төн, тулысынча хужа булып, жир өстен тоташ каплап калган. Тирә-якта күзгә төртсәң дә күренмәслек. Дүртесе дүрт төрле тәгәрмәчле шыгырдавык арбада ике салмыш башкорт Миас каласыннан авылларына кайтып баралар. Ялы, коерыгына тигәнәк ябышкан кечкенә гәүдәле башкорт аты юырткандай иттереп теркелди. Иске малахай, тун, үкчәләре тапталып, авызы ачылып калжайган итек кигән олпат гәүдәле Дәүләтшә башкорт кырында гырылдап йоклап яткан юлдашына төртте:

—Уян әле! Карасы анау тарафка! Усак яна бит! Һин ат янында тороп тор, мин хәзер урап килермен.

Арбасыннан төште дә, тавышсыз, сунарчы адымнары белән караңгылыкка кереп югалды. Күп тә үтмәде, кире әйләнеп килде.

—Төш! Гомере беткән бер мәхлүк йән, япа-ялгызы усак янында нәмәләрдер язгалап ултыра. Әжәле йеткәнен һизмәй!

—Башкортмы?

—Төн менән ниндәй башкорт далала, усак янында, нәмә язып ултырһын инде. Атыннан, арбаһыннан татар икәнлеге әллә каян күренеп тора. Усак янында, төнен язһа, татар яза инде—тагын кем булһын, ти. Әйзә!

—Ай-һай, кәрәкмәс бәлки?

—Кәрәк. Аты лә шәп, арба-дирбияһе лә. Тәгәрмәс янына жыеп куйган барыһын. Әйтерһен алтын менән бизәлгән камыт, эшлияләре. Ялтырайзар бизәктәре.

Арбадан, сәрмәп, капчыгын тапты. Эченә тыгылып нәрсәдер алды да, биясенә каптырды.

—Нәмә ул?—дип сорады иптәше, азрак калтыранган тавыш белән. Ул курка иде.

—Сөсә әпәк. Әүмәләһен авызында, йә кешнәп куяр. Киттек...

Ике көн узгач, карга-саесканнар жыелган урында, кечкенә елга буендагы яфраклары коелып беткән куе таллык эченнән узып барган юлчылар Мифтахетдин Акмулланың үле гәүдәсен таптылар. Аркасыннан йөрәгенә житкереп өч тапкыр хәнжәр белән кадаганнар. Сүнгән учак янында канга буялган кәгазь битләрендә шигырь юллары күренәләр иде. Үтерелгәндә дә шигырь язган чагы булган Акмулланың...

Бу—1895 елның 27 октябрь төне иде...

Гәүдәсе табылганның икенче көнендә канлы эзләрне каплап жир өстенә кар ятты...

...1898 елның язында Хәйдәргали хәлфә белән унике яшьлек Лотфулла урысчалап дүрт еллык укуны тәмамладылар. Инде сынаулар биреп, кулларына таныклык алырга кирәк иде. Алардан башка дүрт ел укып чыкканнар алты малай иделәр. Учител Мирсәет Бийишев Эстәрлетамактагы земский начальникның урынбасары булып эшләгән Габдеррәхим Тукаевка мөрәжәгать итте:

—Габдеррәхим абзый! Бу алты малайдан башка минем тагын ике укучым бар. Шуларга да имтихан тотарга рөхсәт итсәгез иде?

Габдеррәхим Тукаев Эстәрлетамак өязендә атаклы шәхес. Земский начальник урыстан булып, фамилиясе Соколов*. Бөтен Эстәрлетамак каласы белә—Соколовның бик тә каты чире бар. Эчә. Бер башласа, айга якын туктый алмый. Туктаса да, тик Габдеррәхим Тукаев ярдәмендә генә туктый ала. Соколов эчеп-эчеп, инде сүз сөйли алмас хәлгә килеп житкәч, хатыны Мария Романовна өйләренә Габдеррәхимне чакырта. Бер кемгә дә күрсәтмәскә тырышып Мария Романовна белән Габдеррәхим Земский начальникны... өй базына салалар. Шунда берничә тәүлек тоталар. Сөйләшә башлап, урыс маты ишетелә башлаганга кадәр. Соколов базда яткан көннәрдә йорттагы асрауларның барысын да Мария Романовна өйләренә кайтарып жибәрә: "Телегезне тешләрегез артында гына тотыгыз, югыйсә беләсез!..."

Баздан урыс маты ишетелә башлаганның икенче көнендә аннан: "Милая моя Марусенька-а!"—дип ялварулар ишетелә башлый. Шул сүзләр ишетелә башлау белән Габдеррәхим ишек алдындагы мунчаны ягарга дип чыгып китә. Мунча томаланып инде керер вакыт житкәндә хужабикәгә мунчаның өлгерүен хәбәр итә. Шуннан соң гына маржа баз капкачын ачып земский начальникка дәшә:

—Что, проклятый, созрел?

Баздан ялварган тавыш ишетелә:

—Созрел матушка моя, созрел. Выпускай! Государственные дела ждут.

Ике себеркенең яфраклары коелып, яртылаш чыбыкка калганчы чаба Соколовны Габдеррәхим. Хәмер эчүдән сизгерлеген югалткан тән тиресе каен себерке чыбыгының чыелдап сукканын да сизми. Чыбык эзләре буй-буй булып тәнен кызартып чыгалар. Соколов авыртканны сизә башлап, ыңгырашканчы чаба Габдеррәхим. Башында колакчан бүрек, кулларында бияләйләр, эссе алырлык түгел. Шул чапкан арада Соколов бер чиләк куас эчеп бетерә. Мунчадан чыккач, өчәүләшеп утырып ике чиләк сыешлы самаварның суы беткәнче чәй эчәләр. Табында сөйләшү юк. Тик шапыр-шопыр чәй чөмерү тавышы гына ишетелеп тора. Чәйне Габдеррәхим пешерә, Габдеррәхим ясый. Ул кадәр мөһим эшне маржага тапшырып булмый бит инде?! Чәй эчелеп беткәч, Соколов кайчандыр Габдеррәхим Бохарадан алып кайтып үзенә бүләк иткән халатка төренеп софасына менеп ята. Тирән иттереп уфтана:

—О, Господи! Прости меня грешного?!

Габдеррәхимгә дәшә:

—Будь Соколовым! Поработай еще недельку! Я полежу дома. Очухаюсь.

Начальникның үз урынына кушып эшләтүе Габдеррәхим Тукаев өчен яңалык түгел. Земский начальник эчеп алып киткән көннән алып ул болай да барлык эшләрне үзе белгәнчә алып бара иде инде.

Заманында, Казандагы Мәржани хәзрәтләре катнашлыгы белән Эстәрлебашта ачылган урыс ышкулын Габдеррәхим иң беренче укучы булып тәмамлап чыкты. Укуга сәләте зур булганлыктан, алдынгы һәм бик шәп укучы булды. Тукай бабай нәселе бит. Аннан соң Ырынбурда тагын дүрт ел урысча укый. Гимназиядә. Шуннан соң Омск каласында урысларның кадетский корпус дигән уку йортларында укып кайта да, Оренбургское юнкерское училищега кереп офицерлыкка укый башлый. Анда бер елга якын укый. Тик...

Училищеда Габдеррәхимнең яшерен генә кала мәчетенә йөргәнен белеп калалар. Үзен сүгә башлаган офицерга Габдеррәхим әйтә:

—На меня нельзя ругаться русскому. Я—мусульманин и Тукаев...

—Ах ты, гололобый Мамай!—дип офицер Габдеррәхимгә берне китереп сукмасынмы?! Габдеррәхим кайтарып сукканга урыс офицеры өч тешсез калып, сукканнан мие селкенеп Оренбург госпиталендә ай ярым

---

*Соколов фамилиясе үзгәртелмичә бирелде.—Автор.

ятып чыга. Тукаев Габдеррәхимнең эше генерал-губернатор канцеляриясенә барып эләгә. Яшь юнкергә хәрби суд карамагына эләгү куркынычы килеп туа. Аны тик абзасы Харис Тукаев кына коткарып кала. Харис ишанның Ырынбур губернаторы алдында да, Санкт-Петербургта да, патшаның үз алдында да дәрәҗәсе бик зурдан була. Патша галиҗәнабләре исеменә язылган прошение коткара Габдеррәхимне. Тик аның өчен инде патшага тугрылыклы урыс әфисәре булу юллары ябыла. Шуннан яшәргә Эстәрлебашка кайта.

Габдеррәхим Тукаевта урыс белеме көчле. Телләрен дә үзләре кебек ныклы белә. Хәтта күпчелек урыслар укый, яза белмәгәнне Габдеррәхим укый да, яза да. Шуның өстенә урыслар кебек хәмер белән дә мавыкмый. Бик ныклап эшли белү сәләте була аның. Тора-бара земский начальник Соколовның иң ышанычлы ярдәмчесенә әверелә. Күп эшли белгәне өчен һәм Соколов "авырган" чакларда тулысынча земствоның эшләрен өстери алганы өчен өяз халкы аңарга кушамат тага—"Соколов". Чөнки тумыштан уңган, сәләтле, тәвәккәл Габдеррәхим земский начальник Соколов өчен дә, үзе өчен дә эшли белә. Татар, башкорт, чуаш, мукшыга ярдәме күп тия аның.

Инде менә шушы Габдеррәхим Тукаев-Соколов Эстәрлебашта алты малайның дүрт еллык урыс школасын тәмамлауларына имтихан алу комиссиясенең рәисе булып билгеләнә. Шул ук комиссия эченә урядник Тайчинов та кертелгән икән. Янәсе, тәртип булсын да, хөкүмәтнең күзколагы булсын имтихан уздырылган көнне. Авылдан Мөхәммәт Шакир Тукаев белән Габделкадыйр Тукаевларның да комиссияга керттеләр. Беренчесе—зур укымышлы, Эстәрлебаш мәдрәсәсенең мөдәррисе. Өстәвенә алтын казытып баеган Закир Рәмиевнең якын дусты. Ә инде икенчесе—Габделкадыйры—Харис ишанның төпчек улы һәм атасыннан калган тарханлык исемен йөртүче, авылның череп баеган кешесе. Белем ягы сай. Урысчаны белмәү дәрәҗәсендә, үтә дә комсыз, кара эчле бәндә үзе. Авыл аны ихтирамсыз гына "Гапкадыйр мәгъзүм" дип атап йөртә. Аның турында авылның үзе чыгарган әйтеме дә бар: Гапкадыйр мәгъзүмгә көнең калса—беттең! Габдеррәхим тархан Габделкадыйр Тукаев белән мөнәсәбәтләрен кискенләндермәскә тырыша. Урта буйлыдан кайтыш, аскы ирене азрак алгарак чыгып торган, елмая белмәгән йөзле, азрак кысыла төшкән кара күзле бер кеше Гапкадыйр мәгъзүм. Кашлары астыннан һәрчак астыртын гына, кешене кысык күзләре белән бораулап карый. Үзе бик тә чәмле, үч алырга яратучан шәхес. Эстәрлебашның барлык ярлы-ябагае диярлек аңарда ялчылыкта. Иң күп җир аңарда. Кара Балыклы якларындагы дала яланнарында. Тукаевлар ул җирләрне Харис ишан заманыннан ук, Пугач яулары басылгач, патша хөкүмәтеннән арзан гына хакка сатып алганнар. Ул җирләрнең арзанга сатылуының үз сәбәбе дә бар. Борынгы заманнарда ул җирләр болгар җире булган. Сүбүдәй Баһадир далада утырган болгарларны суеп бетергәч, ул урыннарда кыргыз-кайсаклар җәйләүләргә күченеп килеп, шунда мал йөртеп көн күрә башлаганнар. Петр I указы белән Оренбург крепосте салына башлагач, Самара-Оренбург хәрби сызыгы төзелә башлый. Самарадан алып Оренбургка кадәр 12-15 чакрым саен хәрби крепостьлар төзелә. Һәм шул крепостьларга гарнизон итеп патша хезмәтендә 25 ел солдат булган, инде уртак тормышка күчкән хәрбиләрне урнаштыралар. Гарнизон коменданты иттереп шулай ук озак еллар сугышып, шул сугышудан башканы белмәгән карт офицерларны куялар. Агыйделнең сул як ярыннан алып Оренбург-Самара сызыгына кадәр булган дала җирләрен кыргыз-кайсактан тартып алалар. Һәм шул җирләргә урыс өчен ышанычлы саналган, Казан каласы егылганнан соң урыс патшасы Иван Грозный кул астына үзе теләп күчкән башкортны күчереп утырта башлыйлар. Чөнки кяферне яратмаган, даласы өчен кылыч тотып сугышкан кыргыз-кайсак җиренә татарны күчереп утыртуны урыс колонизаторлары кирәк санамыйлар. Татар ул җирләргә

көчсә, кайсак-кыргыз белән бергәләшеп урыска каршы сугыш башлаячак. Ак патшаның аның шулай булачагында шиге юк. Ә башкорт тугры урыска.

Тик урысның башкортка булган өмете тулысы белән акланмый. Башкорт үзе XII гасыр башында Иртеш-Тобол якларыннан Чыңгыз хан гаскәрләренә ияреп килеп утырган борынгы болгар җирләреннән кузгалып, Агыйделнең сул ягына күчәргә теләми. Шулай да урыс гаскәр кулланып, башкортларны Агыйделнең сул ягына көчләп күчерә башлый. Менә шуннан башлана инде атаклы башкорт фетнәләре. Урыска каршы. Казан каласы урыс гаскәрләре тарафыннан штурм белән алынып, Казан ханлыгы юк ителгәннән соң татарлар бер туктаусыз урыска каршы фетнә оештырып торалар. Ә башкорт XVII гасырның уртасына кадәр урыска каршы сугышмый, аның дусты булып санала. Ә инде ак патшалар аның утырган җиренә урыс колонизаторларын күчереп китереп, башкортны көчләп Агыйделнең сул як ярына куа башлагач, башкорт кая барсын!? Урысның мәкерле сәясәтен аңлый башлаган башкорт та коралга тотына. XVII гасыр урталарыннан Алексей Михайлович Романов патшалык иткән еллардан башлана башкорт фетнәләре...

Бүгенге көндә дә башкорт галимнәренең күп кенә язмаларында менә мондыйрак сүзләрне еш очратырга була: "...ер һатып алыр өсен башкорт тип язылган..." Бу сүзләрнең төбенә төшеп уйлый алган кешеләр сирәк бүген. Ничек инде, башкорт Башкортстанда җир сатып алыр өчен, башкорт булып язылган? Кемнән сатып алган ул җирне? Башкорттан алганмы? Бай башкортның җире болай да күп булган бит инде. Ә ярлы башкорт җир алырга акча каян тапсын?

Бу сорауга җавап бирү артык катлаулы түгел. Урыс колонизаторлары башкортны элекке болгар җиреннән гаскәр китереп куганнар һәм... шул куылган урыны өчен аңарга Агыйделнең сул як ярында җир сатып алырлык иттереп акча түләгәннәр. Бар, шуннан җир сатып ал! Ул җирләр тик сиңа гына, башкортка гына сатыла! Татарга сатылмый! Син ышанычлы урыс өчен, утыр, ныгы шул якларда. Син утыргач, ныгыгач аннан соң без синең урынга тагын урыс колонизаторларын кертербез авыллар салырга. Ә син башкортны тагын да арырак, кыргыз җирләренә куарбыз. Менә шул елларда килеп чыккан да инде "асаба" башкорт белән "ебәрелмеш, әтәмбәй, килмешәк" башкортлар дигән аталмалар. "Асаба" башкорт—ыру эчендәге, ыру җиренә тулы хокукы булган башкорт. Ә инде "ебәрелмеш, әтәмбәй, килмешәк" башкортлар—төрле сәбәпләр аркасында ырудан куылган башкортлар яисә урыс тарафыннан җире тартып алынган "асаба" булган һәм Агыйделнең сул як ярына урыс хөкүмәте тарафыннан көчләп күчерелеп утыртылган башкортлар. Урыс башкортны "асаба"дан мәхрүм итеп, "әтәмбәй" башкорт иткән Агыйделнең агышы белән сул як җирләренә караган Бөгелмә, Бөре, Бозаулык, Богырыслан, Оренбург, Эстәрлетамак, Чиләбе, Минзәлә, Уфа, Троицк, Верхнеуральск өязләрендә күпчелек башкортлар үз җирләреннән урыс тарафыннан куылып, шушы якларга көчләп китерелеп утыртылган башкортлар. Бу өязләрдә утырган башкортлар барысы да "ебәрелмеш, әтәмбәй, килмешәк"кә әйләндерелгән башкортлар. Бу җирләр барысы да борынгы болгарлар яшәгән җирләр.

Менә шушы Агыйделнең сул як ярында кыргыз-кайсак куылганнан калган җирләрне патша хөкүмәте саткан чакта, Тукаевларның кайсысыдыр (Нигъмәтулла ишан дигән уй ныграк) башкорт булып языльш, Кара Балыклы җирләренә ия була.* Бүгенге көнне дә Уфадан Оренбургка барган шоссе юлы өстендә Эстәрлетамакка кермичә, аны сул якта калдырып уза торган бик яхшы юл бар. Эстәрлетамакны сулда калдырып шул юл белән барган чакта Куганак елгасы үтелә. Шушы урыннан алып кояш баешына турыдан китсәң, әнә шул җирләр инде Кара Балыклы җирләре дип аталалар. Эстәрлетамактан алып турыга, кояш чыгышына китсәң

* Тик аның башкортлыгы турында бер генә документның да табылганы юк. Бу тик башкорт галимнәренең уйдырмасыдыр.

кырык биш чакрымнан Куганакбаш авылына барып чыгасың. Шул арада Эстәрле белән Куганак елгалары арасында яткан җирләрдә башкача бер генә авыл да юк. Озынлыгы 25, киңлеге 15 чакрым булган авылсыз яланнар. Кара Балыклы җирләре Тукаевларның сатып алган җирләре. Ул урыннарда бүген дә авыллар юк. Тик җир эшкәртү өчен салынган "Алга" һәм "Комсомолец" совхозлары гына бар.

Икенче уйдырмага караганда, имеш, ул җирләрне тарханлык дәрәҗәсе белән бергә Харис Тукаевка ак патша үзе бүләк иткән. Вәгазь укып кына кыргыз-кайсакларның ак патшага каршы булган зур короллы фетнәләрен туктатып торганы өчен. Кайсысы дөрестер, билгесез. Бүгенге көндә боларны раслаучы бер генә документ та юк. Җир сатып алыр өчен "башкорт булып язылган" дигән сүзләр дә нигезсез, тик уйдырма гына булып кала бирәләр...

Учител Мирсәет Бийишевнең, имтихан бирә торган тагын ике укучым бар, дигән сүзләрен Габдеррәхим Тукаев гадәтенчә башын кырын салып тыңлады да сорады:

—Алары кемнәр инде тагын? Каян бар булдылар?

—Берсе Хәйдәргали хәлфә. Фамилиясе—Солтангалиев.

—Теге элекке Кырмыскалы шәкертеме?

—Шул үзе. Бик сәләтле, төпле акыллы кеше. Шунлыктан Мөхәммәт Шакир абзый аны үзенең мәдрәсәсендә хәлфә итеп калдырган. Урыс телен өйрәнеп, татар малайларын укыту теләге зур аңарда...

—Хуш иттек! Икенчесе дә хәлфәләрдәнме?

—Юк. Икенчесе бала гына әле. Әтисе балта остасы. Авыл халкы аны Зәйнетдин Балта дип йөртә. Лотфулла исемле малай ул. Унике яшендә.

—Бә-әй! Ул малай алайса теге атаклы ат белгече, безнең Тукаевларның күчере Әбеннәгыйм абзыйның оныгы булып чыга бит инде. Җирәнме?

—Сары чәчле, зәңгәр күзле...

—Ул малайның чәче кызыл-бакыр кебек булырга тиеш! Нәселләре шундый аларның—чәчләре кызыл.

—Әнисенә ошаган ул малай. Әниләре сары чәчле, зәңгәр күзле.

—Ала-ай! Син шул малайны имтиханга кертеп, аңарга таныклык бирдерергә уйлыйсыңмыни инде?

—Бик тә сәләтле бала...

Мирсәет нәрсәнедер әйтеп бетерми иде бугай. "Соколов" шуны сизенде:

—Син, Мирсәет туган, уйларыңны тулысынча әйтеп бетер. Миннән тартынма. Кулымнан килсә, мин эшләрмен. Үзебезнең татар баласы бит ул малай... сары чәчле булса да...

Күңелле итеп, кыска гына көлде.

—...Эстәрлебаштагы бу урыс ышкулы безнең татарлар өчен бердәнбер бит. Бөтен Эстәрлетамак өязендә. Уйлап карасаң, искитмәле—укытмыйлар без татарны. Ә без бит бик сәләтле халык. Без татарга урыска тигән уку тисәме-е?

—Инде алай булгач әйтим мин. Бу минем генә уем түгел—Мөхәммәт Шакир абзый белән бергәләп киңәшеп китереп чыгарган уй...

—Алай икән! Тыңлыйм туган. Әйтеп кара.

—Лотфулладан имтихан алып, кулына таныклык биреп, аннан соң Казан каласындагы учительская школага укырга җибәрергә кирәк дип уйлыйбыз без Шакир абзый белән. Малайның укуга сәләте бик зур. Урысча яратып, аңлап укый. Малайлар арасында башкача аның кебек юк. Урысча хикәяләрне бер кат укып чыга да, сөйләп тә бирә...

—Ярар. Имтихан тапшырды ди, таныклык алды ди. Җибәрдек тә ди Казанга. Ә аны Казанга җибәрүнең максаты нәрсәдә? Уегыз нинди?

—Мөхәммәт Шакир абзый әйтә, Лотфулла укып кайткач Эстәрлебашка, ди, урысча укыта торган тагын өстәмә сыйныфлар ачарбыз, ди. Кара халыкка урысча белем бирү фарыз безгә, ди. Мәрҗани хәзрәтләре

шулай дип әйтеп калдырган безгә. Бу анын васыяте, ди...

Габдеррәхим дәшмичә Мирсәеткә азрак карап торды да, күнелле иттереп көлде:

—Шакир абзыйга ирек куйсаң, ул Тәтербаш белән Калиновка чуашларына кадәр укытыр иде. Шул укыту белән хыялланып яши торган бер зат инде ул. Без Тукаевларның иң асылы ул. Тәккәмени, анын янына үтсә дә, сүтсә дә шагыйрь Дәрдмәнд керәп йөри. Дуслар!..

Сул кулы белән шапылдатып Мирсәетнең аркасына сукты:

—Уегыз шәп! Давай туган! Шәп! Мин риза. Барсын Казанга, укысын, кайтсын. Земстводан ярдәм дә чыгарырбыз әле. Соколов мине тынлый ул. Тыңламаса, хатыны тынлата аны барыбер! Урыс телен яхшы белгән татарлар нык кирәкләр безгә хәзерге заманда. Бик кирәк!

Кузгала башлаган җиреннән тукталды.

—Син ул малайга белгәнрәк нәрсәләрен укыт. Мәсьәлә, мисалларның бик катлаулыларын бирмә. Каушап калмасын, диюем. Кыюрак бул, дип, әйтеп куй алдан.

—Каушамас. Болай ул үзе дә кыю малай. Урысча укуы шәп, арифметиканы яхшы белә. Нинди генә мәсьәлә булса да, заматта чишеп ташлый.

—Ярар, тәвәккәлләдек. Бу малай белән ачыкланды. Ә Хәйдәргали хәлфәне нәрсә эшләтергә уйлыйсыз. Аны да... Казанга озатыргамы исәбегез? Әллә сиңа ярдәмче итәргә уйлыйсызмы?

—Ул турыда Мөхәммәт Шакир абзыйга мин дә әйтеп караган идем дә, ул әйтә, Хәйдәргали хәлфәне мин башкачарак итеп кулланырга уйлыйм, ди. Тик кайда, ничек икәнен әйтмәде әле.

—Абзыйның уйларын белеп булмый инде анын. Берәр укыту эшенә кушарга уйлыйдыр инде. Вакыты җиткәч беленер әле.

* * *

Урыс ышкулында имтихан алу көне буена барды.

Мәдрәсәнең зур бүлмәсендә, өстенә яшел постау җәйгән өстәл артында имтихан алучылар тезелешеп утырганнар. Уртада земство начальнигының “товарище” Габдеррәхим Тукаев-Соколов утырган. Анын уң ягында моннан егерме биш чакрымнарда урнашкан урыс Николаевка авылы укытучысы Берлов Николай Николаевич, сул ягында туры кылычын (калада аны “селедка” диләр икән) биленнән йоклаганда да салмаучы урядник Тайчинов Фәттах утырганнар. Урыс артында Гапкадыйр мәгъзүм, ә урядник артында Мөхәммәт Шакир Тукаев урын алганнар. Беренче булып Гапкадыйр мәгъзүмнең бер улы имтихан тота. Аңарга урыс язучысы граф Лев Толстойның “Филлипок” исемле хикәясен укырга бирде Мирсәет Учител. Малай ижекләп, авыз эченнән ботка пешерә-пешерә берничә җөмләне ерып чыга алды. Бераз укыгач, Мирсәет аны туктатып әйтте:

—Что прочитал, расскажи!

Малай башын игән хәлендә кузгалмыйча байтак басып торды. Аңардан бер генә аваз да чыгарлык түгел иде.

—Ну, Тукаев!—диде Учител.—Расскажи нам, куда пошел Филлипок?

Ученик-Мирсәет Биишев аларның барысын да шулай атап йөртә—яңа читекләр кигән аякларын кузгаткалап ала. Малайга азрак җан керә башлагандай булды, ахрысы, акрын гына тавыш белән мыгырдый башлады:

—Ма-ая... низнай... Фил-л... Филли-ипу-ук...

—Ну как же не знаешь! Знаешь ведь! Куда пошел Филлипок? Н-ну?!

Малай тар маңгаен җыерып түшәмгә карап ала да, шунда карагач исенә төшерә башлый, ахрысы.

—Ә-ә. Әй-йе! Ышкул пашул Филлипу-ук. Ышку-ул! Ышку-ул пашшул!

Учител дә малай белән бергә куана.

—Ну во-от!—ди ул, йөзен яктыртып.—А говоришь: "Ни зна-ай!" Знае-ешь!

Малайда тагын да нәрсә дә булса өстәп әйтәсе килү теләге туа, ахрысы. Җентекләп тамагын кыра да, өстәп тә куя:

—Ы-ыы. Ышкул паш-шул Филиппу-ук! Улиса упал Филлипук. Сабака пришел его. Мужик гнал сабака. Филиппук бежал патум...

Өстәл артындагылар да җанлана башлыйлар. Урядник башыннан фуражкасын салып өстәлгә куя. Аның эченнән каешланып, каралып каткан түбәтәен алып, ялтыратып кырылган башына кия. Түбәтәен кияр алдыннан кырган башын рәхәтләнеп шатырдатып кашып ала. Сул кулы белән кылычының сабыннан тотып, аны идәнгә очы белән терәп куя. Канәгатьлек белдереп "кх, кх" иттереп тамагын кыргалап, мыегын сыпыра: "Начар гына булса да, урысчалап "әпәли" бит бу малай актыгы! Карале син аны, ә?!" Бүлмәдә, малай сөйләүдән туктагач, тынлык хөкем сөрә.

—Яра-ар!—ди комиссия рәисе "Соколов".—Болай булгач, азрак булды инде бу. Урысча укый белә... ижекләп булса да. Филлипокның кайда барганын да аңлата алды безгә. Ышкул пашел, ди бит инде. Ярар. Димәк, урысча укыганын үзе аңлый дигән сүз. Шулай бит?!

—Шулай, шулай!—дип "агач печәтне сугарга" ашыкты малайның атасы тархан Габделкадыйр Тукаев.—Сөйли дә белә урысча укыганын.

Габдеррәхим:

—Кемдә, нинди сораулар бар?—дип сорады.

—Миндә бар бер сорау,—дип урынында кузгалып куйды Мөхәммәт Шакир мөдәррис.—Миндә. Мөэмин-мөселманга тәүлек эчендә ничә вакыт намаз фарыз? Һәм ул намазлар ничек аталмышлар?

Мөхәммәт Шакир энесенең улына җиңел генә сорау биреп, аңарга ярдәмгә ашыкты. Нәрсә әйтсәң дә, үзеңнеке бит инде! Тик малай ижекләп кенә булса да урысчалап укып, аны "күпләп" сөйләп, ныклап ялыккан иде, ахрысы. Әллә инде "урысчадан татарчага күчә алмады", баскан урынында тик кенә тавыш-тынсыз тора бирде.

—Әллә белмәскә итәсеңме?—диде Габдеррәхим көлемсерәп.—Бу бит сиңа урыс дәресе түгел. Намаз укыйсыңдыр бит?

—Ы-ы, укыйм намаз...

—Соң, укыгач! Тәүлектә ничә мәртәбә мөселманга намаз уку фарыздыр?

Шул чакта артта утырган Гапкадыйр мәгъзүм улына ярдәмгә килде. Уң кулының тырпайган биш бармакларын үзенең кырпы бүреге өстенә күтәрде. Бармаклар кыска, юаннар, үзләре тирес кортларын хәтерләтеп селкенәләр иде. Малай, иреннәрен кыймылдатып, әтисенең биш бармагын санап алды.

—Би... Биш вакыт намаз фарыз мөселман булган бәндәгә.

—Менә, ичмасам, булды бу!—дип куана Тукаевлардан булган Габдеррәхим.—Исемнәрен дә әйт инде.

Малай боларын әтисеннән башка үзе дә белә икән:

—Иртәнге намаз, өйлә намазы, икенде, ахшам һәм ястү намазы.

—Сөбханалла-а!—дип суза Мөхәммәт Шакир хәзрәт.—Сөбханалла-а! Бик тә әйбәт иттереп беләсең бит! Яле "Әлхәм"не дә укып җибәр әле!..

Урыс теленнән тапшырыла торган имтиханнар мөселман догалары укуга күчеп, дин дәресенә ошап китәләр...

Алты малай төрлесе төрле дәрәҗәдә урысча белем күрсәттеләр. Азрак белмичәрәк тора башласалар, Мөхәммәт Шакир белән Габделкадыйр Тукаевлар татарчалап, ислам дине буенча сораулар биреп Тукаевлардан булган малайларны "коткара" бардылар. Урыс Берлов та берничә сорау бирде. Кайберләренә азрак җавап кебек нәрсәләр дә алгач, күңелләнеп китте. Аның күңелләнүенең сәбәбе шул: татар малайларында урысчадан белем түбән, урыс мәктәпләренә бирелгән кебек түгел иде. Урысча укыган

татар малайларын аның әле беренче күрүе иде.

Имтихан тоткан малайлар арасында Лотфый мәгъзүм дигән малай үзенең яхшы, жиренә житкереп урысча укуы белән, укыганын урысчалатып сөйли белүе белән яхшы якка аерылып тора иде. Шул ук граф Толстойның бер хикәясендәге бер көчекнең төнлә белән авылга килгән инә бүрегә ияреп, аның белән урманга киткәнен укып та, сөйләп тә бирде. Лотфыйның урысча яхшы укыганлыгын белгән Мирсәет Учител аны ин соңгы иттереп имтихан бирергә калдырган иде. Лотфый, кара тактага акбур белән шакылдатып сугып яза-яза, арифметикадан дүрт мисал да чишеп куйды. Акка буялган бармакларын бер-берсенә ышкып тыныч кына басып торган малайга урядник Тайчинов та сорау бирәсе итте:

—Русия патшасы галижәнабләренең исемен беләсеңме?

Лотфый ул сораугa "шартлатып" җавап бирде:

—Самодержец царь всея Руси Романов Николай Александрович.

Урядникның кысык күзләре хәйләләнеп тагын да ныграк кысылдылар:

—Ә патшабикәнең исеме ничек?

Малай күзен дә йоммыйча аны да чыгарып салды:

—Александра Федоровна Романова.

—Ай, молодец так, молодец!—диде урядник Тайчинов телен шартлатып. Дастуйный учиник булган бу парин.

Урядник соравыннан соң имтихан алучыларның да күңелләре күтәрелеп киткәндәй булды. Азрак гөрләшеп, куанышып алдылар.

Лотфый мәгъзүмне мактап-мактап озаттылар да, аңардан соң Лотфулланы чыгардылар. Урыс хикәяләре язылган китап бирәү генә иде. Шунлыктан аңарга да шул ук граф Лев Толстойның "Дуб и орешник" дигән хикәясен укырга куштылар.

—"Дуб и орешник",—дип башлап алып китте Лотфулла.—Рассказ графа Льва Толстого.

Ачык көр тавыш белән, өтер, нокталарда тиешенчә тукталып, кабаланмый гына хикәяне укып чыкты. Укып бетергәч, китапны ябып кулында тоткан килеш сүзмә-сүз хикәянең эчтәлеген сөйләп тә бирде. Тактада тапкырлау белән бүлүгә багышланган дүрт мисал чиште. Габдеррәхим-Соколов биргән урыс гәжитеннән ул күрсәткән кечкенә мәкаләне укып чыкты да, эчтәлеген сөйләп бирде. Мәкалә йорт салу өчен әзерләнгән такта һәм бүрәнәләр сату турында белдерү иде. Татарчалап сөйләттеләр эчтәлеген. Ямалган йон оекбашлар өстеннән агач каталар кигән бу сары чәчле, зәңгәр күзле ябык гәүдәле малайга барысының да исләре китеп утырды. Өстәл артында утырганнарның күбесенең йөзенә аптырау белән соклану тойгысы чыккан иде. Тик Гапкадыйр мәгъзүмнең генә йөзе каралганнан карала барды. "Бер хәерче өтекнең баласы бит инде! Кара, ничекләр иттереп сукалый урысчаны, мәлгун нәстәкәй!"—дип көнчелек утында көйри башлады ул. Ә абзасы Мөхәммәт Шакирның башында бөтән төрле уйлар иде: "Менә шушындый малайлардан чыккан егетләр күтәрәчәк безнең бетеп барган милләтебезне! Аллага шөкер! Болай булса бетмәбез, иншалла!"

Габдеррәхим Тукаев сорау бирде:

—Яле, Лотфулла, син безгә урысчалап балта белән утын кискәнне сөйләп бир әле.

Лотфулла такта идәндә шакылдатып, агач каталарын кузгаткалап алды. Кулындагы китабын өстәлгә куйды.

—Балта урысча топор була.

Гомере буена балта күтәреп эшләгән әтисе күз алдына килде. Габдеррәхим-Соколовка карап үтенде:

—Мин әтием турында сөйлим әле. Ул бит балта остасы.

—Сөйлә, сөйлә! Рөхсәт сиңа. Балта сүзе булсын сөйләгәндә...

Малай тәрәзәдән текә тауга үрмәләгән Чуаш сукмагына караган хәлдә акрын гына сөйләп китте:

—Мой папа Зайнетдин плотник. У него есть ... острый топор. Он делает деревянный дом. Он каждый день работает топором. Когда дом готов, хозяин дает деньга. Папа купит хлеб, картошка. Деньга он дает мама...

Киеренкелектән борыны тирләп чыкты. Туктады сөйләвеннән. Габдеррәхим соклануын яшереп тә тормады:

—Менә, ичмасам, егет икәнсең, Лотфулла. Тагын бирер нәрсә өстәп кара әле. Булдыра алырсыңмы икән?

Маңгае җыерылды малайның. Аз гына уйлап басып торды да өстәде:

—У моего папа есть четыре сына. И еще моя мама Гөлмәрфуга есть...

—И-и, Лотфулла-а!—дип куанды Габдеррәхим малайны бүлдереп.—Син үзең граф Талстуй кебек хикәя язарлык егетсең бит. Сөбханалла! Урысчага бик шәп икәнсең син...

Өстәл артында утырганнарга карап алды да, куанып өстәде:

—Рәхмәт сиңа, Мирсәет туган, бу малай өчен! Рәхмәт!..

Лотфулладан соң Хәйдәргали хәлфәдән дә сынау алдылар. Мирсәет аңарга Антон Чеховның "Ванька Жуков" дигән хикәясен укырга бирде. Хикәя журналда басылган иде. Таза гәүдәле хәлфәгә карап, урядник Тайчинов көлеп куйды:

—Атның азгыны тайга иярә!—диләр.—Син дә инде, бала-чагага ияреп урысча укыйм дип җәфаланмасаң, башка эшең беткән икән!

Хәлфә Хәйдәргали саран гына елмайды. Җаваплап тормады. Гомумән ул вакчыл кеше түгел һәм дөньяга һәрчак иң кирәген генә эшләргә атасы Солтангали тарафыннан бала чагыннан ук өйрәтелеп үскән иде. Шулай да үзеннән яшькә олы укучысының кызу канлы икәнен белгән Учител аны яклыйсы итте:

—Эшнең, укуның ояты юк. Укы, әйдә, Хәйдәргали абый, тартынма!

Хәйдәргали тамагын кыргалап хәзерлек үткәрде дә, бабасының яшәгән авылы исемен дә белмәгән тугыз яшьлек Ванька Жуков дигән малайның шул бабасына үзенең авыр тормышыннан зарланып хат язуы турында укып алып китте: "Ванька Жуков девятилетний мальчик..."

Урысча сөйләшү телен ярыйсы гына белгән, тик үз гомерендә урысчалатып бернәрсә дә укымаган урядник Тайчинов, эченнән генә ник Хәйдәргалидән көлгәненә үкенеп, ятим урыс малаеның авыр көнкүреше турында тетрәнеп тыңлады. Башкалар да, барысын да аңлап бетермәгән Мөхәммәт Шакир белән Габделкадыйр Тукаевлар да, авыр хисләргә бирелеп тавышсыз гына утыралар иде. Бүлмә эчендә тик Хәйдәргали хәлфәнең урысчалап укыган салмак тавышы гына яңгырый...

Хикәя укылып бетте. Берлов сорады:

—Скажите, Султангалеев, зачем тебе русский язык?

—Татарских мальчиков учить буду.

—Зачем учить их?

Хәйдәргалинең урысча сөйләү теле ярыйсы гына иде. Җавапны да урысчалап бирде:

—Без татарлар башка алга киткән милләтләрдән елдан-ел артта калабыз. Безгә корабль ничек йөзә, аның машинасы ничек эшли, завод-фабрикалар ничек төзелә—шуларны белү кирәк. Тимер юлдан тимер арба йөри. Ул паровоз дип атала. Паровозны пар йөртә икән. Ә без татарлар шуны белмибез...

Берлов коры гына итеп әйтте:

—Вам татарам все это не нужно. Растите хлеб, пасите скот, кормите державный народ, русских...

Габдеррәхим Тукаевның кул бармаклары өстәлгә тыпырдатып суккалый башладылар. Берловка карамыйча коры гына иттереп әйтте:

—Господин Берлов! Давайте, заниматься экзаменом. А что должен делать мы, татары, об этом пусть думает наш царь батюшка, а не вы...

Хәйдәргалигә башкача сораулар бирмичә генә аның сөйләгәннәрен

тыңладылар да, имтиханнарны очлап куйдылар.

Габдеррәхим күнелле иттереп сөйләргә тырышып әйтте:

—Зәйнуллин Лотфулланы Казан каласындагы учительская школа дигән уку йортына укырга җибәрергә дигән тәкъдим бар. Ул тәкъдим белән мөдәррис Тукаев, Мөхәммәт Шакир белән Учител Мирсәет Бийишев чыктылар. Эстәрлетамак земствосына бу тәкъдим ошый һәм мин дә кушылам аңарга...

Ул борылып Мөхәммәт Шакирга карады. Тик анысы бернәрсә дә әйтә алмый калды. Аның кырында утырган энесе Габделкадыйр ачулы, шытырдавык тавыш белән телгә килде:

—Бармый торсын әле ул хәерче Казанга. Ни эшләп без мөселманнан урыс ясарга ирек куярга тиешбез, ди инде. Яшәсен авылда, йөрмәсен ул Казаннарында. Эшләсен монда. Безгә урыслашкан татар кирәкми...

Бүлмә эче тып-тын булды. Габдеррәхим үзенә теләктәшлек эзләгәндәй өстәл артында утырганнарны берәм-берәм карап чыкты. Тик аларның берсе дә башын күтәреп аңарга карамады. "Соколов" диварга аркасы белән сөялеп елап җибәрүен көчкә-көчкә басып торган Лотфуллага эндәште:

—Син, энем, бар чыгып тор. Без олылар монда сөйләшеп алыйк әле.

Бала чыгып киткәч, Гапкадыйрга әйтте:

—Син нәрсә сөйлисен, Гапкадыйр?! Шушы хәтле сәләтле малайны юк итәбезмени инде? Ә? Укысын Казанда, белем алсын. Школасын тәмамлагач кайтыр үзебезнең авылга, балалар укытыр. Халкыбызны агартыр. Яисә сиңа тылмач булыр, приказщик булыр калада...

Гапкадыйр тархан урыныннан сикереп үк торды:

—Кирәкми безгә урысча укыту. Ярлыларга бигрәк тә кирәкми. Прикашик та кирәкми миңа, тылмачы да кирәкми. Миңа үгез куучы малайлар кирәк тә, сабан артыннан йөрүче хезмәтчеләр кирәк. Башыгызга каплагыз ла урыс ышкүлыгызны. Кем син мине өйрәтергә дә, безнең татар балаларын урыс Казанына җибәреп урыс итәргә? Ә? Маржалар белән уйнаш кылып, Соколов белән хәмер чөмереп йөрегән үзең дә бер Сакалуф син! Белмәсәң, бел! Ә мин тархан Габделкадыйр Харисович Тукаев. Мине патша үзе белә. Импираторга житәрмен, мөфтигә барырмын—үз сүземне сүз итәрмен. Мин сине эшеңнән кудыртмыйча туктамам да әле. Иртәгә үк губирнатырның үзенә китәм. Бел шуны. Шакирны мәдрәсәсез, сине урынсыз калдырырмын. Илләмә ул хәерчене Казанга җибәрттермәм, иншалла...

Берлов урыныннан кузгалып куйды. Ул татарча аңлый да, сөйләшә дә. Тик белгәнен татарлардан яшерергә өйрәнгән иде. Гапкадыйр мәгъзүм сөйләгәннең барысын да аңлап утырды. Эченнән генә куанып утырды ул. Габдеррәхимгә карамаска тырышып әйтте:

—Тархан прав. Не нужно учить татар в русских заведениях. Только в том случае, если примут православие. Я против посылки этого... э-э... татарчонка в Казань...

—Мин дә каршы!—диде урядник Тайчинов кабаланып.—Ни чыкса, шул укыганнардан чыга. Алар укыган саен патшага каршы чыга баралар. Укымасын, кирәге юк!..

Мөхәммәт Шакир хәзрәт сүзсез генә урыныннан торып ишеккә юнәлде. Габдеррәхим өмете сүнә башлаган тавыш белән аңарга эндәште:

—Абый, син китмә инде. Әйт үзеңнең сүзеңне!

Мөхәммәт Шакир тукталды. Азга гына.

—Без икәү генә калдык. Алар өчәүләр. Лотфулла дип үзара ызгышмыйк инде. Тукаевлар бит без. Бармас инде болайга киткәч. Югарыдагылар синең белән мине тыңламаслар алар... тархан Тукаевны тыңларлар. Аннан татарга андый уку тәтемәс инде. Өстәвенә ярлы малае. Сәләте зур зурлыкка. Тик...

Чыгып китте. Өстәл кырында кып-кызыл булып утырган Учител Мирсәет Бийишевне тыңлап та тормадылар. Аның эше укыту һәм шуның

өчен акча алу. Шуннан артыгына кысылып йөремәсен!

Лотфулла өйләренә кич кенә кайтты. Елаудан шешенеп кызарган күзләре, азрак жилсенгән бите әтисе Зәйнетдин белән әнисе Мәрфугага малайның хәлен аңлаттылар. Зәйнетдин көрсенеп куйды да сорады:

—Нәрсә, улым, әллә имтиханнарыңны бирә алмадыңмы?!

—Алдым,—диде пышылдап кына Лотфулла.

—Ә нигә... еладың алайса?

—Тан... таныклык бирдермәде Гапкадыйр мәгъзум ... абзый...

—Нигә алай инде?

—Син укыганга земство акча түләмәгән, шунлыктан сиңа таныклык тиеш түгел, ди. Мирсәет абыйдан бирдермәде.

Байтак дәшми утыргач, әтисе торып, малаен сәкегә алып килеп утыртты. Зур кулы белән малаеның аркасыннан сөйде.

—Шула-ай!—диде ул сузып кына.—Шула-ай улы-ым! Без фәкыйрьгә нинди уку булсын инде. Өстәвенә урысча тагын. Гапкадыйр байга укыган кешенең кирәге юк. Аңа ялчылар кирәк. Жир сөрергә, мал карарга, иген игәргә. Безнең язмыш байлар кулында инде. Син, улым, оныт урыс ышкулын да, урыс укуын да. Ходай безгә андыйны насыйп итмәс инде ул!..

* * *

Лотфулла Бәләкәй базар читендәге төялгән ат йөге янында сөйләшеп басып торган Учител Мирсәет белән Хәйдәргали хәлфәне күрде. Кыяр-кыймас кына алар янына атлады. Исәнләште:

—Әссәламәгаләйкүм... абзыйлар!

—Исән-сау йөрүме, Лотфулла?!—диде Мирсәет аңарга исәнләшер өчен уң кулын сузып. Учителгә ияреп Хәйдәргали хәлфә дә кул бирде.

—Хушлаш, Лотфулла, Хәйдәргали абзый сабакташың белән!—диде елмая биреп Учител.—Китә бит Эстәрлебаштан.

—Кая китә?—дип сорады малай.

—Башкортларны укытырга. Еләмбәт авылына, Күндерәк башкортларына.

—Син, туган, бөтенләй күренми башладың. Менә инде Хәйдәргали абзый да китеп бара бездән. Тагын күрешербезме, юкмы, бер Ходай белә. Син, Лотфулла, минем янга кергәләп йөре. Үпкәләмә миңа. Миннән тормый бит, барлык нәрсә Габделкадыйр Тукаев кулында. Хәтта Мөхәммәт Шакир абзый белән Соколов абзый да каршы тора алмыйлар аңарга. Ул бәндә каршы урысча укытуга. Аңарга батраклар кирәк. Школага тагын өч китап килде. Берсе яңа гына чыккан, Антон Чеховныкы. Биреп торырмын укырга. Кер! Онытмаска кирәк урыс телен. Киләчәктә бик нык кирәк булачак ул сиңа.

—Һы!

—Кил минем янга, ярармы!

—Ярар.

—Әле кая китеп барышың соң?

—Югары очка, әтигә ашарга илтәм.

—Берәрсенә йорт эшлиме әллә?

—Нариман бабайга келәт бурый. Мин китим инде. Бәрәңге суына, югыйсә.

Хәйдәргали, елмаеп, Лотфулланың аркасыннан кулы белән атлы арба ягына этте:

—Әнә, дустың Мирсәет белән саубуллаш! Байтак карадың бит син аны. Ярата иде синең белән уйнарга.

Икенче арбада әнисенә терәлеп утырган Мирсәетне күрде Лотфулла. Зурлар белән сөйләшеп чамаламаган булган икән. Шул ук зәңгәр күзле, коңгырт чәчле малай иде Мирсәет. Ак күлмәк өстеннән килешле иттереп

тегелгән кара камзул, башына матур түбәтәй кигән. Кечкенә Мирсәет үзен караган, аның белән уйнаган Лотфулла абыйсын танып, шатланып елмайды. Зәңгәр күзләре нурланып матурландылар. Арба өстендә аягүрә басып, Лотфулланың муеныннан ике куллап кочаклап кысты, үзе сөйли дә башлады:

—Әти әйтә, ни дип әйтә, башкортларда ит тә күп, кымыз да күп, дип әйтә, бик тиз итеп үсеп китәрсең, дип әйтә...

Малайның гәүдәсе кечкенә һәм ябык иде.

—Әти әйтә, башкортлар курайда бик оста уйныйлар, дип әйтә. Син дә башкорт кебек курайчы булырсың, ди...

—Курайчы булам, ди, дустың, тик башкорт булмыйм, ди, әле,—диде әнисе.

Барысы да көлештеләр. Лотфулла кечкенә малайны әнисе янына утыртты да, хушлашып, төенчеген күтәреп урам буйлап Югары оч ягына китеп барды. Мирсәет Учител салмак кына адымнар белән китеп барган малай артыннан моңсу күзләрен текәп бераз карап торды да, Хәйдәргалигә борылды:

—Юклык, хәерчелек, урыс ашату бетерә безнең татарны. Искитмәле сәләтле бала бу Лотфулла. Укытырга иде дә бит—юк мөмкинлек.

Мирсәет сүз барышын икенчегә борды:

—Минем ишеткән буенча, сине башкортлар Еләмбәтенә Мөхәммәт Шакир мөдәррис җибәртә икән. Дөресме шул?

—Дөрес. Тик өздереп кенә итеп, аны гына әйтеп булмый инде. Аның үтенече буенча Габдеррәхим Соколов үзе барып, шунда губернаторга ук кереп, башкортларның бер авылында мәдрәсә ачарга рөхсәт сорап ала алган. Күндерәк буе башкортларының авылларында бер генә мәдрәсә дә юк икән. Шундагы башкортны аз гына булса да, татарчалап булса да укытырга итәләр. Башкортның әлифбасы да, уку-язуы да бөтенләй юк бит инде. Шул Күндерәк елгасында утырган алты башкорт авылына Уфадан бер мәдрәсә ачарга рөхсәт биргәннәр.

—Минем булганым юк ул якларда. Исемнәре ничек ул башкорт авылларының?

—Алтау алар. Кабыккуш, Табылды, Сарайса, Шәкәр, Еләмбәт. Соңгысын башкортлар үзләре Шипай дип тә йөртәләр. Авыллар сирәк ул якларда. Татар, урыс авыллары юк диярлек, Күндерәк елгасының башында Әмир, Карагош исемле ике мишәр авылы барлар барлыкка. Чабатачылар, пимачылар алары. Мине күндерде инде Шакир мәгъзүм. Земстводан акча да түлиләр. Башкортка белем бирү инде минем максат хәзер...

Мирсәет Учител күңелле итеп көлде:

—Инде ике гасыр буена Эстәрлебаш мәдрәсәсе эшләп килә. Бер башкорт укыганы юк диярлек. Башкорт безнең татар кебек укуга хирыс халык түгел. Ите бар, курае бар, даласы бар. Гыж-гыж китереп, тал төбенә ятып кураен тартса, шул җиткән аңарга. Мәдрәсәгә килеп караганы да юк, яз була башла дисә даласына чыгып тая да, күзен генә кире кайта. Авылларында мулла итеп куярлык бер башкортлары юк. Барлык муллалар татарда. Монда укытканда шуны аңладым мин. Дөресме?

—Бер караганда, синең сөйләгәнеңдә дөреслек тә бар кебек. Тик бик үк төгәл дә түгел. Мин Эстәрле мәдрәсәсендә укыган шәкерт һәм бүген хәлфә булып укытам да. Шунлыктан, сиңа караганда, мәдрәсәне яхшы беләм дип уйлыйм. Башкорт батырлары Кинҗә белән Салават укыганнар Эстәрле мәдрәсәсендә. Икесенең дә аталары Казан ягы татарлары булганнар. Инәләре генә башкорттан, Кинҗә дә, Салават та бик зур гыйлем ияләре булганнар. Сирәк-мирәк кенә булса да башкортлар укыганнар инде укуын. Тик ныклап утырып укый торган халык түгелләр. Анысы белән килешәм. Чөнки башкортта чабыш атыныкы кебек ярсу йөрәк бит аңарда. Андый йөрәк белән ничекләр иттереп түзеп мәдрәсәдә утырырга була ди инде! Сез Казан татарлары барыбер аңлый алмыйсыз

башкортны. Аңласак, аны без генә аңлыйбыз—башкорт белән аралашып яшәгән җирле татарлар...

Мирсәеткә ике кулын суздьı:

—Ярар, күрдем сине, сау булып тор, энем Мирсәет! Сиңа алдан ук әйтеп куя торган бер гозерем бар. Шуны әйтеп китим инде мин, син рөхсәт ит!

—Әйт.

—Әнә, арбада синең адашың утыра. Минем улым Мирсәет. Синең хөрмәткә, синең исемең кушылган аңарга. Уку ягына, әле генә узып киткән Лотфулладан ким булмас дип уйлыйм мин. Тик үз баласын мактый дип уйлый күрмә. Киләсе елга мин аны Эстәрлебаш мәдрәсәсенә китерергә уйлыйм. Шунда син минем малайны урыс ышкулына да укырга ал инде. Шул була инде минем гозерем...

—Малаең үсеп җиткәнче, урысчага кергәнче өч ел вакыт бар икән әле. Алырбыз. Укыр, сәләте булса. Китерерсең.

—Ярар. Хуш иттек. Исән бул, Мирсәет туган! Вәйт, икенче олауның хуҗасы да килә. Кунаклары бар икән. Шуларны көтеп азрак тоткарлык булды. Исән бул туган. Мине урысча укытканың өчен зур рәхмәт сиңа. Миңа биргән кебекләр иттереп, Ходай сиңа да көтмәгән җиреңнән бирсен...

—Амин! Шулай булсын! Сау бул, Хәйдәргали абзый!..

Ике олау Бәләкәй базар тыкрыгыннан түбән төшеп, Мөхәммәтша Чәүкә тимерлеген унда калдырып, Эстәрле елгасы аша салынган күперне чыктылар да, Ясаклы урамы аркылы Хәлкәй авылы юлына юнәлделәр. Хәйдәргали хәлфә Күндерәк буе башкортларына ислам дине дәресләре вә һәм дә урыс теле укыту теләге белән хыялланып үз уйларына чумган иде. Ә кечкенә Мирсәет башкорт авылына баргач, башкорт булмыйча, ничек кенә булса да курайда уйнарга өйрәнергә исәпләп, әнисенә сыенган хәлдә тирә-яктагы матур тау-урманнарга, кыя ташларга карап бара иде.

* * *

Колаксыз, түгәрәк мескен бүреген кулларында әвәләгән Зәйнетдин Балта иртән-иртүк, әле бай тормас борын ук Габделкадыйр тарханның ишек алдында мыеклары чыга башлаган чабаталары белән бер урында тапанып тора иде. Сарай астыннан агач көрәк белән себерке күтәреп чыккан, байның ишек алдын караучы Мәнәхетдин картка ярарга тырышкан тавыш белән сәламләп эндәште:

—Әссәламәгаләйкүм, Мәнәхетдин абзый! Исәнлек-саулыкмы-ы!?

—Вәс-сәламәгаләйкүм, Зәйнетдин энем. Аллага шөкер, себерәм әле! Үзенең шаяртуыннан кыска гына иттереп көлеп куйды:

—Алла куәт бирсен!

Мәнәх карт тагын көлде. Кәефе әйбәт иде, ахрысы:

—Хә-әх, хә-әх, хәх! Үзе бар иткәч, куәтне бирергә тиештер инде. Өстәвенә, бай түләп җибәрсә ипилек, тозлык. Син нәрсә, энем, бик иртәләгәнсең бүген?!

—Ике улымны байга ялчылыкка бирергә дип килгән идем. Нужа бабай йөртә инде безне.

Мәнәх бабай себерә башлаган җиреннән тукталып калды.

—Малайларың үсеп кенә киләләр түгелме соң әле синең?

—Берсенә ундүрт тула, икенчесенә унике...

—Э-э-эй, дөнья диге-ен! Шара сугып, чебенле уйнап көннәре үтәргә тиеш бит әле аларның. Ә син аларны, ялчылыкка-а!..

—Кая бармак кирәк, Мәнәхетдин абзый! Нужа басты бит, нужа-а. Җир юк. Ә тамак туйдырырга кирәк.

—Шулай-ай, энем! Син инде әнә тегеләйрәк, келәтләр алдынарак барып бас. Тархан торып, әбрәкәй тирәләрен урап килгәч, шушында

туктаса, өенә кереп китәр алдыннан янына килерсен. Туктамаса инде, кереп китсә, урам якка чыгып, капка төбендә көтәрсен. Байның сөйләшү тәртибе шундыйрак. Кәеф ягы чамалырак булса, ул капка төбендә дә тукталып тормый. Бай бит. Байлар шулайрак була инде ул. Кара халыкны күрми дә алар. Кая, энем, син кузгал. Мин бу тирәне себереп алыйм әле. Бай иртән торганда, ишек алдын себереп йөргәнне күрергә ярата ул. Бай бит!

Зәйнетдин ишек алдын аркылы чыгып, келәт янына килеп басты. Аның әле Гапкадыйр тархан янына беренче мәртәбә килүе иде. Улы өчен монарчы байларда кучерлектә йөргән атасы Әбеннәгыйм сөйләшә торган иде. Бу юлысы карт кучер Гапкадыйр бай белән сөйләшүдән баш тартты. Кичә кич әтисе улының сөйләгәнен тынлап та бетермәде.

—Син инде күптән үзең әти кешесең! Балаларыңны дөньяга китергәнсең икән, аларны туйдыруны да үзең кайгырт, сабыйларны киендерү, аларның тамагын туендыру синә фарыз. Ә син үсеп бетмәгән малайларны ялчылыкка тыгасың. Бәлки синеңчә, хатыныңча шулай кирәктер. Тик аз гына башы, эчендә ми булган кеше ул балаларны Гапкадыйрга ялчылыкка бирәмени? Тереләй тәмугка тыгасың минем оныкларымны. Биргәч-биргәч ялчылыкка, азрак юньлерәген эзләргә кирәк иде байның. Алар арасында да бардыр мәрхәмәтлеләре, юньлерәкләре. Тик Гапкадыйр бай түгел! Комсызның ар ягына чыгып, аякларын салындырып утырган бит. Шул комсызлыгы аркасында үзе дә катып беткән бит, күрмисеңмени азрак. Үзен-үзе ашый!

Зәйнетдин кызу канлы әтисеннән әле дә шүрли иде. Тик өендә барлык нәрсә турында үзенчә генә фикер йөртеп, салмак кына сөйләп, күп эшләрне тик үзенчә генә башкарырга өйрәнгән хатыны Мәрфуга да бар бит әле. Анысыннан Зәйнетдин атасыннан шүрләгәннән дә ныграк курка бугай. Шунлыктан әтисенә каршы торуны кирәк санады:

—Син шулай дисең дә бит әле. Әнә, Локман абзыйны, малаен Шакир Өтергегә кибетендә йомышка йөрергә биргәч, ничекләр иттереп сүккән Гапкадыйр мәгъзүм. Мәчеттән чыккач. Нигә үземә китермәдең, дип. Мине дә эт урынына сүксә. Аңарда бит көч.

Әбеннәгыйм карт ике кулын артына куйды да китеп барды.

—Аңардан курыксаң, үзең бар. Мин бармыйм Гапкадыйрга, инде кырыкка житеп киләсең, үзең йөре. Үз балаларың—теләсәң нәрсә эшләт! Тик мин оныкларымны Гапкадыйрга бирүеңә риза түгелмен.

Китеп барды. Әбеннәгыймның уң якка янтая биргән гәүдәсе авыл урамы буйлап авыр итеп атлый иде...

Өенә кайткач, Зәйнетдиннең хатыны Мәрфуга сүзне кыска тотты:

—Әтинең үз дөньясы, безнең үз дөньябыз. Яшь хатын алганнан бирле безгә сырты белән тора. Гапкадыйр мәгъзүмгә иртән үзең бар. Малайларыбыз эшчәннәр—алыр. Алмый калмас...

Ялтыратып тазартылган сары жиз комганын тотып ишектән чыккан Габделкадыйр бай келәт ягына күзләрен сирпеп кенә алды. Комганы озын борынлы, билле, Бохара комганы иде. Кабаланмый гына ишек алдын караштыргалап әбрәкәй ягына узды. Себерүдән туктап үзен сәламләгән Мәнәхетдин картка баш кына какты. Ул күздән югалгач, Мәнәх уң кулын һавага күтәреп салмак кына селтештерде. Бу инде байның кәефе ярыйсы дигәнне аңлата иде, ахрысы.

Бераз вакыт үткәч бай кире күренде. Кабаланмый гына, үзенең дәрәжәсен белеп кенә өенең ишеге төбенә житте. Комганын карга куйды да, Зәйнетдин басып торган якка аз гына борылгандай итте. Мәнәх карт кулын селтәде: "Бар тизрәк бай янына!" Зәйнетдин атлый-йөгерә дигәндәй, бай янына ашыкты. Өч-дүрт адым кала туктады. Тагын башына кигән колаксыз түгәрәк бүреген салып түбәтәйдән генә калды. Байны сәламләде. Мәгъзүм баш кына какты.

—Ни йомыш?—диде Зәйнетдингә карамыйча гына.

—Мәгъзүм!—диде Зәйнетдин кысылып чыккан тавыш белән.—Ике

улымны үзенә алмассыңмы икән дип килүем иде.

Бай үзенә "мәгъзүм" дигәнне ярата иде.

—Ничә яшьтәләр?

—Берсенә ундүрт тула, икенчесенә унике тулды.

—Усал түгелләрме? Тыңларлармы?

—Юу-ук! Үземә ошаганнар, юашлар икесе дә. Бик тә эшчәннәр.

—Икесе дә сабанга җигелгән үгезләрне куарга риза булсалар, өч көннән, дүшәмбе көнне үзең китерерсең. Малайлар йортына. Тамак ялына алырмын. Шуның өстенә ыштыр-чабата, көзен бер пар күлмәк-ыштан, бер чалбар бирелер. Игеннәр келәткә кереп беткәнче, кар төшкәнче эшләрләр. Тырыш булсалар, тыңлаучан булсалар, киләсе елга хак куярмын. Бер елдан.

Комганына үрелде, тик аны алмады. Турайды.

—Малайларыңның берсе теге урыслаша башлаган Лотфулла исемле-седер әле?

Куркуыннан коелып төште Зәйнетдин. Дәшмәүне кулайрак күрде.

—Эшләсен. Тыңлаучан булсын. Онытсын урыс ышкулын да, урысча укуын да...

—Ярар мәгъзүм. Тыңлар, онытыр.

Бай җавап биреп тә тормады. Комганын алды да, өенә кереп китте. Бүреген дә киярга онытып, Зәйнетдин баскан урынында торып калды.

—Шула-ай, энем!—дигәнгә сискәнеп китте. Мәнәх карт икән. Мин дә өч ел тамак исәбенә үгез кудым аның атасы Хариста. Ашау—арыш умачы да, арыш ипие иде. Алары да тамак туйганчы түгел. Синең Лотфулланны теге урыс укуына бик шәп ди икән Учител Мирсәет. Ул малаеңны йә үрәтник, йә авыл писере итәргә иде дә бит...

Зәйнетдин дәшмәде. Башын гына кагып саубуллашты да, мескен бүреген киярга да онытып, капка ягына юнәлде. Атлаган уңайга уйлап куйды: "Икесенә бер-ике тәңкә генә булса да түләүне кирәк дип тә тапмады. Мәрфугага нәрсәләр генә диярмен инде..."

Үсеп кенә килгән ике малаен тамак исәбенә саткан, гомере буена нужадан чыкмаган атаның адымнары авыр һәм гәүдәсе кечерәеп калгандай булып, атлавы сүлпән иде...

* * *

Габделкадыйр тарханның Кара Балыклы яланнарында язгы сабанга чыгу нияте белән юлга кузгалган халык ярыйсы гына арыган иде. Хәмбикә ташы дигән калкулык урынга барып җитәргә өч чакрым тирәсе ара калгач тукталдылар. Унике чана белән килгән ялчылар Әлхәмгали прикащик янына җыйналды. Сай Чокыр дип йөртелгән үзәнгә язгы су төшеп, юл су астында калган икән.

—Кичә килгәндә өлгерәсе булганбыз да бит. Бетергән бу су кышкы юлны,—диде сабанчы Имаметдин куангандай тавыш белән.

—Сай Чокырның башына узып урарга туры килер, ахрысы,—диде озын Хәсән.—Теге Ялгыз Карамага хәтле бит әле ул. Өч чакрым чамасы булыр.

Әлхәмгали итек балтырына камчысы белән суккалап уйланды.

—Өч чакрым ук булмас булуын. Тик икедән артык инде. Сай Чокыр җәен чыннан да сай да ул сайлыкка. Тик менә бүгенгесе,—диде ул су астында калган юлга карап.—Нык алган бу юлны. Чыгып булмас ерып. Ничек ага бит шаулап.

Әлхәмгали үзен уратып баскан ялчыларга карап алды.

—Ярар, суның кузгалуы бик әйбәт. Тизрәк чәчүгә төшәрбез. Җир тизрәк ачылыр, иншалла. Болай итик без. Утардан куган үгезләрне шушыннан турыдан йөздереп чыгарыйк. Үгез куучы малайларны үгезләр өстенә яткырып арканнар белән бәйләгез. Теге якка чыккач, үгезләрне куып алып китәрләр. Чаналарны Ялгыз Карама яныннан уратып җибәрик.

Ул тирәдә җир ачыла башлаган булырга тиеш. Ике-өч көннән сабанга чыгарбыз дип уйлыйм мин.

—Көне кояшлы булса, җир өлгерер лә ул. Янгыр, яисә кар яуса, көтәргә туры килер инде...

—Төшәбезме сабанга, төшмибезме—эш анардан башка да җитәрлек. Кайгырмагыз!—диде байның "уң кулы" Әлхәмгали.—Бер-ике көннән бай үзе дә килеп җитәр әле, сезне сагынып...

Көлештеләр. Бай кешесе булса да, Әлхәмгалине ялчыларның күбесе хөрмәт итәләр. Һәрчак тыңлыйлар. Ул вакчыл түгел, юк-барны күрми. Һәрчак эшләгән халыкны яхшырак ашатырга тырыша. Байга сиздермичә генә эш вакытын да кыскарткалап куя. Көзен Эстәрлетамакта баржаларга иген төягәндә берничә капчык бодайның (кай арада эләктерәләр диген!) юк булганын "күрми дә кала". Урысча да ярыйсы гына "сукалый". "Пристаньдәге урыс кручникләре белән аларча сырлап-борычлап "мат-мат" диеп сүгенеп сөйләшә дә белә әле ул. Ә аларча сүгенеп сөйләшү уен эш түгел инде—урыс теле диләр аны белгән башлы кешеләр. Биш вакыт намазны үзе дә калдырмый, ялчыларның барысын да намазга көчләп куша:

—Байларның эше күп була ул аларның. Мөхәммәт Галиәссәлам сезнең кебек эш белән изаланган халыкны аз гына булса да ял иттереп алу нияте белән керткән ул биш вакыт намазны. Ходай Тәгаләнең үзенең кушуы буенча эшләгән ул аны. Намаз укып, азрак хәл алыгыз, дип. Намаз укыганга бай да каршы чыга алмас...

Үгезләрне нукталарыннан парлап бәйләделәр. Лотфулланы сынар мөгезле зур кара үгез өстенә яткырып аркан белән бәйләп куйдылар.

—Аяк-кулларың белән ныклап ябеш!—диде Имам абзый.—Үгез йөзгәндә башыңны күтәрә бир. Тончыга күрмә авызыңа, борыныңа су кереп...

Иң алдан ак башлы аклы-кызыллы үгезне җибәрделәр. Аның аркасына беркемне дә бәйләмәгәннәр иде. Ул үгез беренче булып йөзеп чыгып, башкаларга юл күрсәтергә тиеш иде. Үгез аркасына Лотфулладан дүрт яшькә зуррак Сәлахетдин дигән бер малай менеп баскан. Нукта тезгенен сул кулына тотып, уңына яхшы каеш чыбыркы алган. Аны урталай бөкләп тоткан.

—Аллага тапшырдык!—диде Әлхәмгали, ак башлы үгезнең сыртына зур кулы белән шапылдатып сугып.—Әйдә, хәйванкай, кузгал!

Кая табан куганнарын сизенгән карт үгез пошкырып куйды, алгы аякларын кузгаткалап тапанды да, акрын гына суга керә башлады. Башын күтәрә биреп, муенын алга сузды һәм, аккан суга кыеклап йөзеп китте. Аның артыннан һай-һулап башка үгезләрне дә куарга тотындылар. Алдан йөзгән үгез артыннан алар да парлашып суга төшә бардылар, каршы ярга карап, аккан язгы ташкынны кыеклап йөзеп кичә башладылар...

Үгез суга тирәнгәрәк керә башлаган саен Лотфулланың куркудан йөрәге ныграк кысылды. Ул чытырдатып күзләрен йомды, кул бармаклары белән үгезнең арка йөннәренә ябышты. Ыштыр урап яңа чабаталар кигән аяклары белән үгезнең корсагын кысты. Боз кебек салкын кар суы аның гәүдәсен куырып алды. Кар катыш салкын су, үгез йөзгән уңайга, малай өстеннән дулкын-дулкын булып бәреп агып үтте. Бер-бер артлы белгән догаларын укып, Лотфулла Ходаеннан тере калдыруын үтенде. Күрше үгез аркасында шулай ук аркан белән бәйләнгән абыйсы Хәйрулла ята иде...

Аргы якта читәннән үреп, эче-тышы балчык белән сылап катырылган салам башлы тәбәнәк алачыклар эчендә тау ташыннан чыгарылган зур мичләр бар икән. Юешләнүдән, өшүдән теше-тешкә бәрелеп шыкылдап калтыраган малайларны шул алачыкларга куып кертеп барысын да анадан тума чишендереп, мич алдына тезеп утырттылар. Тизрәк ут җылысы булсын дип мичкә тәүдә салам тутырып ут төрттеләр. Кызып янган саламга чыбык-чыбык өсти тордылар. Тизәк яктылар. Ярты

сәгать чамасы узуга өй эче, төтен белән тулган булса да, ярыйсы ук жылынган иде. Малайларның юеш киемнәрен мич өстенә элеп, үзләрен салам түшәгән мич башына куып мендерделәр. Әлхәмгали абзый кушуы буенча, килгән халыкка күп иттереп эссе сөт эчерделәр. Ярыйсы гына кисәк арыш ипие тоттырдылар. Шуларны ашап бетергәч, мич башында яткан малайлар өстенә зур киез яптылар да, йокларга куштылар...

Карлар китеп, жир ачылгач ялчылар айдан артык сабанда булдылар. Бер сабанга зур гәүдәле дүрт үгез жигелә икән. Сабаннар зур. Алар каты имән агачыннан ясалган, тимер белән тышланган. Сабан төрәне алдыннан аңарга юл ачып, жирне кисеп бара торган пычак куелган. Дүрт үгезне бер малай куа. Үгез куучы һәр малайның кулында чия саплы, өч буынлы каеш чыбыркы. Үгезләр парлаштырып агач камытларга жигелгәннәр. Ул камытлар сабанга беркетелгән, агачка тоташтырып жигелә. Аны дышло диләр икән. Дилбегә бөтенләй юк. Чөнки кирәге дә юк. Алдан уң яктан барган үгез буразнадан атлый һәм шуннан чыкмый. Ул шуңа еллар буена өйрәтелгән. Жир хужасы Габделкадыйр тархан сигез йөз дисәтинәдән торган яланнарын сөрдерер өчен һәр язны кырык сигез сабан чыгара. Һәр сабанга дүртәр үгездән, һәммәсе бер йөз дә туксан ике үгез йөри аның сабаннарында. Болардан башка тагын, сабанга жигелмичә, аерым көтү булып йөргән егермегә якын үгезе дә бар. Болары инде атлар белән берлектә чәчү орлыклары ташу өчен һәм сабандагы берәр үгез йончып тарта алмый башласа яисә ятып үлеп китсә—шуларны алмаштырыр өчен. Жир сөрү бер юлы дүрт урында бара. Һәр яланда уникешәр сабан. Унике сабанчы абзый-бабай, унике үгез куучы малай. Һәр яланда буразна озынлыгы ике чакрымга якын. Дүрт үгез өстерәгән зур сабан кара жирне актарып, әйләндереп китереп сала. Бер-бер артлы килгән унике сабан узган саен, чәчеләчәк иген кыры киңәйгәннән-киңәя бара. Иртәнге кояш белән жир сөрергә тотынган ялчылар дүрт буразна чыкканнан соң туктап үгезләрне ашатып, үзләре дә азрак хәл алалар. Яшел үлән әле үгезнең авызына эләгерлек түгел. Шунлыктан үгезнең ашаганы—кыштан калган печәннән тора. Сабанда йөргән халыкка—иртән азрак көнбагыш мае салган карабодай яисә тары боткасы. Шуңа өстәп сипараттан чыккан сөттән оеткан катык белән ике телем арыш ипие һәм сөтле чәй. Малайларга ипи бер телем. Ике малайга бер тустак тулы катык. Бер-берсенең ашаганын күздән ычкындырмыйча кабаланмый гына малайлар катык ашый. Кайчак катыкка буялган кашык белән бер-берсенең маңгаена да менеп төшәләр.

—Кабаланма ашаганда! Син генәмени монда! Бергә кап катыкны-ы!

Катык ашалып беткәч, тустакны алмашлап ялыйлар. Бер утырганда берсе ялый, икенче утырганда икенчесе. Тамак ялгап алгач, печәнгә ятып аз гына булса да черем итеп алалар. Тик күзләрен яна гына йомган кебекләр иде—Имаметдин абзыйның шыгырдавык тавышы ишетелә:

—Малайлар торыгыз! Үгезләрне жигәбез!

Имаметдин абзый бик тә коры кеше. Сәлахетдин исемле малай якягына курка-курка карап ала да, аның турында пышылдый биреп кенә сөйли:

—Безнең күршеләр алар. Әлләлә хатыны уса-ал аның. Әллә-лә-лә-ә! Ире белән сугыша атна саен. Шунлыктан хатынын жинә алмаганнан үчен монда, бездән ала ул!

Авыл өчен аның исеме Күчән Имаметдин. Әтисе мәрхүмнән калган исем.

Анысы кәбестә күчәнен бик яратып ашый торган булган.

"Хәерчегә жил каршы!" дигәндәй, шул Имаметдингә үгез куарга Лотфулланы тәгаенләделәр. Ике көн эш вакытында андый-мондый явызлыгы күренмәде, сизелмәде. Сөрә башлаганга өченче көн кичкә авыша башлаганда төпкә жигелгән соргылт төстәге Бүре исемле үгез барган унайга муенын сузып бер генә мөгрәде дә, алгы аякларына тезләнде, аннан соң шапылдап килеп ун ягына ауды. Башын жиргә сузып салды да, күзләрен йомды. Парлап жигелгән икенче үгез, егылган үгез ягына

башын иеп баскан хәлендә торып калды. Лотфулла яткан үгезнең юкәдән үргән нуктасыннан тотып тартып, аны торгызырга итеп карады:

—На-а!- диде үгезгә, атка дәшкән кебегрәк итеп.—На-а! Тор, үгез! То-ор!

Тик инде үгезнең ятуы яту иде. Лотфулланың нуктадан тартканына үгезнең күз керфекләре генә селкенеп куйдылар. Үзе авыр итеп сулыш ала иде. Лотфулла нәрсә эшләргә инде дигән кебек сабан тоткасына ябышып басып торган хәлендә Имаметдингә карады:

—Тормый бит үзе! Әллә үлә инде!?

—Сук чыбыркың белән! Инәңнең ...н карап торасыңмыни, хайваан нәстәкәй!

Авыр иттереп сулыш алып яткан үгезгә сугарга Лотфулланың кулы күтәрелмәде.

—Тор инде, тор үгез!—дип нукта тезгеннән тартты.—То-ор инде-е!!!

Арттан Лотфулланың аркасына алагаем китереп суктылар. Авыртуга түзә алмыйча, Лотфулла кычкырып җиргә тәгәрәде. Җылый-җылый сөргән җирдә ауный башлады. Аннары эченә китереп типтеләр. Җиргә егылган малайны Имаметдин әнә шулай типкәләп кыйный иде.

—Ананны....! Нигә ята үгезең! Ә?! Күрсәтермен мин сиңа инәңнең...!

Лотфуллага карлау белән бәргән икән. Типкәләүдән бер мизгелгә туктап карлавын алырга дип иелде. Лотфулла елый-елый сикереп торды да, үгезләрен кууын туктатып куркып карап торган абыйсы ягына йөгерде:

—Абы-ый! Аб-ый!

Калау күтәргән, күзе-башы акайган Имаметдин абыйсы артына сыенып үксеп елаган малайга карап атлады. Үзе ямьсез иттереп сүгенә иде. Куркынып калган ике малай бер-берсенә сыенып, сөргән җир өстендә басып катып калдылар. Бетерә хәзер икесен дә...

Шул чак Хәйрулла куган үгезләр җигелгән сабанны тотып килүче Бәдретдин бабай Имамның юлына аркылы төште:

—Ярамый алай, энем! Тукта хәзер үк! Ул сабыйның ни гаебе бар?! Тукта дим!

—Си-ин! Си-ин!—дип ысылдады күзе-башы акайган Имаметдин.—Инәңнең ..., мин синеме-е!...

Карлавын күтәреп картка селтәнде. Тик сугып өлгермәде. Бәдри картның яшьлеге, сабан туйлардагы көрәшләрдә батыр булган чаклары исенә төште, ахрысы, ул киек житезлеге белән Имаметдиннең карлау белән селтәнгән уң кулын беләзегеннән эләктереп алды да, икенче кулы белән селтәнмичә диярлек, бик катыдан булмаса да, ике каш арасына ярыйсы гына иттереп китереп сукты. Имам Күчән мәтәлләп сөргән җир өстенә барып төште.

—Ничә тапкырлар әйтелде син явызга—тимә малайларга, дип. Ничә мәртәбәләр!

Җиргә тәгәрәгән Имаметдиннең авызыннан әшәке сүгенү сүзләре килеп чыктылар:

—Ананны фәлән итим! Бетерәм мин сине барыбе-ер! Бетерә-әм!

Бәдретдин абзыйның торып ыргылган Күчәнгә икенче сугуы кыска һәм каты булды. Ул ике кулын ике якка җәеп күзләрен йомган хәлдә кара җир өстендә яткан Имамга карамыйча гына сабанына карап китте. Куркышып басып торган малайлар аның янына җыелдылар. Лотфулланы аркасыннан сыпырды да әйтте:

—Елама, улым! Тагын тия башласа, минем яныма йөгер. Үгезең ята башласа, торгызырга тырышып та карама—йөгер минем янга. Нужамихнәттән йөрәге бозылган аның. Кыйнарга болашыр инде ул сине, туктый алмас. Тимә малайларга дип, кыйнап та карадылар инде аны—файдасы тимәде. Туң Күчән инде, нәрсә эшләтмәк кирәк аны...

Кичке аштан соң Хәйрулла энесе Лотфулланы алачыклардан ярты

---

* Сабанга каткан балчыкны кырып төшерү өчен ясалган агач саплы тимер калак.

чакрым чамасы ераклыктарак, кояш баешы ягындагы кечкенә калкулыкта эзләп тапты. Лотфулла зур, кызгылт ташка аркасын терәп утырган да, тавышсыз гына күз яшьләрен тыя алмыйча елый иде...

Ташның исеме Хәмбикә ташы. Байтак еллар элек Харис тарханның бер кызы бала чагында шушы яланда, иген иккәндә кинәт кенә авырып китеп, вафат булган. Сабыйга өч яшь тулган гына булган. Әтиләре Харис кызчыкны әнисе белән бергә "ялан күрсәтергә" алып килгән булган. Балага кичтән "жир зәхмәте суккан": эсселе-суыклы булып төнен саташып чыккан да, таң беленеп, кызарып ата башлаган чакта җан тәслим кылган. Дога-өшкерүләрнең дә ярдәме тимәгән. Шул көнне үк сабыйның гәүдәсен юып, кәфенләп шушы калкулыкта җирләгәннәр. Көн эссе булганга, авылга алып кайтуны тиеш дип тапмаганнар. Тирә-як сазлык, болыннарда көтүләре белән йөргән кабан дуңгызлары йомшак туфраклы каберне казымасыннар дип, шушы зур ташны алты үгез белән тарттырып китереп кабер өстенә куйганнар. Ташка гарәп хәрефләре белән ике генә сүз чокып язганнар: "Хәмбикә кыз." Шул елдан бирле халыкта таш—Хәмбикә ташы, ә калкулык—Хәмбикә тавы, дип аталып йөртелә.

Лотфулла шул ташка аркасын терәп, узган елдан калган кылганнар өстенә утырып, ерак офыкка карап елый иде. Абыйсы Хәйрулла да энесе янына утырды. Үсеп балигъ булмаган, кеше мәрхәмәтсезлеге аркасында җаннарын курку биләгән ике малай кояш баешына карап бик озак утырдылар. Икесенең дә башы тулы өметсез, кара уйлар. Офыкта кызыллык сүнеп, җир өстен караңгылык белән бергә җиңелчә генә салкынлык били башлады., көндез кояш нурларыннан җылы алып калган таш, рәхәт итеп аркаларны җылыта. Ә күкрәкләрне кечке салкынлык ала башлады. Абыйсы, инде бөтенләй сүнеп бетеп, офыкта аз гына сизелеп торган кичке шәфәкънең яктылыгына соңгы тапкыр карады да, кулын энесенең кулбашына салды:

—Әйдә, туганым, торыйк. Иртәгә бәйрәм түгел—ял итәргә ятыйк. Ходай ташламаса—яшәрбез. Син иртәгә Бәдретдин бабай белән сөр җирне. Мин абый кеше—Күчәннең үгезләрен куармын. Бәдретдин бабай миңа бер ысул өйрәтте, ничек итеп Имам Күчәнгә каршы торырга. Тик син кешегә ычкындыра күрмә бүген...

Лотфулла инде елаудан туктаган, тик сулкылдавы гына басылып бетми иде әле.

—Ни... нинди ыс-сул ул?—дип сорады абыйсына карап.

—Әгәр Күчән иртәгә, яисә башка көнне миңа карлау белән бәрсә, яисә мине кыйный ук башласа, Бәдретдин бабай әйтә, карлавын тартып ал да үзенә тондыр, ди.

—Олы кешегә сугарга ярамый!

—Бәдретдин бабай әйтә, үзеңне яклаганда ярый сугарга, ди. Китап, хәтта ханга да сугарга рөхсәт итә андый чакта, ди...

—Үтерә бит ул аннан сине.

Хәйрулла энесенең күзләренә туп-туры карады да, пышылдауга күчте:

—Мин, бездән артта килгән үгезләрне куучы Галләметдин белән дә, Жаппар белән дә сөйләштем ул хакта. Алар мине яклап Күчәнгә каршы чыбыркылары белән чыгачаклар. Сәлахетдин белән син дә кил. Бәдретдин бабай әйтә, үзегезне-үзегез якларга өйрәнегез, ди...

—Мин куркам, абый.

—Мин дә куркам. Бәдретдин бабай әйтә, куркудан туктамасагыз, гомерегез буена кыйналып яшәячәксез, ди. Куркак кешегә Күчәннәр табылып тора ул, ди. Әгәр инде Күчән сезне җиңеп кыйный башласа, мин килермен сезгә ярдәмгә, ди. Курыкма!

Лотфулла дәшмичә азрак утырды да, йөрәгендә тәвәккәллек үскәнен сизгәндәй булды. Ризалашып баш какты...

Иртән ике үгезне җитәкләп Лотфулла урынына абыйсы Хәйрулла килде сабан янына. Сүзсез генә агач камытка үгезләрне җигә башлады.

Имаметдин Хәйруллага карап кына алды да, сабан тоткасының кырына кыстырылган карлавын ала башлады.

—Син нәстә эшлисең минем үгезләр белән. Кая булды теге чучка борын? Энең кая?

Хәйрулла күтәрә башлаган камытны җиргә ташлады да, үгез башыннан китеп, аның икенче ягына чыкты. Уң кулында каеш чыбыркысы асылынып тора иде. Аны яхшылап кулына алды.

—Бүгеннән башлап ... мин йөрим синең үгезләрең белән. Бел шуны...

Имаметдин карлавын ук күтәрә башлады:

—Инәңнең ...! Мин синеме-е... ми-инме-е...

Хәйрулла тимер кыршау кебек йөрәген кыса башлаган куркуны җиңеп, аякларын аерыбрак басты да, үгезгә чыбыркы белән китереп сукты. Үгез урыныннан кузгалып читкә китте. Малай карлау тоткан Имам Күчән белән күзгә-күз торып калды. Дулкынланудан карлыккан тавыш белән әйтте:

—Син... артыңа борылып кара! Артыңа-а!

—Нәстә булган артымда-а? Ә-ә-ә!!!

Үгез куучы өч малай, барысы да бер төрле итеп, каеш чыбыркыларының очын җирдән өстерәтеп, тавышсыз гына Күчән Имаметдингә карап атлыйлар иде. Ә ирләр, картлар башларын күтәрмичә, бернәрсә дә күрмичә... сабаннарын көйлиләр...

Һавага күтәрелгән карлау кире төшә башлады. Сүзсез генә үзенә карап атлаган чыбыркылы өч малайны күргәч, Күчән каушап төште:

—Сез нәстә, ә? Олы кешегә? Ә? Сез нәстә? Катыр китәсегез киләме?! Малайлар, малайлар, дим!..

Өч малай ярымай булып тезелеп атладылар да, Имаметдингә килеп җитәрәк өч-дүрт адым кала туктадылар. Хәйрулла ныклы тавыш белән әйтте:

—Без—бай ялчылары. Синеке түгел, Күчән. Тагын бер тисәң бирәребезгә, чыбыркылар белән ярабыз. Бел шуны!

"Юаштан, юан чыга!"—ди татар. Әтисе Балта Зәйнетдингә ошап юаш иде моңарчы Хәйрулла. Тик, энесенең карлау белән сугудан күгәреп, шешеп чыккан аркасын күргәч, Күчәнгә ачуы нык кузгалды. Өстәвенә, Бәдретдин бабай да өстәде шуңа: "Сез бит күмәксез, малайлар! Бергәләп алыгыз чыбыркыга Күчәнне. Куркып тормагыз. Ул бит бер үзе. Явызны көч белән генә урынына утыртып була аны..."—ди.

Имам Күчән үзе бик тә куркак булып чыкты. Алдына-артына тиз-тиз генә карап алды да, акырып җибәрде:

—Үтерәлә-әр! Кара-ау-ул! Үтерәлә-ә-әр! Бәдретди-ин абзы-ый! Шәкү-үр!

Малайлар бөҗраны кыса башладылар. Күчәннең акыруы көчәйде:

—Үтерәлә-әр!

Шул чакта малайлар янына Бәдретдин бабай якынлашты.

—Чү, чү, оланнар! Чү! Олы кешегә чыбыркы күтәрәләрмени?! Хәзер үк туктагыз!

Малайлар туктадылар. Хәйрулла белән Лотфулла Имаметдингә бүре кебек иттереп ачу белән карыйлар иде.

—Таралыгыз, балалар!—диде Бәдретдин бабай.—Башкача тимәс ул сезгә. Янадан тия башласа, тотынырсыз чыбыркыга. Мин кысылам ул чакта...

—Сүз бирсен тимим башкача, дип...

Шул чакта Имаметдинне уратып шаулашкан малайлар артында көр тавыш ишетелде:

—Нәрсә булды? Нигә һаман тотынмадыгыз сөрергә? Нигә эшләмисез?

Шомырт чыбыкларыннан үргән җиңел тарантаска утырган Гапкадыйр мәгъзүм икән. Барысы да шым булдылар. Кайберләре сабаннары ягына таю ягын чамалыйлар иде. Бай барысын да туктатты. Ачулы, кысык күзләре белән барысын да сөзеп карап чыкты.

—Син яшькә барысыннан да олысы, Бәдретдин абзый. Нәрсә булды монда?

Байның өстендә тезенә кадәр төшеп торган җиңел, кара төстәге, утыртма якалы бишмәт. Кара чалбар, читек-кәвешләр. Башында түгәрәк, кара төстәге кырма бүрек. Кыска иттереп китәрелгән сакал-мыегы килешле булып тора. Тик аскы ирене азрак калын һәм ул алгарак чыгып торганлыктан азрак йөзенең төсен боза кебек.

Бәдретдин абзый баскан урынында аякларын кузгаткалап алды.

—Ни бит әле, мәгъзүм! Монда азрак кына аңлашылмаучанлык килеп чыкты кебек...

—Нәрсәдән тагын?

—Имаметдин бер малайга... э-э-э... карлау белән... э... селтәнгән иде... әй-йе, селтәнгән иде, малайлар каршы тора башладылар... Малайлар... әй-йе...

Байның күзләре алара башлады:

—Кем башлады?

—Э-э... Имаметдин шул. Ул... Кичә Лотфуллага карлау белән...

—Мин аны сорамыйм синнән, картлач. Малайларның кайсысы беренче булып башлады дип сорыйм мин синнән. Аңгыра баш, шуны да аңлый алмыйсыңмыни?

—Мин үгезләр артындаем, анысын күрмәдем мин.

Бай бер өер булып басып торган малайларны ачуы чыккан күзләре белән бетереп карады:

—Кем беренче булып кул күтәрде, Имаметдингә? Ә?

Малайлар куркуларыннан дәшә дә алмадылар.

—Барыгызны да куып чыгарганны көтәсезмени? Кайсыгыз башлады?

—Хәйрулла башлады,—диде Имам Кучән.—Ул атаманнары. Әнә кызыл чәчлесе.

Бай күзләре белән эзләп Хәйрулланы тапты:

—Син башладыңмы беренче булып?

Хәйрулла байга күтәрелеп карамады, җавап бирмәде. Куркуыннан эченә салкын йөгерде. Байның ачуы кузгалды. Ул Хәйруллага табан атлады. Исәбе әллә сугуда иде инде.

—Килмә, бай, якын!—диде малай. Әтиемнең дә тырнак белән дә чирткәне юк миңа. Суктырмыйм мин синнән дә.

Бай барысын да бер тапкыр карап чыкты да, тыныч тавыш белән әйтте. Үз көчен белеп:

—Мондый ялчының миңа кирәге юк. Кит, югал күз алдымнан. Куам мин сине эштән.

Борылып тарантасы янына китте. Утыра-утыра сөйләнде:

—Үз гомерендә башкача миңа ялланырга дип килеп тә йөрмә. Алмаячакмын мин сине...

Кучеренең аркасына төртте:

—Кузгал! Нәрсә утырасың кукраеп...

* * *

Хәйрулла ерак яланнан кичләтеп кенә җәяүләп өйләренә кайтып житте. Исәнләште дә, чишенә башлады. Әнкәләре, нәрсәдер сизенгән күзләре белән улына карап-карап алды да, борчылган тавыш белән сорады:

—Вакытлы-вакытсыз ни эшләп кайттың әле син, Хәйрулла?

Ишек төбендәге түмәргә чабаталарын салырга дип утырган малай башын күтәрмичә генә җавaплады:

—Гапкадыйр бай мине куды ялчылыктан.

—Эй, Ходай-йы-ым!—диде ана.—Нәстә өчен инде тагын?

—Имам Кучән Лотфулланы кыйнады. Карлау белән бәреп тә, аяклары

белән типкәләп тә. Үгезе яткан өчен. Лотфулланы мин алмаштыргач, икенче көнне мине дә кыйнарга итте. Мин кыйнатмадым үземне. Малайлар белән җыйналып үзен чыбыркыларга иткән идек, өстебезгә бай килеп чыкты да...

—Соң?

—Кем башлады, дип сорады да...

—Шуннан?

—Мин башлаганны Кучән әйтте дә, шуннан бай куды инде мине...

—Әй, иллаһы-ым кәри-им! Синдә дә биатай каны икән болай булгач. Нигә генә дәшмичә үткәреп җибәрмисеңдер инде-е! Читкәрәк йөгереп кенә китсәгез булмыймыни инде-е. Ничекләр генә иттереп сезнең тамакларыгызны туйдырыйм инде ми-ин?!

Матчага кыстырган тал чыбыгын үрелеп алды да, түмәрдә утырган улының аркасына ике тапкыр чажылдатып сыдырды:

—Менә сиңа-а, менә сиңа!

Сәкедә куркып карап утырган алты яшьлек Абдулла белән өч яшьлек Галимулла икәүләп такмаклап елый башладылар:

—Абыйга тимә-ә! Тимә абыйга-а!

Унбер яшьлек Гатаулла белән сигез яшьлек Фазулла абыйларын ике яктан кочаклап алдылар. Болары еламыйлар иде. Нужа, фәкыйрьлек баскан ана абыйларын кочаклаган малайларга берәрне сыдырды да, чыбыгын сәкегә ташлап өйдән чыгып ук китте. Өй эчендә дүрт малай абыйларын кочаклап торып калдылар.

—Еламагыз, елама!—диде Хәйрулла малайларны башларыннан сыйпап.—Әни кеше шулай була инде ул. Безне бит ашатырга кирәк аңарга.

Шул чакта өй ишеге ачылып китте дә, анда әтиләре күренде. Кабаланмый гына түгәрәк бүреген салып, ишек яңагындагы чөйгә элде. Бишмәтен салып аны мич арасына кертеп элде. Билбавын җиң эченә тыкты. Дәшми генә ишек төбендәге икенче түмәргә утырып чабатасына үрелде. Салырга дип. Гатаулла белән Фазулла идәнгә тиз генә тезләнеп аталарының чабаталарының киндерәләрен чишә башладылар. Әтиләре ярату мөлдерәп торган коңгырт күзләре белән малайларын барлап чыкты. Алты малайлы Зәйнетдин авылдагы барлык ирләр арасында да бае, иң бәхетлесе иде. Аның шулай икәнен ул үзе дә белә. Үзен уратып алган малайларының кайсысының башы кызыл, кайсысының башы сары чәчле иде. Араларында бер генә кара чәчлесе юк. Аллага шөкер, ярлылык, ашарга житешми дип тормыйлар—тупырдашып үсеп киләләр бит әле алар. Ходайга мең шөкер, исән-иминнәр, кул-аяклары барысының да үз урыннарында. Зур улына карап әйтте:

—Солтый Латыйфын күрдем мин. Әле генә. Ул әйтте байның сине ялчылыктан куганын. Аллага шөкер, әтигә ошап син дә ныклысың. Шулай бул! Минем кебек юаш булмагыз берегез дә. Әнкәңә үпкә тотма! Ана бит ул сезнең барыгызга да. Дөньяга китереп тапкан, күкрәк сөтен имезгән, караган сезне моңарчы. Моннан соң да караячак. Әйбәт анагыз. Тик менә нужа бик нык басты безне. Йөрәге чыдамый әниегезнең фәкыйрьлектән, юклыктан. Чыбыкка да шуңа күрә үрелә ул.

Урыныннан торып тас белән комган торган мич арасына үрелде дә, аларны ишек төбенәрәк этәрде. Малайлар арасында Ак Бөжи исеме алган дәшмәс малай Абдулла комганны башкалардан алдарак эләктереп алды. Тас янына басып әтисенең кулына су салырга әзер иде инде ул. Иренең кайтуына әниләре комганга җылы су салып куйган. Битен, кулларын юа-юа әтиләре үзенең уйларын Хәйруллага җиткерде:

—Ялчылыкка башкача бармассың. Үзем белән балта эшендә йөрерсең. Янгырчы авылындагы Корманай Кордаш өй бурасы буратырга яллады мине. Бүрәнәләрен кичә барып карап кайттым. Юан түгелләр. Үзләренең урманыннан гына кисканнәр. Нечкә башларыннан күтәрергә синең дә көчең җитәрлек, көч утырткачы, дим. Иншалла, эшләрбез, улым, яшәрбез...

Зәйнетдин Балта кулларын тастымалга сөртте дә, көлемсерәп улы Гатауллага ымлады:

—Чыбыгын алып кыстыр әнкәңнен, кире матчага. Берничә көннән тагын кирәге чыгар. Сезне шул чыбык белән тәртиптә тотмасаң, айй-һа-ай! Алтаусыз, бит!

Чыбык урынына кыстырылгач, иң кечкенәләре Галимулла телгә килде:

—Әт-ти!—диде сабый куанып.—Әни азыйны мәэмәй итте. Мине мәэмәй итмәде, Ак Бөжи абыйны да. Фазулла абыйны, Гатаулла абыйны да...

—Шулаймы, улы-ым!—дип аркасыннан сөйде кызыл башлы төпчеген Зәйнетдин.—Тыңласаң, мәэмәй итмәс әниең. Тимәс берегезгә дә. Сине бигрәк тә ярата ул.

Ата кеше шатлык тулы күзләре белән малайларын тагын бер кат карап, барлап чыкты: Хәйрулла, Гатаулла, Фазулла, Абдулла, Галимулла. Тик әллә кайларда киң дала жирләрендә үгез куып йөргән Лотфулла гына өйдә юк иде. Фазулла белән Абдулла әниләренә ошап сары чәчлеләр, сыек зәңгәр күзлеләр. Ә инде Хәйрулла, Гатаулла, Галимулла үзенә ошап бакыр төсендәге чәчлеләр, коңгырт күзлеләр. Ходайның кодрәте кин—кызыл, сары чәчле малайларының барысы да шәпләр. Бигрәк тә табынга утыргач, ашауны булдыралар. Әниләре салып кына өлгерсен...

Шул ялланудан солдат хезмәтенә киткәнче Лотфулла тугыз ел буена ел әйләнәсенә Гапкадыйр байда ялчылыкта йөрде. Язын, көзен өч ел үгез куганнан соң бай аны атлы эшкә күчерергә кушты. Мал абзарларыннан тирес түкте, язын-көзен яланга чәчәргә капчыклап арыш, бодай ташыды. Биш потлы капчыкларны аркасына салып Агыйдел пристанендә баржаларга бодай төяде. Уналтысы тулганда, ирләр белән ярыша-ярыша печән чапты. Озын саплы, дүрт япьле озын саплы агач сәнәк белән кибәнгә печән ыргытты. Көлтә ташыды. Мал карады, үгез көтүе көтте. Үсә барды, ашау ягы байда бик әйбәттән булмаса да, ныгыды, көч утыртты. Инде унсигезен тутырып, унтугызга киткән чакта озын буйлы, киң җилкәле, киң күкрәкле, көче ташып торган зәңгәр күзле, сары чәчле бер егет иде Лотфулла.

Эстәрле елгасы ярында барлык Тукаевлар өчен уртак булган Кала Утлары дигән бер урын бар. Ул Утар Эстәрлетамак пристаненә унбиш чакрым кала Эстәрле елгасының сул як ярында салынган. Утар, Тукаевлар биләгән жирләрнең читенә, борынгы Бохара-Болгар юлы узган жиргә урнашкан, Эстәрле елгасы аша салынган күперне чыгып ярты чакрым барсаң, шул юлга барып чыгасың. Әкияттәге кебек, сулга китсәң—Эстәрлетамак каласы, уңга китсәң—Эстәрлебаш, аннан соң, ерак далалар узгач мәшһүр Бохара. Ә инде туры китсәң, кыргыз-кайсак жиренең читенә илтеп салынган урыс крепосте Оренбург була. Менә шундый урында урнашкан Утар ул. Анда инде Тукай бабай нәселеннән барлыкка килгән ишан-ахуннарның, сәүдәгәрләрнең, мәдрәсә мөдәррисләренең һәм эрелеваклы хәлфәләрнең мал асрау һәм ашлык саклау урыны. Тукаевларның жир биләмәсе исә киң яланнарда бер якка егерме биш чакрым, икенче якка унбиш чакрымнарга сузылганнар. Ул яланнар, алда әйтелгәнчә, болгар бабайлар заманыннан ук Кара Балыклы яклары дип йөртеләләр. Шул Тукаевлар биләгән жирләрдә бер генә авыл да юк. Кола ялан гына. Анда алар иген үстерәләр, иксез-чиксез санда мал асрыйлар. Киң яланнар дала булып, кап-кара туфраклы жирдән торалар. Көзен бу яланнарда арыш, бодай, борай, арпа, тары, солы өлгереп зур уңыш бирә. Ел саен Тукаевлар жирендә көн-төн эшләгән ялчыларның, көнлекчеләрнең исәбен алсаң, игеннең уңганлыгына карап, аларның саны ике меңгә кадәр житкән чаклары була. Уракчылар, чалгычылар, көлтә бәйләүчеләр, ат-үгез жигеп көлтә, печән ташучылар, кибән-эскертләр салучылар, көтүчеләр, баржаларга иген төяүчеләр—бар да шул исәпкә керә. Күпчелеге—иген өлгергән чакларда көнлекләп ялланып эшләүчеләр. Болар инде урак, чалгы белән ике ай чамасы гына эшлиләр дә, аннары тиешле акчаларын кулларына

алып кайтып китәләр. Алар инде Эстәрлебашның ярлы-ябагае, Куганакбаш кешеләре, Хәлкәй, Әмир, Карагыш, Гөлем мишәрләре, Айдәрәле, Янгырчы Турмайдан чыккан ялчылар, Мәкъсет, Мортаза, Ибракай, Югары, Урта, Түбән Калкаш, Баем башкортлары. Дим елгасына барып коя торган Тәтер суының урта агымында утырган Тәтер Арслан авылы татарлары гына Тукаевларга да, башка байларга да ялчылыкка чыкмыйлар. Бу авылның кайбер кешеләре кырык тартмачы булып, авылдан авылга ат белән дә, бәләкәй арба тартып йөреп тә вак сәүдә белән шөгыльләнә. Араларында Ырынбур, Бохарага йөреп сәүдә иткәннәр дә бар. Тик күпчелеге ташчылар, балта осталары, чабата ясаучылар, көянтә, дуга, ат чанасы табаны бөгүчеләр. Барлык тирә-як авыллар белә—Тәтерләр арба, чана ясыйлар, шомырттан бик матур иттереп тарантас үрәләр, су тегерменәнә коры куласалар ясыйлар. Тәтерләр һөнәр ияләре һәм ... бик тә гыйлем яраталар, күпләп-күпләп мәдрәсәдә ятып укыйлар.

Үстергән игенне, иң беренче чиратта бәясе кыйммәт йөргән каты бодайны ат белән Эстәрлетамак пристаненә ташыйлар. Шунда Агыйдел суы белән Уфа ягыннан килгән зур баржаларга төйиләр. Баржаларны Агыйдел белән Кама елгасына, аннан соң мәшһүр Болгар елгасы—Иделгә чыгаралар. Идел белән борынгы болгар каласы Сары Чингә алып барып житкерәләр. Казан ханлыгын юк иткәннән соң урыслар, үзләре дөрес итеп әйтә белмәгәннән, ул каланы Царицын дин атап йөртә башлаганнар.

Тиешле сөйләшү буенча, ул каты бодай тагын олаулар белән Сары Чиннән Дон елгасына чыгарыла, аннан баржалар белән Ростов каласына ташыла. Шунда диңгез корабларына төяп, Италия иленә озатыла. Чөнки Тукаевлар жирендә үстерелгән каты бодайга итальяннар бәяне яхшы түлиләр икән. Һәм каты бодай шул итальян дигән халыкның яратып ашаган макароны спагетти ясарга бик кулайлы икән. Нindирәк ризык икән ул ыспагит дигәннәре дип, бер елны Гапкадыйр мәгъзүм шуны өч зур катырка тартма белән үзенә дә кайтарткан иде. Шул ыспагит дигәннәре чәнти бармактан нечкәрәк, ак тирес кортына охшап торган бер озынча тәмсез генә бер нәмәстәкәй икән. Асыл бодай онынннан да шундый авызга алмаслык ризык ясап була икән?! Итальян дисәң, итальян инде! Акчасы күп, куярга урын тапмаганнан шундый ыспагит дигән чеәүчен ясыйлардыр да инде. Кая ди инде аларга безнең бодай онынннан жәеп, кисеп ясалган токмачны күрү. Безнең татардагы кебек тәмле токмачлы аш бер генә башка халыкта да юк инде ул. Һәм булмас та, иншалла! Ашсуга безнең татар хатыннары кебек башка халыкларда хатыннар юк һәм булмас та! Италиянең үзеннән ыспагит кайтартып ашап караган тархан Габделкадыйр Харисович Тукаев токмач ашаган чакларында һәрчак шулайрак уйлый. Ә токмачны тәүлегенә бер генә булса да ашамый калмый ул. Димәк, көн саен шулай уйлый һәм уйлаячак та!

Унжидесе тулганда Лотфуллага ирләр ала торган хакны түли башладылар. Чөнки ул инде ирләр эшли торган барлык авыр эшләрне дә алардан калышмыйча бертигез итеп эшләргә өйрәнгән иде. Бер елга батраклыкта ул алган хак бер кием тула оек, өч пар киндер чолгау, берсе сатин, берсе ситсы ике күлмәк, ике чалбар, егерме биш тәңкә акчадан гыйбарәт иде һәм ашау байдан.

Лотфулланың куларты жинел булды. Унөч-ундүрт яшьләре тулу белән энеләре дә бер-бер артлы ялчылыкка чыга башладылар. Хәйрулланы бай куып кайтарганнан соң, малайларын ялчылыкка бирергә дип барганда, Зәйнетдин Балта аларның чәчләрен кырып (кызылы, сарысы күренмәсен!) аларга яңа чабаталар кидереп алып барды. Чөнки кызыл, сары чәчле малайны байның алу-алмавында шиге бар иде. Бай ул, бай бит инде! Бар да аның үз кулында. Авыл байлары арасында иң бае, иң кенә куганы, иң мәкерлесе Гапкадыйр мәгъзүм икәнен бөтен авыл белә. Юаш булып кыйланырга ратса да, саранлыгы, комсызлыгы, усаллыгы белән авылда гына түгел, бик ерак-ерак жирләргә дә кара даны таралган кеше иде Гапкадыйр мәгъзүм. Атасы Харистан мирас булып калган тархан исеме

дә бар өстәвенә. Кирәк дип санаган чакларында барлык җирдә ул дәрәҗәсен китереп тыга белә. Байлыгын, үҗәтлеген, тарханлыгын кулланып үзенә кирәкне эшләмичә калмый.

Көтмәгәндә генә эче китеп Кучере Солтый Латыйф Кала Утарында авырып ятып калды. Гапкадыйр мәгъзүмне Лотфулла Эстәрлегә алып кайтып бара.

Кара бия җигелгән җинел тарантас юл тузаны кузгатып авыл ягына тәгәри. Юл такыр, Кара бия көр, юыртуы күнелле. Келтер-келтер тавыш чыгарып тәгәрәгән тарантас тәгәрмәчләре ниндидер монсу, бетмәс-тәкәнмәс уйлар тудыралар. Акрын гына исеп-исеп алган тымызык, җылы җил иренеп кенә кай тарафкадыр күчмә ак болытларны куа. Сайрый-сайрый бер-бер артлы җирдән текә итеп күккә күтәрелеп киткән язгы тургайлар, үзләренә тиешле дип санаган бер биеклеккә менеп җиткәч, җепкә асып куйган кебек шунда тукталып, канатларын тиз-тиз иттереп җилпеп, тирә-якка күнелле, моңлы ямь сибеп сайрапмы сайрыйлар. Табигатьтә Ходай тарафыннан билгеләнгән һәр җан иясенең үз урыны бар. Шулар арасында сайрар кошлар кебек асыл җан ияләре юктыр! Ул тургаен әйтәсенме, ул сыерчыгынмы? Сандугачны әйтеп тә бетерерлек түгел инде анысын!

Кайтыр юлда урысларның Конный Хутор исемле авылларын чыккач, юл кыска гына, сөзәк калкулыкка үрмәләде. Лотфулла атны юыртудан атлауга күчерде дә, һавадагы тургай-кошларны тыңлап, үзенең ялчылык уйларына бирелеп, онытылып бара башлады. Атның җайлап кына атлавы аны оетып җибәрде. Тик ул көтелмәгән тавышка сискәнеп китте. Тавышка колак салды да, гаҗәпләнде. Акрын гына, үзенә күрә моңлы тавыш белән... Гапкадыйр бай җырлый иде.

Акрын гына искән таңгы җилләр
Алып килә кошлар тавышын.
Шулар белән бергә кушып тыңлыйм
Күл буйкайларының камышын.

Бай җырлый! Гомере буена мал артыннан, байлык артыннан куып кырысланган бай йөрәгендә дә моң бар икән ләбаса! Моңая бит җырлап!

—Лотфулла!

—Нәрсә, мәгъзүм абзый?

—Син җырлый беләсеңме?

—Юк бит, белмим бит. Кеше ишетмәгәндә генә, кай чакта гына, үзем өчен генә дип җырлаштырам алай да...

—Ни эшләп алай инде? Үзең өчен генә.

—Безнең нәселнең моңы юк, ди безнең әти.

—Ә-ә, алай икә-ән.

Бераз сүзсез бардылар.

—Ә Солтый Латыйфы бик моңлы җырлый. Моңлы ул.

—Аның энесе Биктаһир да җырлый бик матур итеп.

—Җырлый белсәң, үзеңне күчерлеккә алыр идем. Латыйф абзыйның колаклары нык катыланды. Әйткәнне тиз генә ишетми. Кычкырырга туры килә. Ә мин, үзең беләсең, кычкырып сөйләшә белмим. Мине атлар карарга гына куй, ди миңа әйтә.

Лотфулла җавап итмәде. Азрак баргач, бай тагын дәште—кәефе сөйләшүне тели иде, ахрысы.

—Нигә дәшмисең. Алсам, утырасыңмы күчерлеккә?

—Юк, мәгъзүм, утырмыйм.

—Нилектән?

—Күчер булу ошамый миңа. Ялагайлана, яраклаша белмим. Кан тартмый нилектәндер. Яраклашып яшисем килми.

—Ә бабаң Әбеннәгыйм гомере буена күчер. Ул яраклашып яшәдемени?

Байның тавышыннан сизелә—көлемсери иде.

—Минем бабай, иң беренчедән, яхшы ат белгече бит ул. Икенчедән, чын ир-егетләрчә фикер йөртә белә. Шунлыктан яраткан да аны синен әтиең Харис хәзрәт. Хөрмәт иткән. Алар икәү сүз берләшеп, Эстәрлетамакны чыккач Уфа губернаторын узып киткәннәр берничә мәртәбә...

Гапкадыйр мәгъзүм көлеп куйды. Тик Лотфулланың сөйләгәнен үзенчә борды:

—Тархан кеше шундый булырга тиеш тә инде ул. Губернаторны да узып китәргә тиеш. Губернаторны узып китү кучер эше түгел, тархан эше...

Азрак дәшми баргач өстәде:

—Сиңа да дәрәҗә эләкте бүген. Тархан Гәбделкадыйр Харисович Тукаевның үзен алып кайтып барасың.

Лотфулла дәшмәде. Үрне менеп җиткәннәр иде. Дилбегәне каккалап, атны юыртуга күчерде. Дуга астындагы ялгыз кыңгырау юыртуга күчкәнгә куанып, матур иттереп чыңлый башлады. Алда урысларның Николаевка исемле зур авыллары күренде. Бераз баргач авылга килеп керделәр. Унлап йортны узгач, юлдан сул якта, кечкенә калкулыкны биләп утырган ак төстәге, башында зур тәреле чиркәүне үтеп киттеләр. Уң якка кыйшайган, урамга караган ике кечкенә тәрәзәле, каралган салам башлы йортка житә башладылар. Шул чак ватык капкадан керләнгән озын киндер күлмәк кигән, чәче-башы тузган, картая башлаган бер маржа чыгып, капкасы төбендә туктады. Кулында кыршауланган олы чиләк иде. Килүче атлы тарантаска чайкала-чайкала карап тора башлады. Шул йортны узгач, Эстәрлегә бара торган юл унга борыла иде. Лотфулла атның юыртуын азрак баса төште. Тарантас капка турысына килеп житкәч, маржа чиләккә икенче кулы белән дә ябеште дә, аны һавада селтәп эчендәге көлне тарантаста утырган Гапкадыйрга каратып сибеп җибәрде:

—Татарва-а е...я-я-я! Н-на, пол-луч-ча-ай!—дип акырды маржа.— Катает-с-са-а тут с бубенцами-и! Жри, сволоч-чь!!!

Селтәнгән жиреннән торып кала алмады, маржа юл читендәге пычрак чокырга алды белән лапылдап барып төште. Киндер күлмәге артка кайтарылып китте. Ыштан да кимәгән маржаның "барлык байлыгы" күренеп ята иде. Тарханның өстен соры, кара төстәге көл уратып алды. Авызына-борынына көл тулды. Ярый әле күзен йомып өлгергән иде.

Лотфулла кузладан сикереп төште. Чыбыркысы белән селтәнде, тик хатын кеше бит, дип уйлап өлгерде, сукмады. Дүртаяклап мүкәйләгән маржа акыра-акыра торырга азаплана иде. Ләкин ул лаякыл исерек иде, аягына баса алмады.

Урысларның Николаевка исемле авылында зур гауга куптарды тархан Гәбделкадыйр Харисович Тукаев. Иң башта Лотфулланы җибәреп, авыл старостасын китертте. Аңардан бөтен авыл халкын жыйдыртты. Эш вакыты булуга карамастан, жыелган халыкның күпчелеге салмыш иде. Көне бәйрәм дә түгел бит әле аның. Күкрәгендәге зур, жиздән эшләнгән түгәрәк медален соткалый-соткалый, старосталык иткән карт урыс биленә житә язган яртылаш чал сакалын жиргә житкәнче селки-селки баш иеп тарханны "майларга" тырышты. Авыл халкы исеменнән гафу үтенде. Тырышып-тырмашып татарчалап сөйли бирде:

—Аграфена, карт жүләр... Аракыны күп эчкән. Ире эчеп үлгән, балалары алтау. Ашарларына да, киярләренә дә юк. Начарлык эшләде инде сезгә. Тик аны гафу итегез инде. Бик ярлы бит...

Тархан чыгырыннан чыккан икән. Җыелган, куркуыннан тып-тын калган урысларга карап та тормады. Старостага әйтте:

—Миңа тарханлык Русия патшасы тарафыннан бирелгән. Сез миңа көл сибеп патшадан көлдегез бүген, аның тарханыннан гына түгел. Мәсхәрә иткәнегез өчен миңа йөз сум штраф түлисез. Акчалата. Түләмәсәгез, губернаторга барып, мин сездән биш йөз түләтәм. Бу хатынны төрмәгә яптырам, ә сине старосталыгыннан кудыртам. Авылыңда тәртип тота белмәгәнең өчен. Бүгенге көн белән өч көн көтәм дә, аннан соң губер-

наторга прошение белән китәм. Урыслар дип губернатор сезне якласа, Санк-Питербурхка барып, патша галиҗанәпләренә тапшырачакмын прошениене. Үзем кертеп бирәчәкмен.

Мин—тархан Тукаев. Император Александр-фтаруй бирде безгә тарханлыкны. Катыр атправим...

Тархан тарантасына менеп кунаклады да, старостага ачулы карашын ташлап, кучеренә кузгалырга боерды. Староста аның карашыннан гәүдәгә бәләкәйләнде, картузын салганын үзе дә сизми калды. Ирләрнең барысы да баш киемнәрен салдылар, марҗалар тавыш чыгарып улый башладылар.

—Ку, Лотфулла!—диде бай.—Мин синең урынында булсам, каеш чыбыркы белән марҗаның ыштансыз күтенә берне сыдырган булыр идем. Шәп ачылып киткән иде бит. И-эх, си-ин, ... Лотфулла-а...

—Хатын кешегә сугарга, марҗа булса да, кул күтәрелми бит, мәгъзүм...

—Шундый инде без, татарлар. Кул күтәрелми, имеш... Шунлыктан безнең татар тарханнарына исерек марҗалар көл сибәләр дә инде. Бу кадәр мәсхәрәгә нәрсәгә миңа аларның йөз тәңкә акчалары. Авылда бу хәлне сөйләмә. Үзең дә оныт. Ишеттеңме?

—Ишетүен ишеттем лә ул. Тик барыбер килеп җитәр инде ул авылга.

—Җитүен, җитәр. Тик синнән, миннән чыкмасын. Ә акчаларын каерам мин аларның барыбер...

Тарантас борылыштан сулга каерганчы урыслар баскан урыннарыннан кузгалмыйча карап калдылар. Шуннан соң гына берсе авыр итеп көрсенде:

—О, господи, господи! Грехи наши тяжкие!

Икенчесе ачу белән өстәде:

—Ивана Грозного нет на них, на вонючих. Дворянами стали. Куда цари-то русские смотрят, ... твою мать!!!

Икенче көнне иртә белән Лотфулла хәл белергә, дип Мирсәет Учител янына, урыс ышкулына керде. Җае чыккан саен ул аңардан урыс китаплары, гәҗитләре алгалый иде.

—Әйдүк киләсен, Лотфулла!—диде Мирсәет Учител елмаеп.—Менә тагын бергә җыйналдык. Карале, кем утыра монда!

Мирсәет күрсәткән кеше Хәйдәргали хәлфә иде. Ике куллап исәнләштеләр. Әтисе янында тыныч кына, дәшми утырган малайны да таныды Лотфулла:

—Бу малай бәләкәч Мирсәет бит!—диде ул кулын сузып. Малай Лотфулланың кулын кыскандай итте, үзе кып-кызыл булып кызарды. Зурлар кул бирә бит!

—Нәкъ үзе!—диде Хәйдәргали хәлфә.—Мирсәет улым. Тик нигәдер үсеп китә алмый. Башы үсә тагын үзенең. Инде минем бүрекләр генә ярый башына. Нигә дәшмисең? Әллә танымыйсыңмы Лотфулла абзаңны, ә?

—Таныйм,—диде малай тартынып кына.—Башкорт авылына киткәндә озатканые безне.

Хәйдәргали хәлфә Лотфулланың аркасыннан кулы белән кагып сөйде:

—Илләмә чибәрләнеп егет булгансың син, Лотфулла энем. Көч-гайрәт ташып тора. Сөбханалла! Күз тимәсен үзеңә. Ничекләр итеп көн күрәсең?

—Байда инде. Ялчылыкта. Безгә тагын нәрсә кала инде.

Бүлмә эчендә авыр тынлык урнашты. Лотфулла елмайгандай итте. Тик елмаюы моңсу иде.

—Шула-ай, энем!—диде Хәйдәргали абзый аңарга карап.—Ярлыга шул ялчылык та, зимагурлык кала инде. Урыс әйтмешли: "Хода нет!"

Улы Мирсәеткә ымлады:

—Менә мин малайны мәдрәсәгә китергән идем. Урысчага да бирергә идем дә, Учител бик үк риза түгел бит әле. Малайны гәүдәгә бик ябык, бәләкәй, ди. Бер үк вакытта мәдрәсәдә дә, урысча да укып өлгерә алмас,

ди. Йончыр, ди.

—Мин каршы түгел лә ул,—диде Мирсәет Учител.—Тик малаеның язгы йончу ат кебек күтәртеп куюы бар. Көче житмәс, диюем. Шул хакта уйла син, Хәйдәргали абзый. Аннан соң бит, аңарга яшәү урыны кирәк, ашарга кем кайгырта, кем әзерли. Мәдрәсәдә, шәкертләр арасында, ятып укуга чыдамас, бәләкәй әле. Син гаиләң белән Шипайда, ә бу бала япаялгызы монда. Шуны да уйла син.

—Мин Гали хәлфә белән сөйләшкән идем инде. Минем малайны үзендә яшәтеп тотарга риза ул...

—Теге Чишмә урамындагы, кыргыздан чыккан хәлфәме ул?

—Шул үзе.

—Ул синең малаеңны карый алмас. Аңарга ышанып бирмә.

—Нигә алай дисең?

—Сәбәбен әйтеп тормыйм. Тик кеше баласына тәрбия бирә торган кешеләр түгел алар. Үзе дә, хатыны да. Мин сиңа икенче кешеләрне әйтим. Менә монда, Яр башы тыкрыгын төшкәч тә Хәсәнша бабай белән аның карчыгы Тайбә әби торалар. Миңа әйтеп куйдылар, ипле генә ата баласы бер шәкерт кертер иде кышкылыкка диләр.

—Нindирәк кешеләр соң алар?

Лотфулла телгә килде:

—Мин беләм аларны. Безнең су агышы белән күршеләр алар. Бик әйбәтләр. Базардан туңмай сатып алып, шуны эретеп кадаклап саталар. Балалары булмаган. Без малай чакта аларга сызык ашарга йөгерә торган идек. Кардан, яланаяк, кемузардан. Энекәшләр әле дә йөриләр сызык ашарга дип. Сызыкны иң яратканнары Фазулла белән Абдулла инде...

Хәйдәргали хәлфә азрак уйланып торды да, Лотфуллага карады:

—Әйдә, барыйк әле шуларга. Сөйләшик. Бәлки Мирсәетне шуларга урнаштырып булыр.

Хәсәнша карт белән карчыгы аларны ачык йөз белән каршы алдылар. Самавыр янында утырып сөйләштеләр. Әбисе сүзгә катнашмыйча чәй ясап, тыңлап кына утырды. Сөйләшүне Хәсәнша карт алып барды.

—Ризалашсаң, яшәр малаең, энем Хәйдәргали. Айга бер пот бодай оны, бер пот арыш оны. Ипигә, токмачка, умачка дигәндәй инде алары. Аннан, аена тагын бер капчык бәрәңге. Бер кадак тоз. Маен, итенхәлеңнән килгәнчә китерерсең. Бер дә китермәссең дип уйламыйм. Әйе. Ике чана утын. Имәне, каены күбрәк булсын, диюем. Аннан соң, аена бер тәңкә дә илле тиен көмеш акча инде. Болар күп сорау түгел—син ризалаш инде, Хәйдәргали. Карчык белән безнең башкача килер урын юк. Ике ел элегрәк бер башкортны тоткан идек, тик игелеген күрә алмадык. Ит китергәләде атасы. Шуның белән, вәссәлам! Бит сыпырып калдык. Онны сезгә түгел, үзебез дә күргәнебез юк, без башкортта иген чәчелми бит, ди. Син татар шуны да аңламыйсың, дип келә әле ул өстәвенә. Ике кыш йөреде дә мәдрәсәгә малае, хәреф танудым инде, дип башкача килмәде. Анысына Аллага шөкер иттек.

Ризалашсаң, улың караулы булыр. Карчык өстен-башын юар, ямар. Ямаулыгын рәтләрбез. Безнең карчык белән башкача килер жир юк. Картлык көнебездә карарга Ходай бала-чаганы насыйп итмәде. Ялгызлыкта үтә гомеребез карчык белән. Утын кисәләр, кар көрәштерер кышларын. Уйнарга күршедә Зәйнетдиннең малайлары житәрлек. Үзләре шаяннар, шәпләр, кешелекле балалары күршенең. Хәсәнша бабай дип, күрсәләр әллә каян исәнләшеп киләләр. Йомыш-юлга йөгереп кенә торалар. Синең малаең кебек Фазулласы бар, аннан соң Абдуллалары...

Мирсәет Хәсәнша бабайларда жиде ел яшәде. Кышын аларда торып укыды, жәйгелеккә башкорт авылы Шипайга кайтып китте. Жәй буена әтисе белән кыр эшләрендә булды. Печән чабу, иген игү, көлтә ташу, кышкылыкка утын әзерләү эшләренең төп авырлыгы Мирсәет жилкәсенә төште. Эшкә өйрәнде, малай чагында ук көч утыртты.

Гәүдәгә бик тиз үсеп китә алмаса да, укуга Мирсәетнең сәләте

зурдан булып чыкты. Үзе бик хәрәкәтчән, тиз уйлаучан һәм бик тә тәвәккәл малай булып үсә башлады. Ул Хәсәнша бабайларда яши башлаганнан бирле, аларның капка төбе малайлар җыйналып уйный торган бер урынга әйләнде.

Яз җитеп карага басканнан алып, мәдрәсәдә шәкертләр таралып киткәнче капка төбе малайларның уенынннан шау-гөр килә. Мәдрәсә шәкертләре авылларына таралгач кына капка төбе кара көз килгәнче тынып кала, үлән үсә башлый. Чөнки башка авыл шәкертләре кебек, Мирсәет тә Күндерәк елгасы буендагы Шипай авылына кайтып китә. Ә инде язгы кояш җирдәге карны ашап бетермәс борын ук капка төбе тагын җанлана. Язгы сулар китеп, капка төбе азрак кибә башлау белән Мирсәет анда шаралы уенын оештыра. Капка төбенә Зәйни Балтаның берничә малае (әниләре эш кушып өлгермәгәннәре), Таш Күпер янында яшәгән Гыйззәтулла Пәрәүнең Хәйрулласы, Гобәйдулласы, Сибгатулласы, йорты тыкрык эчендә утырган Галиәхмәт байның Әхмәдулласы, Ясаклы урамыннан сакау Фәхретдине җыелалар. Барысы да шара суга торган таяклар, кәшәкәләр күтәргәннәр. Алар җыелып бетәр-бетмәстә уен оештыручы Мирсәет күренә. Шара уены башланганчы алар кар эрегән чакларда үзләре өчен дә, мәчет картлары өчен дә кызык ясап алганнар инде...

Карлы бураннарны куып яз килә. Кояш җылыта башлап, карлар эри. Кар астына су төшә. Җомга көнне авыл картлары җомга намазына бара башлыйлар. Шул чакта Мирсәет, Фазулла, аларга койрык булып тагылган, көннәр буена сөйләшмичә яши белгән Ак Бөҗи Абдулла бер көрәк тотып Мөхәммәт Шакир мәгъзүмнең мәчеткә киткәнен сагалыйлар. Мәгъзүм каршысында урам аша гына яшәгән, аның адашы Шакир бай йортының мөешеннән генә муеннарын сузгалап карап, мәдрәсә мөдәррисенең мәчеткә киткәнен көтәләр болар. Менә башына зур чалмасын ураган, тышлаган җиңел куян тунын, аякларына читек-кәвеш кигән хәзрәт нурлы йөзен балкытып кече капкасыннан килеп чыга. Күрәген кулыннан төшермичә үзен озата чыккан йорт карауччы Әхмәдулла бабайга елмаеп нәрсәдер әйтә. Тегесе ак сакал-мыек каплаган йөзен бияләйле сул кулы белән каплагандай иттереп кеткелди. Хәзрәт иңнәрен кузгаткалап тунын җайлый да, бисмилласын әйтеп, олы урамга чыга башлый. Бакчасын уратып алган, аршин биеклегендәге такта коймасын яныннан салынган сукмак аны урамга алып чыга. Такта койманың эчке ягында, аның өстеннән урам якка үрелеп карап үскән алма, армут*, чия, шомырт, юкә агачларының бөреләре кояшта җылынып бүртә төшкәннәр. Зурайганнар. Алар күңелле яз килү белән котлап кытыклыйлар, борынга булачак җимешләренең исләрен бирә башлап, кышкы суыклардан, бураннардан талчыккан җанны ял иттерәләр. Алма агачы ботагында, кышкы зәмһәрир суыклардан тере калган Ходай кошы—песнәк авылда иң беренче булып язгы җырны башлап болаша:

—Пти-и-түт! Пти-ии-түтт!

Җирдә апрель... Юллар көннән-көн карала бара. Һавада эрегән тизәк, салам исе. Язгы авыл урамы исе. Күрше Шакир байның абзары янында ике сыер малы басып тора. Икесенең дә күзләре йомык, үзләре иренеп кенә күшиләр. Аркаларында берничә чәүкә кышкы ябагаларын йолкый. Болары инде оя әтмәлләп, бала чыгару уе белән мәшгульләр. Тыныч, рәхәт язын авыл урамында, кояш җылысында. Мең шөкер Ходайга!

Мөхәммәт Шакир хәзрәт салмак кына адымнар белән мәчеткә барып җитеп, укына-укына аның ишегеннән кереп китә. Шуны гына көтеп качып торган өч малай аның коймасы буендагы сукмакка ташланалар. Алмашлап, көрәк белән ярты аршин чамасындагы озынлыкта һәм бер көрәк тирәнлектә чокыр казыйлар. Ярты көрәк тирәнлеккә төшү белән кар астыннан су чыгып, чокыр төбенә җыела да башлый. Малайларга

---

* Армут—груша.

шул гына кирәк тә инде! Чокыр казылып беткәч, үзләре белән алып килгән тал чыбыкларын аркылы тезеп чыгалар да, өстенә азрак салам салалар. Аннан чокыр өстенә юка гына иттереп кар салып, өстеннән салам сипкәлиләр. Казыганнан чыккан карны ераккарак ыргытып, казылган чокыр сизелмәслек итеп тирә-ягын тапаштырып куялар. Кар өстенә сакланып кына аяклары белән "эз салалар". Бу эшне чабаталы Фазулла белән Абдулла башкаралар. Мирсәет аягында итекләр. Ни әйтсән дә хәлфә малае бит! Өстәвенә әнисе әллә нинди байлар нәселеннән ди әле аның. Анарга чабата кияргә ярамый икән. Эшне бетереп, янадан күрше Шакир бай сарае ягына таялар.

Озак булса да иренмиләр, Мөхәммәт Шакир хәзрәтнен мәчеттән кайтканын көтәләр. Чөнки сулы чокырга батканнан аның кебекләр иттереп бер генә бабай да куана белми. Күбесе, танып калсалар, әтигә әйтеп кирәкне бирдерәләр әле! Аларның качып торганын күреп калган, Гатифә әбиләрдән чүпрә алып кайтып килгән Гобәй Пәрәү дигән малай урам уртасында туктала. Авызы чүпрәгә буялган—чөмергән генә Пәрәү чүпрәне! Ул мәдрәсәдәге иң шук, иң күп әкият белүче (үзе уйлап чыгара икән) Пәрәү! Иң шәп дөрес сөйләүче, иң нык иттереп сугыша белә торган малай. Үзеннән көчле саналган малайлар белән дә сугыша, аларны да акыртып кыйный белә. Тик үзенә башлап сукмасалар бер кешегә дә башлап сукмый, тими. Шул ягы әйбәт аның. Дуслыкка да ышанычлы малай! Узган ел җәен Мирсәет белән сугышты Гобәйдулла. Су керә торган җирдә, яр башында. Мирсәет Гобәйнен күлмәк җиңнәрен нык итеп төйнәп "каз боты" ясаган. Төйнәгәч "тозлап" та куйган өстәвенә. Шул чакта чума-чума су кергән Гобәй моны күреп калган. Судан чыкты да, үзе ясаган "каз ботын" Мирсәетнен үзеннән "кимертергә" итте. Китте төрткәләш, китте сугыш. Мирсәет сала Гобәйнең борынына. Китте тегеннән кан, чүрләп ага. Шуны Гобәй учлап сыпырып кына ала да, чәп-пи Мирсәетнең ялангач тәненә. Аркасына, күкрәгенә, битенә. Икесе дә кып-кызыл булып канга буялдылар. Малайлар көчкә аралап алдылар. Шуннан Гобәйне һавага каратып сузып салдылар. Мирсәеттән "кимерттеләр" үзе ясаган "каз ботын".

Шул Гобәйдулла малайларның качып торганын күреп калды. Сөрән дә сала башлады урам уртасыннан:

—Кемнән качтыгыз анда-а?!

Качып торган малайлар кулларын болгый-болгый аны да үзләре янына чакырып алдылар. Чакырганда тик тавышлары гына чыкмады. Ярамый кычкырырга! Гобәйдулла да чана эзләрендә җыела башлаган суларга баса-баса алар ягына атлады. Аның аякларында күтәртмәләр тагылган өр яңа чабаталар. Күтәртмәле чабаталар кигәнлектән Пәрәү гел судан гына йөрергә тырыша. Судан курыкмый янәмәсе Пәр-рәү! Малайлар аның сөяннән ясалган күтәртмәләренә кызыккандай иттереп карап кына алдылар да, шуңардан артык әһәмият бирмичә күзләрен мәчет ягына текәделәр. Аларда күтәртмә кайгысы юк иде!..

—Картлар чыга башлады!—диде пышылдап кына муенын сузып карап торган Фазулла.—Иң алдан Закир Таз бабай чыкты.

Мәчеттән чыккан бабайлар икешәр, өчәр булып авылның төрле ягына тарала башладылар. Мөхәммәт Шакир мәгъзүм дә Түбән очта яшәгән Шәйхелислам бабай белән нәрсә турындадыр сөйләшә-сөйләшә малайларга табан килә башлады. Үзенең такта коймасы янына килеп җиткәч, саубуллашырга дип Шәйхелислам картка борылганда йорт почмагында посып торган малайларны шәйләп алды.

—Ярый, хуш иттек, Шәйхелислам абзый!—диде хәзрәт. Баш кагыштылар да һәркем үз юлы белән атлады. Хәзрәт койма буйлап сузылган сукмакка күз салган уңайга ук малайларның "этлеген" чамалап та алды. Йөзе елмаеп, яктырып китте. Авыз эченнән генә: "Аллага тапшырдык!"—дип бисмилласын әйтте дә, уң аягын кирәгеннән азрак өскәрәк күтәреп чокыр өстенә китереп басты. Шыртлап чыбыклар сынды, чопылдап су

килеп чыгып хәзрәтнең тун чабуын чылатып каплады. Куанычларыннан малайлар чинадылар...

—Алла! Алла!—дип кычкырып, "көтелмәгән хәлдән" хәзрәт "куркып, коелып" төште.—Баттым бит, батты-ым! Кем эше бу? Ай хәсислә-әр!

Тиз-тиз атлап малайларны бастыра башлаган Хавас картка дәште:

—Хавас абзый! Ялгыш кына булса да таягың белән тия күрмә тагын.

Качып барган малайларның иң алдынгысы булып йөгергән Гобәйдулла абынып тәгәрәп китте. Чүпрә салган балчык савыты ат тизәкләре белән капланган юлга барып мәтәлде. Чүпрәсе юлга түгелде. Артына карап йөгергән Мирсәет Гобәй өстенә абынып егылды, аның өстенә Фазулла. Тик Ак Бөҗи генә аларны урап үтеп, Хәсәнша бабай ягына элдертте...

Мәчеттән кайтып барган картлар урамда туктап, егылышып яткан, йөгерешкән малайлар артыннан көлешеп, үзләренең дә малай чакларын исләренә төшереп шаулаштылар. Кире борылган Шәйхел карт кына тыңкышрак тавыш белән ризасызлыгын белдереп болашты:

—Мәдрәсә мөдәррисенә, хәзрәткә ям казыганнар, оятлары качкан нәмәстәлә-әр! Кем малайлары алар, казыйга алып барып тал чыбык ашатырга кирәк үзләренә. Суктырырга барысында-а...

Тик мәчет картларының берсе дә малайларны "танымады". Гөрләшеп шаулашып кайту якларына атладылар. Кайчандыр үзләре дә шундый малайлар иделәр бит. Узды гомерләр!...

...Хәсәнша бабай белән Тайбә әби Мирсәетне үз балалары кебек итеп карадылар, яраттылар. Иртән Мирсәет мәдрәсәгә барды, өйләдән соң Учител Мирсәет Бийишев укыткан урыс ышкулына йөрде. Соңгы дүрт елында ул урысча укып, язарга, арифметикадан кушу-алу, тапкырлау-бүлү гамәлләренә өйрәнде. География, тарих укыды. Шул еллар эчендә Учителнең яраткан укучысына әверелде. Икенче ел укыганда, Учител Мирсәет янына Габделкадыйр байның улы Газизҗанны утыртты.

—Өйрәт Газизҗанны укырга да, язарга да. Аны өйрәтү сиңа киләчәктә бик нык кирәк булачак. Анысын соңыннан аңларсың...

Эстәрледә яшәү, уку чорында Мирсәет күршедә, яр башында яшәгән Зәйнетдин Балтаның улы Фазулла белән нык дуслашып китте. Алар икесе дә яшьтәшләр. Тик Фазулла буйга да Мирсәеттән биегрәк, көчлерәк тә. Әнисенә охшап сары чәчле, зәңгәр күзле. Мирсәетнең дә күзләре зәңгәр. Аяз көндәге һава төсендә аның күзләре. Ә чәчләре әтисенеке кебек коңгырт. Мәдрәсәдә бергә укыйлар сабакны. Укуга Фазулла Мирсәеттән шәбрәк алдыра. Шуның өстенә әнисенең китапларын укып ул үлән серләрен дә белә. Үләннәрне кайсы вакытта җыярга, ничекләр иттереп киптерергә әнисеннән дә өйрәнә. Җәй буена ялан-кырлардан, урман-тугайлардан үлән җыя. Әнисе белән икәүләшеп шул үләннәрдән дару ясыйлар. Бервакыт ул төрле үләннәрне киптереп, әтисе ясап биргән кечкенә генә каен киледә төеп он итте дә, шуны эрегән туңмай белән күкерткә өстәп дару ясады. Шул даруны сөртеп корчаңгыны бетерделәр. Шешнең сызлавын басып, аны тулыштырып, тиштерә иде дару. Фазулла елдан ел укымышлыга, дару өчен үлән белгеченә әверелә барды. Зәйнетдиннең малайлары арасында Фазулласы укуга иң сәләтлесе иде. Әнисе улы белән соклана:

—Бу бала тач үземнең әти мәрхүм инде! Ул атлаулары, ул гәүдә торышлары, үл сөйләшеп көлүләре. Ошаса да кеше кешегә ошый икән!..

Фазулла ыспай. Матур иттереп киенә белә. Хәтта чабата белән тула оекка кадәр бик матур иттереп кия белә. Бишмәте дә өстендә ятышлы булып тора. Ул аны әнисе белән бергә тегә. бер җирен кыскарта, икенчесен азрак тарайта, өченче урынын азрак иркенрәк иттереп җибәрә, кыса, тегә, җөпли. Маңгаена, сул кашынарак каратып кырын салыбрак кигән кәләпүше дә, кыш көннәрендә кигән түгәрәк, колаксыз бүреге дә башында бик килешле булып утыралар, азрак озынчарак чибәр йөзен тагын да

чибәрлиләр. Фазулла киенеп авыл урамнарыннан узган чакта, хәтта картлар да туктальп аның ыспай, матур итеп кигән киеменә, гәүдәсен тотышына, атлауларына сокланып карап калалар.

—Сөбханалла! Чын егетләрчә бит моның барлык табигате. Ул гәүдә, ул атлау дисеңме! Биргән Ходай бу егеткә гәүдәне дә, чибәрлекне дә!...

Фазулланың Мирсәеткә булган дуслыгы да тыныч, чын күңелдән. Әтисе кебек Мирсәетнең дә кызып китә торган гадәте бар. Андый чакларында берәрсенә "кундырырга" исәпләп кызарып-бүртенә башлаган Мирсәет алдында һәрвакыт Фазулла пәйда була. Шунда ук аның янына энесе—дәшмәс Ак Бөҗи Абдулла да килеп баса. Фазулла елмаеп, инде Мирсәет сукса "кайтарып бирергә" әзер булган малайга дәшә:

—Җә, син нәстә инде! Тукта! Мирсәет тә, син дә—икегез дә туктагыз. Бергәләшеп уйныйсы барын онытмагыз! Туктагыз!

Фазулланың күз карашында сихер бар, диләр. Дөрес булырга охшаган. Яшь әтәчләргә ошатып сикергәли башлаган малайларның сугышасылары килүе бетә дә куя ул караганнан. Туктыйлар сугыш башлаудан. Йомарланган йодрыклар языла, кысылган иреннәр ачыла, алгарак иелгән гәүдәләр турая, күзләрендә ачу юкка чыгып, мәрхәмәт нуры бар була.

Җир кибә башлау белән иң беренче уен итеп "Бүрек төшерешле" уйныйлар. Берәр бәләкәйрәк малайны эреп, ачылып кибә башлаган җиргә сапам җәеп аякларын бөкләтеп утырталар. Барлык малайлар да бүрекләрен салып, бер-берсе өстенә тезеп теге малайның башына кидереп өяләр. Шуннан шобага салып, кем артыннан кем йөгерәсен билгелиләр. Аннан соң инде бер-бер артлы йөгереп барып теге күп бүрек киеп җирдә утырган малай аша сикерүләр башлана. Сикергәндә арт тиеп китеп берничә бүрекне төшерәләр. Берәү, казый булып, тәгәрәп төшкән бүрекләр исәбен алып бара. Сикерешеп беткәч, иң беренче булып бүрекләрне тәгәрәтеп төшергән малайны тезләренә, ике кулы белән җиргә тотындырып тезләндерәләр. Аның артыннан сикергән малайның бер ягыннан бер малай, икенче ягыннан икенче малай кулыннан, аягыннан тотып күтәрәләр. Теге тезләнеп торган малай янына киләләр дә икенче малайны азрак селтәгәндәй итеп арты белән тегесеннән артына китереп сугалар. Җирдәге малай катырак суксалар язгы, юеш җиргә борыны белән кереп китә, елау юк. Тагын тезләнә. Тагын бирәләр. Төшкән бүрекләр исәбенчә арт ягына алгач, анысы торып китә. Бушаган урынны башка малай ала. Кул-аягыннан күтәргәннең дә, бүрекләр исәбе беткән булса, алмаштыралар. "Бүрек төшерешле" уйнаганда исәп-хисап беткәч, һәрчак диярлек малайлар арасында сугыш булып ала.

Җир ныграк ачылып кибә башлагач, "шаралы" уенына күчәләр. Аны да Мирсәет оештыра. Аның: "Әйдәгез хәзер шаралы уйныйбыз!"—дигәненә малайлар йөгерә-атлый өйләренә таралалар. Күп тә үтми кышкылыкка яшереп куйган шара суга торган таяклары, кәшәкәләрен күтәреп янадан җыйналалар. "Шаралы" сүзен ишеткән тагын берничә малай килеп житә. Мирсәет, алар килгәндә инде тырышып-тырышып "шаралы" уены өчен "казан" казып болаша. "Казан" әзер булу белән шобага салалар: Кем "көтүче" була? Аның өчен "Казан алдында тигез итеп барысы да тезеләләр. Кем уң аягының, кем сул аягының баш бармагына таягының бер очын тери дә, таякны өстәнрәк кулы белән тота. Казыйның кул селтәве белән барысы да таяк терәгән аякларын артка бирел, кем күпме булдыра алган кадәр сузалар. Аннан соң кискен хәрәкәт ясап, таякны алга, һавага селтиләр. Таяклар һавада очалар! Кемнең таягы иң якын төшкән, шул инде "көтүче" була. "Казанның" ике ягына ярты таяк озынлык ара калдырып үкчә сыярлык кына йомры урын әзерләнә. "Казанның" ике ягына ике малай, шул урыннарга үкчәләрен урнаштырып үзләренә урын алалар. Бу ике малай иң оста "шарачылар" булырга тиеш. Аларның бурычы "Казанны" саклау. Ә "Казан" алдында "көтүче" үкчәсе өчен дә шундый ук "үкчә оясы" ясала. "Казан" янындагы ике малайдан арырак бер таяк озынлыкта тагын ике малай баса. Аларның

үкчәләренә дә урын ясала. Алар артыннан тагын ике малай, аннан соң тагын, тагын... китәләр тезелеп барысы да...

"Көтүченең" уң кулында түгәрәк шара. Аны күбрәк вакыт коры имән агачыннан ясыйлар. Малайлар йодрыгы зурлыгында була ул шара.

Уен башлана. "Көтүче" ничек кенә булса да шараны "казанга" салырга тиеш. "Казан" янындагы ике малай таяклары белән һавадан очып килгән шараны сугып еракка очырырга тиешләр. Әгәр инде шара "Казанга" да төшмичә ары тәгәри икән, аны арттарак басып торган малайлар сугып җибәрәләр. "Көтүче" шараны барып ала да, якынрак килеп тагын "казанга" ыргыта. Малайлар шараны тагын сугып җибәрәләр. Әгәр инде шара "казанга" төшсә, барлык малайлар да бер-берсе белән урыннарын алмаштыралар. Шул чак көтүче үзе өчен тиз генә бер урынны эләктереп калып басарга тиеш. Урынсыз калган малай китә "көтүче" булып.

"Шаралы" уенның язылмаган бер катгый кануны бар. Уен барышында күп тапкырлар хәрамлашырга, кычкырышырга яраткан, уен тәртипләрен бозып эш иткән "көтүчене" малайлар сүз берләшеп бик озак "көтүлектә" йөртәләр. Аны йөгертеп, алҗытып тәмам хәлдән тайдыралар. "Кәҗә маен" чыгаралар, тиргә батыралар. Шундый вакытларда кайбер "көтүче" түзми, еракkарак киткәч шарасын ташлап кача. Шуннан инде малайлар аны куып тота алмасалар, кире "шаралы" уйнаган җиргә кайталар. Берәр таякны алып шобага салалар. Кем иң өскә чыга, шул "казый" була. Һәм ул теге малай турында "хөкем" чыгара. Хөкем мондыйрак була:

1. Ун көн качкан көтүчене бер уенга да кертмәскә, бер җиргә дә ияртеп бармаска. Аның белән сөйләшмәскә. Сөйләшкән малайны тотып ярырга.

2. Чишендермичә, киеме белән биш тапкыр Эстәрле елгасына ярдан ыргытырга.

3. Тотып алып килеп уен беткәнче "көтүче" итәргә.

4. Доңгырга салып егерме тапкыр тәгәрәтергә.

Ата-бабайлардан калган уеннар гадәте буларак иң мәсхәрәлесе "доңгыр аша үткәрү" санала. Ул болай башкарыла.

"Көтүче"лектән качкан төрле хәйләләр кулланып тотыла. Тота торган хәйләнең иң шәбе, берәр бәләкәй малайны өйләре янына җибәреп, урам яктан кычкыртып тегене үртәү. Түзми чыга ул, үзеннән бәләкәй бер малай-шалайның үртәгәненә түзә алмыйча. Теге малай йөгереп кача, "көтүче" аның артыннан бастыра. Менә тотам дигәндә, читән артларыннан башка малайлар сикерешеп чыгып тегене эләктереп алалар. Әгәр инде бер хәйлә дә ярдәм итмәсә, калган көннәр тик шуны тоту өчен генә кулланыла. Качкан "көтүчене" тотарга йөргән көннәрдә берничә бәләкәй малай тотучылар артыннан тик шара таякларын гына күтәреп йөри.

Тегене барыбер бер көнне тоталар. Шара таякларын (кәшәкә бармый—аның башы кәкре) җиргә тезеп салалар. Таяк араларын уч кинлегендә итәләр. Качкан "көтүчене" чишендерәләр. Ыштанын гына салдырмыйлар. Аркасы белән теге тезелгән таяклар өстенә яткыралар. Ике иң бәләкәй малайны бер-берсенә аркаларын терәтеп җирдә яткан малайның корсагына утырталар. Аннан соң ике кулын баш очына сузып бер малайга тоттыралар. Икенче малай ике аягын бергә тотып сузып тарта. Шуннан соң барлык малайлар бердәм булып такмаклап, "Дангыр-доңгыр! Дангыр-доңгыр"—дип кычкырып такмаклап, качкан "көтүче"не ялангач аркасы белән тезелгән таяклар өстендә арлы-бирле тәгәрәтә башлыйлар. "Казый" ничә мәртәбә тәгәрәткәнне кычкырып санап бара. Чөнки ничә тапкыр тәгәрәтергә икәнне "казый" билгеләгән була. "Доңгыр" аша бик сирәк малай гына еламыйча үтә ала. Шунлыктан малайларның күпчелеге "көтүче" булганда аягыннан егылганчы йөгерсә йөгерә, ләкин качмый. Качып, тотылып "доңгыр" аша үткәнен ул малайның исенә картайганчы төшереп торалар: "Теге елны, малай чакта, син бит "доңгыр"га эләккән идең. Исеңдәме? Инде картаеп барасың, сиңа тагын "доңгыр" кирәк, ахрысы. Кара аны!.."

* * *

Урыс ышкулында 1907 елның май урталарында сынаулар булды. Габдеррәхим Тукаев-Соколов тагын сынау алу комиссиясенең рәисе иде. Урысчасы йомшак булганны сәбәп итеп, Габделкадыйр тархан сынауларга килмәде. Тик чын сәбәбе башка иде. Ул, 1906 елнын язында абзасы Габдеррәхим белән бик каты кычкырышты. Габдеррәхим аңарга:

—Барлык жирдә ярлы халык күтәрелә. Син азрак эшләгәннәргә хакны арттырыр идең. Бигрәк изәсең халыкны,—дигән, түзмәгән.

Шул сүзләргә комсызлыгы, байлыгы ташып торган бай жаваплый:

—Сасыял димакрат булдынмы әллә, минем байлыкка кызыгырга?! Рәхмәтләр төшсен падишаһыбызга, аттырып бетереп бара аларның барысын да. Сиңа да житеп килә нәүбәт, әзерләнә тор, урыска әйләнгән нәмәстә!

Габдеррәхим акырган тарханга кул селтәп чыгып китә. Шулай да Шакир мәгъзүм аркылы житкерә тегеңәргә:

—Урысча дөрес иттереп "рәхмәт"тә әйтә белми—үзенең мин тархан дип тыгылмаган жире юк. Хәсис нәрсә! Надан!

Шул сүзләрне ишеткәч китте чыгып тархан кыңгырауларын тактырып Уфа губернаторына. Тарханлыгыннан файдаланып "Соколов"ны Земстводан эшеннән кудыртырга исәпләп. Тик...

Эстәрлетамактагы земство начальнигы чын Соколовның хатыны губернаторның бер туган апасының кызы икәнне Гапкадыйр мәгъзүм белми иде. Ә ул хатын эчкән ире Соколовны тик Тукаев-Соколов ярдәмендә генә тотып тора ала. Габдеррәхим чын Соколов өчен эшен дә башкара, аның вакытлыча гына булса да эчүен дә туктата ала. Шунлыктан тархан Габдеррәхимне эшеннән алдыра алмады. Чишә алмаслык төенгә әйләнде мөнәсәбәтләре ике Тукаевның...

...Сынау алучылар каршысында, жиде ел элек Лотфулла Зәйнуллин басып торган идән тактасында инде Мирсәет Солтангалиев басып тора. Урыс теленнән сынау бирә. Ул онытылып, урыс шагыйре Лермонтовның шигырен укый:

Под ним луч солнца лазури,  
Над ним луч солнца золотой.  
А он, мятежный, просит бури,  
Как будто в бурях есть покой.*

Мирсәетнең тавышы яңгыравыклы, көчле, моңлы. Русия Дәүләт Думасына Депутат итеп сайланган Мөхәммәт Шакир Тукаев инде бу малайга сокlануын яшермичә карый. Һәрбер күзәнәгенә хәтле татар мөселман, шагыйрь Дәрдмандның якын дусты булган мәдрәсә мөдәррисе урыс астында юкка чыгып бетеп барган асыл татар халкын коткару утында янып яши. Хәзрәт тә үзен әтисе кебек Шиһабетдин Мәржани шәкерте, аның мөрите итеп исәпли. Һәм белә, урыстан кайчан булса да котылу өчен Аурупача аң-белем алу өчен, урысның телен белергә кирәк. Шул тел аркылы дөньяви гыйлем алып, урысның үзеннән дә аңлырак, белемлерәк булырга кирәк. Урысны сәнәк, балта күтәреп кенә жиңеп булмый—белем белән алдыру фарыздыр. Шунсыз безгә юллар ябык. Зәйни Балтаның Лотфулласы очраган саен мөдәрриснең эчләренә салкын йөгерә: "Теге елны шушы асыл баланы Казандагы урыс ышкулына жибәргән булсак, инде ул аны тәмамлап, кире әйләнеп кайткан булыр иде. Авыл малайларын урысчага укытыр иде. Булмады бит!"

Куелган сорауларга жавап биреп басып торган Мирсәеттән сорады:

—Син, улым, безнең Габдулла Тукай дигән шагыйребезне беләсеңме?

—Беләм.

—Шигырьләрен укыганың бармы?

—Бар.

* М.Ю.Лермонтовның "Парус" исемле шигыреннән.

—Каян алып укыдың?

—Мирсәет абый Уральскидә чыккан татар телендәге “Фикер”, “Әлгасрел җәдит”, “Уклар” дигән журналлар алдыра. Шул журналларда бастыралар, язалар Габдулла Тукайның шигырьләрен. Шуннан укыйм.

—Яттан берәр шигырен сөйли аласыңмы?

—Сөйлим. Рөхсәт итсәгез.

—Сөйлә.

Мирсәет Учителгә карады. Тегесе дәшмәде, елмайды гына.

—Габдулла Тукай шигыре. Исеме: “Үз-үземә”.

Тавышы бик көчле чыкмаса да, яңгыравыклы һәм дәртле иде Мирсәетнең. Ике кулын артына куеп, сул кулының беләзегеннән уңы белән тотты. Гәүдәсе сизелеп җыйнакланды, тураеп китте. Башлады:

### Үз-үземә

Телим булырга мин инсане гали[1],
Тели күңелем тәгали биттәвали.[2]

Күңел белән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм,
Кырылмасмы вавы[3], валлаһе эгъләм?

—Сөбханалла! Сөбханалла!—диде куанып хәзрәт.—Тагын беләсеңме?

Хәзрәтнең куанганы Мирсәеткә дә күчте. Көттереп тормады, елмайды, сөйләп алып китте.

### Яз галәмәтләре

Язлар житте, карлар эри башладылар,
Толыплылар толыпларын ташладылар;
Киемсезләр иркен йөри башладылар,
Тунсызларга иркен көннәр килде имди.

Ката, чана табаннары ял итәләр,
Шалтыр-шылтыр юлдан арбалар китәләр;
Тарантаслар, велосипидлар, кареталар.
Урамнарны чуарлыйлар бер-бер имди.

Каткан-тунган агачларны хәзер кара;
Һәрберсе яшәрешеп яфрак яра;
Бу урамнар бакча булыр бара-бара,
Һәр агачта сандугачлар сайрар имди.

Кышлар үтеп, яз көннәре килер исә,
Сахраларда йомшак саба жиле исә;
Аһ, бу көннәр гамькин күңелләрне кисә,
Үткән гомер бер-бер искә төшә имди.

Бүлмә эчендә “шылт” иткән тавышта юк. Тып-тын. Шул тынлыкны уятып Мөхәммәт Шакир хәзрәтнең сүзләре ишетелде:

—Афәрин, Мирсәет улым! Афәрин! Йомшаттың күңелемне минем. Рәхмәт! Менә бу шигырьләрне язган Габдулла да Тукаев, безләр дә Тукаевларбыз. Аллага шөкер! Әй-йе! Безнең шәҗәрәләргә караганда, безнең

---

1 Инсане гали—бөек кеше.
2 Тәгали биттәвали—туктаусыз югары күтәрелүне.
3 Кырылмасмы вавы—вәгъдә күп булса да юкка, бушка булмасын дигән мәгънәдә.

бабайларның бер Тукай исемле бабасы Казан арты, Малмыж өязенең Салавыч исемле авылыннан чыгышы белән. Тукай бине Урманай. Ул безнең, Габдулла Тукаев белән уртак бабабыз шәҗәрә буенча. Менә бу Габдулла исемле баланы унике ел элек безнең Эстәрлебаш авылы аша Уральски каласына кыш көннәрендә алып китеп бара иделәр. Безгә кереп кунып, ике көн атларын ашатып, мунчалар кереп ял итеп алдылар. Ул баланы яхшылап мунча керттек. Өстенә янадан кулмәк-ыштан тегеп кидердек. Сабыр гына холыклы, куркынган сигез-тугыз яшьләр чамасындагы кечкенә гәүдәле бер малай иде. Әтисе дә, әнисе дә үлеп, ятим калган. Әтисенең сеңлесенә илтәләр иде аны. Сабый, кеше кулларында күп булган, бик кагылган иде. Алдыма утыртып сөя башлаган идем, йөрәге кош йөрәге кебек куркуыннан леп-леп килеп тибә.

Шул бала үсеп җитеп, шагыйрь Габдулла Тукай булган дип уйлыйм мин. Теге баланың да исеме Габдулла иде. Җаек ягында башкача Тукаев булып йөргән затларны белмим мин. Тукаевлар алар Казан артында...

Тантаналы күзләрен үзен тыңлаганнарга йөртеп чыкты:

—... вә һәм дә бездә, Эстәрлебашта гына Тукаевлар...

Мирсәеттән сорады:

—Син Мирсәет Тукай бабайның кабере безнең зиратта икәнлеген беләсеңме?

—Йу-у-ук, белмим,—диде Мирсәет тотлыга биреп.

—Зират уртасындагы калкулыкта ике зур төрбә бар бит?!

—Әй-йе.

—Зурысында минем әтием тархан Мөхәммәт Харис белән аның энесе Мөхәммәт Харрас җирләнгәннәр. Хатыннары да шундалар. Икенчесендә—кечерәгендә—аларның әтисе, минем бабам Нигъмәтулла ишан күмелгән. Аның әтисе Биктимер хәзрәт тә шунда. Аларның да хатыннары шунда җирләнгән. Менә шул төрбәнең сул ягында инде Тукай бабай кабере. Ташы да бар, тик төрбәсе генә юк. Иншалла, ясатырбыз дип уйлыйм...

Туктады сөйләүдән. Чалбары кесәсеннән ап-ак яулык чыгарып күзләрен, борынын сөртте. Габдеррәхимгә әйтте:

—Теге елны Лотфулланы җибәрә алмадык Казанга, урыс укуына. Мирсәетне җибәрик без. Алсын бу малай урысча белемне. Үзебезнең халыкка файдалы булсын. Син ризадыр бит, Хәйдәргали?

Алардан читтәрәк, диварга аркасын терәп утырган Хәйдәргали хәлфә шатлыгыннан тик башын гына кага алды...

Язмыш, язмыш! Татар халкы өчен янып-көеп яшәгән Мөхәммәт Шакир Тукаев Мирсәет Солтангалиевнең фаҗигале язмышлы, бик тә бәхетсез кеше булачагын алдан каян белсен инде Мирсәет 1922 елда татар халкына азатлык яулау өчен Ленинга, Сталинга каршы төшеп караячак. 1923 елдан алып, 1940 елның көзенә кадәр большевистик режимның төрмәләрен, каторгаларын, концлагерьларын, одиночный камераларын үтәчәк Мирсәет. Үз хатасын үзе аңлап, көрәш юллары эзләп караса да, большевикларның тән палачлары, җан палачлары тарафыннан ул сындырылачак, юк ителәчәк...

Аны 1940 елның ноябрь аенда Лубянка подвалында атачаклар...

* * *

**1907** елның июль аенның азаккы көннәре иде. Эстәрлетамакка барып, солдатка китәргә дип "каралып кайткан" никрутлар ике кич инде тальян гармунга ияреп, авыл урамнарын җырлап таптыйлар. Никрутлар барысы җиде кеше. Шулар арасында Лотфулла да бар. Ул да китә солдатка. Моны бик үк шаптән булмаса да, иптәшләренә кушылып ул да җырлый.

Тәүге кичне чыкканда, үзенең капкасы төбендә чикләвек таягын һавада бутый-бутый акырган, никрутларны "алласыз урыслар" дип әрләгән,

орышкан Түбән оч Колмак Госман картның тарантасын мунчасы башына мендереп куеп, тәгәрмәчләрен күтәртеп куелган ике тәртәсе арасына таякка кидереп бәйләп куйдылар. Элекке елларда яисә аулак өйләрдә, яисә авыл очындагы Тал Борыны дип йөртелгән тугайда җыелган уеннарны куарга килгән картларның йортларын йөреп чыктылар. Иң усаллардан булган дисәтски Пүчтәк Бәшәрнең урыс капкасының ике ягын да суырып алып Эстәрле елгасына алып төшеп агызып җибәрделәр. Капкалар әллә ни ерак акмадылар агуын. Таррак урында берсе өстенә икенчесе менә биреп тукталдылар. Тик барыбер акканга исәпләнделәр. Ә икенче Гыйлаж Ку-Ку дип йөртелгән диндар картның җил капкасын урам ягтагы тәрәзәләре каршында үсеп утырган ике тирәгенә һавага күтәртеп тарттырып бәйләп киттеләр.

Җамали староста җыеп алып чыккан унлап авыл карты белән дә чәкәләшеп алдылар. Унбиш яшьләр чамасындагы Сәмигулла исемле гармунчы малайны уртага алдылар да, түгәрәкләнеп тезелеп, таякларын селти-селти үзләренә һөҗүм иткән картларга каршылык күрсәттеләр. Картлар кулыннан тартып алынган шомырт, чикләвек таяклары шартлап сындылар, Җамали старостаның медале тагылган каешын өзеп, медален читән аша ыргыттылар. Гафур Писергә дә яхшы гына иттереп егетләрнең берсе күз төбенә "манчыды." Егетләрнең дә күлмәкләре шатырдап ертылды, иннәрендә таяклар уйнады. Инде ике бәрелеш кызуга табан барган чакта, Таш Күпер ягыннан ак чалмалы, таягын тоткан Мөдәррис Шакир мәгъзүм күренде. Аның белән янәшә Хавас карт титаклый иде. Күрәсең, ул кереп әйткән инде мәгъзүмгә бәрелеш башланачагын. Картларның дәрте артты сугышырга, егетләр "шүрли" төштеләр. Кабаланмый гына атлап килгән хәзрәтне күреп барысы да туктап, тынып калдылар. Тик аркасы азрак уалы Бәшир карт кына егетләр аша таягы белән төртеп гармунчы малайга үрелә иде. Лотфулла дәшми генә аның кулыннан таягын тартып алды. Бәшир бабай да шулай булырга тиеш дигән кебек хәзрәт ягына карап тынып калды. Хәзрәт килеп җитте. Тукталды. Барлагандай картларны, түгәрәк ясап өерләре белән басып торган егетләрне карап чыкты. Барысының да сәлам биргәненә башын гына какты. "Эһм, эһ-һм!"—дип тамак кыргандай итте дә... йөзен балкытып елмаеп куйды. Телгә килде:

—Син, Галләметдин абзый, никрут булып каралып кайткач, авыл урамнарын өч төн буена халыкка тынгы бирмичә тапаган идең. Минем әле малай чак кына иде. Сездән калмастан ияреп йөрдем. Әти мәрхүм чыгарды, бар, кара никрутларны, җырларын тыңла, исендә калдыр, ияреп йөр, дип. Безнең динебез, Аллага шөкер җыр, биюне тыймый. Шунда мин сез никрутларга ияреп, синең дә нәрсә кыйланганнарыңны карап йөргән малай. Битәй Әхмәдулла бабай янындагы Эстәрле елгасы аша салынган күпернең өстен сүтеп очырдыгыз. Алабаен үзегезгә өргән өчен чыпта капчыкка салып, авызын бәйләп, бакчасындагы карамасы башына мендереп элеп куйдыгыз. Бау белән бәйләп. Улый теге эт. Биктәш бабайның зур кара этенең коерыгына иске комган тагып, урам буйлап сызгырып, куып йөрттегез. Качмасын өчен муенына бау салып. Сезне куып таратырга дип ат менеп чыккан картларны биргәләп туздырдыгыз. Мәмәнетдин бабайны атының өстенә коерыгы ягына каратып утыртып астан аякларын бәйләп, атын җитәкләп җырлап йөрдегез. Өстәвенә тунын әйләндереп кидергән идегез. Исендәме: "Шүрәле тоттык, Шүрәле тоттык!"—дип такмаклап йөрдегез. Бичарага үлгәнче шул Шүрәле исемеябешеп калды. Сезгә яраган башкага ярамый икән. Ә син Җаббар абзый...

Картлар кеткелдәп көлешә башладылар. Җаббаретдин күзеннән чыккан көлке яшьләрен чикмәненнән җиңе белән сөртә-сөртә әйтте:

—Ярар инде, мәгъзүм, безнең битне ертма. Булды. Көнләшкәннән чыктык—никрут чаклар, яшь чаклар искә төшеп. Китәрбез хәзер...

—Хәмер эчмәгәннәр, әшәке сүзләр сөйләмиләр, кешегә кул белән тимиләр. Никрутлар бит. Урасыннар авыл урамнарын гармуннары белән. Гармунчылары моңлы, гармуннарының тавышы көмеш. Җырлары да

йөрәкне кузгата торган җырлар. Таралыгыз картлар...

Кесәсенә тыгылып бирәр тәнкәлек көмеш акчалар чыгарды да, никрутларга таратып чыкты. Гармунчы малайның башыннан сыйпап аңарга да бер тәнкәне тоттырды.

—Кайда уйнап өйрәндең бу хәтлек оста итеп? Ә?

—Күлгә төшеп, тал арасына кереп утырып,—диде малай, барысын да көлдереп.

Хәзрәт кыска гына дога укып, битен сыпырды. Барысы да аңарга иярде.

—Хәердән булыр, хуш иттек! Исән-имин йөреп, өйләнеп кайтыгыз авылга. Салдаттан зимагурлыкка чыгып китмәгез. Мөселман читтә йөреп урыслаша, оныта ул туган илен, телен. Андый-мондый салдаттагы баш китә торган эшләргә урыстан алда тыгылып харап була күрмәгез. Сак булыгыз!

Картлар үзара мыдыр-мыдыр килеп, кайсысы ризасызлыгын сиздереп, кайберләре елмаешып таралыша башладылар. Алар киткәч, егетләр азрак басып торып кинәшеп алдылар. Җырга маһир Сабирҗан әйтте:

—Әйдәгез, егетләр, җырлап узыйк авыл урамнарын. Аннан аулак өйгә барырбыз. Бүген Чишмә урамында, Сагызчы әбиләрдә аулак. Үзе өйдә юк, Гайнәдәге кызына киткән. Тегесенең малае бар ди...

Барысы да елмаештылар, көлешеп алдылар.

—... Тимик капкаларына да, этләренә дә, үзләренә дә. Булды инде безне искә алып, сагынып сөйләрлек. Өстәвенә бүген Сәрбиҗамал белән кунып та булса, барып чыга да куя...

Барысы да ризалаштылар.

—Әйдә, энем, чык алга!—диде Лотфулла, бер тәңкәсен авызына кабып яшергән малайга.—Тимибез акчаңа. Синеке ул. Менә шуңа минекен дә өстә. Безнең белән йөргәнең өчен түләү сиңа. Тарт тальяныңны! Өздер, әйдә!

—Башла, Сабирҗан дус!—диде егетләрнең берсе.—Әйттерик әле бер!

Сабирҗан сул кулы белән гармунчы малайның аркасыннан кочаклады да җырлап җибәрде:

Без китәбез салдатка дип,
Калганнарга хәсрәт.

Дәррәү күтәреп алдылар:

Без җырлашып узган чакта,
Ачуланма, хәзрәт...

Ике көннән никрутларны Чуаш юлы белән Әкчүн тимер юлы стансасына озаттылар. Алар аннан вагонга төялеп, Уфага китәргә тиешләр икән.

...Калкаш волостеннән ул көнне утыз ике никрут китте. Староста Җамали тугыз олау әзерләткән. Стәрлетамактан никрутларны озатып куярга Фәттах стражник килеп җиткән. Староста белән стражник алдына баскан Гафур писер исемлек белән китәсе никрутларны барлый. Алар капчык, дүрткелле кәрҗиннәрен күтәреп ике рәт булып тезелеп сафка басканнар.

Писер кычкырып укый:

—Гималетдинов Кәшшафетдин Гималетдин улы.

Лотфулланың сул ягында басып торган Карагыш авылы мишәре тавыш бирде:

—Мин булам ул Кәшшафетдин.

Гафур аңа карап алды да, кулындагы исемлеккә тамга куйды.

—Зәйнуллин Лотфулла Зәйнетдин улы.

—Мин!—диде Лотфулла һәм шул чакта Җамали старостага карап атлаган Хәйдәргали хәлфәне күреп алды. Аягына искерәк кенә күн итек, башына шулай ук кырыла башлаган түгәрәк кырпы бүрек, җәй булуга

карамастан өстенә бишмәт кигән хәлфә тазарган, матурланган. Кырма сакал-мыегы да килешле иттереп китәрелгән, кыскартылган. Җамали старостаны җиңеннән тартып читкәрәк алып китте. Шуннан аның колагына табан иелә биреп акрын гына нәрсәдер сөйли башлады. Җамали староста Гафур писер ягына караштыргалап аның сөйләгәнен тыңлый һәм тыңлаган саен йөзе уйчанлана бара иде. Хәлфә сөйләп бетергәч, староста аңардан нәрсәдер сорады. Тегесе кулы белән әле генә үзе килгән якка күрсәтте. Лотфулла ул күрсәткән якка карады. Анда хәлфәнең улы Мирсәет басып тора иде. Аяклары янында өсте капкачлы зур гына дүрткел кәрҗин һәм авызы бәйләүле, яртылаш тулы капчык. Малайның да аягында итек, башында өр-яңа, атасыныкы кебек түгәрәк кырпы бүрек, өстендә озын кара бишмәт. Җамали Хәйдәргалине тыңлап бетергәч, Мирсәеткә тагын бер мәртәбә карап алды да, башын селкеде. Ул нәрсә беләндер ризалашты.

Исемлекне укып, барлап чыккач, никрутларны арбаларга бүлеп утырта башладылар. Лотфулла шәл очы белән битен яртылаш ябып, тавыш чыгармыйча гына сыктаган әнисен сакланып кына кочаклады. Аркасыннан сөйде. Битеннән иелеп үпте. Әтисе белән ике куллап кочаклашып саубуллашты.

—Исән йөреп сау кайт, улым!—диде әтисе калтыранган тавыш белән.—Үз-үзеңне сакла. Иншалла, үтәр хезмәтең!

Тавышы өзгәләнә башлады. Әтисеннән соң үзен озата килгән дүрт энесен кочаклап берәм-берәм битләреннән үбеп чыкты. Аларга бишәр тиен акча тоттырды. Әнисе пешергән төчекүмәчләр, корт катыштырып каймак тутырылган агач котырчык, бер пар яңа чабата, чолгау, кашык, чәй эчәргә балчык савыт салынган капчыгын күтәреп олаулар янына китте. Анда Җамали староста никрутларны арбаларга утырта башлаган иде инде. Арбалар янына килеп җиткәч, арттарак Лотфулланың исемен әйтеп дәштеләр. Кулына капчык тоткан, кәрҗин күтәргән Мирсәетен ияртkән Хәйдәргали хәлфә икән дәшүче.

—Әссәламәгаләйкүм!—диде ул, капчыгын җиргә куя-куя.—Синең салдатка китешмени инде?

—Озаталар бит. Китәм инде.

—Миңа да Җамали староста сезнең белән бергә Әкчүн стансасына хәтле барырга рөхсәт итте. Аннан инде сезнең белән бер вагунга эләгеп Уфага хәтле барырга иде исәп. Фәттах стражникка да әйтте, алып бар, дип. Анысы инде сезне Уфага илтеп тапшыргач, Эстәрлетамакка шуннан кайтып китә икән. Аннан инде минем исәп Уфадан Казанга барырга иде. Мирсәет дустыңны теге учительски ышкулга укырга кертеп кайтырга иде. Юлга җитәрлек акча юк. Шуннан Шакир абзый әйтте: “Син никрутлар белән бар Уфага хәтле”,—дип. Чыннан да буш чыга бит. Стражникка азрак төртми булмас инде. Мәгъзүмнең ходай гомерен озын итсен инде. Әнә чыкты мәдрәсәдән, болайга килә үзе дә.

Мәчетнең сул ягында урнашкан, урам якка өч тәрәзәсе караган мәдрәсәдән чыгып, Мөхәммәт Шакир хәзрәт килә иде. Аның якынлашканын күреп, халык тына башлады. Килеп җиткәч, аңарга гөрләшеп сәлам бирделәр. Хәзрәт сәламнәрне алып җаваплагач, кулындагы бамбук таягын иплəбрәк тотты да, кыска гына итеп вәгазь әйтте:

—Юлыгыз имин булсын, ак падишаһыбызга булган хезмәтегез тыныч узсын! Барыгызга да исән-имин кайтырга язсын туган илгә! Барган, хезмәт иткән урыныгызда мәчетләрне эзләп табыгыз. Начанствагыздан җомга намазына йөрергә вакыт сорагыз. Җибәрмәсәләр, миңа хат салыгыз. Мин Дума дипутаты буларак, аңарга рөхсәт алдыртырмын, иншалла! Урыс хезмәтендә булгач, хәрам ризык белән тукланырга да туры килер. Анысыннан тартынып тормагыз, ач йөрмәгез. Коръән Кәримебез хәрам ризыкны “бисмилланы” әйтеп өч очракта ашарга рөхсәт итә. Исегездә тотыгыз. Беренче очрак: карапка утырып диңгез кичкәндә. Шунда башкача ризык калмаган чакта. Икенче очрак: сугышлар барган чакта. Өченчесе: дошман кулында әсирлектә. Сезнең солдатта хезмәт итүегез өченче очракка

тәнгәл килә. Чөнки сез үз ирегегез белән бармыйсыз урыс патшасы хезмәтенә. Алып китәләр сезнең ризалыкны сорамыйча. Шунлыктан ул солдат хезмәте әсирлек белән бер санала. Көненә бер генә мәртәбә булса да, ул кич булыр инде дип уйлыйм, минем өчен намаз фарыз дип исәпләп, шуңарга ният кылып намаз укыгыз. Теләк булса, юынырга, тәһарәт алырга урын табыла ул. Кайда гына булсагыз да, урыс тоттырган мылтыгыгыз никадәр генә озын булса да онытмагыз—сез мөселман балалары. Ягез, бер дога!

—Әгүзү биллаһи минәш...

Лотфулла, мишәр егете Кәшшафетдин, Хәйдәргали хәлфә һәм аның улы Мирсәет бер арбага туры килделәр. Алар артыннан иң соңгы олау булып җинел тарантас урын алды. Җирән кашка җигелгән тарантаска Гафур писер белән Фәттах стражник утырдылар. Алар иң соңгы олау иде. Гафур Әкчүннән кире кайтырга, ә стражник Уфага хәтле китәргә тиеш иде.

Җамали староста кузгалырга боерык бирде. Атлы арбалар ике катлы таш кибетне унда калдырып, тыкрык белән Тау Асты урамына чыгып сулга борылдылар. Бикмәт тавы янындагы тыкрыктан унга борылып Чуаш юлына күтәрелә башладылар. Ике тау арасыннан юл текә итеп тауга үрмәли. Авылның иң биек, ләкин өстендә бер генә куак та үсми торган Бикмәт тавы мәһабәт гәүдәсе белән юлның сул ягында күтәрелеп басып, никрутларны озатып калды. Юл ике тау арасыннан үтеп, өскә менеп житкәч, Лотфулла артына борылып авылга карады. Тетрәнеп китте. Аста, юл читендә әтисе, әнисе һәм дүрт энесе басып торалар иде. Әтисенең таза, озын гәүдәсе янында әнисенең кечерәеп калган гәүдәсе мескен һәм кызганыч булып күренде. Аларның алдында басып торган дүрт энесе Лотфуллага кул болгыйлар, нәрсәдер кычкыралар иде. Лотфулланың күңеле тула башлады. Тауга каршы җәяүләп менгән никрутларны Җамали арбаларга утыртты. Лотфулланың аркасына кулын салып, аны йомшак кына иттереп арба ягына этте:

—Утыр, энем!—диде ягымлы гына итеп.—Юлчының юлда булганы хәерле.

Алдагы олаулар кузгала башладылар. Лотфулла өр яңа чабаталар кигән аякларын арбадан салындырып җайлап утырды. Җамали аңарга кулын биреп хушлашты.

—Хуш, Җамали абзый! Күрешмәсәк, бәхил бул!

—Күрешербез, энем! Күрешербез! Ак патшаның андый-мондый сугышлары күренми бит әлегә. Хәер...

Лотфуллага карап күңелсез генә елмайгандай итте:

—... кем генә белеп бетерсен инде ул урысның ... патшасын.

* * *

Шул кичне Әкчүннән бер вагонга төяләп, Уфага чыгып киттеләр. Вагонга кереп утыргач Лотфулла әйтте:

—Бу урыстан котылып исән-имин әйләнеп кайтырга язсын инде безгә. Исән кайта алсам, авылның иң ярлылары чабатачы Зәетдин бабай белән Мәфтуха түтигә хәер итеп бер сарыкны бирер идем. Алла кушып...—диде.

Мишәр егете Кәшшафетдин догалар укуга күчте...

Уфага килгәннен икенче көнендә өйлә житеп килгәндә, өяздән жыелган берничә йөз никрут арасыннан Лотфулланы Хәйдәргали хәлфә эзләп тапты. Ишек алдында, жиргә ятып йоклаган Кәшшафетдин янында кирпеч диварга аркасы белән сөялеп утырган Лотфулла үзенең фамилиясен ишетеп сискәнеп китте:

—Зәйнулли-ин Лутфулла-а! Тебя земляк ищет!

Ишек алдында тәртип саклап күз-колак булып торган унтер-әфисәр

кычкыра икән. Лотфулла урыныннан торып аңарга табан китте. Казарма ишек алдының уртасында Хәйдәргали хәлфә белән аның улы Мирсәет басып торалар иде. Капчыклары, кәрҗиннәре үзләре белән. Ике куллап күрештеләр.

—Безнен Агыйдел пристәненә төшеп баруыбыз. Казан каласына моннан парахут йөри икән. Минем әни ягыннан абзый бар монда Уфада. Шуның хатынының энесе парахутта кәчигәр икән. Ишетеп белә идем инде белүен. Исеме Кәрәметдин аның. Кода тиешле инде миңа. Шул парахут казаны астына күмер ыргытып, суын кайнатып пар чыгара икән. Шул парахут миче янында безне яшереп утыртып алып барырга ризалаштырды аны абзый. Алланың рәхмәте төшкере, икесенә дә! Төнен минем памушшикка мич эченә күмер ыргытышырсыз икегез дә, ди. Ыргытабыз, нигә ыргытмаска, дим. Эштән курыккан юк, Аллага шөкер!

Күнелле итеп көлеп куйды:

—Болай булгач, улым Мирсәет белән Казаннарына бушка барып җитәбез инде. Стражник Фәттахка бер тәңкә акча бирергә иткән идем, алмады, әй. Малаең бик шәпкә чыгарга охшаган, укысын әйбәт иттереп, ди. Шул булыр миңа түләү, ди. Йә, стражник диген инде син аны. Ходаебыз безгә мөселман булганлыктан, юнен биреп кенә тора...

Ун кулының учы белән Мирсәетнең аркасыннан сөеп алды:

—Менә Мирсәет улымның синең белән хушлашасы килде. Әйдә, ди, Лотфулла абзыйны күреп чыгыйк, саубуллашыйк аның белән, ди. Тенкәмә тиде бит иртәннән бирле. Аның янына кертмәсләр, дип тә карыйм. Юк. Үзенекен итте барыбер. Зимләки дип әйтербез, кертерләр шулай дисәк, ди. Аллага шөкер, үткер булырга ошый малай. Гурыт-кала дип тартынып тормый—сорый бөтен кешедән урысчалатып. Чатнатып сөйләшә.

Хәйдәргали абзыйның туктамастан күбрәк итеп сөйләве авылыннан аерылып чыгып киткән Лотфулланың йөрәгенә ял бирә һәм аңарга дәва иде. Әтисе аз гына туктаган иде, Мирсәет сорап та өлгерде:

—Лотфулла абзый! Сезне моннан кайчан озаталар? Әйттеләрме—кайсы якка икән?

—Бүген иртән тезеп әйттеләр. Кәшшафетдин белән икебезне Кырымдагы Киреч дигән крипостка җибәрәләр. Барыбызны да чишендереп, тоткалап карады бер әфисәр. "Сила нужны!"—ди үзе көлеп. Мине, Кәшшафне алды. Башкаларны юньләп карап та тормады. Кәшшафетдин ике ел инде авылларында сабантуй батыры икән. Куллар, аяклар, бүрәнә ишкән аркан кебек. Көче ташып тора. Безне бүген кич шул якларга бер унтер-әфисәр алып китә. Барлыгы алты кеше генә. Шул әйтте пышылдап кына: "Биригавай артилирия"—дип.

Хәлфә кабалана башлады. Кочаклашып хушлаштылар. Иртән Лотфуллага ике тәңкә дә, унбиш тиен акча биргәннәр иде. Юллык икән. Шуның бер тәңкәсен чыгарып Мирсәеткә сузды. Малай, алмаска ниятләп, ике кулын да артына яшерде.

—Тот! Тот!—диде Лотфулла, аның уң кулын артыннан тартып чыгарып. Безне бүген кич белән Харьков дигән калага озаталар. Тимер юл белән. Юлда ашаталар стансаларда. Тәүлегенә өч мәртәбә. Ашау патшадан хәзер безнең. Ялчылыкта йөрү түгел—ашауны кайгырту бетте.

—Ал, улым, ал биргәнне!—диде әтисе.—Укып кеше булгач ярдәмең тияр әле синең дә абзаңа. Ал. Онытмассың!

—Миңа ул Казан укуы тәтемәде инде. Син нык итеп, тырышып укы, яме! Кеше бул! Ходай кушса, тагын күрешербез әле—дөнья бит! Сау бул!

Хәйдәргалигә бер тәңкә акча сузды:

—Монысын Эстәрлегә кайткач әнигә кертеп бир. Улың Лотфулла җибәрде, диген. Дога укып алсын. Кайтырмын, иншалла...

—А-ай, рәхмәтләр генә төшкере җан икәнсең, Лотфулла! Әнкәнне дә онытмадың. Үзенә калмый да бит акчаң.

—Нәрсәгә ул миңа хәзер. Ашау байдан, үлем Ходайдан, дигәндәй минем бүгенге көнкүреш...

—Хуш, Лотфулла! Тапшырырмын! Исән йөре! Киттек, улым.

Аталы-уллы Солтангалиевлар капчык белән кәрҗиннәрен күтәреп, җәяүләп Агыйдел ярындагы пароходны эзләп, казарма ишек алдыннан чыгып киттеләр. Ишек алды уртасында Лотфулла ялгыз гына моңсуланып басып калды...

Татар халкының фаҗигале язмышлы улы Мирсәет Солтангалиев белән Лотфулла Зәйнуллин тагын ике тапкыр очрашачаклар әле:

1914 елда Герман сугышы башлангач. Сугышка алынган Лотфулла белән Мирсәет Эстәрлетамак каласында август аенда күрешәләр.

Соңгы тапкыр очрашулары 1923 елның гыйнвар башында Эстәрлебаш авылында, Мөхәммәт Шакир Тукаев йортында булачак...

* * *

Укучым!

Әгәр язмышың сине Эстәрлебашка алып барып чыгарса, аның үзәк мәйданындагы универмаг янына барып, йөзең белән каршы тауга карап бас әле. Синең каршыңда тауга карап үрмәләгән тыкрык-урам булыр. Шул тыкрык-урам каршыдагы текә тауга барып төртелеп туктар. Тауга тик сукмак кына үрмәли. Шул сукмак башланган урында, тыкрык беткән җирдә, уң якта булган элекке учительски ышкул.

Эстәрле халкы телендә шушы сукмак үрмәләгән тауның исеме бүген дә Учител Тавы була инде...

## ШИГЪРИЯТ



### Зөлфәт

### ҖИРНЕҢ ЙӨРӘГЕНӘ ЮЛЛАР ЯКЫН

**Дала уртасында ак теплоход...**

Юлы бетеп бара Иделкәйнең...
Зур Хәзәргә хәзер төшәсе...
Килә колач салып бер йөзәсе,
Каерылып ишкәк ишәсе!

...Идел читтә калды... Дала безне
Кунак итеп дәште түргәрәк.
Тик далада күреп була икән—
Чыннан да бит бу Җир түгәрәк!

Шулчак... әллә инде акылыма
Дала сихерләре сирпелде?—
Ак теплоход бара дала буйлап,
Карап туймас мираж шикелле!

Катлы-катлы "Титаник"тай бөят
Алсу мәкле дала түрендә!—
Иделкәйнең Хәзәр кочагында
Эреп юкка чыгар җирендә!

... Идел ярында тик мин аңладым:
Булган икән минем алдымда
Дала рәшәсенең шук уены—
Серле мираж түгел— чын дөнья...

...Югарыдан— очкычтан мин күрдем—
Таралгандай булды томаннар:
Менә кайда икән Иделкәйне
Тотып алып, буып салганнар!

Килгән юлы инде диңгез аның,
Юл дәвамы мәгәр... күр але!—

Шушы икән
Безнең буынга ят
Борынгы, чын Идел дигәне!

Казан янындагы шау дулкынлы
Сусаклагыч түгел икән лә!—
Бормаланып ага... Яры таллы...
Теплоходлар йөзеп үткәндә

Минем сыман
тын даладан, читтән
Кемдер кылса моны тамаша,
Әйтер:
—"Титаник"тай олы бөят
Дала буйлап бара лабаса!

...Сугынасы бүтән... Инде хәзер
Су коену хәтта тыела...
Әмма ярлар монда—чып-чын ярлар,
Борынгылар булып тоела!

Казан-Болгар күреп белгән ярлар
Күптән аккан ләмгә уралып...
Очкыч тәрәзеннән карап уздым—
Өнсез калды йөрәк беравык...

Күз алдына гел килә дә баса:
Без яшәгән сәер бу заман—
Дала уртасында— ак теплоход!
..."Титаник"ка никтер охшаган...

## Җир йөрәге якын гына...

Синең йөрәк тирән икән, Җирем...
Бәндәләреңнеке шикелле!—
Уйларыңны аңлар өчен килдем...
Шунсыз моннан китмәм бит инде?!

Җизказганның
Ачык шахтасына
Төшү генә түгел бу миңа—
Җир йөрәге сулык-сулык килеп
Торды сыман минем алдымда.

Кәбир кияү һәм Халисә сеңел
Көлә генә:
—Күбрәк йөр але!—
Кайнар руда гына булып калыр
Син әйткән
Бу Җирнең йөрәге...

... Катламнардан
җәһәннәмдә сыман
Сәер томан тоташ бөркелә,
Әйткән сыман:
—И беркөнлек бәндә,
Ниләр генә кылдың бу көндә?

Кратерларга төшкән кешеме мин?
Менә бүген—
ишетәм йөрәгең!
Иң гаҗәбе—
беленә лә икән
Өстә кемнең нишләп йөргәне?

... Аһ, шахтерлар...
Нишләде бу чорлар?
Андагылар—
туклар аңлармы
Җирнең хисләренә
Кушылып гел
Сулкылдаган
Тере каннарны?

...Җан җылысы
Шахта төбендәге
Җылыдан да, юкса, җылырак...
...Җирнең йөрәгенә
Юллар якын—
Җанга илткән юллар бик ерак...

## Остаханә

*Рәссам Әхсән Фәтхетдиновка*

—Сез бит аяк асларында яткан
Тамырларны таный белмисез!—
Алар аунап ята...
Алар төссез...
Мин күрмәсәм— алар билгесез!

...Гел яшәде миндә рәссам рухы...
Шуңа күрә дә бит, и Әхсән!—
Барлык рәссамлык хыялымны
Әгәр бүген сиңа сөйләсәм,

Әйтсәм әгәр күпме
Төп-тамырны
Өйгә ташыганны эт булып,
Сукраганны хатын:
—Кайчан шушы
Тамырлардан булыр котылып?!—

Ул хәлләрне син аңларсың инде...
Әхсән туган, тамырдаш ла син!—
Күктән ишеп яуган кардаш та син,
Таңда койган яңгырдаш та син!

Синең атың йортымда бит яши—
Моңнарның да моңы бит инде!
Бар язмышым
Шул ат белән бергә
Чапты... китте... Тәмам сүтелде...

...Остаханәңдә мин, Әхсән,
Өнсез булдым.
Кешене син бакый иткән бит...
Син— җан табигате генә түгел,
Табигатьнең җаны икән бит!

Кабатладың:
—Бөек әсәрләр гел
Аунап ята аяк астында—
Күрер күзең белән шуларны күр,
Янәшәгә килеп бас кына!

Сыйханәңдә, остаханәңдә мин
Түбәнге бу гүзәл Чулманда,
Әллә нинди серләр сөйләр сыман
Биек күкләр хәтта тынганда,

Җирләр күккә күтәрелгән чакта,
Йолдызлы күк җиргә төшкәндә—
Уйларымны меңгә тапкырлап гел
Йөрим, Әхсән, остаханәңдә!

Сөйләшергә мин табармын сине
Кара яңгыр, тоташ кар аша!—
Кардәштән дә кадерлерәк кешем—
Тамырдашым ла син ләбаса...

...Фикерең хак, дустым...
Бу дөньяның
Юк-бар җилләрендә җиллибез!—
Җир астына кереп
Сеңеп яткан
Тамырларны таба белмибез...

## Ыгымның агымнары

Ничекләр түзә комнары,
Ничекләр түзә яры?—
Гомернең адымнары күк
Ыгымның агымнары...

Чиге бар микән дөньяда
Шул кадәр ыргылуның?
Туктата алмастыр сине
Кыямәт хәтта, Ыгым!

Талпынгын тере суым син,
Алкынган тере суым!
Төн йокылары белмәгән
Сердәшем, серле Ыгым...

Юк, гади агым түгел шул
Ыгымның агымнары!—
Гомернең агымнары бу,
Гомернең адымнары...

## Дала

**Юл югалтмас кеше бар микән?**
**Бар булганбыз ерак киңлектән,**
**Көткән сөю, көткән хыянәт—**
**Тормыш үзе мәллә кыямәт?**
**Ни соң җирдә җанны җилкеткән?—**
**Юл югалтмас кеше бар микән?**

**Бар булганбыз ерак киңлектән!**
**Адашып ла бетмәбез микән**
**Эзсез сукмак, ерак юлларда?**
**...Тукталып бер тыңлап тын ярда**
**Шым калуны җаным гел көткән!—**
**Килгәнбез лә серле киңлектән...**

**Көткән сөю, көткән хыянәт,**
**Сакламадың, яшәү, син әдәп**
**Без кичәсе сәер дәвердә,**
**Алгысып гел узган гомердә**
**Бер җанга мең булды дүңгәләк...**
**Көткән сөю, көткән хыянәт!**

**Тормыш үзе мәллә кыямәт?**
**Атлап түгел, ятып-үрмәләп,**
**Яшәгәндәй иттек һаман да**
**Һичкем яшәмәстәй заманда...**
**Безнең исән калу— әкәмәт!**
**Тормыш үзе мәллә кыямәт?**

**Ни соң җирдә җанны җилкеткән?**
**Бу дөньяда безне кем көткән,**
**Нигә кирәк без бу дөньяга?—**
**Бездән башка да бит тын ага**
**Ап-ак болыт чагылып күктән...**
**Ни соң җирдә җанны җилкеткән?**

**Юл югалтмас кеше бар микән?—**
**Дала чиксез күккә тиң икән,**
**Керфек ачып гөлләр "гөлт!" итсә...**
**Дөрес яшәдем лә югыйсә,**
**Ләкин җаным бәлагә киткән...**
**Юл югалтмас кеше бар микән?**

## Тагын нишлим?

**Син килергә тиеш идең миңа**
**Мең давыллар кубар булса да...**
**Мең тылсымы белән көтеп торды**
**Син атлыйсы изге бусага...**

**Үзе ачылырга әзер килеш**
**Көтеп торды сине бу капкам...**
**Һичбер үзгәреш юк...**
**Бу дөньяма**
**Тоташ дулап, дөрләп ут капкан!**

**Син дип йолдызлы күк булдым инде,**
**Кайнар таңнар булып балкыдым—**

Менә шундый чагым...
Тагын нишлим?
Синең өчен тагын ни кылыйм?

## Ят бер йолдызлык...

Балкы, балкыш, безнең күңелләрдән!
Һәр теренең җаны хуш булсын—
Афәт өләшүче иблисләрнең
Хәстәр кесәләре буш булсын!

...Мин бит төнлә туган бер
Малаймын,
Шуңа күрә тәмам җенледер,
Сез белмәгән ят бер йолдызлыклы,
Гел адаша торган төнледер?

Ә барыбер
Гомер йомгагын мин
Үзем теләгәнчә сүтәрмен—
Гыйнвар кары белән бергә килдем,
Гыйнвар кары белән китәрмен...

## Барым да, берем дә...

Ходаем,
жылы сулышың
Кагылган сыман
Имин узам ла язмышның
Кыл уртасыннан!

Барым да, берем дә, мине,—
Тәгаләм, Ходам!—
Мәхрүм генә итә күрмә
Газиз яктыңнан...

Гомергә янымда булсын
Яраткан гынам!—
Шундый мәрхәмәтең булса
Сынмам, сыгылмам!

Якында итә күр инде
Яратканымны—
Сердәше булып калсын ул
Һәрбер таңымның...

Бу бәндәң сөюдән, Ходам,
Янган, балкыган—
Кабына аның сүзләре
Синең яктыдан!

Яклый күр!

Җанда Син барда
Абынмам, Ходам!
Мин— сау...
Алдымда Синең ут
Кабынган сыман...

*1998*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Гариф Ахунов**

# ТИМЕРХАННЫҢ ЭЗЛӘНҮЛӘРЕ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

## 1

Мәскәү вокзалында әзмәвердәй таза гәүдәле шофер күптәнге дусты Тимерханны күкрәгенә кыскач, тегесе тын ала алмыйча торды:

—Ну көч тә бар инде синдә, Арча егете! Пәрәметеки үтерә яздың бит!—диде мактауларга юмарт Борһанов.—Әле һаман шул эшеңдә эшлисеңме?

—Әйе, егерме елдан артык инде... Министрлар Советында... Кайчагында мактыйлар, беренче кул шофер син, диләр. Кайчагында эттән алып, эткә салып, атаң-анаң белән сүгәләр. Так ышту, төрле чак була минем, Тимерхан абый...

—Син бүген бик вакытлы килдең. Поезд да соңга калмады. Әйдә, Әмир, мине Социаль-тәэминат министрлыгына алып бар. Безнең ярты сәгать кенә вакытыбыз калды.

Четерекле заман иде ул. Кадрларны энә күзеннән үткәрә торган заман. Министрлыкта кадрлар бүлеге башлыгы белән сөйләшкәч, ул Тимерханга күрше бүлмәне күрсәтте.

Озын буйлы, ач яңаклы инструкторның бүлмәсе кечкенә, ләкин анда корыч сейф, папкалар тутырган пыялалы шкаф, бер тумбалы өстәл һәм терәкле ике урындык сыйган иде.

Кырыс чырайлы инструктор аның белән баш кагып кына исәнләште дә, утырыгыз дигәнне аңлатып, урындыкка таба баш изәде.

“Моның белән борчак пешмәс, ахры”,—дип уйлады Тимерхан.

“Борчак пешмәсе” күренеп тора—ач яңаклы инструктор, шүрәленеке төсле озын бармаклары белән шатыр-шотыр китереп, Тимерхан алып килгән кәгазьләрне актара, чыраенда бернинди дә җылылык сизелми иде.

Кәгазьләрне актарып бетергәч, һаман да җитдилеген саклаган хәлдә инструктор әйтте:

—Иптәш Борһанов, Сезнең бары да тәртиптә икән. Сугышта да булгансыз, депутат булып та сайлангансыз, эшләгән урыннарыгыз да зур, сез—номенклатура кешесе, биредә формаль сүз артык булыр. Минем сезгә бер генә соравым бар: хатыныгыз кайда эшли, балаларыгыз бармы?

Бу инде кешечә мөнәсәбәт иде. Тимерхан җәелеп китеп, мангаендагы

тирен ак кульяулыгы белән сөртә-сөртә, сөйләргә тотынды:

—Хатыным минем Минлеасия, гомер буе шәфкать туташы булып эшли, эшләгән урынында яраталар, кайда гына эшләмәсен, ихтирам итәләр...

Инструктор кисәтү ясады:

—Кыскарак тотыгыз.

Ләкин Тимерхан сөйләвенә бирелгән, аны тиз генә туктатып булмый иде инде:

—Балалар безнең өчәү. Олы улым Хафиз—Арчада ветврач, гел бер эштә, урын алыштырып йөрүне яратмый. Әнисе кебек. "Арча кайда?"—дип сорасагыз, ул—Татарстанның иң зур районы, иң күп язучыларны биргән як. Гомумән, Арча минә туган-үскән районым Мөслим кебек үк кадерле...

—Сез, иптәш Борһанов, читкә кереп киттегез. Кыскарак тотыгыз, зинһар.

—Алай да була,—үзен бүлдергәнгә Тимерханның бераз кәефе китте.—Икенче балам—Әнисә. Бик сөйкемле. Хезмәт ярата торган итеп тәрбияләдек. Өченчесе малай, Рафис исемле...

—Димәк, гаиләгездә тәртип,—дип йомгаклады инструктор. Мин сезгә бер киңәш бирер идем. Сезнең бар ягыгыз да килгән, эш кешесе икәнегез дә күренеп тора... Тик бер кимчелегегез бар—күп сөйлисез икән. Ә бит Социаль-тәэминат министрлыгында сезгә зарлары белән килүчеләрне күбрәк тынлап утырырга туры киләчәк.

Тимерхан аңлап алды: инструктор бик тә зыялы кеше булса кирәк. Зур урыннарда, зур түрәләр янында озак еллар эшләп бозылмаган, ул Борһановны ишеккә кадәр озата килде, кул биреп саубуллашты:

—Эшләрегез игелекле булсын!—дип соңгы сүзләрен әйтте. Киңәшен кабат искә төшермәде, Тимерханның китә алмыйча, ишек төбендә таптанып торуын күргәч, сорамый булдыра алмады:

—Нәрсә, иптәш Борһанов, әллә берәр йомышыгыз онытылып калганмы?

—Юк, ни...—дип тотлыгып җавап бирде Тимерхан.—Миңа министрның үзен күрергә кирәк иде...

—Сез хәзер кадрлар бүлегенә барыгыз, ул сезне министр урынбасарына алып керер. Бездә тәртип шулай куелган.

—Юк, миңа министрның үзен күрергә кирәк,—дип кабатлады Тимерхан.

Инструктор гаҗәпләнебрәк, тавышына борыч өстәп:

—Аңа керер өчен бер атна элек язылып куярга кирәк. Бу сезгә Казан түгел, Мәскәү,—диде. Аның яңакларында төерләр биешә башлады.

Тимерхан тирләп китте. Маңгаен кульяулыгы белән сөртә-сөртә, сүзләрен тамак төбеннән кысып чыгарды:

—Миңа Татарстанның Министрлар Советы председателе Гомәр Усманов Мәскәүгә киткәндә әйтте: "РСФСР Социаль-тәэминат министры Комарова Даина Павловнага минем сәламемне һәм ихтирамымны тапшырып, министрның үзен күреп, сөйләшеп кайтырсың",—диде. Усманов—бик төгәл кеше, әгәр мин иптәш Комарованы күрми кайтсам: "Борһанов, син кайда гына йөрдең соң?"—диячәк.

Инструктор тынычлана төшкән иде, яңак тирәсе астындагы төерләре биюдән туктады, телефоннан министрның өйдәме-юкмы икәнен белеште, Татарстаннан килгән Борһановның аңарда йомышы барлыгын, ул аны һичшиксез күрергә тиешлеген әйтте.

Аннары ул Тимерханга таба борылды. Ач яңагы алсуланып, төптә утырган коңгырт күзләре елтырый иде.

—Хәзергә Даина Павловна үзендә юк. Эш белән киткән. Кичке алтыдан да иртәрәк кайтмаячак,—диде.

—Минем министрны күрмичә китәргә хакым юк,—диде Борһанов.

—Алай да сез бик үҗәт кеше икән!—диде инструктор.

Мәскәү урамнарын карап, тагын министрлыкка килгәндә, сәгать алтылар тирәсе иде. Төп-төгәл алтыда министр кайтып керде.

Кабул итү бүлмәсендә утырган Тимерханга күз дә салмастан, үз дәрәҗәсен саклап, өстәл буендагы телефоннар янында утырган, чырае тулаем ярашучан, калын иреннәре кып-кызыл итеп буялган, кашлары җеп нечкәлеге итеп кенә калдырылган яшь кенә кызга:

—Катюша, кемнәр шалтыратты? Мине эзләп килүче булмадымы?—дип сорады.

—Шалтыратучы күп. Өстәлегезгә язып кертеп куйдым. Сезне күрергә теләүче менә Борһанов бар, Татариядән. Биш минутка аудиенция сорый,—диде секретарь кыз.

—Ярый. Керегез,—диде министр ханым, модалы кыска күлмәгенең итәген тарткалап куйгач, кабинетына үзе алдан кереп китте.

Кабинетка кергәч, Тимерхан югалып калды. Кабинет, инструктор бүлмәсенең капма-каршысы буларак, бик иркен, матур итеп бизәлгән, тиешенчә генә җиһазланган иде. Пыялалы кара шкафта Ленин томнары тезелеп киткән, алар шкафның ике киштәсен алып торалар, алардан соң "Зур Совет энциклопедиясе" ике киштәне били, аннары ак катыргы тышлы папкалар—алары еллык исәп-хисап кенәгәләредер инде...

Тәрәзәләр зур, якты, аларга калын-авыр шторалар һәм өрфиядәй нәфис челтәрләр элентән. Түшәм тип-тигез, ап-ак, стеналарга яшькелт обойлар ябыштырылган.

Тимерхан "ә" дигәнче боларга күз төшереп өлгерде, идәнне тутырып җәйгән бизәкле йомшак келәм буйлап барды да, министр ханым күрсәткән урынга—йомшак кәнәфигә, өстәл буена утырды.

—Исәнмесез, иптәш Борһанов. Миңа сезнең турыда әйттеләр, мин сезне белә дип исәпләгез... Йомышыгыз ни икәнен дә әйтеп җибәрсәгез...

—Мин Сезгә Гомәр Исмәгыйлович Усмановтан кайнар сәлам алып килдем,—диде Тимерхан, аяк өсте басып.

—Утырыгыз, утыр,—диде министр ханым, аның инде ольгаеп килүенә карамастан, туры борынлы аксыл йөзе әле мөлаемлыгын җуймаган иде. Усманов исемен ишеткәч, чыраен балкытып елмаю чыкты, ул гүя яшәреп, тагын да чибәрләнеп китте.

—Сәлам китергәнегез өчен рәхмәт! Мин бит үзем дә Гомәр кебек, житәкче урыннарда озак эшләдем: Брянск өлкәсенең башкарма комитеты председателе идем, Гомәр эшкә килгәндә, без өлкәннәр идек инде, аны—яп-яшь кенә чибәр егетне "юнга" дип атый идек. Юнганың кем икәнен беләсездер? Ул бит—яшь матрос дигән сүз.—Келтерәп кенә көлеп алды. Аннары министр ханым кинәт исенә төшеп:—Үзегез кайда урнаштыгыз?—дип сорады.

—Әмир исемле дустым бар минем, Арча егете, якташым. Ул сездә шофер булып эшли, сезне яхшы белә,—диде Тимерхан.

—Инде миңа керергә җөрьәт иткәнсез икән, минем сезгә ике соравым бар. Беренчесе—министр урынбасары эшенә үзегез теләп барасызмы, яки, номенклатурадагы хезмәткәр дип, мәҗбүр иттеләрме?

—Тәкъдим иттеләр, мин шуңа риза булдым.

—Менә бу, ичмасам, дөрес җавап. Инде тагын бер соравым: сезнең республикада, минем белүемчә, Мира Анатольевна Космодемьянская Социаль-тәэминат министры булып эшли. Хатын-кыз кул астында эшләве кыен булмасмы?

Бу сорауны Борһановның икенче мәртәбә ишетүе иде инде.

Тимерхан, сылтау эзләп торырга теләмичә, Табеевка әйткән сүзен кабатлады:

—Кыен булмас. Мин гомер буе хатыным кул астында яшәдем.

Комарова, Тимерханның уен-көлкегә бай кеше икәнен абайлап, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

—Мин татарларны ихтирам итәм. Алексей Максимович Горький шулай дип әйткәнгә генә түгел, үзем алар белән аралашканга. Бергә

яшәдек, бергә эшләдек. Партизаннар арасында да татар егетләре белән очрашырга туры килде. Үзләре генә булганда татарча сөйләшәләр, ачулары чыкса, урысча сүгенәләр иде.

Тимерхан, әйе, шулай, дип баш какты.

—Урысча сүгенү бездә сүгенүгә керми,—диде ул, ирен чите белән генә җемиеп куйды.

Министр ханым ана унышлар теләп, Гомәр Исмәгыйловичкә сәлам әйтеп, озатып җибәрде.

Вестибюльдә аны Әмир көтеп тора иде.

## 2

Казанга кайту белән Тимерхан Борһанов үзе эшләгән министрлыкны тәртипкә кертү турында хыяллана башлады. Ләкин ул, райбашкармада унбиш еллап эшләсә дә, тормышның әле сиңа бәйле булмаган яклары барлыгын онытып җибәргән иде.

Совмин рәисе Усмановка Мәскәү министры сәламен тапшырырга дип кергәч, Гомәр Исмәгыйлович урынбасары Мансур Хәсәновичны чакырып алды да аңа Тимерхан Борһановны коллективка тәкъдим итәргә кушты.

Хәсәнов—озын буйлы, күпме еллар җитәкчелектә эшләсә дә, юаная алмаган һәм картаюны белми торган кеше—Тимерханның күптәнге танышы иде. Тукайның 90 еллык юбилее вакытында ул Арчага атнасына ике мәртәбә кайтып йөрде, Тукайның Кырлайдагы музеен алар икесе—Борһанов һәм Хәсәнов төзеделәр. Эшне, уй һәм фикерне Мансур Хәсәнов башлады, киңәшләрен биреп, эш барышын күзәтеп һәм барлап торды, Тимерхан Борһанов аның боерыкларын җиренә җиткереп үтәтте. Шунлыктандыр, бәлки, Хәсәнов министр урынбасары булачак кешене якыннан белә, аның өчен Борһановның тормышын яңабаштан өйрәнеп тору кирәкми иде.

Министр Мира Анатольевна Космодемьянская кабинетына җыелды халык. Мира Анатольевнаның эшкә килгәненә дә бер генә ай, ул монарчы Яшел Үзән каласындагы партия комитетының беренче секретаре булып эшләгән иде.

Мансур Хәсәнов министр кабинетының яргаланган түшәмнәренә, буявы уңып беткән диварларына күз йөгертеп алгач, сүзен турыдан-туры башлады:

—Сезнең, җәмәгать, бу бинагыз бик тузган. Яңа бина төзергә кирәк булыр, Мира Анатольевна. Менә без сезгә министр урынбасары итеп яңа кешене тәкъдим итәбез. Тимерхан Борһанович Борһановны. Ул—Мөслимдә, Әтнәдә, Арчада партия-совет аппаратында эшләгән кеше: беренче секретарь, райбашкарма рәисе. Тәртипле, кешеләрне ихтирам итә, тыйнак. Ватан сугышы солдаты. Төзелешне белә. Без аның белән Кырлайда музей төзедек. Урысчасы да, татарчасы да камил. Ике мәртәбә Татарстан депутаты. Тагын нәрсә әйтим? Ике орден кавалеры. Кыскасы, мин сезгә бик яхшы кадр алып килдем.

Җилтерәтеп кенә кул чабып алдылар.

Министр ханым маңгаендагы җөен капшап алгач, алсуланып киткән чибәр йөзен сыпырып, кыска гына итеп әйтте:

—Без шатбыз. Тәҗрибәле иптәш килүенә сөенәбез. Мәскәүдән миңа шалтыраттылар: Тимерхан Борһанович аларда уңай тәэсир калдырган. Аның безгә эшкә килүе тагын бер шатлыклы вакыйга белән туры килә: бүген унберенче июль, аның туган көне—илле ике яшь тулган икән. Без аны яңа эшкә, яңа коллективка килүе һәм туган көне белән котлыйбыз. Аңа менә шушы чәчәк бәйләмен тапшырырга рөхсәт итегез!—Министр ханым Тимерханның кулына чәчәкләрне тоттырды, урысчалатып өч мәртәбә битеннән үпте. Тимерханга затлы хушбуй исе бәрелеп узды.

Министр ханымның кулы йомшак һәм җылы иде...

Әле эш башланганчы Тимерхан Борһановка кешеләр белән танышып чыгарга кирәк иде. Министрның урынбасары икәү булырга тиеш икән. Гаҗәп сәер фамилияле Петрашень Евгений Сергеевич эшне инструктор булудан башлап, барлык баскычларны үтеп чыккан, тәэминат өлкәсендә егерме елдан артык эшли икән инде. Петрашень аз сүзле, ягымлы, йомшак тавышлы. Өстәвенә әле ул ярдәмчел дә булып чыкты. Тимерханны ул иң әүвәле бирелгәге эш тәртипләре белән таныштыра башлады. Тимерхан уйлап алды: "Кая гына бармасын, аңа гел яхшы кешеләр очрый. Күрәсең андыйлар күптер. Начарлары, су өстендәге күбек кебек, яр читенә җыелганга гына күзгә ташланадыр. Эчкерле, мәкерле кешеләр алгарак чыгарга, ничек тә булса, күренеп калырга тырышалар шул"...

Ә икенче урынбасар Тимерхан Борһанов үзе булды бит инде.

Эшләп үскән кешегә эш муеннан. Аңа пенсияләр бүлеген алып баруны йөкләделәр. Башта ул бүлекне булдырырга кирәк иде әле. Булдырдылар. Аның башлыгы итеп Галина Александровна Романованы билгеләделәр. "Бәхет басты",—дип уйлады Тимерхан. Галина, университетның юридик факультетын тәмамлап, министрлыкка гади бер инструктор булып килгән. Шулкадәр дә зиһенле ул, пенсия законнарын яттан белә, теләсә кем белән бәхәсләшсә дә җиңеп чыга.

Министр ханымның да үзенә күрә шатлыгы, күңел юанычы бар: Арчаның райбашкарма рәислегеннән килгән Борһановны ул, пенсия мәсьәләләрен кайгыртудан тыш, төзелеш эшләренә җигә ала. Арча райбашкармасында аңа төзелеш белән җиң сызганып эшләргә туры килгәнлеген чамалый.

Чыннан да, Тимерхан Борһанов Казандагы төзелеш оешмаларын да, тәэминат учреждениеләрен дә биш бармагы кебек белә иде. Өстәвенә бит әле Яшел Үзән ягыннан булган оешмалар да моңа кушыла. Ни дисәң дә, Мира Анатольевна ул районда байтак тир түккән, оешма җитәкчеләрен якыннан белә, алар ул ни кушса, шуны үтәргә әзер торалар иде. Хәзер генә, ул Казанга күчеп, министр ханым булып эшли башлагач кына, чыгымламасалар...

Министрлыкның кабинетлары бик искергән, аларга капиталь ремонт ясатырга кирәк. Моның өчен зур чыгымнар таләп ителә.

Тимерхан, Мәскәүнең РСФСР министрлыгындагы тәртипне һәм гүзәллекне күреп кайткан булса да, министр ханым белән ул хакта ничегрәк сүз башларга белми йөри иде, Мира Анатольевна үзе көннәрнең берендә Борһановны кабинетына чакырып алды да сүз кузгатты:

—Тимерхан Борһанович, сез ничек уйлыйсыз, безгә министрлыкның кабинетларын ремонтлар вакыт җитмәдеме икән?

—Беләсезме, Мира Анатольевна, һәр яңа җитәкче эшне кабинет үзгәртүдән башлый. Аның өчен аны кайвакыт зур түрәләр тиргәп тә ташлыйлар, шелтәләр дә бирделәр. Мине коллективка тәкъдим иткәннән соң, Хәсәнов әйтте, бинагыз бик искергән, сиңа, Тимерхан, беренче эшең итеп ремонт эшләренә тотынырга кирәк булмагае...

Космодемьянская, алсуга кабынып, урыныннан торды, дулкынланып әйтте:

—Шулай дидеме? Бик яхшы. Алай булгач, ул безне яклаячак. Бүген үк Гомәр Исмәгыйловичка акча сорап хат языгыз.

—Юк, алай гына булмас ул, Мира Анатольевна. Безгә беренче чиратта ремонтның проект-сметасын эшләтү кирәк. Без менә шуннан соң гына күпме акча кирәклеген белән алабыз. Аннары бит Усманов укымышлы кеше, нәрсәнең нәрсә икәнен ул әллә каян белеп тора. Иң элек ул миннән: "Проект-сметагыз бармы?"—дип сораячак.

—Ә ул сметаны төзү еллар буена сузылса?

—Сузылмас. Таныш инженер-проектировщик бар минем.

—Алайса, хәере белән башлыйк бу эшне, Тимерхан Борһанович,—диде министр ханым.

Бәхете бар икән Тимерханның: таныш инженеры Казанда булып чыкты, бер атна дигәндә ул проект-сметаны өлгертеп тә бирде. Хәзер бу смета белән Министрлар Советына керү дә оят түгел иде инде.

Анда сметаны төгәл дип таптылар, ремонт өчен кирәкле акчаны Усманов министрлыкның исәп-хисабына күчертеп тә куйды.

—Ремонтны мин Мәскәүчә эшләтәм,—диде Тимерхан министр ханымга.

—Үзегез теләгәнчә эшләтегез. Хәзергә мин сезнең эштән канәгать,—диде Мира Анатольевна.

Эшне планнан тыш башкарырга дип, "Казпромстрой" тресты үз өстенә алды. Столярлар, сантехниклар, электриклар Яшел Үзән заводларыннан үз материаллары белән килделәр. Күрәсең, алар кайчандыр үзләрендә эшләгән Мира Анатольевнаны ихтирам итәләр. "Үз материаллары" дигәннән, алар фанер, пластмасса, идәнгә җәяргә паркетлар да алып килгәннәр иде. Дөрес, паркет министр кабинетына гына җәярлек иде. Космодемьянская анысына да тыны-көне бетеп сөенде.

Тимерхан бер минутка да ремонтчылар яныннан китмәде. Хәтере яхшы иде аның—Мәскәү министрлыгындагы кабинетларның, андагы келәм-паласларның, диварларның кыяфәтен ул күңеленә нык сендергән иде. Ремонтчылардан ул шуларны төгәл үтәтте.

Ремонтның тиз һәм яхшы сыйфатлы итеп башкарылуын күреп торган министр ханым урынбасары Борһановның үзенә аерым кабинет ясарга рөхсәт итте. Борһанов үзенә кирәкле кабинетның сызма-проектын министр ханымга күрсәтергә дип керде. Мира Анатольевна проектны кашларын җыерып карады. Борһанов үзе утырырга тиешле кабинетны чамадан тыш кечкенә итеп, Мәскәү министрлыгындагы инструктор кабинеты чаклы гына итеп планлаштырган иде.

Министр ханым проектны киредән эшләргә кушып, Тимерхан белән саубуллашмыйча гына, кашларын җыерган килеш үз кабинетында,—яктылыкны мул итеп эшләткән иркен кабинетында,—торып калды.

## 3

Эш яраткан кешегә эш муеннан. Тимерхан Борһановка пенсияләр бүлеген тапшырдылар, дигән идек инде. Бүлек башлыгы итеп билгеләнгән Галина Александровна Романова, матур һәм тату гаиләдә яшәгәнлектән, үзен бәхетле итеп сизә, дөнья янгыратып көлә, үзен башка хатын-кызлардан югары санамый, эшлисе эшен җиренә җиткереп башкара, инсафлы, таләпчән. "Көлгән түрәдән ерак кач",—дигән әйтем аңа ифрат та туры килә. Тормышта, гади иптәшлек мөнәсәбәтләрендә, Галина үзен дустанә итеп тота, әмма пенсия кебек четерекле мәсьәләгә кагыласыңмы—ул аяусыз, законга гына буйсына. Галина шулкадәр дә зиһенле, ул Татарстанда ничә пенсионер, ничә картлар йорты, инвалидлар җәмгыяте, ничә интернат барлыгын яттан белә, пенсия законнарын, бернинди кәгазьгә карамыйча, сүзмә-сүз әйтеп бирә. Андый законнарны моңа кадәр бөтенләй дә белмәүче Тимерхан Борһанович өчен Галина Александровна хәзинә булып чыкты.

Борһановның да хәтере әйбәт, башлаганына ярты ел була дигәндә, ул Татарстанны айкап чыкты, законнарны өйрәнде, өйрәнеп житә алмаганнарын—закон җыентыкларын үзе белән йөртә, районбашкармада озак еллар эшләгән булуы аңа хуҗалык эшләрен башкаларга караганда ансатрак һәм тизрәк башкарырга мөмкинлек бирә иде. Мира Анатольевна аны гел үз кабинетына чакырып, якты йөз белән каршы ала, төзелеш буенча берничә сорау бирә, ул сорауларның аны сынавы икәнен аңлый Тимерхан. Мира Анатольевнаның сорауларына җавап бирүе кыен түгел. Министрлар Советы рәисе Гомәр Усманов аны, ни сорап керсә дә, буш кул белән чыгармый. Тик Тимерханның үзе өчен язылмаган бер законы

бар—эше тәмам килеп терәлми торып ул Усмановны тинтерәтми, ә моны Усманов яхшы белә, шуңа күрә Тимерханның гозерен ничек тә үтәргә тырыша иде.

Тора-бара күрәләр, Тимерхан Борһанов төзелеш эшләрен авырсынмый башкара. Аңа интернат-йортларны ремонтлау, яңаларын төзүне тапшырсак, ничек булыр икән? Министр коллектив белән киңәшә дә, ризалыкларын алгач, Тимерханны үз кабинетына чакыра.

—Тимерхан Борһанович,—ди ул, тулган ай кебек балкып. Тимерхан белеп тора, Мира Анатольевна балкып каршы ала икән, димәк, ул эш кушачак. Ленинградта туган, Ульяндa Ленин укыган мәктәпне тәмамлаган, Яшел Үзән каласында озак еллар җитәкчелектә эшләгән ханым дәшми әле, урынбасарының кәефен тикшерә. Ул моны сүз белән дә тикшереп карый:

—Йә, ничек, Борһаныч, буразнага кердегезме инде?—ди.

Беркайчан да "өлешенә тигән көмешеннән" зарланмый торган Борһанов тигез ак тешләрен күрсәтеп елмая.

—Буразнага кереп җитә яздым, Мира Анатольевна. Безнең министрлыкта хатын-кызларның күп булуы ошый миңа. Ни генә димә, хатын-кыз заты ир-атка караганда миһербанлырак. Гарип-горабага карата, диюем. Нечкә күңеллерәк хатын-кыз заты...—Ул, нидер исенә төшеп, көлеп җибәрде.

—Нәрсәне исегезгә төшердегез?—дип сорый Мира Анатольевна, йөзенә кырыс матурлык чыгарып.

—Фикрәт Әхмәтҗанович Табеевның сүзләре искә төште. Ул миңа шушы министрлыкка эшкә күчкән чагында әйткән иде: "Сине, Тимерхан, Тәэминат министрлыгына күчерәбез. Хатын-кыз кул астында эшләргә ризамы син?"—"Риза, бик тә риза. Гомер буе хатыным Миңлеасияга буйсынып яшәдем мин",—дип җавап биргән идем. Моны миннән Мәскәүдә дә сорадылар. Әнә шулар искә төште дә көлеп җибәрдем. Бервакыт, беләсезме, Мира Анатольевна, безнең Әтнәгә, мин райком секретаре булып эшләгәндә, башкорт язучылары килде. Килде, ярый, хуш, кичен халык алдында чыгыш ясадылар. Мин дә булдым. Шуннан соң мин боларны ресторанга алып кереп, сыйлап утырам. Күрәсең, сүз артыннан сүз чыгып, озак утырганбыз. "Татарны тәмле телле",—диләр. Ә башкортларның көйләп-җырлап сөйләве перәме оета мине. Шул матур көйле тавышны тыңлап, күрәсең, озак утырганбыз, бервакытны ишек дөбердәп ачыла да минем хатын килеп керә. Керә-керешли үк кычкырып җибәрә Миңлеасия:

—Тимерхан, син Әтнәгә эшләргә килдеңме? Әллә бәйрәм ясап, сыйланып утырыргамы?

Бу юлы министр ханым көлеп җибәрде:

—Ә бит дөрес әйткән Асия ханым!

—Әлбәттә, дөрес.

—Менә шуңа күрә мин сезне, Тимерхан Борһанович, киңәшкә чакырдым да инде.

—Киңәшкәме, әллә йомыш кушаргамы?

Министр ханым ирен чите белән генә елмайды.

—Кайсысы шәп?

—Әлбәттә, эш эшләтү.

—Алайса, тыңлагыз: сез инде байтак районнарны йөреп чыктыгыз. Арча районының Яңа Чүриле бистәсендә төзелеп бетмәгән интернат-йортны күргәнсездер? Ул бит картлар йорты булачак. Шуны төзетеп бетерергә кирәк.

—Эшне нәрсәдән башларга?

—Урман хуҗалыгы министры Гуляевтән агачтыр-фәләндер аласыз. Моның өчен нәрсә эшләргә кирәген беләсезме?

—Беләм. Гуляевка язу язып бирергә.

—Әйе. Мөмкин кадәр җылы итеп языгыз.

—Анысын да беләм, Мира Анатольевна. “Жылы сөяк сындырмый” диләр бит. Тукай-Кырлайда музей салган чакта Гуляев белән берничә мәртәбә очрашырга туры килде.

—Йомырка тавыкны өйрәтми, дигәндәй, сезне өйрәтеп торасы юк. Кәгазьне бүген үк минем исемнән языгыз. Ул эш Гомәр Исмәгыйлович белән килешенгән...

Борһанов язуны бер сәгать эчендә язып кертте.

Министр ханым язуны укып чыккач, Тимерханга сораулы караш ташлады:

—Моны сез үзегез яздыгызмы, әллә урыслардан тикшертеп алдыгызмы?

—Үзем яздым. Фәкать үзем генә.

—Урысчагыз сезнең шулкадәр төзекмени?

—Мин бит армиядә эш башкаручы булып эшләдем. Барлык боерыкларны үзем яза идем.

—Шулаймыни?!—дип гажәпләнде министр.—Алайса, сез минем бәхеткә килгәнсез!

Ләкин аңа ай ярымнан соң тагын да ныграк гажәпләнергә туры килде: элекке ташландык вә җимерек йорт урынына кирпечтән салынган өр-яңа бина балкып тора иде. Арчада райбашкармада рәис булып эшләгән чакларыннан оста файдалана белде Тимерхан. Үзе яшәгән заманнарда күргән иң яхшы балта осталары, столяр һәм электрикларны туплау хакында райком белән, райбашкарма белән килешеп, аларга өстәмә түләү һәм бүләкләр вәгъдә итеп, осталарны төзелешкә китереп кушты. Арчалар белән шулай ук килешеп, әлеге осталарның тамакларын туйдыруны оештырды, үзе көн саен диярлек алар янында булырга, эшнең барышын күзәтеп, унбиш көн саен түләү оештырып бару, бер сүз белән әйткәндә, картларның, ялгыз калган карчыкларның соңгы елларын бәхетле итү өчен, ул жанын-тәнен аямыйча эшләде.

Бөкшәеп беткән картларның жыерчыклар тулы битендә зәгыйфь кенә елмаю күрү—аның өчен чиксез куаныч иде.

Менә шул мәшәкатьләр белән йөргән чагында, оештыру эшләре кулыннан килгәнне аңлау белән, аның күңелендә берсеннән-берсе матур уйлар кузгалды. Карале, баксаң-күрсәң, ул бит җәмгыятьнең ин дә кирәкле оешмасында эшли түгелме соң?! Шушы уй күңеленә килгәннән соң ул үзен бәхетле итеп сизде. Социаль-тәэминат эшенең чит илләрдә ничегрәк куелышы белән кызыксынды. Ләкин ул хактагы китаплар аз, булса да безнең илдә кешеләр язмышын кайгырту иң югары дәрәҗәдә икәнлеген раслыйлар иде. Бөек Октябрь революциясе булганнан соң Татарстанда кемнәр халык комиссары булып, тәэминат эшендә эшләгәнне беләсе килү, тәэминат министрлыгының узганы белән кызыксыну аның бөтен барлыгын биләп алды.

Ә көннәрдән бер көнне аның аңында министрлыкның музеен төзү уе кузгалды.

Музей ул—үткәннәргә якты күз белән карау. Музей—киләчәк көнебезнең өметләрен аклау өчен үткәннәрдән гыйбрәт алу. Атаклы авар шагыйре Рәсүл Гамзатов “Минем Дагстаным” дигән китабында әйткән: “Әгәр син үткәннәргә пистолеттан атсаң, киләчәгең сиңа туптан төрселдәтер”,—дигән.

Бик тә гыйбрәтле сүзләр!

Димәк, бүгенгебезне, үткәнебезне намуслы рәвештә барлап чыгарга, киләчәгебезгә булган өмет чаткысын сүндермәскә кирәк.

Музей экспозициясез була алмый. Шуңа күрә Татарстанда Социаль-тәэминат халык коммиссариаты кайчан төзелгәнне, аның беренче комиссарлары кемнәр булганны ачыклау Тимерхан Борһанов өчен төп мәсьәлә булып чыга бит әле.

Халык комиссариатының үзе эшләгән урында 1920 елны, ягъни Татарстан Автономияле Республикасы төзелгән елны ук булганын тапты

Тимерхан. Әмма аның беренче комиссарлары атылып яки Себер якларына сөргенгә җибәрелеп бетүен дә белде. Бу—аның өчен коточкыч хәл иде. Сугыш елларын узган, фронтовик булган кешегә моны белү ифрат нык тәэсир итте—йөрәгенә китереп сукты. Аңа унҗиде көн хастаханәдә дәваланып ятарга туры килде.

"Бу җәрәхәт гомер буе минем күңелдән китмәс инде",—дип фикер йөртте Тимерхан. Сталинда булган палачлык—милләтләрнең каймагын, иң зур зыялыларын юкка чыгару, үзенең тар маңгай сәясәтен үткәрү, янәшәсендә акыллы кешеләрне калдырмау нияте Тимерхан Борһановка барлык фаҗигасе белән ачылды. Өстәвенә атылган комиссарлар турында мәгълүмат юклыгы аны тирән кайгыга салды. Шуңа күрәдер, бәлки, ул мәкер белән, явызлык белән эче тулган "даһи Сталинны" яклаучыларны күрәлмәс булды.

Бу хәсрәт-үкенүләр аның җанын кайчанга тикле талар иде икән, бәлки, намуслы кешене мәгънәсез тормыш белән яшәгәне, Сталинга аягүрә басып кул чапканы өчен, караңгы гүргә дә тыгып куяр иде, шуның өстенә монсу көзнең иләмсез яңгырлары, ләпеккә батып, буксовать итеп яткан машиналары, узып барган тормышның сагышлары аның үлемен бик тиз якынайтырлар иде, әмма тормыш гел бер төсле генә булып тормый икән ул, үлчәү тәлинкәсендә кайгы белән шатлык тигезләшәләр икән.

Тимерхан Борһановка Казанның урта бер җирендә, һич тә көтмәгәндә, өч бүлмәле фатир биреп куйдылар. Шундук телефон да керттеләр. Кайгыларны күченү мәшәкате күмеп китте.

"Минем унҗиде ел буена Казан каласына бәрәнге әзерләгәнемне, шәһәр халкын азык белән тәэмин иткәнемне онытмаганнар",—дип уйлады Тимерхан.

Миңлеасия, әлбәттә, моңа сөенәчәк. "Болар барысы синең аркада бит, Тимерхан бәгырькәем",—диячәк. Мактауга да, тузынуга да оста аның хәләле. Олы уллары Хафиз инде өйләнгән, Арчада чакта алар бергә яшәделәр. Хафиз аз сүзле, йомшак холыклы бала, Арчада ул ветеринария врачы булып эшли. Күчеп киткән чакта аны Тимерханнар торган йортта калдыру ярамас, яшь гаиләгә башка урынга күчү дөресрәк булыр. "Райбашкарма рәисе үзе яшәгән фатирны малаена калдырып китте",—дип чүбек чәйнәүчеләр табылыр. Арчада да фатирга мохтаҗлар җитәрлек.

"Ике күченү—бер януга тора",—ди халык.

Әгәр саный башласаң, әлеге күченү сигезенчеме, тугызынчымы инде! Дүрт мәртәбә янганнар булып чыга Тимерханнар. Әйе, алар күченеп беткәнче, Хафизга Арчада фатир биргәнне көткәнче айлар узып китте.

Күченү мәшәкатьләре өстенә министрлыкта әледән-әле булып торган хәлләр гел дә тенкәгә тия иде.

## 4

Казанның Кремль ишегалдына карап, үз кабинетында уйга чумып утыра иде Борһанов. Берьюлы өч яктан килеп төшкән бәхетне күпсенә күрмәсеннәр. Казан каласында ул фатирлы булды. Миңлеасиясе гомер буе эшләгән эшенә—Казанның бер хастаханәсенә эшкә урнашты. Шәфкать туташы булып эшли. Сәламәтлеге аллага шөкер! Өченче бәхете—министр ханым аның үзенә һәм бүлегенә кабинетлар эшләтте.

Бу якты тәрәзә Кремль ишегалдына карый. Биредәге пөхтәлек сокланып кына торырлык. Әгәр Казанның барлык урамнары да, Кремль ишегалды кебек чиста-пөхтә булса, нәрсә әйтер идең кана, юк шул, Казанны чиста итеп, гөл бакчасы кебек итеп тотар өчен, урам себерүчеләрне алмаштырып бетерергә кирәк. Тоташ яшьләрне куярга иде урам җыештыручыларга! "Сиңа без фатир бирдек, рәхим итеп, үзеңә йөкләнгән эшне намус белән үтә!"—дип әйтергә булыр иде.

Шулай урамга карап, үз уйларына чумып утырганда, ишектән, шакымый-нитми, таза гәүдәле, йолкыш киемле бер адәм килеп керде. Исәнләшеп-нитеп тә тормастан:

—Мин Ростов-Доннан килдем. Ырымбурдан Сталинградка. Анда сугышкан идем. Акчам юк, акча бирегез миңа,—диде урысчалатып.

Тимерхан аның чүбекләре бөселеп чыккан бүрегенә, хатын-кызныкымы, ир-атныкымы икәнен аерып булмый торган пәлтә кисәгенә сәерсенеп карап торганнан соң:

—Бездә андый акча юк бит. Ростов-Доннан килсәң дә,—диде.

Таза гәүдәле урыс, сакал-мыек баскан битен күкрәк чаклы дәү пычрак кулы белән сыпырып алды да, ләм-мим дәшмәстән, борылып чыгып китте.

Ул да түгел, ачыргаланып кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелде.

Тимерхан: "Тагын нәрсә бар икән",—дип, коридорга чыкса, министр кабинетының ишеге ачык, тавыш шул яктан килә.

Тимерхан ашыгып шунда атылды.

Керсә, әле генә анардан чыгып киткән урыс, кулларын җәеп, аякларын аерып идәндә ята.

Аның янына бер хезмәткәр баскан, өч-дүрт хатын-кыз җыелган, аптырашып карап торалар. Мира Анатольевна да шунда, йөзе агарган, чыраенда курку, ул әкрен генә тавыш белән әлеге йолкыш адәмне торырга кыстый, ә тегесе нәрсәдер әйтеп, мыгырдана иде.

Тимерхан бу бүлмәдә бердәнбер ир кеше, идәндә яткан адәм өстенә иелде.

—Сезгә ни җитми? Нәрсәгә кыланасыз? Хәзер үк торыгыз!—дип усал тавыш белән дәште.

—Акча бирмәсәгез, бер кая да китмим, шушында ятам,—диде әлеге сәер адәм.

—Яхшы. Хәзер мин милиция чакыртам. Ята бирегез, алайса,—диде Тимерхан.

Егылган адәм, терсәкләренә таянып, аягына басты, ниндидер ямьсез сүзләр әйтә-әйтә, чыгу юлына таба китте.

Тагын бер сәгатьтән шул ук урыс янә дә министрлыкка килеп керде, бүлмә саен акча теләнеп йөрде, Мира Анатольевна аны кызганып, ун сумлыгын чыгарып биргәч кенә юк булды.

Ә кичкә таба, эш урыннарыннан тарала башлагач, министрлыкта эшләүче бер ханымның пальтосы югалганлыгы мәгълүм булды. Дөнья бетереп эзләсәләр дә, пальто табылмады. Аны кат-кат кереп акча теләнеп йөргән урыска сылтадылар.

—Әй, куллары корышкыры!—дип каргады аны пальтосын югалткан ханым.

Тимерхан да, башкалар да аны юаттылар:

—Кайгырма, без сиңа акча салышып, пальтоның яңасын алып бирербез,—диделәр.

Мондый хәлләр сирәк булса да, кабатланып тора, алар Тимерханны, музей төзү кебек, күңеленә кереп урнашкан хыяллардан аералар иде.

Беркөнне Хикмәт Шәйдуллин дигән адәм министрлыкка ау мылтыгы күтәреп килеп керде.

—Сез кайсы юлдан йөрисез, Борһанов? Миңа шуны әйтеп бирегез әле,—диде.

Борһанов урыныннан торды, йөзендә берниндн дә каушау юк иде, кергән кешегә чатнатып әйтте:

—Мин—фронтовик, кырык үлемне узып чыккан кеше. Мине шантаж-мантаж белән куркытырга маташмагыз. Беренчедән, сезнең ул мылтыгыгыз атмый, озак ятып күгәргән, икенчедән, сезнең патроныгыз юк. Өченчедән, сез—фронтовик түгел, күпме генә яңасагыз да мин сезнең пенсиягезне арттыра алмыйм...

Шәйдуллин сугыш елларында колхоз рәисе булып, бронь белән

калган тыл күсесе иде. Аның бер мәртәбә өстәмә пенсия даулап кергәнен Борһанов белә, җайлы гына сөйләшеп, аңа фронтовикларга бирелә торган өстенлекләрнең тиеш түгеллеген аңлатып чыгарган иде инде.

Бу юлы менә мылтык күтәреп кергән. Маңгай астыннан сөзеп карап, Тимерханны сынап маташа, имеш...

—Син миңа тишәрдәй булып карап торма, мин синең әбиеңне үтермәдем, милиция чакырткачы чыгып кит моннан!—диде Тимерхан.—Синең белән кешечә сөйләшәләр икән, акылыңа кил...

Шәйдуллин җилкәсенә аскан мылтыгын сала башлады. Хәрәкәтләре салмак, үз-үзенә ышанучан иде. Телефонга тотынсаң, аның тагын берәр төрле этлек эшләве мөмкин иде. Тимерхан, йә ат инде алайса, дигән кебек, тураебрак басты, күңеленнән шомлы уй узды:

"Әгәр аның мылтыгы корулы булса? Әгәр ул акылыннан ычкынып барса?"

Ләкин барыбер курыкканны күрсәтергә ярамый иде. Ул чагында каршы як кыюланачак. Кем белә, атып җибәрүе дә мөмкин.

Шәйдуллин мылтыгын җилкәсеннән озаклап салды. Бәлки, ул кадәр озак та булмагандыр, курыкканга куш, койрыгы белән биш, дигәндәй, каршы яклар бер-берсен сынйылар иде.

—Йә, ат!—диде Тимерхан, сабырлыгын җуймыйча.

Шәйдуллин мылтыкны иңбашына терәде, Тимерхан күзләрен йомды һәм... мылтык шартлаганга сискәнеп, күзен ачты.

Юк, мылтык атылмаган, Шәйдуллин аны идәнгә дөбердәтеп ташлаган икән. Ул инде ишеккә таба ашыгып атлый иде.

Тимерханның кинәт ачуы чыкты. Ул тавышына борыч өстәп:

—Әй, Шәйдуллин!—дип кычкырды.

Тегесе, сискәнеп, артына борылды, аның чырае качкан, бите кәфен кебек агарган иде.

Тимерхан әкрен, әмма дәһшәтле итеп:

—Ал бу чүбеңне! Юкса, эшең хөрти булачак,—диде.

## 5

Хәзер Тимерхан гаиләсе белән Казанда яши. Яңа урында мәшәкать никадәр күп, эше никадәр тыгыз булмасын, шәһәр шәһәр инде ул—шимбә, якшәмбе көннәрендә син үз иркеңдә. Район үзәгендә чакта ал да, ял да юк иде бит. Җәй көннәрендә син инде иртәнге дүрттән аяк өстендә, кышын да бик иркенәеп булмый, тәҗрибә уртаклашу, семинарлар үткәрү, язгы чәчүгә әзерләнү кебек эшләрне обком сиңа тагып кына тора. Шуларны көн саен диярлек барлый, кисәтү ясый. Апрель җиттеме, Тукай көннәренә әзерлек башлана. Түгәрәк датасы булмаган елны да Казаннан, автобуска төялеп, егерме биш-утыз кеше кайтып төшә. Аларны ипи-тоз белән, Казан юлына чыгып каршы аласы, Арча бистәсендә бер митинг, Тукай-Кырлайда икенче митинг үткәрәсе була. Аның белән генә эш бетми Тукайга, шигырь бәйрәменә багышланган әдәби кичә үткәрәсең колхоз клубында, һәвәскәрләрне әзерлисең, кунакларның тамагын туйдырасың, күңелләре булды микән дип борчыласың!

Түгәрәк даталарны инде әйткән дә юк. Анда инде йокы кача. Тукайның туксан еллыгында, йөз еллыгында Кырлай музееи өлгертү, бөтен илдән җыелган кунакларны каршылау, аларга урман аланында 150-200 кешелек табын әзерләү, яңгыр-мазар булса дип, табынны бөркәп куюлар. И-и-и, әйтерең бармы дигәндәй, кунаклары нинди бит әле аның! Дөньяга атаклы шагыйрьләр. Украинадан, Урта Азиядән, Финляндиядән, Беларусьтан... Ничек өлгергән дә, ничек "партачить" ителмәгән...

Казандагы тормыш... җәннәт бит ул. Башында мең төрле уй булсын—барыбер җәннәт.

Әкренләп ул үзенең якташларын да, сутыш вакытларында бергә

булган дусларын да таба башлады. Алар үзләре дә Тимерханнарның Казанга күчкәнен ишетеп, эзләп киләләр. Шундый очрашуларда яшьлек еллары, бергә үткәргән көннәр искә алына, үзәкләрне өзеп, ваемсыз чаклар искә төшә. Күрәсең, гомернең истәлекләр дөньясында яши торган заманнары житәдер инде...

Фатих Әмирхан кайсыдыр бер пьесасында: "Гайнетдин—кырык яшендәге авыл карты",—дип язган иде бугай. Кешеләр революция давыллары чыкканчы иртә картайганнар, ахрысы. Күз тимәсен, Тимерхан кырык яшьләрендә менә дигән егет иде әле. Ә менә алтмыш белән барганда, алай бик кукыраеп булмый шул.

Күргән-белгәннәр гел мактап торалар үзен. Син, Тимерхан, бер дә картаймыйсың, консервыланган кук, диләр. Андый чакта Тимерхан дәшми, ирен кырые белән елмаеп кына куя.

Шулай бер очрашуда Вәрәшбаш авылының Тимерхан белән бергә укыган Әхмәтгариф дигән кеше Борһанов белән килеп күреште.

—Саулыкмы, Тимерхан авылдаш? Сине очратуыбыз әйбәт булды әле. Мин сине күптән күрмәкче идем. Казанга күчкәненне дә, Тәэминат министрлыгында эшләгәнеңне дә ишеткәнием. Менә моны кем дип белергә телисеңдер? Бу чибәр ханым—минем хатыным була. Мәрзия исемле. Кстати, башкортлар көлеп сөйли бездән: "Татарлар үзләренең хатыннарын и п т ә ш дип таныштыралар, ә без, башкортлар хатыныбызны б и с ә к ә й дибез". Менә мин дә Мәрзияне сиңа хатыным дип таныштырам. Мәрзия—Сарман кызы. Син, бәлки, оныткансыңдыр да инде, сугыш башланган елларны син колхозда хисапчы булып эшли идең, гармунда кичләрен "Сарман" көен өздереп уйный идең. Хәзер дә тотасыңмы соң гармунны, әллә ташладыңмы инде?

—Гармун белән утырырга вакыт юк бит,—диде Тимерхан.

—Дөрес сөйлисең, авылдаш. Безнең белән яшьти булсаң да, жаваплы эшләрнең барысы синең өстә иде. Сугыш башланганда, без уналтыны тутырып кына киләдерик әле. Кырык икенче елның жәендә ФЗОга малайлар жибәрергә нәрәт килгәч, эти-әнисе тигез, үзләре генә дә яши алырлык дип, мине фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбенә яздырганыең. Каршы килеп булмый, сугыш вакыты, закуннар каты. Хәрби заводка эләктем, сугышка жибәрмәделәр, бронь белән калдырдылар. Баштарак сиңа рәнжеп тә йөргәнием, соңыннан, Мәрзиягә өйләнгәч, тынычландым. Ул аңлатты, минем егетләрем сугышта үлеп беттеләр, син минем бәхеттән исән калгансың, ди. Фашистларны кыра алмадым дип үкенеп яшәмә, син ясаган кораллар байтак гитлерчының башына житкәндер, ди. Менә шушы акыллы хатын белән матур гына яшәп ятабыз. "Чын тиле үзен, урта тиле хатынын мактар",—ди халык. Әммәдәген мин хатынымны мактыйм. Ник дибәйтеп әйткәндә, ул миңа биш бала табып бирде. Мин тоташ эштә булдым, балаларыбызны ул тәрбияләп үстерде. Барысы да инде башлы-күзле булдылар, аерым яшиләр.

—Барысы да Казандамы?

—Юк, төрле калаларда.

—Алай икән...—диде Тимерхан, тагын ни дип әйтергә белмичә.

Аны сүзсез калудан Әхмәтгариф коткарды:

—Әлеге дә баягы, Рамазан таягы, дигәндәй, бер сүзне кабатлыйм, мин сиңа, авылдаш, баштарак үпкәләп, рәнжеп йөрдем. Аннары өйләнеп, хатыным Мәрзиядән дә уңгач, тормышларым да рәтләнеп, үз жаена ага башлагач, бигрәк тә балаларыбыз аерылып чыгып, Мәрзия белән икәүдән-икәү генә торып калгач, сезне, Асия белән сине сагына башладым. Мин моны сиңа сабакташым дип, якын дустым итеп сөйлим. Безгә кунакка килегез, Алланың биргәненә шөкер әйбәт яшибез.

—Адресыгыз?—диде төгәллек яратучы Тимерхан.

Тимерханның күзен маңгаена менгерерлек итеп Әхмәтгариф түш кесәсеннән визит карточкасы чыгарып бирде.

Тимерхан аны кулына алды, күзлек киеп укыды, анда Әхмәтгарифның

торган җире дә, телефоны да, кайсы заводта мастер булып эшләве дә аермачык язылган иде.

—У-у, эшләр зурдан киткән икән синең!—диде Тимерхан, авылдашының өс-башын кабат күздән үткәреп.—Затлы бүрекләр дә, затлы пальтолар да киеп җибәргәнсең. Мәрзия ханымны да чук кебек киендергәнсең. Котлыйм, авылдаш!

Әхмәтгарифнең үзенә игътибар иткәнгә кәефе килде.

—А какже! Дөньяда бер генә яшибез бит,—диде.

Әхмәтгариф белән, аның хатыны белән урамда очрашу бәрәкәтле булып чыкты. Тимерханның исеме Казанда яшәүче авылдашлары белән көн саен диярлек очрашуга китерде. Йә алар урамда—ул һава сулап йөргән чакка туры киләләр, йә—һич югы—өйгә килеп керәләр. Шундый очраучыларның берсеннән сораган иде Тимерхан, тиледән туры хәбәр дигәндәй, әйтте дә бирде:

—Сезне авылдашыгыз, сабакташыгыз очраткан икән, аты коргыры—исемен онытып җибәрдем әле, шул сөйләп торды. Тимерханны күрдем, ди, ул галәмәт урында эшли, министр хәтле министрның урынбасары икән, ди, әммәдәген бер тамчы да эрәймәгән, гап-гади булып калган, ди, үзе и матур киенгән, үзе и матур итеп, кояшлар кебек балкып сөйләшә, бер елмаеп җибәрсә, авызын җыя алмый аптырап бетә, ди.

Боларны Тимерханның сыйныфташы Нурлыхәят сөйләде. Хатынкызның, бер сөйли башласа, туктый алмый торган гадәте бар: әллә кайчан, моннан илле еллар элек булган истәлекләрне яңартып, Тимерханны йәнә дә тарих дөньясына, сагышлар дөньясына кайтарды.

—И Тимерхан җаныкаем, хәтереңдә микән, син колхозда хисапчы булып эшли иең, без, алты кыз, сугыш афәте чыккан елны Вәрәшбашта бригадирлар булып эшлидериек. Урып-җыю вакыты, ягъни урак өстенең иң кызу чагы, эшләүчеләр җитешми, атларны сугышка алып бетерделәр, иң яхшы, иң күп тарта ала торганнарын. Комбайннар суктырган икмәкне басу читләренә—алдан чистартып куйган урыннарга бушаттырабыз. Көннекен көнгә ындыр табагына кайтарып өлгереп булмый. Кичләрен эшләнгән эш турында сиңа мәгълүмат бирәбез. Персидәтелдән иртәгәгә эшкә нәрәт алабыз да, өс-башны алмашып, клубка чыгабыз. Ни дисәк дә, без унҗиде-унсигез яшьлек кызлар бит.

Шулай бер көнне барыбыз бергә идарәгә мәгълүмат бирергә килдек. И Тимерхан, и җаныем, боларның күнелләре күтәрелеп китсен, дигәнсеңдер инде, бик якты чырай белән каршыладың безне. Ул да түгел, өстәл тактасына папкадан бер кәгазь чыгарып салдың. "Кызлар, менә бу документка кул куегыз әле",—дидең. "Без бик ашыгабыз, нәрәт алырга керәсе бар, укып торырга вакыт юк безнең".

Син әйттең, суктырып алган ашлык турында төзелгән акт ул, дидең. Алтыбыз да кул куеп, персидәтел янына нәрәт алырга кереп киттек. Берничә минуттан, Тимерхан җаныем, син дә идарә бүлмәсенә килеп кердең. Персидәтел нәрәт биреп бетергәч, син папкадан баягы кәгазьне чыгардың. Бу юлы инде синең чыраең якты түгел иде. Бик җитди, бик караңгы чырай белән, аяк өсте басып, син кәгазьне укый башладың. Бүлмә эче тып-тын булды. Без, сүзсез генә, бер-беребезгә карашып алдык.

Кәгазьдә мондый сүзләр бар иде:

"Без "Динамо" колхозының алты бригадиры (фамилияләребезне санап чыктың), сугып алган ашлыкны, көннекен көнгә ындыр табагына кайтарып аударырга тиеш булсак та, басуларда калдырабыз. Хәтта ки каравылчы да куймыйбыз. Бу соң урлашуга юл кую түгелме? Гаебебезне таныйк. Җәза бирүне үтенеп, имзаларыбыз..."

Син, абзыкаем, күзеңне дә йоммыйча, юри басым ясап, безнең исем-фамилияләрне кабатлап чыктың.

Без көләргә дә, җыларга да белмәдек. Бу әкәмәт кәгазь шаяртып язылган булса да, хак сүз әйтелгән, бу сүзләр бригадирлардан бигрәк, персидәтелгә кагыла иде.

—Ярар,—диде чырае качкан Низамов.—Тимерханны беләм мин. Шаярткан булып, йөрәккә пычак кадый ул. Ә сез, бригадирлар, моны мина иртәгесен үк әйтергә тиеш идегез. Хәзер менә кайсы басуга ашлык бушатылган, барыгыз бергә каравылга барасыз, таң атканчы монын тиешле чарасын күрү әмәлен уйлап табыгыз.

Без сине, Тимерхан, тукмап ташларга әзер идек. Беренчедән, бригадир кызлар, кичке уенга чыгудан мәхрүм калдык, төн йокламый, басудагы икмәкне сакларга мәҗбүр булдык, икенчедән, яшьлекнең канаты булган гармунчыдан колак кактык. Безнең урынга башка кызлар синең уйнавыңны тыңлагандыр инде...

## 6

Борһанов авылдашлары белән очрашканнан соң уйга калды. Авылдашлары аның үсмер егет чактагы хикмәтләрен онытмыйча, күңелләрендә саклыйлар икән, димәк, үткәннәрне онытырга ярамый. Ул яңа баштан авар шагыйре Рәсүл Гамзатовның сүзләрен исенә төшерде. “Үткәннәргә син пистолеттан атсаң, киләчәк сиңа туптан гөрселдәтер”. Әлеге сүзләрнең тирән мәгънәсенә ул менә хәзер төшенгәндәй булды.

“Музейны булдырырга кирәк. Халык үзенә, картлыгына нинди оешмалар ярдәм иткәнне белсен. Тәэминат министрлыгының тарихын күптән инде халыкка житкерергә кирәк иде. Ләкин чын дөреслекне “даһи юлбашчы” заманында халыктан яшереп килгәннәр. Чөнки министрлар “халык комиссарлары” дип аталган дәвердә аларны юк итә барганнар”,—дип фикер йөртте Борһанов.

Нурлыхәят Закирова белән очрашу, үсмер егет уйлап тапкан хикмәтләрне аның күпме еллар ихтирам белән күңелендә саклавы Тимерханны Тәэминат министрлыгының музеен булдырырга кирәк, һичшиксез, кирәк, дигән уйга китерде.

Нурлыхәят сөйләгәннәр аның өчен ифрат дәрәҗәдә кадерле иде. Ул аның фронтта зур батырлыклар эшләвен белә иде. Хатын-кыз башы белән ут эченә барып керү, сугыштан күкрәгенә орден-медальләр тагып кайту, “Батырлык өчен” медаленең генә дә икәү булуы, Тимерханга карата ничәмә-ничә еллар ихтирам белән каравы күп нәрсә турында сөйли иде.

Беркөнне ул эштән бик якты йөз белән кайтып керде. Аның арыпталып кайтуына инде күнегеп беткән Миңлеасия:

—Нәрсә әле син айның үндүртенче кичәсе кебек балкыйсың? Әллә орден бирделәрме үзеңә?—диде.

Йөзендәге якты чырайны бер генә мизгелгә дә югалтмаган хәлдә, ул ашыкмый гына өстен чишенеп, пальтосын чөйгә элде, йомшак башмакларын аягына элеп алгач, хатынын залдагы өстәл янына—каршысына утыртты да сөйли башлады:

—Бүген мине министр үз кабинетына чакырып алды. Министрлыкка ремонт ясаткан өчен дә, Яңа Чүриледә картлар йорт-интернат төзеткән өчен дә рәхмәт әйтте.

—Рәхмәтне телдән генә әйттеме, әллә приказ язып, благодарность белдердеме?—дип ашыгып сорады һәр нәрсәнең ачык булуын яратучы Миңлеасия.

—Рәхмәтне телдән әйтteләр ни, язмача белдерделәр ни—барыбер түгелмени?

—Слушай, Борһанов!—дип урыс сүзе кыстырды Миңлеасия. Моны ул кәефе китә башлаган чакларда сирәк кенә әйтә иде.—Слушай, Борһанов, барыбер түгел. Миңа, шәфкать туташының эшен җиренә җиткереп башкарганым өчен, көн саен ун авыру рәхмәт әйтә, мин аны үзем генә ишетәм. Баш врач бер мәртәбә миңа, приказ язып, благодарность белдергән иде, мин шундук халык теленә мендем.

—Ярар, синеңчә булсын, иртәгә приказ язар,—диде Тимерхан.—Минем шатланганым ул түгел. Безнең министр, Мира Анатольевна бик тә зыялы кеше. Кемнең нинди эшкә сәләтле икәнен ул бик тиз күреп ала. Мине бит ул башта пенсия эшләрен алып баручы урынбасар итеп куйган иде. Менә бүген әйтә, сез, Тимерхан Борһанович, ди, хужалык кешесе, сезне пенсия эшләрендә тоту гөнаһ, сез оештыручы, сезгә колач җәеп эшли торган эш килешә. Менә безнең Петрашень интернатларны җитәкли. Ул—яшь ягыннан да өлкән, җитмәсә—сугыш инвалиды. Әйдәгез, сезнең урыннарны алмаштырыйк. Интернатлар белән сез әйбәтрәк эшләрсез кебек тоела миңа. Сез командировкаларга йөрүдән дә җиксенмисез бугай.

—Ә син нәрсә дидең?

—Бу хакта Петрашеньның үзе белән сөйләшергә кирәк, ул риза микән әле, дидем. "Петрашень белән сөйләштем мин, ул биш куллап риза, командировкаларга бер дә чыгасы килми анын",—ди. Министр ханым шулай дигәч, мин шатланып риза булдым. Беләсеңме, әнисе, мин моны үзем өчен перспективалы эш дип саныйм. Минем әле сиңа әйткәнем юк иде, мин, әнисе, Социаль-тәэминат министрлыгының музеен төзергә хыялланып йөрим.

—Бушкамы?

—Әлбәттә.

—Ни чыкмаса, шул Борһановлардан чыгар. Алтмышынчы яшеңә таба барасың бит инде...

—Пенсиягә чыккач, әнисе, соң була. Син бит җыр яратасың. Халыкта шундый җыр бар:

Урманнарга керсәң, сызгырып кер,
Сискәнмәгән кошлар калмасын.
Дөньяларда шундый итеп яшә,
Сокланмаган дуслар калмасын!

Беләсеңме бу җырны?

—Белсәм, ни була?

—Миннән башка кеше булдыра алмый ул эшне! Чөнки ул эшнең кирәклегенә мин беренче булып төшендем.

—Ярар, үзеңә кара, сине бит уйлаган эшеңнән кире кайтару кыен,—диде Минлеасия.

—Менә рәхмәт, мин башта ук уйлаган идем, минем чибәркәем аңламый калмас әле мине, дип. Тәки шулай булып чыкты. Кил, үбим бер үзеңне.

—Кит әле, җүләрләнмә. Картаеп беткәч, юкмы тагын?!

Тимерхан кеткелдәп көлде дә портфеленнән бер шешә "ак башлыны" чыгарды.

—Менә бүген министрлыкның музее төзелә башлаган көн дип исәплә. Синең ризалык кирәк иде миңа, Минлеасия. Әйдә, табыныңны әзерлә. Бәйрәм итик шул шәрәфкә.

***

Эш таныш, Тимерханның беренче генә бина төзүе түгел. Законнар өйрәнеп баш ватасы юк. Көченне генә кызганма. Ул хәзер турыдан-туры районнардагы картлар йорты, гарип балалар интернатлары белән мәшгуль булды. Биналарны ремонтлыйсы, җиһазлар белән тәэмин итәсе, киемнәр һәм азык-төлек кайтарасы—кыскасы, эш муеннан булып чыкты.

Эш сәгате иртәнге тугызда башланса да, Тимерхан җидедә үк инде эш урынында. Интернат директорлары, интернатлары булган районнарның җитәкчеләре белән телефоннан сөйләшеп өлгерә, иртәнге сәгатьләрдә,

бигрәк тә тугызга кадәр, элемтә каналлары буш була.

Тимерхан тәэминат оешмасын анда эшли башлаганчы ук белә иде. Кайбер район житәкчеләре райсобес хезмәткәрләрен хөрәсән ялкаулары дип атыйлар, кукуруз басуыннан чүп утатып, яфрак азык әзерләтеп, бәрәңге алдырып тенкәләренә тияләр—колхозларга "шефлык" итүдән бушатмыйлар иде. Иң түбән хезмәт хакы аларда, кием алырга рәтләре юк, ә яшәргә кирәк. Колхозга бармас жиреннән барасың. Ичмасам, анда тамагың тук. Монысы—гади хезмәткәрләр хәле. Бүлек мөдирләре итеп югары юридик белемле кадрларны куярга кирәк. Районнар белән элемтә урнаштыргач, күрә, гадәти урта белеме дә таманча гына булган адәмнәр эшләп йөри, аларны колхозларда даими вәкил итеп тоталар. Шушындый башбаштаклык булганда, ничек инде социаль-тәэминат жәмгыятьне кайгырта алсын!

Иң начары—теләнеп йөрү. Казанның бер предприятиесенә шулай "теләнеп" барып чыгарга туры килде Тимерханга. Предприятие житәкчесеннән, пеләше исәбенә мангае зур күренгән, шома тулы битле кешедән, ремонтка шифер сорагач, ул әйтте:

—Сез ни бирәсез соң?—диде.—Мин бит сатып бирә алмыйм, баш на баш.

Кыяфәте бик житди икәнен, калын сары мыегының селкенмәвен дә күреп торган Борһанов аңлатырга тотынды:

—Туганкаем, бу шундый оешма, аның алмашып бирерлек әйберсе юк. Без йә сатып алабыз, йә, өлкәннәрне кызганып, сугыш ветераннарын кызганып, безгә бушлай бирәләр.

—Юк, кызганып та бирә алмыйбыз,—диде Шома бит. Ул ризасызлыгын тышка чыгармый булдыра алмады.—Хәзер теләнеп, кул сузып килүченең исәбе-хисабе юк. Сез бит, тузга язмаган оешма, мин сезне ишетәсем дә килми,—дип ычкындырып ташлады.

Тимерхан да төшеп калганнардан түгел, жавап эзләп кесәгә кереп тормады:

—Мин сезне аңладым, әфәндем, Социаль-тәэминат министрлыгына алай әйтергә ярамый. Сез хәзергә яшь тә, кәчегез дә ташып тора, килер бер көн, сез шәлберәйгән бер карт булырсыз, бу тәкәбберлегегез сезне кәкре каенга илтеп терәтер, менә шунда сез безнең оешманы искә төшерерсез!—дип чыгып китте.

Тимерханга булышырга теләүчеләр дә шактый. Шулай бер вакыт ул Госснаб башлыгының беренче урынбасары Сөләйманов янына зур күләмдәге акча тора торган электр товарлары жибәрүне сорап килә. Бу планда каралмаган. Сөләйманов башын кашып, бераз уйланып торганнан соң, әйтә:

—Тимерхан Борһанович, син бик мескен оешмада эшлисең. Сиңа товар жибәрсәң, ул планда каралмаган. Жибәрмәсән—сиңа ул товарларны бирәү дә бирмәячәк...

Ул Тимерханның үтенеч кәгазенә "Прошу рассмотреть. Сулейманов" дип резолюция яза да бүлек мөдиренә бирергә куша.

—Бу сүзләр миңа таныш, Мидхәт Мөхәммәтович,—ди Тимерхан, кәгазьне урынбасарга кире биреп.—Миңа бер нәрсә дә бирмәячәкләр. Сез менә бу "рассмотреть" дигән сүздән соң өч өндәү билгесе куегыз.

Сөләйманов көлемсерәп, баш чайкап тора. Шулай да өндәү билгеләрен куя.

Электр товарларын тоткарлыксыз жибәрәләр. Менә бит ул өндәү билгеләренең нинди тылсымлы көче бар. Ләкин бит әле шуны белергә дә кирәк.

Тимерхан—тынгысыз кеше. Ул өзлексез эзләнә. Төрле өлкәләргә барып чыга, китаплар укый, яңалыклар белән таныша. Аңа Иркутскида (безненчә әйткәндә—Өркет каласында) предприятиеләр исәбенә төзелгән әлләни хәтле картлар йорты барлыгы билгеле була, Мира Анатольевна имзасы белән Татарстан Министрлар Советына хат яза. Моның белән

генә чикләнеп калмый, телефоннан үзенең күргәннәрен-белгәннәрен өлкә комитетының бүлек мөдире урынбасарына сөйли. Ә урынбасар Тимерханны тыңлар-тыңламас кына тора да: “Юкны бушка әйләндереп, баш катырмагыз, иптәш Борһанов, алдан ук белеп торыгыз, без төзәмәбез аларны!”—дип кырт кисә.

Тимерханның төшеп калганнардан түгел икәнен бер әйткән идем инде. Бу юлы да ул җавапны тиз таба:

—Мин сезгә социаль-тәэминат турындагы карарларның башка өлкәләрдә ничек үтәлүен үзем күргәннәрдән чыгып сөйләдем, ә сезнең тыңларга да түземлегегез җитмәде, хушыгыз,—дип трубканы куя.

“Әйтсәң сүз, төртсәң күз чыга”,—ди халык.

Казанның Ленин районындагы административ бинасы каршында тугыз катлы йорт төзелеп бетеп килә. Аны РСФСР Министрлар Советы биргән акчага Татарстан Социаль-тәэминат министрлыгы салдыра.

Хакимият хуҗаларының, бу бина берәүгә дә кирәк түгел, дип еллар буе проект документларына кул куймыйча, министрлык хезмәткәрләрен интектерүләрен әйтеп тә торасы юк, бина салынып беткәнче урынбасарларның сәләмәтлекләре какшап, алар хәлдән таеп беткәннәр иде инде, ул да түгел, бина салынып бетәр алдыннан яңа министр Лоцмановага район җитәкчеләренең берсе килә.

—Сез райбашкарма бинасы каршында йорт салдырасыз икән. Мин сезне, Галина Павловна, алдан ук кисәтеп куярга тиешмен. Йортның фасадын һәм машиналар кую өчен билгеләнгән мәйданын икенче якка ясатыгыз. Чөнки министрлыкка килүче карт-корыны, култык таягына таянган гарипләрне карап торуы безгә күңелле булмаячак.

Моннан да ныграк вөҗдансызлыкның, инвалидларга карата ихтирамсызлыкның булуы мөмкинме? Министр Лоцманова, завод эшчесеннән күтәрелгән. Бары тик үз хезмәте белән генә көн күреп яшәгән кеше, битен каплап, кабинеттан чыгып китә.

Аллага шөкер, районның яңа җитәкчеләре ярдәмсез калган “карткарчыкның” хәлен яхшы аңлыйлар, социаль-тәэминат министрлыгының дә хәленә керәләр.

Министрлыкка йомыш белән килүчеләр күп. Карт-корылар гына түгел, тап-таза, яңь-яшь кешеләр дә аның юлын беләләр. Министрлыкта кабул итү көннәре һәм сәгатьләре күрсәтелми. Кабул итү көннәр буе бара. Чөнки өлкән яшьтәге кешегә, сугыш һәм хезмәт инвалидына, минем кабул итү көнем түгел яки, эш сәгатем бетте, дип әйтү гөнаһ булыр төсле тоела.

Төрле кеше килә. Акыл-зиһеннәре сау-сәламәтләре белән бергә, авырулар да кергәли. Шундыйлардан берсе көн саен кереп чыга, акча сорый, бәйләнә.

—Мин синең кайсы юлдан йөргәнеңне беләм. Бүген өеңә кайтып керергә өметләнмә, ди.

Тимерхан сабыр. Ул йомшак кына итеп әйтә:

—Мин беләм, сез биш мең тәңкә акча өчен намусыгызга тап төшерә торган кеше түгел.

—Ярый, алаеч, бүгенгә калып тор, исән-сау бул,—дип чыгып китә теге бәндә.

Хикмәти хода—дөньяның кеме генә юк. Берәүләр, мин космонавт булган чакта, дип әкият сөйли. Икенчеләре, мин фронтта командующий идем, дип министрлык коридоры буйлап, команда бирә-бирә марш атлап йөри.

Тимерхан аларны сүзсез генә тыңлый, алар аның ышануына ышанып, бераздан үзләре чыгып китәләр.

Чыкмый торганнары да була.

Казанның кайсыдыр районнан таза гәүдәле бер егет килә. Диңгезчеләр киеме кигән. Тимерхан утыра торган кабинетка килеп керә. Ул фронтта чыннан да булган—моряк чактагы фотосын күрсәтте. Аның килүе

алты тулгач, кешеләр дәррәү эштән китеп барган чакка туры килә. Башта ул сүзсез утыра, аннары акча сорый, куркыта, яный башлый. Тимерхан аңа берничә мәртәбә үз акчасын да бирде. Моряк һаман килүдән туктамый. Бу хәлне Тимерхан, якын итеп, Петрашеньга сөйләде.

Петрашеньның тәэминат оешмасында эшләгәндә төрлесен күргәне бар. Борһановка ул үзе белән булган хәлне сөйләде.

—Шулай бер заман, Җиңү бәйрәме алдыннан, орден-медальләрне тагып собеска килдем дә, кабинетта уйланып утырам. Бер кеше ау мылтыгы тотып, шашынып килеп керде. Минем күкрәк тулы орден-медальләремне күргәч, каты итеп бер сүгенде:

—Мин син кабәхәтне атып үтерермен дип кергәнием, ярый инде бәхетең, фронтовик икәнсең, киттем, ананның кабер такталарын!—дип сүгенеп чыгып та китте.—Син, Тимерхан, бик йомшак холыклы кеше. Сиңа кереп, акча талап йөргән егет, акылы алышынган дигәч тә, бигүк җүләр түгел, гел куркыту ягына эшли, синең награда колодкаларың шактый, шуларны тагып йөр. Колодкаларга сәламәт акыллы кешеләр генә түгел, психик авыруларның да күзе бик тиз төшә...

Тимерхан министрлыкка орден-медаль колодкаларын тагып килде, теге моряк та кичке алтыдан соң килеп житте. Күзен шарландырып колодкаларга төбәлеп торгач, бер сүз дә дәшмичә чыгып китте.

Бүтән вакытта аның беркайчан да күренгәне булмады.

## 7

Тимерхан Борһанов районнарга чыгуны мөһим эше дип саный иде. Бу, бер яктан, күңелендә сер итеп тоткан музей төзү өчен экспозиция материалларын өйрәнү һәм туплауга мөмкинлек ачса, икенчедән, картлар йорты төзүгә җирлек тудыра иде.

Районнар, башлап йөрүче, проектларын әзерләүче булгач, бу эшкә җиң сызганып керештеләр. Актанышта, яңа типтагы проект белән, берике ел эчендә колхоз ветераннары өчен илле кешелек йорт әзерләнеп бетү аның җанына сөенеч алып килде. Берничә районга ул үзе эзләп тапкан проектларны җибәрде.

Яшел Үзән каласында, урман буенда, интернат-йорт төзелеп, анда өч йөздән артык картлар, карчыклар урнаштырылды.

Болар үзләре генә дә Тимерхан Борһановның йөзенә кызыллык китермәслек эшләр иде. Әмма аның башкарасы бик зур эше бар—ул эш министрлыкның музеен төзү иде.

Гомернең узуына исләрең китәрлек! Әле кайчан гына Мәскәүгә барып, расланып йөргән иде, әле кайчан гына ремонт эшләре белән шөгыльләнгән иде, районнарда төзеләчәк картлар йортларына проектлар эзләп, ил буйлап чапкан иде, инде менә пенсиягә чыгар вакыты да житеп килә.

Хәер, ул бит министрлыкка илле ике яшендә килде. Көн артыннан көн, ай артыннан ай, ел артыннан ел уза тора. Әнә бит Космодемьянская пенсиягә китеп барды. Үзеннән соң тугыз катлы йорт салып калдырды. Бу йортның озын коридорларына, кояшлы кабинетларына кергән саен аны искә алачаклар. Гомерлек һәйкәл салды Казан каласына! Ленинград кызы Казан каласына һәйкәл салды!

Яңа министр булып Лоцманова Галина Павловна расланды. Яшь ханым ул, озын буйлы, чибәр, холкы тигез, үзе чамадан тыш беркатлы. Әнисе, ире, бер кызы бар. Ул әле цехтан, монтажчы дигән белгечлектән. Кыскасы—гади эшчедән күтәрелгән. Моңарчы ул җәмәгать эше буенча—партия Үзәк Комитетында ревкомиссия әгъзасы иде. Ләкин шул кадәрле зур урын да аны боза алмаган, гади итеп, тиз аралашучан, халык вәкилләренең сүзенә колак сала торган итеп калдырган. Башта ул, бик яшьләй электротехник училище тәмамлаган, аннары читтән торып югары

партия мәктәбен бетергән. Акылы, фикер йөртүе—министр булырлыгын әйтеп тора. Тик аңа әле тәҗрибә тупларга кирәк.

Инде пенсия яшендә булса да, әле тагын бер ел яңа министр белән эшләде Тимерхан. Тәҗрибәсез кешене ташлап китәргә ярамый иде.

Бер ел эшләгәч күрә: министр ханым зирәк, алдан күрүчән, мөстәкыйль фикер йөртә белә. Иң тынычландырганы Тимерханны—эштән курыкмый, йомыш белән килгәннәргә игътибарлы, күңеле нечкә—кызгана белә. Инде Тимерханга китсә дә ярый.

Һәм ул китте. Аңа персональ пенсия билгеләделәр. Инде менә тормыш көйле, балалары өчесе дә башлы-күзле булдылар, Миңлеасиясе һаман үз эшендә—шәфкать туташы вазифаларын башкара, пенсиягә чыгар вакыты узып китсә дә, яраткан эшеннән аерыласы килми.

"Хыялымны тормышка ашыра башларга вакыт",—дип уйлый Тимерхан. Хыялы аның—музей төзү. Моны Миңлеасия белә дә, үзе генә белә. Ләкин пенсиягә чыгып, бер атна да тормады, аны Лоцманова чакырып алды.

—Тимерхан Борһанович, кадерлем, кадрлар бүлегендә эшләргә кеше кирәк. Үзегезгә мәгълүм, бездә хезмәт хакы түбән, эшкә килүче юк, кадрлар буенча инспектор булып вакытлыча булса да эшли алмассыз микән?—диде.

—Мин риза, тик бер шарт белән...

—Нинди шарт ул, әйтегез?

Борһанов башта әйтергәме-юкмы дип икеләнеп торды, аннары, беткән баш беткән дип, әйтергә булды.

—Минем әле моны берәүгә дә әйткәнем юк иде. Хатынымнан башка дип әйтик...

—Тимерхан Борһанович, сузмагыз.

—Ярый алайса, әйтәм, минем күңелемдә күптән инде министрлыкның музеен төзү уе йөри иде.

—И җанкисәгем, күптән шулай диләр аны. Ел буе бергә эшләдек. Ә сез миннән яшереп йөрисез шуны. Ул уй минем дә башыма килгән иде бит.

—Шулаймыни?!—дип сөенде Тимерхан.—Алайса, сез минем музей төзүгә риза?

—Риза гына түгел, ярдәм дә итә алам. Бинабыз үзебезнеке бит хәзер. Анда теләсә нинди музей төзеп була. Мин сезнең оештыра белүегезне күрдем бит инде...

Тимерхан Галина Павловнаның сүзләреннән шул тикле дәртләнеп китте, ул аны кочаклап алырга әзер иде.

Министр ханым белән килешеп эшләү Тимерханга да, Галина Павловнага да файдага булды. Тимерхан документлар белән бик төгәл эшли, күрәсең, армиядә эш башкаручы булуы бушка китмәгән. Кадрлар бүлегендә ул бер-ике ай эчендә бөтен эшне яңадан үзгәртеп корды: министрлык хезмәткәрләренең һәркайсына аерым папкалар булдырды, йомыш белән килүчеләрнең документларын хәзер сәгатьләр буе эзлисе юк, аларны "ә" дигәнче табарга була. Борһановның төгәллеге бүлек мөдирләренә дә йокмый калмады. Төгәллек, үзенә йөкләтелгән эшне вакытында, төгәл итеп башкару ягыннан министр ханым Борһановның эшләү стилен аларга үрнәк итеп күрсәтә иде. Аны ихтирам итәләр, аны тыңлыйлар, министр берәр кая китсә, йомышларын аңа кушып калдыра. Интернат директорларына боерыклар бирү, райсобеслар белән элемтәгә керү, Министрлар Советына кереп, аерым мәсьәләләрне хәл итү, Мәскәү белән сөйләшеп алулар—барысы да аңа йөкләнә һәм ул аларны авырыксынмыйча башкарып килә.

Шушы эшләрне вакытында, җиренә җиткереп башкару аның житәкче оешмалар алдында абруен күтәрде—социаль-тәэминат тарихын кешеләргә күрсәтеп бирү уен көчәйтеп җибәрде.

Хәзер инде бу эшкә мөмкинлек туды.

Беренче итеп архив материалларын кузгатасы иде. Шул максат белән баш архив идарәсенә килде. Министр Галина Лоцманова имзасы куелган үтенеч кәгазе иде кулында. Идарә башлыгы Тамара Прохорова аны хуплады. Тиешле белешмәләрне алгач, архив хезмәткәрләре белән бергә Тимерхан 1917 елның декабреннән җыйналып килгән тарихи документлар эченә чумды. Әлеге гамәле аның холкына туры килә, тарихны ул мәктәп эскәмиясеннән үк ярата, социаль-тәэминат өлкәсе аңа таныш—иренмәскә генә кирәк.

Язмышлар, язмышлар...

Саргаеп беткән кәгазьләрдә кеше язмышлары ята.

Һәр туган көн яңа язмышлар алып килә.

Тимерхан музей өчен кирәкле кәгазьләрне күчереп ала. Еллар тәртибе белән белешмә төзи, фоторәсемнәрне зурайттыра...

Архив хезмәткәрләре аның тырышлыгына сокланып карыйлар.

"Әллә элекке елларны сез архивта эшләгән идегезме?"—дип сорыйлар.

Шактый күләмдә белешмәләр туплагач, 1990 елның башында ул министрлыкка әйләнеп кайта. Инде музей төзү өчен башлангыч документлар җитәрлек сыман. Инде социаль-тәэминат тармагына җитәкчелек иткән комиссарлар, министрлар, бүлек мөдирләре турында мәгълүмат тупларга кирәк.

Ләкин менә монда инде эш комга терәлде.

Тимерхан белде: егерменче-утызынчы елларда эшләгән җитәкчеләр барысы диярлек кулга алынып, атып үтерелгәннәр. Гаепләнүчеләр хакында архив идарәсендә материаллар йә бөтенләй юк, йә "дело"ларның тышлары гына бар. "Дело" эчендәге кәгазьләрне суд тикшерүчеләре алганнар да кире кайтармаганнар. Шунлыктан кемнәрнең кайсы елларда нарком булып эшләвен һич кенә дә ачыклап булмый.

"Бар икән күрәселәр, юк икән үләселәр!"—дип аптыраšта кала Тимерхан. Нуҗәли аның ничәмә еллар хыялында йөрткән төп эше тузан булып җилгә очар?

Киңәш-табыш итеп, зур урындагы кешеләр белән сөйләшкәч, Тимерханга партия архивына барып карарга куштылар. Моны Борһанов дөрес дип тапты. Ник дигәндә, наркомнар барысы да партияле кешеләр булган бит.

Ул министр Г. Лоцманова имзасы куелган үтенеч кәгазен кулына тотып, партархив мөдире Дамир Шәрәфетдиновка юнәлде. Дамир аны ягымлы каршылады. Бүлек мөдире Надежда Устиленконы үз кабинетына чакырып, тиешле ярдәмне оештырырга кушты.

Бу юлы Тимерхан архивта айдан артык утырды. Халык комиссарлары—наркомнар турындагы мәгълүмат партахивта шактый ук сакланган булып чыкты. 1936 елны партбилетлар алыштырганда тутырган анкеталар исән иде. Халык комиссарларының анкетадагы бәләкәй фотоларын да зурайтып бирделәр аңа. Хәзер Тимерхан кулында ике архивтан да алган рәсми документлар бар. Аларны еллар тәртибе белән бөтен бер белешмә итеп төзисе калды. Шулай да документларны тәртипкә китергәч, архивларда "дело"лары сакланмаган наркомнар, аларның урынбасарлары, бүлек мөдирләре барлыгы билгеле булды. Чөнки 1936 елга кадәр, ягъни партбилет алыштырганчы, партиядән чыгарылганнарның анкеталары юк. Алар турында өлкән яшьтәге кешеләрдән, якын туганнарыннан сорашып кына мәгълүмат алу мөмкин булачак.

Ләкин аларны каян табарга?

"Эзләгән табар, ташка кадак кагар",—ди халык.

Тимерхан бер генә минутка да министрлыкның музеен төзисе барлыгын исеннән чыгармады. Урамга саф һава суларга чыккан чакларында, очраган бер кешегә, ул хәзер музей төзү хакында сөйли, "сез фәлән кешенең туганын белмисезме?"—дип сорау бирә торган булып китте. Сораша торгач ул Ибәтуллин Абдулла барлыгын белде. Абдулла егерменче

елларны ятим балалар йортында тәрбияләнгән кеше икән. Балигъ булгач, наркоматта йомышчы булып эшләгән, соңыннан, совет власте елларында, Мәскәүдә халык хуҗалыгын электрлаштыру оештырган инженер. Абдулла гаҗәп хәтерле кеше булып чыкты: ул барлык урамнарны иске исеме белән белә, кайсы урамда нинди бинада кайсы наркомат булган, анда наркомнар булып кемнәр эшләгән, аларның язмышлары ни рәвешле беткән—барысын, бүген генә булгандай, ачык итеп сөйли. Абдулланың соңыннан эшләгән урыны да күренекле: ул бит, пенсиягә чыкканчы, Татарстан Министрлар Советының материаль-техник тәэминат идарәсе башлыгы булып эшләде.

Музей төзү тәртипләре белән танышу өчен Тимерхан Мәдәният министры урынбасары Мөҗип Низамиев янына барды. Әкрен сүзле, кап-кара чәчле, ягымлы чырайлы Мөҗип Тажиевич үз кабинетында аны бик тә үз итеп:

—О-о, Тимерхан Борһанович! Нинди җилләр ташлады сине Мәдәният министрлыгына?—дип каршылады.

Ул аны Арчада райбашкармада эшләгән заманнарыннан ук белә. Арчада, дөресрәге, Кырлайда Тукай музеен булдырырга түккән көче, урманнан диләнкәләр алып, аны кистереп, балта осталары яллап йөргәне өчен ихтирам итә иде. Европа күләмендәге музей булып чыкты ул Кырлайдагы Тукай музее!

Тимерханның Социаль-тәэминат музее төзү артыннан чапканын белгәч, Мөҗип көлеп җибәрде:

—Хыялый кеше син, Тимерхан Борһанович! Валлаһи газим дип әйтәм—хыялый. Син әле бушлайга эшлисеңдер? Әйтәм бит—бушлайга! Синең кебек кешеләр күбрәк булсын иде бездә. Сиңа мин хәзер музей төзелеше буенча иң зур белгечне табып китерәм.—Ул телефон номерын җыеп:

—Ольга Евгеньевна, минем кабинетка кереп чыгыгыз әле,—дип дәште.

Озак та тормый, ишекне тавышсыз диярлек ачып, кара чәчле, урта яшьләрдәге ханым килеп керде.

—Таныш булыгыз, Тимерхан Борһанович, бу—музейлар эше буенча безнең методистыбыз Шелковская Ольга Евгеньевна була, ә Борһанов Тимерхан Борһанович Социаль-тәэминат министрлыгында урынбасар булган кеше, хәзер пенсиядә...

—Гафу, Кырлайдагы Тукай музееның бинасын салдыручымы?

—Туктале, ә сез каян беләсез аны?

—Анда бит безнең кызлар экспозиция төзеделәр. Әле һаман шул эшләре белән мактанып сөйлиләр. Ә мин аңа ник кирәк булдым, Мөҗип Тажиевич?

—Тимерхан Борһановичка Кырлай музееннан соң тарих җене кагылып калган. Хәзер ул Собес музеен төзергә хыялланып йөри. Менә ярдәм сорап безгә килгән. Ә сез моңа якты күз белән карыйсызмы?

—Мондый чибәр картка биш куллап булышырга риза. Киттек, Тимерхан Борһанович.

Ольга—дөньяда бер чибәр. Йөзен каймалап алган кара чәчләре дә, алсу янып торган бит алмалары да, уймак ирен дә, үзен, милләтенә хас булганча һавалырак тотуы да—барысы килешә иде аңа.

Ольга Евгеньевна башта бик җентекләп музей булачак бүлмәне карады, аннары өзеп кенә әйтте:

—Бер кат аска төшә алмыйсызмы? Музей карарга килүчеләрнең сезнең бүлмәләрне карап, ишекләрне ачып-ябып йөрүләре кирәкми. Музей астарак булырга тиеш.

Галина Павловнаны чакырып, ул ягын килештеләр.

Ольга Шелковская булачак экспонатлар белән таныште.

—Бик күп эш эшләгәнсез, Тимерхан Борһанович. Бик күп эш. Әмма әле сезнең музей өчен иң дә кирәкле төп нәрсәгез җитешми:

егерменче-утызынчы елларда эшләгән наркомнарның биографияләре. Менә шуларны эзләп тапсагыз, ул чагында музейның экспозициялек материалы әзер дип әйтергә була. Без, музей хезмәткәрләре, эшкә тотына алабыз. Шунарчы, документлар куяр өчен, пыялалы стендлар ясата торсагыз әйбәт булыр иде...

Ольга Евгеньевна нинди стендлар ясатырга, нинди рамнар куярга, экспозиция өчен тагын нәрсәләр эшләргә кирәк булачагын Борһановка һәм Галина Лоцмановага сәгатьләр буе аңлатты.

Боларның берсен дә онытмаска, стендларның, рамнарның, тагын башка кирәк-яракның үлчәүләрен язып алырга кирәк иде.

Алар—министр ханым һәм Борһанов—үзәк музейдан рәссам чакыртып китерергә мәҗбүр булдылар.

8

Тимерхан Борһанов, Мәдәният министрлыгының методисты киткәч, үзе җыйган документларны кабат күздән үткәрде. Шелковская әйтте бит, бирелә наркомнарның биографиясе җитми. Ә шулардан башка музей тарихы ачылмаячак.

Бер документта шундый сүзләр бар: "Татарстанның Социаль-тәэминат наркоматында беренче нарком булып Исхаков дигән кеше эшләгән. Аның тормыш юлы турында берни дә билгеле түгел".

Беренче нарком, ягъни халык комиссары—Исхаков.

Кем ул? Кайда туган? Авылныкымы, шәһәрнекеме?

Икенче бер белешмәдән Тимерхан аның Арча кантоны, Шармыш волосте, Кече Мәтәскә авылында туганлыгын белде. Мәтәскә дигән авыл Саба районында да, Арча районында да бар. Кече Мәтәскә дигән авыл Сабада булгач, Исхаковның туган җирен Тимерхан башта шуннан эзләтте. Ләкин уңай җавап ала алмады. Кече Мәтәскәдә Исхаковлар булмаган. Тикшерә торгач, Исхаковның халык комиссары булып Арча кантоны башкарма комитеты рәисе эшеннән билгеләнгәне ачыкланды. Димәк, аны өлкән яшьтәге кешеләрдән кем дә булса белә торгандыр. Тимерханның келт итеп исенә төште: язучы Гомәр Бәширов егерменче еллар башында Арча кантонында эшләгән бит. Ул белми калмас Исхаковны. Тик ул бит хәзер инде туксан яшендә, хәтере ничегрәк икән?

Китте Тимерхан Гомәр абыйны эзләп Язучылар берлеге. Адресын белеште. Новаторлар урамында яши икән. Анда барды. Гомәр ага аны шатланып, якты йөз белән каршы алды. Кырлай музеен салышып, киңәшләрен биреп йөргән чактан бер дә үзгәрмәгән. Хәтере дә шәп булып чыкты аның.

—Бәрәкалла, син түгелме соң бу, Тимерхан?—диде ул, яктырып. Тимерханның музей төзү уе белән йөргәнен белгәч, тагын да ныграк сөенде.—Бәрәкалла, бик изге эш белән йөрисең икән! Мин сиңа ничек ярдәм итә алам инде?

—Сез, Гомәр ага, Арча кантонында башкарма комитеты рәисе булып эшләгән Исхаковны беләсезме?

—Беләм, белмәгән кая! Түбән Мәтәскә егете иде бит ул. Безнен Арча районыныкы. Уртача буйлы, төскә-биткә чибәр, мыек йөртә, бик тә пөхтә киенә, тырыш, эшне бөтен көчен-дәртен куеп эшли. Аны егерменче еллар азагында милләтчелектә гаепләделәр шикелле. Ул бит син эшләгән министрлыкта нарком булды бугай. Ул чагында сезнен министрлыкны наркомат дип йөртәләр иде. Менә шуннан кулга алынды да юкка чыкты ул. Ул чагында милләтләрнең иң зыялы кешеләрен кулга алып, "халык дошманы" дип атап, юк итәләр иде бит. Бәлки, инде аны аклаганнардыр. Син, Тимерхан, ул хакта Югары судка мөрәҗәгать итеп кара.

Аксакалның киңәшен тотты Тимерхан—Татарстанның Югары судына

үтенеч белән барды. Анда җавап төгәл булды: Исхаковның хатыны һәм малае, 1969 елны әтиләренең эше буенча Югары судтан белешмә сорап, гариза язганнар. Һәм анда адресларын да күрсәткәннәр. Бу инде таяныр нокта иде: Тимерхан әлеге адрес белән адреслар бюросына мөрәҗәгать итте, Исхаковлар гаиләсенең әле дә шунда яшәүләрен белде. Аларның телефон номерларын да тапты, шылтыратып сорады.

Телефонга Исхаковның улы Ирекле килде. Берничә көннән алар министрлыкта очраштылар. Мәсьәлә ачыкланды. Исхаков Вәли Исхак улы Татарстанның Арча районы Түбән Мәтәскә авылында туган.

Ирекле әтисенең берничә фотосын, әти-әнисенең никахлашкан язуын да алып килгән иде.

Исхаковның улы сөйләвеннән һәм партархивта тупланган документлардан чыннан да шәхеснең Татарстан Социаль-тәэминат наркоматында беренче халык комиссары булып эшләве ачыкланды. Вәли Исхак улы Исхаков (тулы исеме Габделвәли) 1889 елның 15 сентябрендә Казан губернасы, Арча кантоны Түбән Мәтәскә авылында туган. Гомәр Бәширов дөрес әйтә: Татарстанның Социаль-тәэминат халык комиссары булып Арча кантоны башкарма комитеты рәисе вазифаларыннан күтәрелгән.

Тимерхан аның мыеклы фотосурәтенә озак кына карап, уйга батып утырды. Ничаклы тарих ята бу мыекбайның язмышында! Ул башта Казан шәһәренең социаль-тәэминат бүлегендә мөдир булып эшли, димәк, нарком булганга кадәр үк бу өлкәдә тәҗрибә туплап өлгерә. Революциядән соң бик тә мәшәкатьле унтугызынчы-егерменче еллар бу. Зур оештыру эшләре башкарылган. Казан каласында канлы бәрелешләр булган, Мулланур Вахитовлар, башка комиссарлар һәлак ителгән еллар. Гражданнар сугышы котырынган дәвер. Аннары Идел буендагы ачлык!

Вәли Исхаков—зур белемгә ия кеше. Ләкин ул автобиографиясендә, анкеталарда "Белеме" дигән графада: "Бер мәктәптә дә укымадым. Казан байларында малайлыкта хезмәтче булып йөрдем. Үзлегемнән укырга туры килде",—дип яза.

Аның белемле, зирәк акыллы, эрудицияле шәхес булуын партархивта сакланган анкета да әйтеп тора иде:

1920-1921—ТАССР Социаль-тәэминат наркоматында халык комиссары.

1921-1922—Грозный шәһәре, эшче-крестьян инспекциясе башлыгы, юстиция бүлеге мөдире.

1922-1924—ТАССР, эшче-крестьян инспекциясе халык комиссары.

1924-1925—Татсовнархоз рәисе урынбасары.

1925-1926—ТАССР эчке сәүдә халык комиссары.

1926-1927—ТАССР Халык комиссарлары Советы Дәүләт планы сәүдәкооператив секциясе рәисе.

1927-1929—ТАССР Дәүләт планы Комиссиясе рәисе.

Архивта Исхаковка Мәскәүгә барыр өчен бирелгән командировка бланкы саклана. Ул РСФСР Халык Комиссарлары Советына Татарстанның беренче бишъеллык планы төзү өчен бара. Әнә нинди тәҗрибәле, белемле кеше була ул Вәли Исхаков!

1921 елгы ачлык белән көрәшүдә Социаль-тәэминат комиссариаты оештырган чараларны дулкынланмыйча уку мөмкин түгел.

Комиссариатның хәзерге К. Тинчурин исемендәге театр каршысына урнашкан ике катлы бинасында Вәли Исхаков җитәкчелегендәге комиссия әгъзалары тәүлек буена эшлиләр. Комиссар Исхаковның урынбасары Сибгатулла Гафуров үз-үзен аямый эшли. Тарихтан билгеле булганча, соңрак Гафуров партия өлкә комитетының партколлегия секретаре була. 1937 елны, "халык дошманы" саналып атып үтерелә. Хәзер инде гаепсез булып чыкты, акланды. Ә аның җитәкчесе, комиссар Вәли Исхаков 1929 елны ук биш елга сөргенгә сөрелә, ун елга хокукыннан мәхрүм ителә, мал-мөлкәте тартып алына. "Милләтче Солтангалиев" белән элемтәдә булганы өчен гаепләнә. 1928 елны, Мәскәүдә командировкада чакта, Солтангалиев белән очрашуы зур бер гаеп итеп санала. Ә Мирсәет

Солтангалиев судта болай ди: "Исхаков белән безнең арада бервакытта да милли мәсьәлә турында сөйләшү булмады. Әгәр беләсегез килсә, Исхаков—чын коммунист ул".

Исхаковның гаиләсен—хатыны Бибинур ханымны, уллары—биш яшьлек Ирекләне, дүрт яшьлек Азатны декабрь суыкларында фатирларыннан куып чыгаралар.

Суд карары белән Вәли Исхаков төньякка сөрелә. Чамадан тыш авыр физик хезмәт аның сәламәтлеген какшата, ул авырый башлый. Биш елга сузылган коточкыч михнәтле концлагерь срогын тутыргач, аны тагын ун елга Вологда өлкәсенә сөргенгә җибәрәләр. Җиде ел буена түзә ул анда, авыруы көчәеп китү сәбәпле, 1941 елның азагында аны Мари республикасының Катласала бистәсенә кайтаралар, икенче группа инвалидлык бирәләр. Вәли инвалидлар артилендә фотограф булып эшли. Үз янына хатынын, балаларын алдыра. 1942 елны улы Азатны сугышка алалар, ул шунда һәлак була. Өлкән улы Ирекле, урта мәктәпне тәмамлагач, Казан авиация институтына укырга керә. Анкетадагы "Туганнарыгыз кайда?" дигән сорауга: "Берни дә белмим",—дип язып куя. Кем белә, ихтимал, аны шул язу коткаргандыр, юкса аны институтка алмаган булырлар яки бераз укыгач, "халык дошманы" баласы дип, куып чыгарырлар иде. Бәхетедер, моны белмиләр һәм ул институттан инженер дипломы алып чыга.

Вәли Исхаков, зыялы булганы өчен, җәһәннәм газаплары күргән татар, 60 яшендә якты дөнья белән саубуллаша. Хатыны—95 яшендә дөнья куя. Хатын-кызны мәче кебек яшәүчән, диләр. Бибинур ханым югыйсә, күпме газап күргән, күпме ирсез яшәгән, гөнаһсызга утыртылган ире белән фронтта һәлак булган улының хәсрәтләрен башыннан кичергән, ничәмә-ничә еллар "халык дошманы" хатыны булып яшәгән. Чыдаса да чыдый икән адәм баласы!

Атылган, һәлак булган, төрмәләргә, концлагерьларга утыртылып, гомер буе газап чиккән комиссарларның биографияләрен төзегән чагында, Тимерхан Борһанов татар әдәбиятының юк ителгән классикларын исенә төшерде. Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, Фәтхи Бурнаш, Гомәр Гали, Мәхмүт Галәү, Ләбиб Гыйльми, Галимҗан Нигъмәти, Фатих Сәйфи-Казанлы, Гомәр Толымбай, Мин Шабай... Күп алар, санап бетерерлек кенә түгел. Димәк, Сталин һәм аның ялчылары татар әдәбиятын башсыз калдыру нияте белән янып яшәгәннәр. Котылып чыгучылар арасында Кави Нәҗми, Газиз Иделле, Фатих Кәримнәр бар бит әле. Аларны, янәсе, гаделлек ягында торучылар без, дип халыкны алдар өчен чыгарганнар. Бөек Ватан сугышында 30 язучы башын салды. Фронтларда! Шулар арасында данлы шагыйрь Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Совет Армиясе подполковнигы Нур Баян бар. Муса Җәлил эшләгән батырлык, аның 12 иптәше эшләгән батырлык бүтән бер халыкта да юк. Әсир төшкән хәлдә, совет гаскәрләре җинсен өчен, ниләр генә эшләмиләр алар. Мусаның "Моабит дәфтәрләре" Ленин бүләгенә, ә үзе, үлеменнән соң, Советлар Союзы Герое исеменә лаек булды. Аның сугышчан иптәшләре күп еллар узганнан соң орденнар белән бүләкләнделәр. Мондый легендар геройлар башка халыкларда, бигрәк тә "олы туганыбызда" булса, һәммәсенә Советлар Союзы Герое исеме биргән булырлар иде. Моны шикләнми әйтергә мөмкин...

Төрмәгә утыртылганнар арасыннан, сугыш беткәч, Сталин культы фаш ителгәннән соң, "зинданнарның бозын имгән" берничә язучы исән кайтты. Болар яшь кенә көйгә утыртылганнар булып чыкты. Иң әүвәл Мин Шабай китеп барды, аннары—Сөббух Рәфыйков. Торып калды—Ибраһим Сәлахов, торып калды—егерменче гасырның бөек шагыйре Хәсән Туфан. Алтмыш ягына атлап кайткан иде әсирлектән, сиксәнгә житеп вафат булды. Илебез халыкларына ул татар шигыренең куәтен күрсәтеп бирә алды. Шуның өстенә сугыштан соң әдәбият мәйданына килгән яшьләрне җитәкләп, талантлы шагыйрьләрне үстерде, аларга канат куйды... Инде Ибраһим Сәлахов та вафат...

Музей эшләре белән йөри торгач, Тимерхан ябыкты, хәлсезләнде, башы авырта, йөрәге сызлый башлады. Хатыны Миңлеасия аның "кычытмаган җирен кашып йөрүенә" баштарак түзгыган иде, карты урын өстенә үк менгәч, сабырлыгы төкәнде:

—Слушай, Тимерхан, ул музей-хуҗи дигән кирәкмәс эшеңне ташлыйсыңмы әллә? Түзмәдем түгел, түздем бит инде, әйттерерсең әлләни! Сарыга сабыштың, аппитетың югалды, тагын нәрсә дип әйтим соң? Минемчә, җитеп торыр. Калганын әнә түтекәең Лоцманова эшләсен. Әйтми дигәченнән дә, белми йөриләр ди торгандыр. Үз кесәңнән дә сәмәнең чыга башлады бит инде...

Тимерхан дәшмәде. Атна-ун көн урын өстендә ятты да тагын шул эшенә тотынды. Аңа хәзер 1924 елларда социаль-тәэминат комиссары булган Гыйлаҗ Фәсхетдинов биографиясен төзергә кирәк иде.

## 9

Тимерханнарның фатиры министрлыктан ерак түгел—җәяүләп барсаң да ярты сәгатьтә барып җитеп була. Нәкъ менә шул ният белән өеннән чыкты Тимерхан. Исәбе җәяүләп кенә музей булачак бүлмәгә бару, ун көн буена кулына тотып карамаган кәгазьләрне кабат актарубарлау иде.

Ишектән чыгуга аның битенә июль кояшы китереп бәрде. Урамда күзләр камашырлык якты, бар нәрсә җете булып күренә, бакчалар ямьяшел, куаклар бөдрә-бөдрә, күзгә күренгән һәммә нәрсә балкып, нур чәчеп тора, ул үзен анадан яңа гына туган кебек итеп сизә иде.

Урамда аның янына ук кычкыртып "Волга" машинасы килеп туктады. Машинада кемнәр барлыгын, автомобильнең ник шулай каты кычкыртып килеп туктавын Тимерхан белергә дә өлгермәде, ишекне ачып җибәреп, министр Лоцманова килеп чыкты, гадәтенчә елмаеп:

—Сәлам бирдек, Тимерхан Борһанович! Көн саен мин сезне көтәм. Өегезгә дә шалтыратып карадым, җавап-мазар бирүче юк. Әллә, мәйтәм, берәр җиргә ялга киттеләр микән, дим, Асия Җәмилевна белән?

—Авырып яттым мин,—диде Тимерхан.

Галина Павловнаның төсе бозылды.

—Гафу итегез, Тимерхан Борһанович. Белмәдем. Асия Җәмилевна шалтыратып әйтмәде. Хәлегезне белгән булыр идек.

—Министрлыкны алҗытаса килмәде. Авыруыңны хәбәр итү—борчуга салу бит ул...

—Инде терелдегезме? Кай төшегез авыртты?—Галина Павловна машинаның арткы утыргычына Тимерхан янына утырган иде, якынрак килде, Тимерханның башын тотып карады.—Температурагыз юк. Терелгәнсез ахрысы? Шулай да яшерми әйтегез әле, сезгә ни булды?

Тимерхан күреп тора, ялганнаганны яратмый министр ханым, шуңа күрә ул туп-туры, дөресен әйтеп бирергә булды:

—Беләсезме, Галина Павловна, безнең наркоматтан атылган комиссарларның биографиясен ачыклый башлагач, йөрәгем туктап кала язды. Нинди кешеләрне һәлак иткәннәр бит! Милләтнең каймагын! Совет власте өчен җаннарын аямый эшли торганнарны! Документлар әзерли торгач, арып та киткәнмен, йөрәккә дә китереп сукты. Мин боларны сезгә юкка сөйләп торам, иске яраларыгызны кузгатам...

Тимерхан телен тешләп туктап калды. Галина Павловнаның ире, Май бәйрәмендә, балык тотарга дип киткән җиреннән юкка чыккан иде. Бөтен Иделне бетереп эзләсәләр дә, аны таба алмадылар. Шул хәсрәттән айнып та җитмәгәндер әле ул, Тимерхан аңа үз кайгысын сөйләп, ярасын кузгатып бара.

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...

Кайсыгызның кулы жылы?—
Бәйлисе бар йөрәкне...—

дигән Хәсән Туфан.

Тимерхан тын гына шуларны уйлап барды.

Тугыз катлы бина янында машинадан төштеләр.

—Сезнең министрлыкка килешегез идеме? Әгәр, юк-барны сорашып, авырткан төшегезгә кагылсам, сез мине, зинһар, гафу итегез,—диде Галина Павловна.—Йөрәгегезне дәвалау—Чехов базары янындагы спецклиникададыр инде? Фронтовик кеше бит сез.

—Дәваланырга теләмим әле мин,—диде Тимерхан.

Башка бер сүз дә әйтмәде, музей булачак бүлмәгә керде. Анда такталарны шомарту станогы куелган, ике столяр стеналарга пыялалы буш стендлар куеп маташалар иде.

Тимерхан Борһанов министр кабинетының ишегең шакып керде дә:

—Рәхмәт сезгә, Галина Павловна. Эшне башлагансыз икән. Кайбер документларны шкафтан алдым. Биографияләр төзүне дәвам итәргә исәп,—диде.

—Тимерхан Борһанович, бер генә минут, сабыр итегез. Бәлки, сезне санаторийга җибәрергә кирәктер? Йөрәк белән шаярырга ярамый. Аңа син дип түгел, "сез" дип дәшәргә кушалар врачлар,—диде.

—Минем кәефем яхшырды инде. Мин бүген Гыйлаж Фәсхетдиновның биографиясен машинкада бастырырга җыенам. Башта язып чыгып, билгеле.

Хәзер аның күңеле тулы уй—Гыйлаж Фәсхетдинов документларыннан укыганнарын ул күңел җебенә тезә иде.

1938 елның февраль аенда партия Үзәк Комитеты пленумы була. Пленум илдә "халык дошманнарын" фаш итүгә йомгак ясый. Анысы табигый хәл. Эшләгән эшкә йомгак ясалмый калмый, билгеле. Тик аның нәтиҗәсе бик аяныч. "Социалистик төзелештә уңышлар арта барган саен, сыйнфый дошман совет дәүләтенә булган каршылыгын көчәйтә". Димәк, Пленум сизгерлекне көчәйтергә, "сыйнфый дошманны" тамырыннан юк итәргә дигән сәяси юнәлеш бирә.

Гыйлаж Фәсхетдинов, "халык дошманы" саналып, утыртыла һәм атып үтерелә. Нибары 38 яшендә. 1899 елны туган, 1937 елны атылган. Ә бит аның Бондюг заводында эшләүче эшче гаиләсендә тууын исәпкә алырга тиешләр иде. Бик яшьләй әтисез калуы да, үндүрт яшеннән үзенең шул ук заводта кара эшче булып эшләве дә, Татарстанда яшьләр оешмасы төзүдә дә искә алынырга тиеш иде. Республиканың НКВД органнары үтә чыккан аңгыра булганнармы? Әллә үз шәүләләреннән үзләре куркып яшәгәннәрме?

Үзәк Комитет Пленумыннан соң булган хәлләрне документлардан укыгач, Тимерханның чәчләре үрә торды, йөрәге атылган наркомнарны кызганудан гына түгел, аларның гаиләләрен җәлләүдән генә түгел, системага булган аяусыз нәфрәттән кысылып килде.

Гражданнар сугышында катнашкан кешеләрнең хуҗалыкларында (крестьян гаиләләрендә, әлбәттә) сыер йә сарыклар булса, җиде сум күләмендәге пенсия түләнелә торган була, ул пенсия туктатыла. Чаллы районының сугышта үлгән ирләре өчен ала торган 66 хатын-кызның пенсиясе киселә. Пенсияләрне кисү турында һәр район югары оешмаларга ай саен хәбәр итеп тора. Шундый бер хисап кәгазендә мондый сүзләр укыды Тимерхан: "Ниһаять, авыл җирендә красноармеецлар өчен, аларның тол калган хатыннарына—солдаткаларга түләнә торган пенсияләр киселеп бетте".

Йә Хода, бу ни галәмәт?!

Ләкин документлар белән күбрәк танышкан саен, аның тешләре кысылды. Фирка әгъзалары арасында "уң тайпылыш", "сул тайпылыш" дигән сүзләр килеп чыга. Шикләнүчеләр күбәя. Доносчылар армиясе барлыкка килә.

Утыз тугызынчы елларда инде Тимерханга ундүрт яшь тулган иде. Авыл кешеләренең бер-берсенә кермәүләрен, иң күп сөйли торган кешеләрнең—тел бистәләренең дә телләрен тешләүләрен аңламый иде. Дәфтәр тышындагы рәсемнәрдән дә илне яманлый торган сүзләр эзләнүне ул аңламый иде. Менә хәзер аңлашылды. Кешеләр аз гына да үз фикерләрен әйтүдән мәхрүм ителгән булганнар икән.

1937 елның февраль аенда үткәрелгән партҗыелышта юрист Остров үзенең чыгышында әйтә: "Инде хәзер троцкийчыларны фаш итеп бетергәч, дошманны ил эченнән эзләргә кирәкми, бәлки аны тышкы дөньядан эзләргә кирәктер",—ди.

Аның чыгышын фиркачылар шик астына алалар. "Син иптәш түгел безгә. Син сизгерлегеңне югалткансың",—диләр. Шундый җыелышларның берсендә коммунистлар халык комиссары Җиһаншинга ташланалар. Имеш, ул Абдуллин, Хәйруллин, Казаков ишеләрне эшкә алган. Бу кешеләр—партиягә каршы, алар—халык дошманнары.

Нарком аңлатырга мәҗбүр була:

—Мин бит аларны совнарком рәисе кушканга алдым.

Бу җыелышта райком инструкторы да катнашкан икән.

—Контрларны эшкә алуда Җиһаншин үзе гаепле. Ул сәяси сукырлык күрсәткән. Үзе эшли торган аппаратны дошман элементлар белән чолгатып алган,—ди.

Наркомның ачуы чыга.

—Безнең наркомат эш нәтиҗәләре буенча Россиядә икенче урында. Безнең эштә гаеп эзләрдәй нәрсә юк...

Райком инструкторыннан соң берәү дә сүз әйтергә батырчылык итми. Шулай итеп, февраль Пленумы карарын тикшерүдә катнашкан тугыз коммунист нарком Җиһаншинны бернинди сәбәпсез партиядән чыгарып ташлыйлар.

Ул эшсез кала. Авырып китә. "Эшләү сәләтен югалту сәбәпле, икенче группа инвалидлык бирелә",—дип мөһер сугылган кәгазь тоттыралар аңа.

Тимерхан бу урында башын кашып, уйга калып тора, авыр итеп бер көрсенә. "Әлеге гамәл кешене тере килеш үтерү дип аталмый микән?"—дип уйлап куя.

Менә тагын бер белешмә. Киселев дигән кешене, троцкийчылар белән элемтә тоткан өчен дип, партиядән чыгаралар. Ул икенче көнне, мине кулга алыгыз дип, НКВДга бара. Ләкин аны кулга алмыйлар. Утыртмыйлар. Яңадан партия сафына кайтаралар. Шелтә-мазар белдермиләр. Ул елларда кеше язмышы белән уйнау бер тиен тормый!

Наркоматта Абдуллин фамилияле кеше эшләве әйтелгән иде инде. Фирка әгъзасы. Урысча бик оста сөйләшә. Патша армиясендә унтер офицер булып хезмәт иткән. Моны ул беркемнән дә яшерми. Ләкин ул үзен коллективтан читләштермәүне үтенә. Заманы нинди бит аның! "Бай токымыннан" дигән исем тагылса, аны юып ташлармын дип уйлама. Җае саен, көтүче токымындагы бәндәләр бәйләнеп кенә торалар. "Контр син"—и вәссәлам! Абдуллинга да каныгалар. Ул моңа бик гарьләнә, кимсенә, ахыр чиктә, түзә алмагач, үзен үзе атып үтерә.

Беркетмәгә яла яга торган сүзләр языла: "Абдуллинның үлемен антипартийный эш дип санарга. Ул үзенең советка каршы элементлар белән бәйләнгән булуы фаш ителүдән куркып, үзен үзе үтергән".

Бу да тере вә сәламәт кешене юк итү юлы түгел микән?

Җиһаншинга кайтыйк. Аның бернинди дә гаебе юк. Урынсыз бәйләнүләр, яла ягулар аркасында ул эшеннән алына. Ә бит наркоматның барлык тармаклары да канәгатьләнерлек эшли.

Заманасы шундый. Җиһаншин, үз-үзенә каршы килеп, боерык язарга мәҗбүр була:

"Барлык бүлек мөдирләренең, предприятиеләрнең һәм инвалидлар йортларының 1938 елның 15 гыйнварена чаклы корткычлыкны бетерү

өчен нинди чаралар күрелүе хакында мина жентекле хәбәр итүегезне боерам.

ТАССРның Социаль-тәэминат халык комиссары".

Менә шушы боерык архивта саклана—тарих эзсез югалмый шул. Ләкин нинди корткычлык турында сүз бара, ул чордан исән калган кешеләрнең берсенә дә мәгълүм түгел.

Архивларда сакланган һәрбер документта, кирәксә-кирәкмәсә, партиягә ихлас бирелгәнлек, халык дошманнары белән аяусыз көрәш турындагы сүзләрне очратасың.

Социаль-тәэминат халык комиссариатының 1939 елның 5 маенда башлангыч партия оешмасы үткәргән жыелыш беркетмәсендә латиннан кириллицага күчү мәсьәләсе язылган. Анда әйтелә: "Гарәп алфавиты үлек, схоластик алфавит. Яңалиф—кучеш елларыныкы. Яңа графика—рус язмасына күчү, русча белүне якынайта. Дошманнар кириллицага күчүгә каршы торачаклар, әмма алар, бу юлы да, элеккеләре кебек, жиңелүгә дучар ителәчәкләр".

Тимерхан жиденчене латин язуында тәмамлаган иде. Урыс хәрефләренә күчүне ул вакытта "Кызыл Татарстан" гәзите халыкка бик иркен житкереп барды. Тимерхан аны жәй эчендә гәзит аша өйрәнеп, бик әйбәт яза башлады. Хәтерендә, аны баш хисапчы Гайфуллинның ярдәмчесе итеп алдылар. Ул анда колхозның "Эчке тәртип кагыйдәләре"н яңача күчереп язды. Аннары аңа колхозда "Эшләп чыгару нормалары"н күчерттеләр. Китте эшләр хутка—күчертәләр дә күчертәләр. Соңыннан кириллица хәрефләре белән лозунглар яза башлады. Ташка басылган хәрефләрне ул балачактан ук белә иде. Авылда ураза бәйрәме үткәрәләр. Тимерхан гәзит кисәкләрен ябыштырып, "Яшәсен ураза бәйрәменең 17 еллыгы!"—дигән лозунг язды, аны түргә элеп куйды. Аларның йорты мәктәп белән янәшә иде. Су эчәргә керүче малайларның берсе әйткән булса кирәк, иртәгесен директор аны үз кабинетына чакыртты.

—Кем өйрәтте сине андый ярамаган эшне эшләргә?—дип ачулы кычкырды ул Тимерханга.—Ни өчен 17 еллыгы?

—Октябрь бәйрәменә унжиде ел, димәк, ураза бәйрәменә дә—унжиде,—диде Тимерхан.

Директор мыек астыннан көлемсерәде дә шундук житдиләнде.

—Синең әтиең Борһан да кичә түбәноч мәчетендә азан әйтте. Матри, малай, яңадан да шул ярамаган эшеңне кабатласаң, әниеңне-әтиеңне дә, үзеңне дә төрмәгә утыртырбыз.

Әнә нинди заманнар бар иде Тимерхан үскәндә!

Дини бәйрәмнәр хәзер гөрләп уза. Кириллицадан кабат латинга кайтабыз, дигән сүзләр дә бар. "Казан утлары" журналы кайбер шагыйрьләрнең шигырьләрен "яңалиф"тә бастырып та күрсәтте.

Тимерхан үсмер чагында ишетеп килгән бер гыйбарә бар иде: "Улы әтисе өчен жавап бирми". Моны Сталин әйткән, диләр. Ләкин тормышта нәкъ киресе килеп чыкты. 1938 елны авыл жыенында Кызыл Армиягә хезмәткә баручылар исемлеге тикшерелә. Хезмәткә алынырга тиешле кешеләр закон нигезендә туган жирләренә кайтып каралалар. Габделхак исемле егет кайта, хәзер егерменче яше белән бара. Әтисе указлы мулла икән. Жыен аның Кызыл Армия хезмәтенә бару-бармау мәсьәләсен карады. Тимерхан, әле бала гына булса да, ул жыенга катнашты—иң алгы эскәмиягә кереп утырды.

Авыл Советы рәисе беренче булып сүз башлады:

—Закон нигезендә мулла балалары армиягә алынмыйлар. Шуңа күрә, Габделхак, без сине исемлеккә кертә алмыйбыз.

Габделхакның жылый-жылый ялынганын Тимерхан әле дә оныта алмый. Авыл жыены, Габделхакны хәрби хезмәткә барудан мәхрүм итәргә, дигән карар чыгарды.

Озакламый сугыш башланды. Габделхак сугышның беренче көннәреннән үк фронтка жибәрелде һәм ул анда батырларча һәлак булды.

## 10

Нићаять, пенсиягә чыгып, көне-төне архивларда утыргач, танышбелешләр аркылы, шул заманнарда комиссарлар белән бергә эшләгән кешеләр аша, хәлләрнең чын дөресен белде Тимерхан. Өч ел тоташ бинићая күп көч сарыф итеп, музей экспонатларын әзерләде.

Тимерхан бик нык арыган иде, әмма күңеле бик көр иде. Ул башлаган бу эшнең дә гамәлгә ашыр көннәре якынлашты.

Атылган, сөргенгә сөрелгән, эшеннән чыгарылган, төрмәләрдә иза чиккән комиссарлардан, аларның урынбасарларыннан, бүлек мөдирләреннән ул 16 шәхеснең биографиясен төзеде. Аңа бу эштә Арчада бергә эшләгән милиция майоры Горшков Федор Ильич бик нык ярдәм итте. Ул—керәшен татары—хәзер Казанда яши, хәтере бик шәп, кул астындагы белешмәләр дә, ярдәмчел булуы һәм күркәм холкы да аңа Арчадагы райбашкарма рәисенә ярдәм итәргә кирәклеген әйтеп тора иде. Сәгатеминуты белән ул адресларны табып бирә, әнә шул булдыклы сыйфаты белән Тимерханга әйтеп бетергесез кирәкле эш эшли иде.

Комиссарларның биографияләрен төзү өстенә Борһанов Татарстан районнарындагы картлар йорты, акылга зәгыйфь балалар йорты, дистәләгән интернат-йортлар турында мәгълүмат җыйды, фотоларны зурайттырды, 1917 елдан башлап үзе урынбасар булып эшләгән министрлыкның тәгәл тарихын ачты. Үзәк музей хезмәткәрләре һәм рәссамнар ул җыйган экспонатларны музей бүлмәсенә урнаштырдылар.

Бер дә бер көнне музейны ачтылар. Социаль-тәэминат министрлыгында эшләгән министрларның исәннәре, исән булмаганнарның хәләл җефетләре, балалары, предприятиенең хезмәткәрләре—барысы да җыелды.

Дулкынландыргыч минутлар иде бу. Тимерхан Борһанов хәзер генә аңлап алды—ул үзенә, Пушкин әйтмешли, "гаҗәп һәйкәл" салган икән...

Галина Лоцманова аңа беренче итеп сүз биргәч, ул каушавыннан әйтер сүзен онытып җибәрде. Авыр итеп көрсенде, тик шуннан соң гына:

—Туганнар! Халык бәхете өчен көрәшеп, шул юлда һәлак булган халык комиссарларын бер минут тынлык белән искә алыйк,—диде.

Бүлмә эче тын калды.

Тимерхан хатын-кызларның күз яшьләрен сөртүләрен күреп, тагын да ныграк каушады. Аңа сүзен дәвам итәргә кирәк иде.

Ләкин ул нәрсә сөйләргә кирәк икәнен белми, үзенең дә күңеле йомшап киткән иде.

—Бу музейны төзү өчен... әйе, бу музейга көч күп түгелде. Мин әйтер идем, чамасыз күп... Шул эш белән шөгыльләнә башлагач кына, мин үземнең нинди учреждениедә эшләгән булуымны аңладым. Бик тә миһербанлы, бик тә шәфкатьле министрлыкта эшләгән икәнмен мин. Олыны олы, кечене кече дип белү, өлкәннәргә, ярдәмсез калган карткорыга, карчык-корчыкка ярдәм итү, пенсияләрен вакытында түләтү—дөнья халыкларының иң изге бурычы. Бу музей үткәннәрне искә алу өчен генә түгел, киләчәккә аек акыл белән карау өчен дә кирәк. Дөньяның атаклы шагыйре Рәсүл Гамзатов әйткән: "Әгәр син үткәннәргә пистолеттан атсаң, киләчәк синә туптан гөрселдәтер",—дигән. Бик тә урынлы, гыйбрәтле сүзләр!

Рәхмәт Галина Павловнага—минем уй-теләгемне аңлаган өчен. Рәхмәт Мира Анатольевнага—музей бүлмәсен бүлеп алырдай бина салдырган өчен. Рәхмәт барлык иптәшләргә—эчкерсез ярдәмнәре өчен. Барыгыз алдында да түбәнчелек белән баш иям.

### АВТОРНЫҢ СОҢГЫ СҮЗЕ

Менә, кадерле укучым, Тимерхан Борһановның тормыш юлы турындагы өченче повесть тәмамланды. Мин аңа юлыгуыма, алай гына да түгел, аның

белән бергә, бөек Тукаебызга музей салуның шаһиты булуыма шатланам. Мин бик күп повестьлар, хикәяләр, очерклар, романнар, әдәби портретлар яздым, пьесаларымны куйдырдым, урысчадан җиде роман тәрҗемә иттем, классик пьесаларның тәрҗемәләрен эшләдем, телевизион фильмнар өчен сценарийлар иҗат иттем.

Әмма бер шәхескә багышланган өч повестьны беркайчан да язганым юк иде әле. Тимерхан Борһановның тормышы егерменче гасырның барлык вакыйгаларын сыйдыра. Сугыш алды елларындагы ятимлек, Бөек Ватан сугышы ветераны булу, районнарда партия-совет эшләрендә эшләү, Казанда Социаль-тәэминат министрының урынбасары булу, пенсиягә чыккач, шул министрлыкның музеен җәмәгать эше тәртибендә төзү—моның өчен хезмәт ярату, булдыклылык, туган ягына чиксез бирелгәнлек кирәк. Гаилә корып, өч бала үстерү, аларның барысының югары белем алып, иң җаваплы эшләрдә эшләве, аларга Хафиз, Рафис, Әнисә кебек чын татарча исемнәр кушу—бу ир-атны, гомер буе шәфкать туташы булып алтмыш җиде яшендә генә пенсиягә чыккан Миңлеасия ханымны гел дә менә бизи. "Таһир-Зөһрә" газитендә аларны мәхәббәт алиһәләре итеп чыгарырга кирәк! Тиздән, тагын ике елдан, аларның алтын туйлары булачак. Хәләл җефетем Шәһидә белән икебез шул туйның түр башында булсак, и дә сөенер идек соң!

Безнең дә ул чагында туебыз булыр. Йа Ходаем, ул туйларны күрергә язсын. Тимерхан белән Асия да безнең туйның түр башында булсыннар иде.

Тимерхан турындагы повестьларны мин укучыларым өчен яздым. Рәхмәт укучыларыма, алар минем иҗатыма гомер буе мәрхәмәтле булдылар.

Мөслимдә "Тимерханның яшьлеге" повестена укучылар конференциясе үткәрделәр. "Тимерханның авыл юллары" повестена карата да укучыларымның фикерен ишетеп торам. Каләмдәш прозаикларым да, урамда очраган укучылар да "Тимерханның авыл юллары"н гел искә төшерәләр.

Борһанов үзе белән бергә, япон самурайларына каршы сугышкан, бергәләп армиядә җиде ел хезмәт иткән Дубинин белән хат язышa. Дубинин хәзер Кемерово шәһәрендә яши. Солдат хезмәтеннән кайткач, ул эчке эшләр идарәсендә эшли. Полковник дәрәҗәсендә пенсиягә чыга. Борһанов аңа минем повестьларны—"Тимерханның яшьлеге"н, "Тимерханның авыл юллары"н җибәрә. Озакламый Борһанов фронтовик дустыннан хат ала.

*"Кадерле дустым Тимерхан!*

*Синең хактагы повестьларны миңа майор Габделхак Әшрәфҗанович Тимербаев тәрҗемә итеп бирде. Синең яшьлегең турында мин баштарак белми идем, синең миңа аны сөйләгәнең дә булмады. Хәзер инде мин синең армиядән соңгы эшләреңне дә беләм. Без—милиция ветераннары, безнең арада Байкал күле буенда хезмәт иткәннәр байтак,—минем фронтовик дустым Тимерхан Борһанов турында Кемерово шәһәрендә русча укыйбыз...*

*Сәлам белән: Николай Петрович Дубинин".*

Менә мондый хатлар күңелне күтәрә—эшләгән эшеннең файдалы икәненә төшенәсең.

Кадерле укучыларыма хәбәр итәм: Тимерхан Борһанов исән-сау, үзен бәхетле итеп сизә. Ул инде сигезенче дистәневаклады. Идел буенда дачалары бар. Без, аның дуслары, вакыт-вакыт ул дачага җыелабыз. Тимерхан, су буйларын яңгыратып гармун уйный, Миңлеасиясе җырлап җибәрә, без аңа кушылабыз, дөньяның ямьсез икәнен, болганчык икәнен онытып торабыз. Җыр, канатлы кош булып, күкләргә оча, шаңдау булып кире кайта. Көр күңелле дусларың булу—дөньяның рәхәте.

# ШИГЪРИЯТ



Җәүдәт
Дәрзаман

## Моңнар фәрештәсе

*Халкыбызның сөекле җырчысы*
*Гөлсем Сөләймpraвованың якты*
*истәлегенә багышлыйм*

Еллар аша ул эндәшә миңа,
Ул эндәшә ерак чор аша.
Үз улыдай, сыйпап чәчләремнән,
Хәлләремне минем сораша:

"Нихәл, бала? Инде үскәнсең дә,
Онны байтак тарткан тегермән—
Күз тирәңне уйчан нурлар сарган,
Чәчләреңә көмеш йөгергән.

Хәтерлимсең сабый чакларыңда
Без көйләгән моңлы җырларны?
Әйтче, балам, әйтче, сезнең чорда
Элеккедәй моңлы җыр бармы?

Диварларда радио-"эшләпә"ләр
Сөйләп торалармы бүген дә?
"Әллүки"ләр, бүтән ямьле көйләр
Сакланамы татар күңелендә?"

Хәтерләдем! Әйе, хәтерләдем!
Бүгенгедәй истә гамьле көй.
Әнкәм сөте белән күчкән миңа
Син җырлаган мәшһүр "Әллүки":

*"Ишеттем мин кичә, берәү җырлый*
*Чын безнеңчә матур моңлы көй—*
*Әллүки, бәллүки.*
*Чын безнеңчә матур, моңлы көй..."*

Әй, син, мәшһүр моңнар фәрештәсе,
Аллаһыдан Вәхи алдыңмы,
Үз халкыңның йөрәк сагышларын
Ялкын итеп көйгә салдыңмы?

Җырларыңның бер авазы килсә,
Сулыгып-сулыгып куя күңелләр.
Ул моңнарның сихри аһәңнәре
Онытылырга мөмкин түгелләр!

Тарихыбыз ерак, тамыры—тирән,
Болгарларга барып тоташа.
Болгары да, Урда, Казаны да
Кичә-кичә мәхшәр, ут аша,
Күпме янган,
Болгар бабайларның
Йорт-җирләрен күпме ялмаган.

Илен йоткан, ярты телен йоткан,
Тик моңнарын ялмый алмаган.
Хак динен дә ялмамакчы булган,
Тик Аллаһның сүзе көчлерәк—
Мөселманның динен тыйганнарга,
Дене өчен җанын кыйганнарга
Ахирәттә тәмуг төслерәк.
Шул чорлардан күчкән аһәңнәр бу,
Гарасатлар кичкән моң-зар бу.
Телә-телә гасыр катламнарын,
Безнең телгә күчкән моңнар бу!

*“Иртә лә томан, кич тә томан,*
*Томан азакларында чык булган.*
*Ай, югалттым*
*Сәгать ләй чылбырын...”*

Моң һәрвакыт ил сагында булган,
Дошман явы кергән чагында.
Бүген дә моң туган телен саклый,
Бүген дә моң Ватан сагында.

Ә ул еллар... Гарасатлы еллар...
Кара сөрем сарды күкләрне.
Канлы сугыш корбан, әсир итте,
Гарип, ятим итте күпләрне.

Йөзәү китсә, бары берәү кайтты,
Йә кайтмады,—калды хәбәрсез.
“Ул сугышны син бит белмисең!”—дип,
Гаеп ташласагыз әгәр сез,
Ялгышырсыз. Ярты яралмышым
Минем газиз әткәм җанында.
Аның белән мин дә утка кердем
Ул сугышта йөргән чагында.

Аның белән бозлы сулар кичтем,
Дары исен эчтем тончыгып.
Ничәмә кат күзгә яшьләр килде,
Күкрәкләрдән изге моң чыгып.

Мин тылда да булдым. Әйе, булдым.
Ярты жаным—әнкәм жанында.
Әнкәм белән мин дә жыр тыңладым
Казан концерт биргән чагында.

Әй, ул жырлар, әй, ул изге моңнар,
Дога булып иңә күңелгә.
Тыңлый авыл. Йөрәкләрдә—давыл.
Халык рухы нурга күмелә.

Күңелләрнең кинәт биге бетә,
Чиге бетә шашкын хыялның.
Михнәт чиккән авыл халкы өчен
Бәһасе юк иде бу ялның.

Колакта—жыр. Күңелләрдә исә
Тынып тора сугыш беразга.
Ирләр кайткан, гүя, сабан артларыннан
Сызылып кала жылы буразна.

Мунчалардан сузылып төтен чыга,
Куанышып яна учаклар.
Онытылып, шашып ярын коча
Назга сусап янган кочаклар.

Шушы моңнар, шушы жыр аһәңе
Яшәү бирә күпме жаннарга—
Кара төндә йолдыз булып яна,
Нурлар булып иңә таңнарда.

*"Таң әтәчләре кычкыра—*
*Таң атуның билгесе.*
*Бу бүләгем—сине сөеп,*
*Чын күңелдән кайнап чыккан*
*Вәгъдәләрнең билгесе..."*

* * *

Һай, бу жырлар, һай, бу халык моңы,
Кайгыларың бераз онтыла.
Шаша йөрәк, актарыла хисләр,
Галәмнәргә күңел омтыла.

Галәм ерак. Болын—янәшәдә,
Янәшәгә чыгу озакмы—
Ач кына син шашкын хисләреңне
Бикләп торган авыр йозакны!

Сызып жибәр тальян гармуныңны,
Дер селкет бер фани дөньясын.
Уйнамасаң, әнә, улына бир,
Әтисе өчен улы уйнасын!

Йоклап яткан таллар сискәнсеннәр,
Сискәнсеннәр әле толлар да—

Бер ымсынып, түгәрәккә чыксын
Чиккән яулык алып кулларга.

Уйнасыннар әле, җырласыннар,
Биесеннәр күңел булганчы.
Тол киленнәр кинәт айныганчы,
Ялгызлыктан күңел тулганчы...

*"... Шаулат, шаулат бию көен,*
*Ашкынсыннар барсы да.*
*Яшь егетләр чакырсыннар,*
*Кызлар чыксын каршыга..."*

* * *

Җиңү килде. Җылы җилләр белән
Кабат кайтты исән калганнар.
Кулсызы да кайтты, телсезе дә,
Кайтты орден-медаль алганнар...

Кайтты алар кырга, эшкә сусап,
Җырга сусап, сусап моңнарга.
"Насыйп булыр микән илгә кайтып,
Үз телемдә җырлар тыңларга?

Шул җырларны юлдаш итәр идем,
Кулдаш итәр идем эшемдә.
Алла боерса, насыйп булыр әле,—
Пар аккошлар күрдем төшемдә".

Әнә шундый изге хисләр белән
Күпме татар йөрде сугышта,
Күпме татар, шуны ишетәлми
Күзен йомды соңгы сулышта?!

Исәннәре—өйдә. Колак салган көйгә
Радиодан килгән моңнарга,
Мөмкинмени авыр суламыйча,
Еламыйча гына тыңларга?!

*"Шәмдәлләрдә генә ләй утлар яна, Гөлҗамал.*
*Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр.*
*Энҗе дә мәрҗән кызларның кул бавы.*
*Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы..."*

Газиз тавыш җырлый, өзеп-өзеп,
Өзелепләр китә бәгырьләр.
Гомер уза. Ул да картая шул.
Кемнәр багар, кемнәр кадерләр?

Кадер түгел, хәтта кабереңне
Белмәүчеләр булыр. Дөнья бу!
Чыршыларның түгел, шагыйрь, җырчыларның
Тамырына чапкан дөнья бу!

Әмма синең моңсар тамырларың
Балта йөзләреннән көчлерәк.
Берсен чапсаң, йөзәү чыга торган
Әкияти зәйтүн төслерәк.

Яннарыңда күкрәп үсеп җитте
Фәридәләр, Зифа, Илһамнар.
Яңа аһәң, яңа җырлар белән
Матур була икән бу таңнар.

Мин үзем дә...
Инде ике ярты яралмыштан
Бөтенгә дә күптән яралдым.
Дөньялыкта кара чәч агарттым,
Бик пакь идем, бераз каралдым...

Шул караны синең җырлар белән
Кайта-кайта кабат агартам.
Ярым яралмышлар хәлемдәге
Изге хисләремне яңартам.

* * *

*"Кәккүк сайрый яз килгәч урманда,*
*Җир яшәргәч, гөл үскәч кырларда.*
*Чут-чут итеп тирәкләрдә сандугач сайрый,*
*Шул чакларда йөрәкләрдә ярсу дәрт кайный..."*

Син дәшәсең миңа еллар аша,
Эндәшәсең ерак чор аша.
Әле һаман хәлем сорашасың
Изге моңнар, изге җыр аша:

"Нихәл, бала? Инде олгаясың,
Онны байтак тарткан тегермән—
Күз тирәңне уйчан нурлар сарган,
Чәчләреңә көмеш йөгергән.

Хәтерлимсең сабый чакларыңда
Без көйләгән моңсу көйләрне.
Ямьле көйләр—"Кәккүк", "Сабан туе",
"Уел", "Фазлуш", "Әллүки"ләрне?"

Мин хәтерлим, җырчым. Мин хәтерлим!
Бүгенгедәй истә гамьле көй—
Халкың белән яши, мәңге яшәр
Син җырлаган мәшһүр "Әллүки"!

Син бүген дә, җырчым, халкың белән,
Күңелләрдә безнең бүген дә.
Кара төндә кыйбла йолдызы син,
Көндез—Кояш татар күгендә,
Якты кояш—татар күңелеңдә!..
Бүген дә!

## Чәчмә әсәрләр

# Әхмәт Гадел

# ӨЗЕЛГӘН КЫЛЛАР

хикәя

Өзелгән кыллар... Бу вальс әйтерсең колакларымда әле дә яңгырап тора. Ул вакытта минә нибары унтугыз яшь иде. Техникум инде тәмамланган. Тиздән армия сафларына китәчәкмен. Көн саен эштән соң күңел ачарга клубка йөрибез. Биюләр... уеннар... Анда без элекке классташлар белән дә очрашабыз. Мәктәптә укыганда ук күңелем төшеп йөргән иде аңа. Тик ул вакытта миңа борылып та карамаган Нурия Чистай педучилищесыннан җәйге каникулларга кайткан. Аның нурлы яшькелт-соры күзләре, көмешсу-коңгырт чәчләре күңелне җилкендерә, җанга тынгылык бирми. Их, бу билгесезлектә булган мәхәббәт газаплары!

Клуб мөдире Тәлгат ару-талуны белмәс иске патефонны уйната башлый. "Өзелгән кыллар" вальсы яңгырый. Бу вальсны без—авыл яшьләре, аеруча яратабыз. Ул көйнең ниндидер бер сихри могҗизасы, тылсымы бар шикелле.

Әйе, андый илаһи көч булмаса, җилкенер идемени безнең күңелләр! Канатлы бөркет сыман очып барыр идеммени мине өнәмәгән Нурия каршына, чакырыр идеммени аны бу вальска?!

Юк, бу юлы да чыкмады Нурия минем белән биергә. Теләмәде. Матур-горур башын чайкады да, тәкъдимемне кире какты. Китәргә иде янышнан, башка кызны чакырырга иде миңа. Беткәнмени безнең чакыруны өзелеп, зарыгып көтеп торган кызлар! Әнә Лилия, әнә Флүрә, әнә Мәдинә... Миләүшә... Зәкия...

Тик мин шул Нурия янында таш сындай, гипнозланган сыман селкенмичә дә торам. Яныннан һич китә алмыйм. Адәм көлкесе.

Нурия!

Урман кизләүләре сыман тулы, саф һәм тирән күзләренә чумып югалыр идем мин аның. Их, әйтәсе, сөйлисе, ачып бирәсе иде аңа эч серемне, бөтен хис-кичерешләремне. Аңлар иде микән ул?

Мин монсу гына Нурия янында торам. Башка кызлар белән биисем дә, янәшә торасым да килми...

Миннән бер-ике айга гына яшьрәк, безнең авылга әле генә гамәли дәресләргә килгән Җәмил безгә таба якынлаша. Ул Нурия каршына туктап баш ия, танцыга чакыра, нидер әйтә. Нурия аңа ягымлы елмаеп җавап бирә, ул шуны гына көткән күрәсең.

Шул чакны колакларыма мин яраткан "Өзелгән кыллар" музыкасы көчле дулкындай килеп бәрелә. Күңелдә давыл күтәрелә. Тукта! Ничек әле ул минем белән танцыга чыкмады, ә ниндидер килдем-килмешәк белән бии, аңа елмая, аның кочагына сыенып әйләнә. Аның көмешсу коңгырт чәчләре Җәмилнең чем-кара бөдрә чәчләренә тия-тия җилферди. Нуриянең чәчләре зур тантана-бәйрәмнәрдә җилфердәгән әләмне хәтерләтә. Нуриягә бәйрәм...

... Бу кичне дә, башка кичләрне дә Җәмил аның белән бии, өенә озата. Минем өчен менә алмаслык бәхет тавы Җәмил өчен кечкенә бер үрчек кенә булды түгелме соң?

Шулай да көннәрнең берендә, кыюлыгымны җыеп, кызга мөрәҗәгать иттем мин:

—Нурия,—дидем,—син мине шул Җәмилгә алыштырдыңмыни?

Ни ишетәм:

—Ничек инде алыштырыйм?! Мин бит сине беркайчан да сөйгән ярым итеп санамадым. Ә аннары... син бит тиздән солдатка китәчәксең...

—Китсәм бит, өч елдан кайтып та килермен!

—Һе, өч ел... Мин нишләрмен, сине көтеп саргаеп өйдә утырырмынмы? Син кайтканчы башка, яшьрәк кызлар үсеп куячак...

—Мин сине бирәүгә дә алыштырмас идем, Нурия.

—Һе, ышан сезгә. Минем Чистайда да бер егетем бар иде. Ул авыл хуҗалыгы техникумында укыды. Әллә нинди вәгъдәләр бирә иде. Үзе техникумны тәмамлады да әллә кая шылды. Менә ышанып яшә сезгә?! Ә Җәмил әле дурак... Алдый белми ул.

—Дураклыгы өчен яратасыңмы?

—Әйе, шуның өчен дә! Аннары ул синең кебек кыюсыз да түгел. Ә диергә житешмисең, кочаклый да үбә...

Утлы күмергә салсалар да, болай янмас идем. Нуриянең болай дуамалачык сөйләшүе мине чыгырдан чыгарды. Вальс бетү белән мин клубтан чыгып киттем.

Караңгы көзге төн. Сентябрь аенда сирәк була торган җылы төн. Әмма салкын декабрь төне булса да, мин хәзер туңмас идем кебек. Чөнки тирәннән, эчемнән янам.

Урамда юл станцасына таба барам. Караңгыда япа-ялгыз йөрисем килә. Их, Нурия, Нурия! Нишләттең син мине исәр кызый?! Мәктәп елларыннан бирле яратам бит мин сине, Лубянда укыганда да башка кызларга күзем төшмәде. Гел син идең минем күңелемдә, Нурия. Син дә мине яратасың кебек тоела иде. Ә син... Шулай да була микәнни соң ул мәхәббәт?!

... Тиздән миңа хәрби комиссариаттан чакыру килде. Кечкенә генә тар колеялы тимер юл поезды мине Казан—Мамадыш юлына алып китте. Станцага кадәр мине әнием генә озата килде. Өстендә иске плюш жакет, башында йомшак мамык шәл. Үзе бәйләгән шәл. Әнинең күзләре кызарган. Моңлы, менә-менә елап җибәрер сыман.

—Әни, елама, тиздән кайтып җитәрмен! Өч ел күп түгел ич. Әле ялга да кайтырмын!—дим мин. Кинәт әнинең иреннәре калтырый...

Әйе, аның үзенә генә җинел булмаячак.

... Армиядән мин Нуриягә хатлар яздым. Ләкин ни беренче, ни икенче, ни унынчы хатыма җавап булмады. Тик сеңлемнән килгән хатта гына, авыл яңалыклары турында язылган урында: "Нурия Җәмилгә кияүгә чыкты",—дигән җөмлә бар иде. Йөрәкне нидер чәнчеп алгандай булды, күңелне моң басты. Нуриягә бүтән хат язмадым. Сеңлемнән дә аның турында сорашмадым. Хезмәтемне тутырып, өйгә кайтырга бер ел калды дигәндә, Җәмилне армиягә алганнар. Әмма бу хәбәр дә миңа берничек тә тәэсир итмәде.

Хатирәләр... Югары классларда укыганда мине пионер вожатые итеп сайлаганнар иде. Мин алтынчы сыйныфта укучылар белән эшләдем. Шунда Земфира исемле кыз бар иде. Сылу гәүдәле, төпле холыклы кыз бала иде ул. Әнә шул кыздан миңа, соңгы елымны хезмәт иткәндә, хат килеп төште. Һәм без бик теләп хатлар яза башладык. Ул Казан финанс институтының беренче курсында укый иде.

Җавап хатларында аның эчке нур, самимилек, акыл бөркеп тора иде сыман. Тормышчан кыз иде ул. Мине ярата да төсле. Миңа җибәргән рәсемен дә һәрчак куен кесәмдә йөртәм. Аулакта алып сокланам. Бөтен уй-теләгем—Земфира белән очрашу. Демобилизациягә кадәрге көннәрне саный-саный арып беттем. Көннәр шундый акрын үтәләр. Әле бит бер елга якын вакыт бар.

Тиздән без диңгездәге бер исемсез утрауга киттек. Анда хәрби самолет һәм корабларга каршы сугышырга өйрәнәбез. Иртә таңнан алып кичке эңгерләр төшкәнче, еш кына төнлә белән дә күкне саклыйбыз, "дошман" очкычларын

күзлибез. Пеленгаторчылар ни әйтә, мин шуны тиз генә команда пунктына, командирларга житкерәм. Морзе аппараты дер-дер килә: нокта да сызык, сызык та нокта эфирга очалар гына. Әйдә, дошман аңлап карасын. Шифрны ул түгел, тапшыручы мин дә белмим. Ни бирделәр, шуны сугам гына. Ә командирлар, бәлки миннән йөз мең чакрым ераклыктадыр, укыйлар да тиешле нәтиҗә ясыйлар. Һәм зенит тубындагыларга тиешле команданы бирәләр...

... Менә өч ел гомер узып та китте. Тиздән туган якларга, өйгә— туганнар янына кайтып китәчәкбез. Тагын бер-ике айдан соң булыр бу тантаналы вакыйга. Ләкин өйгә, туган илгә кайтканчы, без иң элек Варшава килешүен төзегән илләр гаскәрләренең хәрби уеннарында катнашырга тиешбез.

Тукта чү! Радиодан үземнең исемемне ишетәм. Бу көйне "Юность" радиостанциясе аша мина Нурия багышлый. "Өзелгән кыллар". Мин яраткан борынгы вальс! Кинәт күз алдыма авылыбызның агач клубындагы уен кичәләре, шунда елмаеп-көлеп йөргән Нурия килеп баса. Ул Җәмил белән бии. Мин исә монсу гына читтә торам. Их, Нурия! Нурия!..

Күңелдә ниндидер сызлану, үпкә, канәгатьсезләнү хисе уяна. Нуриянең күңелдәге сурәтен ихлас күңелле, кешелекле, мине табып, ике елга якын хезмәт итәргә ярдәм иткән, хатлары белән өмет тудырган һәм киләчәк тормышыма ышаныч биргән Зимфираның нурлы йөзе алыштыра.

Юк, юк! Зимфирага хыянәт итә алмыйм мин. Ә аннары, Нурия кияүдә ич ул. Ирен көтсен. Кияүгә чыгар алдыннан нигә уйламаган соң? Муенында ул вакытта да башы бар иде бит!

Менә мин Казанга да кайтып җиттем. Ашыга-ашыга Карл Маркс урамына төшәм. Менә финанс институтының студентлар йорты. Керәм. Һәм ни күрим, кизү өстәле артында Зимфира үзе утыра. Мине күргәч, ул үзе дә абайламастан сикереп тора. Әкренләп битләре алсулана. Ул каршыма атлый. Аннары бер мизгелгә туктый. Әнвәр!.. Әнвәр... абый...—ди ул һәм кочагыма ташлана! Кайттың! Ә мин Малиновский приказын да бүлмәдә элеп куйдым...—Һәм ул тагы да кызара... Мин ни әйтергә белмичә, сүзсез торам. Алтынчы сыйныфта укыганда кечкенә генә кыз иде Зимфира. Кара, нинди үскән, сылуланган...

Зимфира, иптәш кызы белән сөйләште дә, мине үзенең бүлмәсенә алып менеп китте. Без кергәч, бүлмәдәге кызлар, төрле сәбәп тапкан булып, чыгып киттеләр.

Мин Зимфираны кочып үбәрмен, дип, хыялланып кайткан идем. Кая китте минем кыюлыгым да тәвәккәллегем?! Зимфира белән күзгә-күз карашкач, мин гел югалып калдым. Теге вакытта, аларның классында әйдәмән-вожатый булган чакта, гел башкача иде бит. Мин—Әнвәр абый, ә алар—кечкенә сеңелләрем. Анда мөнәсәбәтләр дә башкача иде. Ә монда гел башка хәл— хәзер мин аның сөйгән егете сыйфатында кайттым булып чыга лабаса!

Шулаймы икән?

Бәлки...

Зимфира йөгерә-йөгерә чәй куеп, табын әзерли башлады...

Үзе нидер сөйли, сөйләшә. Мин исә берни дә аңламыйм. Әллә чукракландым инде...

Аннары Зимфира минем кулымнан ала. Шинелемне салырга ярдәм итә. Погоннарымны сыйпый. Фуражкамны киеп, көзге алдына килеп баса. Һәм көлә-көлә, әйләнә-әйләнә бүлмә буйлап күбәләк кебек оча.

—Нинди рәхәт, Әнвәр абый,—ди ул минем янымa килеп. —Мин кечкенә чагымда сине үз абыем итәргә тели идем. Син шундый матур, шундый йомшак, әйбәт күңелле, шундый кешелекле идең... Минем бит абыйларым юк.

—Әй-е, әй-е!—дим мин. Үземнең Зимфираны кочып аласым, онытылып-онытылып үбәсем килә. Үзем ул үпкәләр дип куркам.

Чәй эчәргә утырабыз. Кызлар керә. Дүрт кыз һәм мин—солдат, бергәләп чәй эчәбез. Үзем күз чите белән генә аларны күзлим. Чибәрләр чукынмышлар! Ләкин араларында иң гүзәле—Зимфира. Минем Зимфирам! Тукта әле? Ничек синең Зимфираң?! Ай-һай, өлгер дә инде син! Синең Зимфираң?!.

Кызлар радиола җибәрәләр.

Янә "Өзелгән кыллар" көе түгелме соң?!

—Синең яраткан көең, Әнвәр абый,—ди Зимфира, миңа тагын да якынлашып.

—Әйе, минем яратуымны каян беләсең?

—Хәтерлисеңме безнең авыл клубын? Мин дә клубка танцыларга йөри идем бит. Ләкин син мине ул чакта күрми дә идең. Ә мин читтә үз тиндәшләрем белән утырыр идем. Һәм бу көй башланганда синең йөзеңне ниндидер сәер, сагышлы шәүләләр күләгәләвен күп тапкырлар күргәнем булды...

Зимфира аз гына тынып торды. Аннары дәвам итте:

—Хәтерлисеңме Нурия апаны?! Син аны ярата идең, ахры. Ә ул сиңа битараф, алай гына да түгел, синнән көлә иде... Шулчак мин сине кызгана идем. Синең янына килеп, житәкләп клубтан алып чыгасы да еракка-еракка китәсе, сине сагышларыңнан аралап аласым килә иде. Үбәсем, назлыйсым, сабый баланы юаткандай юатасым килә иде.

Өйгә кайткач та, күңелемдә син генә булдың... Әнвәр абый. Син, син, син! Мин синең фоторәсемеңне дә таптым. Бүлмәмә элеп куйдым.

Әни: "Кем бу, Әнвәр түгелме соң, бик охшаган!"—диде. Ачуланмасын, дип куркып: "Юк, әни, бу артист фоторәсеме ич, Әнвәр абыйга охшаган гына!"—дидем. Әни елмаеп, миңа ышангансыман булды. Шуннан бирле ул фоторәсем турында беркайчан да сорамады. Ә инде синнән минем хатларга җавап килә башлагач, ул гел тынычланды. Начар егет түгел Әнвәр абыең, язып,—диде.

Кызлар да тынлый дип уйлап, башымны күтәрдем. Бүлмәдә без икәү генә калганбыз икән. Без икебез һәм... "Өзелгән кыллар" вальсы...

Әйе, Нурия мине яратмый иде шул. Ләкин нигә исенә төшергән соң әле ул мине? Нигә ул үзәгемне өзә торган шушы көйне бөтенсоюз радиосы аша, минем өчен тапшыруны сорады икән соң?..

Уйларымны сизгәндәй, Зимфира сүзен дәвам итте:

—Нурия апа Җәмилгә кияүгә чыгып бәхетле була алмады. Өйләнешеп яши башлаганнарының икенче атнасында ук, алар сугышып урамга чыктылар. Җәмил исә аның турында бөтен авылга: "Кыз түгел иде!"—дип, сөйләп йөрде. Аннары тагы дуслаштылар. Стансага менеп, анда урманчылык өендә тордылар. Җәмил урман техникгы иде бит. Анда яшәгәндә дә Нурия көн саен авылга, әниләренә төшә иде. Йә каенанасы рәнҗеткән була, йә Җәмил тәпәләгән була иде аны. Күз төпләре күгәреп шактый йөрде ул. Авыл халкы: "Шәмси кызы егетләрне сайлый-сайлый, ниһаять, телэгенә ирешеп, тукмаклыга кияүгә чыкты",—дип сөйләде.

Хәзер Нурия леспромхоз балалар бакчасында эшли. Җәмиле армиягә киткән ди.

Авылга без Зимфира белән бергә кайтып киттек. Өйгә уйлана-уйлана кайттым. Төн. Тәрәзәләребездә инде күптән ут сүнгән. Тик каршыма йокы белмәс Сарбай атылып чыкты. Сарбай—ул безнең этебез. Ике-өч тапкыр өрде дә, таныгач, ялагайланып чиный-чиный аяк астында урала башлады. Өч елдан артык гомер узса да онытмаган, көткән изге җан. Тавышка, ишекне киң итеп ачып, әни килеп чыкты. "Улым!"—диде дә кочагыма килеп сыенды. Сеңелләрем, энеләрем дә уянганнар. "Абый!"—дип, муеныма килеп сарылдылар. Таң атканчы сөйләшеп утырдык.

Икенче көнне кич мин клубка чыктым. Авылда кайткан солдатлардан бер үзем генә идем. Зимфира да килгән. Рәхәтләнеп биедек. Яшьләр, мин киткәндә күз дә төшмәслек малайлар, кыз-кыркыннар үсеп житкәннәр инде, кызлар пешкән алма төсле, берсеннән-берсе чибәр, буй җиткән.

Танцылар бетеп, өйгә кайтырга дип чыгып барганда, клубка берничә хатын-кыз арасында Нурия дә килеп керде. Мин исәнләштем дә Зимфираны җитәкләп чыгып барам.

—О, солдат кайткан икән, сине танырлык та түгел хәзер!—диде Нурия. Күзләре ут яна. Бит алмаларында ялкыннар уйный. Йөрәгемне, эчемне, бөтен вөҗүдемне электр тогы яндырып үткәндәй булды. Нурия! Күп яндым, хыялландым, күп тилмердем мин син дип, Нурия!

Зимфира терсәгемне кысты:

—Әнвәр абый, әйдә инде, соңга калабыз бит!—ди. Кая соңга калабыз? Ни сөйли Зимфира?! Киттек. Ә арттан Нурия һәм теге хатыннар: "Утырмага килергә онытма. Станцада аулак өй, урманчы йортында!"—дип, кычкырып калдылар.

Аулак өйгә мин, әлбәттә, бармадым. Зимфира үзләренә чакырды. Аларда бик озак кунак булдым. Әнисе-әтисе белән сөйләшеп утырдык. Армиядән соң ни эшләргә уйлавым турында, авылда каламмы, укырга, йә эшләргә шәһәргә китәмме—шулар турында әңгәмә кордык. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар. Сүзгә дә, фикергә дә бай кешеләр.

Мин үземнең яңа гына төзелә башлаган Түбән Кама нефть-химия комбинаты төзелешенә китәргә ниятләвем, аннан, бер ел эшләгәч, берәр институтка керергә исәп итүем турында әйттем. Бәлки КХТИга керермен,—дидем мин.

—Менә Зимфира да икенче курсны тәмамлый инде. Бергә-бергә укырсыз, алай җиңелрәк тә була ул,—диде Зимфираның әнисе.

—Бәлки Казанда түгел, шул ук Түбән Камада укып та булыр әле, Җамал апа,—дидем мин.

—Юк, юк! Казанга барып керергә кирәк, анда укытучылар да күптәнге, тирән белемле,—диде кызның әтисе.—Аннары бер тирәдә булсагыз, безгә дә күңелле булыр иде,—дип өстәп куйды ул.—Зимфираның абыйлары да, апалары да юк ич. Сине ул үзе бик ихтирам да итә.

—Алай гынамы, әтисе,—диде Җамал апа көлемсерәп,—Зимфира Әнвәр дип аһ итеп тора лабаса. Ярата ич ул аны.

—Ярар инде, әни!—диде кызара төшеп Зимфира.

Мин исә оялуымнан башымны иеп утырдым.

Тиздән, әнидән рөхсәт алып, мин Түбән Камага эшкә киттем.

—Фатир ала алсаң, янына без дә килербез, бәлки,—диде әни.

Мин көн саен диярлек Зимфирадан хат алам. Укуы турында яза. Минем кая эшләвем, буш вакытымны ничек уздыруым турында җентекләп сораша. Мин барысы турында да тәфсилләп язам.

Менә инде икенче ай мин төзелеш идарәсенең бердәнбер компрессор-машинисты булып эшлим. Машинамны һәм эшемне яратам.

Көтмәгәндә Зимфирадан телеграмма килде: "Шимбә көнне Чургат чалына төшеп каршыла. "Метеор-81", сәгать 11 дә килеп җитә".

Мин ашыга-ашыга Чургатка киттем. Җәяү өч-дүрт чакрым барырга кирәк. Автобуслар сирәк йөри. Чал* баржасы буйлап арлы-бирле йөрим. Чистайдан "Ракета" килде: Бер-бер артлы кешеләр төшә. Һәм... ни күрим, төшүчеләр арасында—Нурия. Күрмәмешкә сабышып, яр буеннан китәргә ашыктым. Ләкин мине Нурия күреп алды: "Әнвәр!"—дип кычкыра-кычкыра, артымнан куып җитте.

—Кара, кара, танымый да башлаган шәһәр кешеләре!—ди. Үзенең күзләре яна.—Кемне каршылыйсың?—ди.

—Зимфира кайтырга тиеш,—дим мин, юри "кайтырга" дигән сүзгә басым ясап,—телеграмма җибәргән. Сәгать 11дә "Метеор" килергә тиеш,—дим. Күзләрен җиргә төбәде Нурия.

—Димәк, сине тәки аулады инде ул елан! Менә сиңа Зимфира!—ди ул. Тавышында ниндидер яшькелт агу сизелә, көнчелек агуы.

—Мин аны үзем ауладым. Әйбәт кыз ич! Кайберәүләр кебек, тегендә-монда сугылып йөрми, үзе тормышчан да...

—Ә мин аны Казанда бик каты типтерә дип ишеттем. Бер урыс егете белән чуала икән... сүз йөри...

Йөрәгем жу итеп өзелеп төшкәндәй булды. Әмма Нуриягә сер бирмәскә тырыштым.

—Зимфира андыйлардан түгел!—дим, елмаеп.—Көнчелек шулай сөйләндерә сине, көнчелек!

—И-и-и, агулаган үзеңне, сихерләгән шул маңка кыз! Сиңа тиңме инде

---

* Чал—пристань.

ул?! Әнвәр, мәктәптә укыганда син мине ярата идең бит... Онытгыңмыни?

—Ир хатыннары белән бернинди дә мөнәсәбәткә кермим! Бигрәк тә дусларымның хәләлләре белән... Бу минем алтын кагыйдәм. Кануным!—дим, елмаеп Нуриягә.—Син нигә килдең соң?

—Авыл туйдырды. Гайбәт. Теләгән эчемлегеңне эчмә, теләгән ашыңны ашама...

—Теләгән кешең белән очрашма... Бигрәк тә җанкаең армиядә чакта! Шулаймы?

—Дөресен әйтәсең!—диде Нурия, моңлы гына.—Аннары ул, җанкаем, минем тырнак очыма да тормый. Хатыннардан бер ягы да артык түгел аның. Өстәвенә сугыша иде әле... Әнвәр, әйдә бүген очрашабыз, ә?.. Иптәш кызларым биредә яши... Бергә укыдык... һәммәсенең фатиры бар... Шуларның берсендә. Аерым... икәү генә...

—Юк! Теләмим. Булмый.

—Нәрсә булмый?!—диде ул, борчылган тавыш белән,—Нигә булмый?

—Өзелгән кылларны яңадан ялгасаң, алардан барыбер көй дөрес чыкмый... тавышы башкача чыга, син теләгәнчә булмый ул, Нурия...

—Нинди өзелгән кыл! Әллә ни сөйлисең син, аңламыйм? Әллә ычкындың инде. Мин сиңа—берне, син—икенчене...—ди үпкәләп һәм кыза төшеп Нурия.

—Син, Нурия элек тә мине аңламадың шул...—дидем мин һәм аның янынннан читкә атладым. Ул моңсу гына артымнан карап калды. Кызгандым мин аны. Борылып килеп, аны юатасым, тынычландырасым килде, әмма...

Еракган, Сөнтәк таулары итәгеннән якынаеп килгән "Метеор" күренде. "Өзелгән кыллар"...—дип пышылдадым мин, үзем дә сизмәстән. Нишлисең бит, акыл соңара шул кайчак...

"Метеор" яр буена килеп җитүгә, аның палубасында, ярга текәлеп, мине эзләүче Зимфираны күреп алам. Шатлыктан йөрәгем ашкынып тибә. Ул да мине күрде, әнә кулын болгый. Шунда үземне якты уйлар, яңа хисләр биләп алганын, күңел кылларымның әлегәчә ишетелмәгән матур вә моңлы бер көйгә чыңлавын ишеткәндәй булам...

---

## Журналның киләсе санында укыгыз:

"Казан утлары"ның 3 нче саны чәчмә әсәрләргә аеруча бай булачак. Ул танылган язучы, публицист һәм милли хәрәкәтнең актив эшлеклесе **Айдар Хәлимнең** "Гомер сәгате" исемле кыска романы белән ачыла. Болардан тыш **Әмирҗан Моталлаповның** "Нигез" дип исемләнгән лирик повесте, Үзбәкстанда яшәп иҗат иткән язучы, чыгышы белән милләттәшебез **Җәүдәт Ильясовның** "Тынлык манарасы" романыннан өзек тәкъдим ителәчәк.

Март аенда Татарстанның халык язучысы, әдәбиятыбызның аксакалы **Әмирхан ага Еникигә** 90 яшь тула. Журнал битләрендә күренекле әдип һәм фикер иясе турында чордашлары һәм каләмдәшләренең фикерләре, истәлекләр, шагыйрьләр авазы урын алачак. Укучылар игътибарына шулай ук юбилярның "Шаяру" дигән хикәясе тәкъдим ителә.

Шигърият сөючеләрне **Рәдиф Гаташ, Илдус Гыйләҗев, Нәҗибә Сафина** кебек шагыйрьләр, поэзиягә әле беренче адымнарын гына ясаган унҗиде яшьлек кыз бала **Луиза Янсуар** шигырьләре белән очрашулар көтә.

*Журналның публицистика, әдәби тәнкыйть, фән бүлекләре сәхифәләрендә укучылар бүгенге әдәби процесс һәм үткәнебезне чагылдырган, фән вә дин проблемаларын колачлаган эчтәлекле язмалар, сәяхәтнамәләр белән таныштырлар.*



# Роза Хафизова

## ПАРЧАЛАР

### Бәлеш

Авыл мичендә пешкән чын татар бәлешен авыз итеп караганыгыз бармы сезнең? Хуш исеннән үк башлар әйләнә. Кызыл чүпләмле ашъяулык җәйгән күркәм табын уртасына куелган кызарып пешкән, пар бөркеп торучы бәлешне күрүгә үк авыздан сулар килә башлый. Үзеннең бу дөньяда яшәвенә тагын бер кат шөкрана итәсең. Шушы чын сәнгать әсәрен тудырган хуҗабикә исә, бәлешне табынга куйгач, "ошатырсызмы икән" дигән кебек, кыюсыз гына кунакларга күз сирпеп ала. Татар дөньясының моннан да илаһи, моннан да изге мизгелләре бармы икән?! Без, шәһәрдә яшәүче хатын-кызлар, духовкада, газда пешереп азапланган бәлешләрең бер читтә торсын!

Күптән түгел бер авылга китап укучылар белән очрашуга барган җирдә мин шундый әйтеп аңлатып булмый торган гаҗәеп хисләр кичердем. Табынга гаҗәеп зур, мәһабәт бәлеш килде. Хуҗа бөтен хәсиятен китереп, бисмилла әйтеп, башта бәлешнең өстен кисеп тәлинкәгә куйды. Аннары агач кашык белән аны бутап алды. Бәлеш өстеннән хуш исле пар күтәрелде. Тамак та ачкан булгандыр күрәсең, бәлешне кочаклап алып, бер ялгызым кабып йотардай булып түземсезләнеп утырам. Кулымда агач кашык. Шулчак табын хуҗасы, ачык, мөлаем йөзле яшь кенә ир уң кулы белән үрелеп, өстәл астыннан, үзе әйтмешли, "урыс малаен" тартып чыгарды. Йә, Алла!

Хуҗа бик канәгать кыяфәт белән стаканнарга аракы коя. "Бәлеш алдыннан фарыздыр ул, җәмәгать",— дип сөйләнә. Миңа исә нидер булды. Өй эче караңгыланып, кечерәеп калгандай күренде, табынның сихри тылсымы юкка чыкты. Шундый да затлы, телләрне йотарлык татар бәлешен аракы белән хурлаган табын артыннан тизрәк кузгалып китәсем килде. Алдыма куйган стаканны читкәрәк этәрдем дә, бәлешне аннан-моннан капкалап, табын яныннан кузгалу ягын карадым. Күңелне "нишләдек без, кая барабыз" дигән газаплы уйлар боргычлый иде. Кызганыч, чит арбага утырып бара шул халкым, чит арбага...

### Ялгыз кабер

Без үскәндә авылыбызның Сары чишмә дигән болынына бару юлында, Шушма елгасының дуга ясап борылган бер төбәгендә, кечкенә генә калкулык бар иде. Болынга казлар карарга барган чакта, әби шул калкулыкны читләтеп үтү ягын карый һәм авыз эченнән генә нindidер догалар укый иде. Мин үсә төшкәч кенә әби ул калкулыкның кабер булуы турында сөйләде. Анда авылның эчеп үлгән бер кешесен күмгәннәр

икән. Ул кеше озак вакытлар каядыр читтә, авылча әйтсән, зимагурлыкта йөргән. Авылга кайтып озак тормаган, эчеп үлгән. Картлар аны зиратка күмәргә рөхсәт итмәгәннәр. Чөнки аракы эчү гөнаһ саналган. Эчеп үлү гайре табигый хәл булган.

Сугышка хәтле авыл тормышын яхшы хәтерлим. Безнең авылда ике мәчет бар иде һәм кичләрен азан әйткән тавышлар янгырап тора иде. Рамазан ае без, бала-чага өчен дә зур бәйрәм кебек кабул ителә иде. Мәчет ишегалдына җыелып, мөәзиннең авыз ачар вакыт җиткәнен белдереп азан әйткәнен сабырсызланып көтеп алабыз һәм чабып кайтып әбиләргә житкерергә тырышабыз. Ул елларда мин безнең йортка аракы кергәнен хәтерләмим. Сугыштан соң таралды ул эчкечелек дигән афәт. Күбебезнең әтиләре кайчандыр безнең газиз ватаныбызны канга батырып тар-мар иткән бөек урыс" дәүләте мәнфәгатьләрен яклап шәһит китәргә мәҗбүр ителделәр. Исәннәргә ияреп, урыс гадәте, "галиҗәнап аракы", афәт кайтты. Ни аяныч, бу афәт тыйнаклыгы, сабырлыгы белән дан алган татар хатын-кызларын да читләтеп үтмәде. Димәк, халкыбызның генофондына, тамырына балта чабылды дигән сүз. Хәзер инде Шушма елгасы буенда ялгыз каберләр юк. Исереп үлгәннәрне дә авыл зиратына күмәләр.

## Хуҗа һәм куян

Хуҗа мал суя торган пычагын кайрап утыра. Куян чалырга әзерләнә. Суяр өчен читлектән чыгарылган соры куян тирәсендә җиде-сигез яшьлек ике малай әвәрә килә. Аны колакларыннан тотып күтәрәләр, авызын ачтырып, тешләрен барлыйлар. Малайларның куян белән уйныйсылары килә, куян исә алардан котылырга теләп азаплана. Әмма берничек тә булдыра алмый, ычкынып китүе була, малайлар аны шундук эләктерәләр. Качар урын юк, абзар кечкенә.

Хуҗа пычакны сакал очларына тидереп, аның үткенлеген барлый. Малайлардан тәмам гаҗиз булган бичара куян ярдәм, яклау сорап, хуҗаның аякларына сарыла. Манкротларның "бөек халык" мәрхәмәтенә өмет итеп яшәгәннәре кебек...

**Редакциядән:**

*Балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән күренекле язучы Роза Хафизованың февраль аенда туган көне. "Казан утлары" коллективы юбилярны ихлас котлый, аңа сәламәтлек, озын гомер тели.*

# ШИГЪРИЯТ

## ШИГЫРЬ ТАМЫРЫ

Һәр шагыйрь Шигырьгә үзенчә килә...

Шушы юлны күзалларга тырышып, иҗатның тамырын эзләп Галиҗәнап шигырь турында сүз чыкканда шагыйрь дусларыма мин менә мондыйрак сорау белән мөрәҗәгать итәргә яратам:

—Беренче шигырьләреңне кайчан яза башладың син, шагыйрь туганым? Үзеңне кайчан шагыйрь итеп тойдың?

Беркатлылык, әлбәттә, әмма минем шул рәвешле шагыйрь дустымның үсеш эволюциясен күз алдыма китерәсем килә—кызык ич, нәрсә мәҗбүр иткән аны кулына каләм алырга, шигырьдә нинди уйлар җилкендереп яшәтә аны? Һәм минем шушы сорауны биргәндә, яшьтән үк иҗат белән җитди рәвештә шөгыльләнә башлаган шагыйрьләр генә (талант мөмкинлек биргән кадәренчә, әлбәттә,) профессиональлек дәрәҗәсенә ирешәләр, дигән "гипотеза"ма уңай җавап та аласым килә бугай. Чөнки—ерактан килгән генә еракка китәр, диләр ич.

Танылган шагыйрь Госман Садә белән дә безнең шушы хакта озаклап моназара килеп утырганыбыз бар. Булды андый хәлләр.

—Башкалар турында әйтә алмыйм,—дигән иде ул сөйләшүләрнең берсендә,—шәхсән үземә килгәндә, бәхет эшедер инде, Ходай миңа шигъри җимне имезлек белән бергә салган булган. Дәүәни—әтиемнең әнисе—Хәкимә картый сөйләвенә караганда, минем телем бик иртә ачылган: әле сәке буйлап мүкәләп йөргән чагында ук ул миңа җырлар җырлаган, Габдулла Тукай китабыннан көйләп "шиерлар" укыган. Әйе, мин: "Бәбкәм, кем бу? Кем китабы бу?"—дигән сорауга: "Актүнәкәй... Актүнәкәй шаерли булган, ул шиерлар язган",—дип әйтә торган булганмын; Габдулла Тукай дип әйтә алмаганмындыр инде, күрәсең.

Әбиле үскән бүгенге урта һәм өлкән буын әдипләр өчен таныш кичерешләр бу: аларның күбесе беренче шигъри мәктәпләрен шул рәвешле үтте ләбаса.

—Монысы сабыйчак хатирәсе,—дип сүзен дәвам итте Госман әфәнде.—Балачактан исә мондый бер вакыйга истә уелып калган. Нәкъ менә Такташча инде: үземнән бер генә яшькә олы Мәүләви абый белән "зурлар кебек кулны артка куеп", якында гына агып яткан Төй елгасы буена морда үрер өчен тал чыбыклары алып кайтырга төшеп барабыз. Абый сөйли, мин тыңлыйм. Шунда ул миңа:

—Шигырьләр язып карадым әле, энекәш,—ди.

—Аны ничек язалар соң?—дим мин исем китеп. Шигырь хәтле шигырь язып кара әле син...

—Башта күргән-уйлаганнарыңны хикәя итеп язасың, аннары юлдан-юлга шигырь итеп күчерәсең.

Абыйдан калышасым килмәгәндер инде, качыра-качыра шигырь чыгара башладым; кыскасы, ләззәтле дә, сихри дә билгесезлеккә чумдым. Беренче шигырьләрем 6 класста укыган чагында "Башкортстан пионеры" гәзитәсендә басылып чыкты. Шуннан соң китте инде. Бөтен класс мине "язучы" дип атап йөртә башлады.

—Үзең үзеңне кайчан шагыйрь итеп тоя башладың?

—Уфа дәүләт университетының 3 курсында укыганда мин беренче зур тетрәнү кичердем. Уфада "Мөселманнар зираты" дигән бер зират бар. Салават баһадирга куелган һәйкәл дә янәшәдә генә. Шәһәр белән танышып йөри торгач, көннәрдән беркөнне шул тирәгә барып чыктым бит. Үземчә уйлыйм инде, татар зираты булгач, татарлар яши торган урам да булырга тиеш бит, дим. Шунда бер карт кына абзыйдан сорыйм, ә ул бәләкәй генә тыкрыкка төртеп күрсәтә. Йөрим, карыйм, саныйм: алты

гына өе бар. Шул чакта миңа халкым өчен бик тә, бик тә кыен булып китте: 6 миллионлы татарның (официаль мәгълүматлар буенча шулай иде) Уфада татарның алты йортлык урамы бар... "Татар урамы" дигән шигырем шундый хисләр шаукымында дөньяга килде.

Урамнарга берүк чыга күрмә,
Бурый гына февраль бураны;
Бар Уфаны айкап-айкап киләм:
—Кайсы якта татар урамы?
... Табалмагач эзләп, сорап та,
Мин эндәштем ак сакаллы картка,
Ул күрсәтте төртеп зиратка...

Бу юлларның "гонорары" миңа шактый кыйммәткә төште: татарлыгым өчен стипендия дигән сәдакадан мәхрүм иттеләр, кырын карый башладылар. Кемнәрдер (кемнәр икәне билгеле инде) астыртын киная белән: "Исәнме, татар урамы?"—дип эндәшә башлады, икенче берәүләр исә (алары азлар иде), бу сүзне горурланып әйттеләр. Шушы ярлык тагылгач, миндә Казанга китү теләге уянды. Бары тик Казанга, Казанга...

Бер "теле ачылгач", билгеле, минем Госман әфәндене сөйләтәсем дә сөйләтәсем килде, чөнки кеше дигәнең күңел түрендәге изге хисләрен тышка чыгарып салырга бик ашыкмый ул.

—Сөйлә әле, Госман дус, "бер матурның балдагын, йә калфагын?"

—Шагыйрь дигән "паспорт"ны миңа Хәсән ага Туфан үзе тапшырды. Ул болай булды. 1972 ел. Октябрь айлары иде бугай, Язучыларның Тукай клубында "Казан утлары" журналының беренче алты санына ел саен үткәрелә торган күзәтү бара. Шунда Хәсән ага 9 санда басылып чыккан "Язгы җыр" исемле шигыремне (миңа калса!) бик мактап телгә алды. Тагын бер айлап вакыт узды. Зөлфәт белән Язучылар союзы коридорында басып торабыз. Кайсыдыр бер бүлмәдән Хәсән ага килеп чыкты. Зөлфәт инде үз кеше иде, могтәбәр әдип белән ике куллап барып күреште. Һәм миңа таба борылып: "Хәсән ага, Сез трибунадан мактап телгә алган Госман Садә дигән егет шушы була инде!"—диде, мәгънәле генә елмаеп: кил, күреш, янәсе. Хәсән ага мине ике кулы белән кочаклап алды: "Һи, улым, ул син буласыңмыни инде Садә дигән егет? Яз, язарга, язарга кирәк сиңа..." Бу сүзләр миңа наказ булып ишетелде һәм мин үземне шушы кыска гына сөйләшүдән соң Хәсән аганың мине шагыйрь итеп кабул иткәнен тойдым...

Әйе, олуг шагыйрьнең фатихасын алган Госман Садә бүген татар шигъриятенең үзенчәлекле бер таланты булып танылды. Ә ул үзенчәлек шуннан гыйбарәттер: Госман "ачык текст" белән яза, ул фикерләрен, ассоциатив кинаяләргә яшереп маташмый, ә бәлки билгеле бер эзлекле калыпка салып, ачыктан-ачык әйтеп бирергә ярата. Хисләр—вакыйгалар белән бергә үрелеп бара. Шушы хасияткә буйсынып булса кирәк, күп очракта аның шигырьләре динамик үсешле сюжетка, вакыйгалар агышына корылган булалар. Госман Садә үзе бу алымны "Уфа мәктәбе" дип атый. Шулай булуы да бик мөмкин, чөнки ул Уфа чорында Әнгам Атнабаев кебек күренекле шагыйрьләр белән аралашып яшәгән, алар белән бер үк иҗади мохитта кайнаган. Әнгам ага аны "мин олы мыек булсам, син кече мыек" дип атап йөрткән (Госманның журналдагы сурәтенә генә карагыз: аңарда, чынлап та, Әнгам аганың төсмерчалымнары чагыла түгелме соң?), мондый рухи якынлык, әлбәттә, шагыйрьнең иҗатына да йогынты ясамый калмагандыр. Кайчак Госман Садә иҗатында Фатих Кәрим аһәңнәре дә яңгырап киткәндәй була; бу аһәң аеруча шагыйрь яратып иҗат итә торган балладалар жанрында ачык ишетелә—әйе, әйе, Чечняның күз яше төшкән "Фирүзә чишмәсе" дигән балладаны укыганнан соң, ирексездән, бөек шагыйребезнең "Аникин", "Гөлчәчәккә хат" поэмалары телгә килә. Шул ук халыкчан иңрәү, моң, фаҗига... Вакыйгалар гына башка...

Сизгер тоемлы Рәдиф Гаташ исә, Госман Садә иҗатындагы "йолдызларны җиргә коя хыял-атның тоягы..." дигән юлларда "Мостай Кәримнең тавышын" ишетеп куана.


... Госман Садә татар шигъриятенә, мәдәниятенә игелекле хезмәт итеп килүче шәхесләрнең берсе. Ул—"Мәхәббәт елы", "Җиләкле тәрәзәләр", "Тайфун күзе" кебек

җыентыклар авторы. Аның утыздан артык шигыренә композиторларыбыз көй язганнар: "Әссәламәгаләйкем", "Рамазан", "Җомга азаны", "Кәккүк, яме" кебек милли рухлы җырлары исә халык күңеленә "язылганнар".

Болары шулай... Әмма Госман Садәнең әле өстәлендә беркайда да басылып чыкмаган көлтә-көлтә шигырьләрен күргәч, моннан берничә еллар элек булып узган гыйбрәтле бер вакыйга хәтергә төшеп, күңелне әрнетеп куйды әле. "Чаян" журналында бергә эшләгәндә, мәрхүм Фаил Шәфигуллин Зөлфәтнең өстәлендә тузгып яткан шигырьләренә текәлеп карап торган торган да, киная белән: "Син, Зөлфәт, кәнишне, бөек шагыйрь, әмма син үзеңнең кадереңне үзең белмисең",—дигән. "Ничек инде, ничек?",—дип акланмакчы булган Зөлфәт. Фаил исә, аңа гына хас үҗәтлек белән Зөлфәтне стенага терәгән: "Кая китабың?" Икенче бер вакыт, җаен туры китереп, Зөлфәт бу тортмәле сүзне Госман Садәгә күчерә: "Син, Госман, билгеле, зур шагыйрь, әмма... Фаил әйтмешли..."

Әйе, Фаил әйтмешли, юк ла, Зөлфәт әйтмешли: кая дүртенче китабың, Госман дус? Бу синнән генә тормый, әлбәттә. Барыбер... бар иҗатны ташка басылган Сүз итеп күрәсе килә. Төй һәм Караидел буйларыннан, Урал төбәгеннән башланып, Казансу белән Идел киңлекләренә җәелгән җырыңның дәвамын ишетәсе килә. Ишетербез, Ходай насыйп итсә, чөнки җырларыңның тамыры халык күңеленнән күтәрелә синең...

Наис ГАМБӘР



# Госман Садә

## Сүзем—ялкыным

Сүзләр дә әүвәл
Утта яралган;
Ут булып алар
Җиргә таралган.

Сөю сүзе дә
Утта коелган;
Аның ялкыны
Җанга уелган.

Ялкынлы яшен—
Җандагы балкыш;
Хыянәт килеп
Кагылса ялгыш,

Яшен чаткысы
Шартлап кабыныр.
Нәфрәт учагы
Җанны яндырыр.

Нәфрәт сүзе дә
Ялкында туган.
Мәхәббәт-нәфрәт
Йөри бер юлдан.

Сүзнең ялкыны
Әгәр сүрелсә,
Кулның салкыны
Җанга үрелсә—

Җиргә кешеләр
Бик кыйммәт түләр;
Җанда беренче
Мәхәббәт үләр.

Мәхәббәт үлсә—
Нәфрәткә чират;
Җанның үзен дә
Йотачак зират.

... Сүзләр дә әүвәл
Утта коелган,
Мәхәббәт булып
Җанга уелган.

Син дә мәхәббәт
Телендә сөйләш.
Сүзем-ялкыным,
Җанга ут өләш!

*1990*

## Синдә генә җан сулышым

Туган ягым—җәен яшел,
Кышын ап-ак намазлыгым.
Сабый чактан дога сыман
Җанга иңгән азатлыгым.

Мин читнеке, ят илнеке
Була алмам—теләсәм дә.
Шуны сөйләр урманымда
Киек мәче—селәүсән дә.

Суларыңда дулкын кичә
Кызыл канат—көмеш балык.
Алыштырмам сине ятка,
Тилмерсәм дә сусыз калып.
Мин ирекле синдә генә
Кардәш кошым—шәүлегәндәй.
Янам фәкать синең өчен
Шәмдәлләрдә сүнмәс шәмдәй.

Туган ягым, синдә генә
Горур булып үсә нарат.
(Тамырың нык булсын дисәң,
Туфрагыңны, җирне ярат!)

Кыяларың—афәтләрдән
Йолып калган сынмас калкан.
Сиңа гына таянганга
Мин яктыга карап калкам.

Зәңгәр күзле чишмәләрдән
Алдым кодрәт—тел ачкычы.
Туган телен хурлаучыга
Төшсен каһәр—җир каргышы.

Туган ягым—җәен яшел,
Кышын ап-ак намазлыгым.
Синдә генә—җан сулышым,
Синдә генә—азатлыгым.

*1992*

## Тетрәү

Тауларга килмә кайчан—
Сер булып кала таулар.
Килә дә беркөн тетрәү—
Ут чәчеп яна таулар.

Мең еллар эндәшмәгән
Тын торган таулар яна...
Таулар да җансыз түгел—
Тетрәүләр кабатлана.

Янарга, тетрәнергә
Тауларны кем өйрәткән?
Иртәме, яки соңмы—
Тетрәү уза йөрәктән...

Тауларга кайчан килмә—
Күңелем тетрәү тоя.
Дәһшәтле тетрәү булып,
Яңа-яшь таулар туа.

*1972—1989*

## Кемдер—иртән, кемдер—кичен

*Баллада*

Тып-тын иде, аяз иде
Иртәсе җәйге айның.
Күрде егет зират карап
Йөргәнен бер бабайның.

Киткәннәрнең рухын зурлап
Кем монда дога кылмас!
Ап-ак җилән кигән бабай—
Нәкъ инде Хозыр Илъяс.

Пәһлевандай Егет аның
Каршына басты килеп,
Гыйбадәтен бүлдергәнен
Белмичә, әллә белеп.

—Ни югалттың, ни эзлисең,
Нигә монда йөрергә?
Сиңа, картлач, күптән вакыт
Кара гүргә керергә.

—Дөрес, улым, бу дөньядан
Китми калмас беркем дә.
Кемдер—иртән, кемдер—кичен...
Барсы—тәңре иркендә...

Каһкаһәләп көлде Егет:
—Миндәме Тәңре колы?
Бәйләнгәнме Ходай белән
Минем дә гомер юлы?

—Тәүбә, диген көлмә, улым,
Зинһар, Тәңре каршында;
Бер ул гына белеп тора,
Күреп тора барсын да...

Егет һаман көлүендә:
—И картлач, сатма юләр;
Сөйли күрмә башкаларга,
Алар да синнән көләр.

Аз гына да акылың юк,
Җитсә дә йөзгә яшең...
... Тып-тын иде, аяз иде...
Егетне сукты яшен.

Кемгә—иртән...
Кемгә—кичен...
Кем дә мәхрүм белүдән...
... Көйрәп калды күмер генә
Каһкаһәләп көлүдән.

*1990*

## Әпә

Бер юләрлек кылсаң,
Син үлгәч тә
Көлә-көлә сөйләп йөрерләр.
Һәр корольнең шуты булган кебек,
Авыл саен була бер юләр.

Үз юләре безнең авылның да:
Әпә Хәким—ягъни дивана.
"Ү-ү!"—ди ул, шулай исәнләшә,
"Ү-ү, Әпә!"—димен мин аңа.

Гыйбарәттер бөтен тел байлыгы,
Күп дигәндә, кырык ымлыктан.
Матурлыкны Ходай җәлләмәгән—
Диванабыз кара мыектан.

Матурларны таный ул үзе дә—
Җиңгәләрне: "Апа, тәт-тә!"—ди,
Хәер бирсәң,
Дога кылган була,
Бит сыпыра: "Алла әп-пә!"—ди.

Сәрхүш күрсә, җен ачуы чыга...
Гәрчә күпләр бездә салгалый.
Андыйларның тетә тетмәләрен
Аты-юлы белән:—Йаф-фа-лый!

Яшел яздан кара көзгә кадәр
Чыбыркысы төшми кулыннан;
Үргән булыр аны кыш аеннан,
Очын үрер айгыр кылыннан.

Ятратканга күрә мал-туарны,
Өй борынча йөри котүгә.
Авыз итә суган-йомыркадан,
Тозын ягып кара ипигә.

Ашап туйгач, битен сыйпап куйгач,
Махоркасын төрә кәгазьгә;
Бу шөгыльдән аны тыеп булмый,
Мохтаж түгел Әпә вәгазьгә.

Гүя король тажы—
Бөжралары
Махоркадан чыккан төтеннең.
Ашап туйгач,
Төреп гәжит бите
Тарта микән шуты корольнең?

Кайдан килсен аңа мондый ләззәт—
Көнләшә ул, бераз чамалый.
Көтүлектә Әпә үзе король—
Чыбыркысы король, йаффалый!

*1989*

## Мәхәббәттә аңлашу

Әгәр дә син жылы туфрак икән,
Ә мин анда—яшел кыяк үлән.

Үлән булып үссәң әгәр син дә,
Мин чык булам үлән күкрәгендә.

Әверелсәң син дә күксел чыкка,
Мин әйләнәм чиксез күк-офыкка.

Әверелсәң син дә әгәр күккә,
Кавышырбыз шулчак гомерлеккә.

*1990*

## Бар итүчем, яратучым

Бар итүчем, яратучым,
Уемда син гомер бакый.
Синнән килгән тиңсез бүләк—
Мәхәббәтем ишек шакый.

Күрсен Җиһан, күрсен Галәм—
Ишегемне ачам иркен.
Мәхәббәттә яна белү—
Синнән күчкән бөек иркем.

Бар итүчем, яратучым,
Синең чиксез кодрәтеңчә;
Дәвамчыма сулыш өреп,
Җаным булып каным күчә.

Күрсен Галәм, күрсен Җиһан:
Ишек ачып улым көтә.
Синнән килгән бөек кодрәт—
Мәхәббәтем дәвам итә.

Исемеңне һәр иртәдә
Тел очымда яңартырмын,
Минем бөек яратучым!
Гомер—бакый, яратырмын.

## Мәхәббәт

Яудырдылар гайбәт уты
Дүрт тарафтан, дүрт яктан;
Бер кара сүз җитә кайчак
Егар өчен аяктан.

Кара төндә кара елан
Ыргыттылар морҗадан;
Кем килер дә йолып алыр
Сихерләнгән бөҗрадан?

Кем дә түгел, син ул фәкать
Ия чиксез шәфкатькә;
Барысын да син аңларсың—
Кара кичке шәфәкъкә.

Йөгерерсең ялан тәпи
Утлы күмер өстеннән.
... Сүндерергә мәхәббәтне
Килми сихер көченнән.

*1997*

## Көтү куганны искә төшереп язылган шигырь

Моржалардан төтен чыга,
Яңа көнне каршылап.
Вакыт безне кая куа
Көтүчедәй камчылап?

Юк, абынма!
Вакыт көтми,
Әйләнеп кайтмый кабат.
Юл читендә, ташлы комда
Калтырап ята канат.

Кайчан гына бер кош булып,
Ул канат очып йөргән.
Югарыдан, тәрәз аша
Бизәнгән кызны күргән.

Кошлар оча һаман күктә
Ярышып вакыт белән.
Аста сазлык...
Сарган аны
Хәнҗәрдәй кыяк үлән.

Моржалардан төтен чыга,
Көтү куар чак җитә.
Чорга акыл кайчан керер?—
Айлап-еллап ил көтә.

Канатка ни...
Хәзер аны
Кем дә кумый камчылап.
... Әллә инде вакыт елый—
Яңгыр ява тамчылап.

*1997*

*Фәнзаман Батталга 60 яшь*

# БАТМЫЙ ТОРГАН БАТТАЛ

Ошбу мәкаләмне язарга утырганчы бу каләм иясе турында әлегәчә нинди фикерләр әйтелде икән дип, эзләнә башлагач, гаҗәпкә калдым. Исемен әйтү белән укучыда елмаю уята торган сатира-юмор остасы, җәмгыятебездәге яман шешләрне кисеп, көйдереп ала торган үткен телле, кискен фикерле публицистик мәкаләләре белән халыкта ихлас ихтирам казанган Фәнзаман Батталның иҗат кыры тәнкыйтьчеләр өчен әлегә күтәрелмәгән чирәм икән ләбаса. "Совет Татарстаны язучылары" дигән китапта да аның турында библиографик мәгълүмат юк. Хәер, бусы аңлашыла да. Аны бит Язучылар берлегенә илле яшен узгач, 1990 елда гына алдылар. Бу турыда Фәнзаман: "Миңа Союз билетын тапшырган көнне Советлар Союзы таркалды, тәк шту, мин—СССР Язучылар союзының соңгы әгъзасы..."—дип, көлеп искә ала.

Үзе туган Үрсу (Урыс) авылының башлангыч мәктәбендә укыганда ук Тукай иҗатына гашыйк булып, каләмгә ябышкан яшь талантның вакытлы матбугатта, күмәк җыентыкларда кайбер әсәрләре дөнья күргәләсә дә, аның мөстәкыйль китабын чыгарырга ашыкмыйлар. "Советка, партиягә каршы кара фикерләрең белән үзеңне дә батырырлар, безне дә харап иттерерсең!"—дип, кире борып торалар...

Тукта, чү! Мин Фәнзаман Баттал иҗатын әлегәчә тәнкыйтьчеләр урап узганнар, дигән идем. Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, дигәндәй, тәнкыйтьче Мансур Вәли "Казан утлары" журналы битләрендә ошбу сатира-юмор остасы белән бик эчтәлекле әңгәмә үткәргән икән. Бу әңгәмә аның узган ел Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән "Тукайлар рухы" дигән китабында да басылып чыкты. Менә шунда Фәнзаман үзенең әдәбият мәйданында ни өчен соңлабрак күренүе турында бик ачык әйтә. "Типик татар совет язучысы ул нинди? Без аның төп сыйфатларыннан арына алдыкмы әле?"—дигән сорауга ул болай ди:

—Кайберәүләр аннан бик тиз суынды. Чөнки башка язучылар коммунистик системаны бәхетле тормышка алып баручы бердәнбер система дип, ихлас күңелдән алданган чорда да, бу төр әдипләр күңелләре белән икенче дөньяда яшәделәр. Дөресен әйтергә кирәк, андыйларның шактый өлеше иҗатка кул селтәде, байтагы эчүгә бирелде. Гаепләп тә булмый. Тирә-ягыңда бер тормыш кайнасын, ә син шуңа капма-каршы фикерле, сюжетлы әсәр язып ят, имеш. Йөрәгеңә, вөҗданыңа каршы гамәл кылу бик авыр ул...

Язучылык иҗатында социалистик реализм кысалары хөкем сөргәндә, яшәп килүче җәмгыятьнең гел тәти якларын гына күрсәтү мәҗбүрият итеп куелган заманда гомум гипнозга бирелми сакланып калырга, рухындагы хакыйкать утын сүндерми яшәргә нәрсә ярдәм итте Фәнзаман Батталга? Сабый чагында ук кайчандыр Шәрифулла бабасы Минзәлә өязендә дин әһеле—имам булуы белән битәрләүләрме, әтисе Сәетбатталны "кулак калдыгы", дип, кат-кат кулга алулар, соңра колхоз кырыннан башак уып кайтуын (гаиләдәге алты баланы ачтан үтермәс бит!) сәбәп итеп, хатыны Миңнебәдәр белән зинданга ябып куюмы, шуннан соң үзеннән кече дүрт туганының ачлыктан һәлак булуларымы, үзенең Хуҗәмәт авылындагы балалар йортында күргән ятимлек ачысы, михнәт-кайгыларымы? Билгеле инде, боларның берсе дә булачак язучының нечкә-сизгер күңелендә тирән эзләрен калдырмый булмагандыр. Хәлбуки, үндүрт яшендә "минем туган илем—бәхет һәм шатлык иле..."—дип шигырь язганнан соң, беренче "тормыш дәресен" әтисе бирә

Фәнзаманга. Улының район гәзитендә басылып чыккан шушы шигырен укып чыга да туры сүзле Сетбаттал абзый, "һы-һы, һы-һы-һы!" ди-ди, озак кына башын чайкап утыра. Аннары улының пионер галстугыннан чеметеп тотып, тәрәзә янына китерә:

—Әнә, күр, Дүсә әбиеңнең өе бүген-иртәгә өстенә җимерелергә тора. Бәхетле ил карчыгымы ул? Әнә тегендәрәк, аякларын сугышта өздергән хәерче өй борынча килә. Шулмы шатлык?!—дип, "яшь шагыйрь"нең зиһен тартмасына "шык" иттереп чиертеп куя.—Менә монда рәтең бар икән үзеңнең. Сүз җаен, язу тәртибен дә беләсең шикелле. Бәс, шулай булгачтын, Ходай биргән сәләтеңне дөрес куллан. Дөресен яз, нәселебезгә кызыллык китермә ыштубы!

Шуның өстәвенә шук телле әнисе сүз җае чыккан саен:

—Карале, атасы, бу "бәхетле ил баласы"на бүген нәрсә ашатыйк икән? Бура төбе такырайды бит... Быелга Фәнзаман улыбызга ертык бүрек белән кыш чыгарга туры килер инде. Хәер, аның "дәртле йөрәгенә суык кыш җиле нипачум" икән бит...—кебегрәк сүзләр белән төрттерә.

Башында фәһеме булган балага мондый "дәресләр" эзсез уза аламыни?! Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, дип, халык юкка гына әйтмәгән.

Инде дә килеп, оясыннан очканнан соң, язучыга бик кирәкле булган бай тормыш юлы, дөнья йөген үз җилкәңдә күтәрү: Минзәлә, Әлки, Түбән Кама, Башкортстанның Калтасы район гәзитләре редакцияләрендә эшләгәндә туктаусыз халык арасында кайнау, шул елларда читтән торып, Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлау, республика радиокомитеты белән даими элемтәдә торып, бинһая четерекле мәсьәләләрне кузгаткан тапшырулар оештыру, Татарстаныбызның мөстәкыйльлеге өчен көрәшнең алгы сафында бару...

Ә тереклек итү өчен аз-маз акча эшләп алырга аңа рәссамлык сәләте дә булыша...

Фәнзаман Батталның иҗаты илдә-көндә үзгәртеп корулар башланганнан соң гына киң укучылар аудиториясенә ирешү мөмкинлеген алды дисәм, ялгышмамдыр. Аның беренче мөстәкыйль китабы—"Сакалыңа ут капса..." 1990 елда гына дөнья күрде. Шуннан соң бер-бер артлы "Безнең сурәт", "Гөнаһ шомлыгы" (1993), "Бака да бата" (1995) дигән сатирик һәм юмористик хикәяләрен, публицистик уйлануларын берләштергән китаплары нәшер ителде. Һәм алар күз ачып йомганчы таралып та беттеләр.

Фәнзаман Баттал моннан дүрт ел элек милләтебез намына янә күркәм бер эш башкарды: "Көфер почмагы" дип аталган сатира-юмор театры оештырып җибәрде. Анда үзе кебек җор телле, хыялга бай, талантлы яшьләрне табып җыйды, биш-алты минутлык миниатюралардан торган һәм сәгать ярым буе бертуктаусыз көләргә, елмаерга, рәхәтләнеп ял итәргә мөмкинлек биргән тамашалар иҗат итте. Ошбу коллектив республикабыз авылларында, төрле предприятиеләрдә тамашачыларны йөздән артык чыгышы белән сөендерергә өлгерде инде. Нәүмиз булырлык, борын салындырырлык хәлләргә бай бу заманда боеккан күңелләрне дәвалый торган мондый гамәлнең шифасы аеруча кирәкле шәйдер. Күңеле-рухы сауның тәне дә сәламәт булучан бит. Моңа Фәнзаман Батталның үз тормышы дәлил. Бу турыда ул болай ди:

—Язмышым үгисетеп күпме генә какмасын-сукмасын, мин дөньяга суынмадым, киләчәк көннәргә өмет-ышанычымны, кешеләргә карата мәрхәмәт хисемне җуймадым. Тормышның җил-давыллы гарасатларында да батып калмадым. Бу юлда миңа һәрвакыт җанымдагы юмор хисе ныклы таяныч булды. Шушы шифалы хис рухыңны дәвалап торганда даруларың бер читтә торсын. Минем, шул яшемә җитеп, сәламәтлегемнән зарланганым, дару капканым юк...

Афәрин, Фәнзаман замандаш! Киләчәктә дә шундый булып кал, Тукай Шүрәлесе күңелеңне кытыклап торсын, юмор хисе вә халкыбыз мәхәббәте юлдашың булсын.

Шамил МАННАП

# Фәнзаман Баттал

## САТИРИК ХИКӘЯЛӘР

### Унҗиде секундлык реклама

Фабрикада кояш сүнгәндәй булды. Монда эшләүче меңнәрчә хатын-кызлар, башлары киселгән тавыклар шикелле күпме генә әйләнеп-тулганып йөрсәләр дә, һәркайсын гашыйк иткән механик егетне тапмадылар—Ирбулат, суга баткандай, юкка чыкты...

Ажгырып алга баручы фабрика иртәнге сәгатьтә үк аксый башлады...

Бүтән көннәрдә келтерәп торган тегү машиналары туктап калды...

—Барыгызның да техникасы төзекме, чибәркәйләр?—дип, һәр иртәдә цехтан-цехка балкып керүче, үзен күрсәтеп үтүе белән дә чәчбикәләрне бәхетле итүче Ирбулат төшкә кадәр дә, кичкә таба да күренмәде. Авырып киткәндер, дияр идең, һәр мускулы гына түгел, һәр күзәнәге тирә-яктагыларга саулык рухы иңдереп торучы егетне һәр чир әйләнеп узарга тиештер сыман.

Мондагы бүтән ирләр турында ни сөйләсәң дә, нинди фараз кылсаң да, гөнаһлы булмыйсың: эчкәндер, сугышып имгәнгәндер, диген, ялган бүллитин яки бирер хәйлә тапкандыр, айныткычка эләккәндер, диген—барысы да бата. Андый хәлләрнен исәбе-чуты юк. Аларның эшкә килүләре дә көндәлек аракыга акча юнәтү өчен генә шикелле...

Шушы шикләрнен берсен дә ябыштыра алмыйсың Ирбулатка. Ходай аны, гүя: "Дөньяда мондый ук адәми затлар да була икән!" дип соклансыннар өчен, запасында булган бөтен чибәрлекне, сафлыкны бергә җыйгандыр да, шулардан бар иткәндер сыман.

—Ул килеп керсә, бүлмәдәге һава да сафлана иде!..

—Барыбызны да бердәй тин ярата иде кебек...

Өр-яңа хәбәр моңаеп серләшүләргә, юксынып сөйләшүләргә ялкын өстәде: "Кичә, эш ахырында, Ирбулатны "генерал" чакырткан!.."

—Генераль директор ул цехлардагы инженерлар белән ваксынмый. Механик егеттә нинди йомышы булсын аның?..

—Ирбулатны күргәне дә юктыр әле...

Ләкин теге хәбәр расланды. Әйе, "генерал"ның чакыртуы хак! Әйе, "генерал"ның кабинетына кереп киткәнен дә күргәннәр! Чыгуына да шаһитлар бар. Ләкин... кая соң ул Ирбулат???

* * *

Бу минутларда Ирбулат, чем-кара "Мерседес"ның арткы утыргычында тирбәлеп, нарат урманы аша үтүче асфальт юл буйлап җилдертә иде. "Генерал" белән сөйләшү бик тә ихлас кебек тоелса да, күңелендә барыбер ниндидер шик калды. Фабрикада эшли башлавына ярты ел да тулмаган Ирбулатка айлык ял тәкъдим итүе, алай гына да түгел, ул ялны мәҗбүр дәрәҗәдә бирүе бер сәер хәл булса, аны менә шушы табибка үз кулы белән дигәндәй тапшыруы икенче табышмак иде. Хәер, ни өчен тапшыруын да әйтте:

—Ай буе ял зонасындагы махсус коттеджта яшәрсең, алар кушкан режим белән ял итәрсең,—диде.—Бәлки вак-төяк йомышлары да булыр, иренмәсән, үтәргә тырышырсың,—дип өстәүне дә кирәк тапты.

—Аңлап бетермәдем...—дип авыз ачкан иде дә Ирбулат, "генерал", мәрхәмәтле генә көлемсерәп, сүзне түгәрәкләп тә куйды:

—Калганын менә бу абыең аңлатыр.

Юлга чыгар алдыннан үзен Искәндәр дип таныштырган табиб, Ирбулатның уйларын укып баргандай, салмак кына сүз башлады:

—Монда катлаулы бернәрсә дә юк, энем. Синнән генә түгел, дөньядан да яшерә торган серебез юк. Син ул коттеджта бары тик безнең фирма житештергән ризыкларны гына ашарга, безнең заводлар, фабрикалар чыгарган товарлар белән генә файдаланырга тиеш буласың. Әйтик, теш пастасы, шампунь, кием... Ни өчен, дип сорар булсаң, анысын да әйтеп куям: үзең дә белеп торасың, капитализмга кучтек, коммунистлар үзләре үк коммунизм юлыннан баруны хата дип таптылар. Хәзерге тормыш байракларга, вымпелларга, идеяләргә таянмый инде. Акчага, товарга таяна! Ә аларны хәрәкәткә китерүче тылсымның нәрсә икәнен үзең дә беләсеңдер?..

Табибның сораулы карашына игътибар иткәч, Ирбулат үз фикерен әйтүне кирәк тапты:

—Намуслы хезмәттер инде...

—Намус—пүчтәк нәрсә ул, энем! Кибет, базар тулы товар торса, халык шуларны алу өчен кара тиргә батып эшләячәк. Дөньяны хәрәкәткә китерүче кодрәт бөтенләй башка. Ул—реклама! Менә без, ял иткән арада, синең белән шул эшне дә эшләячәкбез—фирмабызның рекламасын әзерләячәкбез.

—Миндә сәләт бар микән соң?..

—Хәзергә үзең булу житкән. Сәләтен табарбыз. Табып бетермәсәк, бүтәннәр табышыр!

Ирбулат авыр сулап куйды, күңелендәге ихлас уен да әйтеп салды:

—Минем бер дә каядыр ял итеп ятарга исәбем юк иде, Искәндәр абый. Бер жирдә ай буе мүкләнеп, ужым бозавы кебек ашап, күбенеп ятуны бер дә өнәп бетермим мин.

—Өнәрсең, энем, әле ничек кенә өнәрсең! Мин сиңа чирек сүзне дә сөйләмәдем бит әле... Белүемчә, сиңа хәзер егерме сигез. Өйләнәсен булырмы? Булыр! Ике кешелек тулай торак бүлмәсенә алып кайтырсыңмы ул чибәркәйне? Фатир кирәк була түгелме соң, ә!

—Берничә ел эшләгәч, фабрика бирер әле, бәлкем... Аны сатып алырлык акчам да юк, булачагы да юктыр.

—Ә без сиңа фатирны бер айдан бирмәкче булабыз, әгәр шефка да ошасаң... Әле, сер итеп кенә әйтәм, барысы да без дигәнчә барып чыкса, жиһазлап та бирәбез фатирыңны!

Ирбулат көлеп жибәрде. Шаян сүзне житди итеп сөйли белүче артистларны күргәләгән булса да, үзен табиб дип санаган кешенең болай матур шаяртуы бик тә кызык булып тоелды.

—Балачактан ук әкият яратып үстем, абый. Синен әкияттән соң рәхәт булып китте.

Анын сүзен ишетмәгәндәй, табиб дәвам итте:

—Өйләнү өчен туй да үткәрергә кирәк бит әле. Анысын да үз кесәсеннән вәгъдә итеп тора хужабыз. Моның ише чакта "Алла боерса! яки "амин!" дип кенә торырга кирәк, энем. Урынсыз көлү өчен башка урыннар да табылыр. Әле мин шефтан монда ял иткән көннәрең өчен дә иллешәр доллар түләвен үтендем. Әйтергә кирәк, сулышында авырыксыну сизелмәде.

—Анын мине күргәне дә юк бит әле...

—Аның күрмәгән, белмәгән кешесе дә, нәрсәсе дә юк, энем.

Ирбулат, әллә сагаеп, әллә матур хыялларга бирелеп, тынып калды. Искәндәр абзыйсы да ачык тәрәзәдән карап баруны артыграк күргәндәй, башын урман тарафына борды. Инде бөтенләй сүзе чыкмас кебек тә тоелган иде. Әмма көтмәгәндә генә бөтен сүзгә йомгак ясап куйды:

—Әйтелгәннәрнең барысы да булачак. Синнән таләп ителгәне—барысын да кирәгенчә эшләргә тырышу.—Кайбер киңәш-күрсәтмәләрне бирүне дә кирәк тапты табиб.—Әгәр шеф кабул итә калса үзенне, кирегә сукалаудан сак бул. Беренче карашка кырыс тоелса да, рәхимле зат ул. Бигрәк тә файдага яраклы кешеләргә... Бүгенге көнен урнашу, тирә-як белән танышу көне булыр. Иртәгәдән эшли башларбыз!

* * *

Ай буе үзе яшәячәк коттеджның этажларын, бүлмәләрен карап йөргәндә, Ирбулатның күңелен горурлык биләде. Мондый мөмкинлек бирелгән икән, без дә бер адәмчә яшәп карыйк әле, дип уйлады егет. Әнә, һәр катында җиде-сигез бүлмә, шуларның алтысы бары тик аның өчен әзерләнгән: йокы, аш бүлмәләре, спорт бүлмәсе, телевизор карап, газит-журналлар укып утыра торган бүлмә... Хәер, теге икесен берничек тә бүлмә дип булмый икән. Аларның берсе—бассейн, икенчесе—подвалдагы тир. Бассейнның тәрәзәсез ягында мунчага кереп китә торган ишек бар. Мунчаның эче үзе бер дөнья: керүгә үк банкет залыдай бүлмә, андагы шкаф-сервантларда кырыкмаса-кырык төрле сервиз, планетаның һәр иленнән диярлек кайткан коньяклар, ромнар, вискилар, тагын әллә нинди эчемлекләр. Тагын бер ишекне ачкач, чишенү-киенү бүлмәсе, тагын да арырак—юыну, чабыну бүлмәләре...

Канат үстергән горурлык тиз арада мескенлеккә әверелде. Ярый, хуш, шушындый шартларда ял да иттең, ди, ә шуннан соң нәрсә? Тулай торагыңа кайтып егылсаң да, хәтта теге абзый вәгъдә иткән фатир хуҗасы булсаң да, үзеңне бик тә фәкыйрь, түбән итеп тоячаксың... Әлбәттә, табибның фатир турындагы сүзе матур әкият булып кына керде Ирбулатның колагына. Ышандырмый ул нәрсә! Ашап-эчеп, ял итеп ят та, имеш, шуның өчен сиңа фатир да бирсеннәр... Шефының сүзен аңлап бетермәгәндер ул.

Хәер, бу йортта ул бер үзе генә түгел. Искәндәр абыйсы астарак—икенче катта, шунда ук ниндидер тележиссер бүлмәсе. Әле ул режиссерның төшерүче операторлары, тагын әллә кемнәре бар икән. Шулар көн саен Ирбулатны кинога төшереп торачаклар икән. Алар бу катка менми—ашханәләре дә, юыну һәм туалет бүлмәләре дә аерым икән. Хәтта ашарга пешерүче кешеләре дә аерым, диләр...

Иртән сәгать сигездә табиб ишек шакыды. Ирбулат алты тулганда ук торып, парикмахер абзыйда булып менгән иде. Абзый шулкадәр тырышты ки, Ирбулатның һәр чәч бөртегенә махсус тәрбия күрсәтте сыман. Яхшылап кыргач, битенә, муенына бик текемле массаж да ясады. Грим да салды, ахры... Үзен көзгедән карамакчы иде дә егет, парикмахер кеткелдәп көлде:

—Монда, энекәш, көзгенең кирәге юк. Менә мин булам синең көзгең! Шунысын да бел, бу йортта көзге күрмәссең.

Бик телчән, юморлы абзый булып чыкты бу. Тарихны да, әдәбиятны да яхшы белә, ахры, көзгегә бәйле бер кыйссаны да җинел ябыштырып куйды баягы сүзенә.

—Бөекләр, үз кадерен белүчеләр берчакта да көзгегә мохтаҗлык сизмәгәннәр, энскәш. Суворов дигән бөек полководецны беләдер буласыңдыр... Хәер, ул баш күтәргән Россия халкын да дистә меңләп кырган адәм инде. Үтерүдән ләззәт ала торган шәхес... Менә шуның походтан кайтып керәсен белүгә үк, өендәге бөтен көзгеләрне калын тукыма белән каплап куя торган булганнар. Ул һәрвакыт: "Минем тагын бер Суворовны күрәсем килми!" дияргә яраткан. Әгәренки дә берәр көзге ябылмый калса, гаепләләргә рәхим-шәфкать булмаган—үкертә-үкертә камчы белән яргаи... Шулай булгач, син дә үзеңне бөек итеп хис ит, һе-һе-һә-һә...

Табиб исә бүген дә житди.

—Син, Ирбулат энем, дөрес аңлагансыңдыр: монда бары тик "Сафлык" фирмасының товарлары белән генә файдалану зарур. Син үзең белән сумка алып килдең кичә. Анда артык әйберләр юктыр бит?..

—Берничә китап, кроссвордлы журнал, эчке киемнәр, сөлге, теш чистарткычлар...

—Китапларың, кроссвордларың ярар, анысы... Башкаларына тимә, орынма! Ул әйберләр монда житеп ашкан. Чит ризык та ашама. Ни теләсәң дә, пешекченнән сора—барысын да табар. "Сафлык" ул шундый зур фирма, житештергән ризыклары гына да йөздән арта. Ә хәзер... Бөтенләй башка соравым бар. Ат менгәнең бармы?

—Атка атланып чапканыммы? Минем, абый, авыл сабантуенда да ике мәртәбә ярышканым бар. Беренчелекне генә алып булмады... Авыл малае идем бит мин.

—Безгә беренчелек кирәкми. Ярыш оештырасы юк. Ат өстендә ныклы тора алсаң, шул житә.

... Бер сәгатьтән Ирбулатны режиссер хөкеменә тапшырдылар. Режиссер беренче минутта ук аның кулына кәгазь кисәге тоттырды.

—Менә бу шигырьне ятлап ал. Истә калдыру авыр булмастыр.

Кәгазьгә карап алу белән, Ирбулат елмаеп жибәрде—шигырь чыннан да беренче укуда ук истә калырлык иде:

Үлә идем, гүя, утта янып...
Кеше булдым сиңа таянып!!!
Рәхмәт, рәхмәт, изге "Сафлык",
Син бар жирдә бетмәс шатлык!

Егеткә гажәп матур джинсы костюм кидерделәр, әле генә китертелгән сылу гәүдәле, кешедәй акыллы карашлы аргамакка мендерделәр. Йөгән белән ияре дә сокланып туймаслык нәкышьләр, укалар белән бизәлгәнлектән, бу ат хыял дөньясыннан килеп чыккандыр да, кинәт кенә юк та булыр сыман тоелды Ирбулатка. Ләкин режиссер хискә бирелеп торырга вакыт калдырмады, егетнең ат өстендә ышанычлы утыруын шәйләп алуга ук, кыска-кыска гына күрсәтмәләр бирде:

—Менә бу урман читендәге юлдан йөз адымлап барасың да, кире борылып, болайга таба чабып киләсең. Игътибар ит: шушы сызыкка житүгә үк йөгәнне ныклап тартып, "тормоз" бирәсең. Максат шул—аргамакның алгы аяклары да, башы да күтәрелеп калсын. Икенче төрлерәк әйтсәм, арт аяклары белән биеп торырлык булсын! Йөгәнне тарту белән бөтен дөнья ишетсен, дигәндәй, теге шигырьне укыйсың. Кулыңдагы кылыч бөтерелеп тә, уйнап та торсын. Онытма: син чиксез бәхетле, елмаюың тирә-якка нур сибә!

Операторларга да сынаулы карашын төшереп алгач, өздереп кенә боерды режиссер:

—Кит-тек!

Теге юлны ун мәртәбә генә урамагандыр Ирбулат. Чабып килгән саен укый торгач, теге шигырь хәтеренә генә түгел, бөтен тәненә гомерлеккә сеңде кебек.

—Вообще-то, молодец!—дип нәтижә ясады режиссер.—Ә хәзер менә шушы өч-дүрт сүзне ятла: "Бу дөньяда күп интектем... Рәхмәт, "Сафлык", кеше иттең!" Инде йокы бүлмәнә кереп тә ярты минут кына төшереп алырбыз...

Анысы ансатрак булды. Ирбулатны майка-трусиклы килеш тахтага яткырдылар. Ул бераз елмаеп ятырга һәм, кинәт кенә калкынып, яңа шигырьне сөйләп куярга, режиссерча әйтсәк, "тамашачыга ыргытырга" тиеш.

—Оптимизмың көчле! Шигырьнең соңгы ике сүзен укыганда мускулың кабарып куйсын!.. Кит-тек!

Камера—гөжләп, төрле төстәге утлар уйнап алды. Монысын да берничә мәртәбә төшерделәр.

Елмая-елмая теш чистартканда да, хәйләкәр генә көлемсерәп, кулындагы шампуньга карап утырганда да, бәхетле кешедәй ашап утырганда да "кадрга ала тордылар" аны.

—Туалетта утырганымны да төшерсәгез, барысы да түгәрәк булыр иде, егетләр,—дип шаяртырга да теләгән иде, әмма табибның "кирегә сукалама" дигән үгете телдән тотып калды.

Көн саен телекамералар алдында уйнап алу үзенә дә ошый башлады Ирбулатның. Ат өстендә бүтән төшермәделәр. Булган кадәресе дә шефның күңеленә хуш килгән икән. Ә тахтада яткан килеш төшерү көн саен кабатланды. Аерма шунда гына, режиссер, төшергән саен, бер үк сүзне әйтеп куя:

—Оптимизм—кичәгедән сыеграк, елмаю—сүрәнрәк!

Ике атна чамасы үткәч, елмаю урынына житдилек, тора-бара сүрәнлек, ә инде тагын да сонрак хәлсезлек таләп итә торган булды режиссер.

Хәлсезлек дигәннән, ризыклар ничек кенә тәмле, кызыктыргыч булмасын, ун көнләп ял иткәч, күңел болганy сизә башлады Ирбулат. Башын сыпырганда да, нишләптер, учма-учма чәче йолкына... Күзенә генә күренәдер инде, бәлкем,—кул һәм күкрәк тиреләре дә уңа, бәлшерәя сыман... Бу хакта табибка әйткән иде, тегесе кул гына селекте:

—Була торган хәл... Су һәм ризык үзгәрүдән андый вакытлы чигенешләр сизелгәли ул...

—Бит тә кытыршырак тосла...

—Кояш ашагандыр... Аннан сон, урысчалап әйтсәк, переходной возрост синен. Беркем дә гомер буе ялтырап кына яшәми. Чын иргә әверелеп баруынны да онытма. Вакыт ул үзенекен эшли...

Айнын сонгы көннәрендә урыныннан да иренеп кенә кузгала башлады егет. Ашарга керү мәҗбүри булмаса, туалет "кыстап" тормаса, торып та маташмас иде. Хәтта кырынасы да килми... Хәер, кырынмавына режиссер да бәйләнми хәзер. Төшерер алдыннан биргән консультацияләре дә бөтенләй бүтән:

—Карашын өметсез булсын...

—Авыр сула...

—Объективка тилмереп кара...

—Күзенне йомып ят та әкрен генә ач...

—Үлгәндәй ят...

* * *

Коттеджда яши башлавына айдан арткач, эчен тотып, бөгәрләнеп ятучы Ирбулат янына, гадәттәгечә, телекамера белән сонгы мәртәбә кереп чыктылар, бернинди боерык та биреп тормыйча, хәтта сүз дә әйтмичә, төшерделәр. Аннан сон табиб керде.

—Хәлем авыр, Искәндәр абый...

—Синен берәр чирен булгандыр, энем, монда килгәндә... Ничауа, профессордан каратырбыз... Әйдә, тор әле, шеф янына барып кайтабыз. Бер сәгатьтән кабул итәргә килеште. Анын вәгъдәләре бар бит. Анын үз сүзендә тормавын хәтерләмим. Телеоператорлар төшергән кадрларны карап барып, ул сине яратып өлгергән... Ләкин мондагы шартлардан зарлана күрмә! Бөтен эшне харап итүен бар...

Теләмәсә дә торды, көчәнеп булса да киенде Ирбулат. Гәүдәсенә дә кабат игътибар итте: аяклар нечкәргән, тиреләре бөрешкән, тез башлары ике туп сыман калыккан, корсагы, су салынган полиэтилен капчык кебек, салынып төшкән, тәне дымлы...

... Шеф озак көттермәде. Кабул итү бүлмәсенә керүләрен монитордан, ягъни бәләкәй телевизор кебек нәмәстәкәйдән күзәтеп торган һәм секретарь кызга боерык биргән: керсеннәр!

Шеф дигәннәре илле тирәләрендәге кара тут йөзле адәм икән. Кара күзләре йөгереп тора. Хәрәкәт иткән саен шактый ачылган пеләшендә тәрәзәдән төшкән кояш уйный.

Ул башта Ирбулатка текәлде, аннан сон карашын табибка күчерде. Металл арасыннан чыккан шылтырау сыманрак тавыш белән жикереп куйды:

—Мин сезнен эшегездән канәгать түгел, Искәндәр Исмәгыйлевич!.. Шундый матур егетне чирләткәнсез бит! Димәк, врач күзәтүе житмәгән. Хәзер инде ахырга кадәр үзегез кайгыртыгыз. Уфадагы академик дустыма илтегез. Мондагы... Казандагы медикларга ышанмыйм мин... Егет, штубы, бер айдан элекке хәленә кайтсын.

Ул ниндидер төймәгә басты. Теге тарафтан кемнендер сулышы ишетелүгә үк, өзлереп боерык бирде:

—Бухгалтер керсен!

Хисапчы дигәне, гүя ишек төбендә генә торган—шундук килеп тә керде һәм "бөтен күзәнәгем белән сезне тынларга әзермен" кыяфәтен саклаган хәлдә үрә катты.

—Бу егеткә...—Ул Ирбулатка ымлады,—... хәзер үк өч мен доллар бирерсез.

—Нинди чуттан, кайсы фондтан, нинди документ нигезендә?

—Чут-чуртларын соныннан карарбыз, акчасын хәзер үк бир! Шунысын да исендә тот, ул тәмам терелгәнче ай саен ике йөз илле доллар матди ярдәм биреп барачакбыз.

Хисапчы баш иеп чыгып китүгә үк, карашын кабат Ирбулатка юнәлтте.

—Син, энем, гафу ит мине, игътибарым җитмәгән. Эш күплек бугаздан буа. Тагын бер сүземне тыңла, зинһар: вәгъдә иткән фатирны Казанда бирә алмыйбыз. Уфа белән сөйләштек—фатир әзер. Давай, кеше рәтенә кергәнче булса да, шунда китеп яшә, телисең икән, Казанга үзең алыштырырсың. Үтенечем дә бар. Коттеджда яшәгәненне беркайда да телгә алма. Сиңа да, миңа да зыян гына китерәчәк артык сүз. Хәзергә Агыйделгә карап торган ике бүлмәле фатирында ашап-эчеп ят, ял ит. Акчаң җитәчәк! Ә син, доктор, егет өчен башың белән җавап бирәчәксең. Иртәгә үк Уфага озат, фатирына урнаштыр, академикка күрсәт! Күңелемдә шик тә бар минем: безнекеләрдән тыш та ризыклар ашамады микән бу чибәр егет?

Ярты башы пеләшләнгән, хәтта кутырлаган, йөзе сиксән яшьлек картларныкыннан әлләни аермасы калмаган Ирбулат көчәнеп кенә җавап бирде:

—Юк...

Аннары, гаме бик тирән кешедәй, башын игән хәлдә, озак кына сүзсез утырды шеф. Инде бер сүзе дә калмагандыр кебек тоела башлагач кына, табибка ишарә ясады:

—Бер минутка калып тор, өстәп әйтәсе сүзем бар...

Ирбулатның сөйрәлеп диярлек чыгып китүе булды, шеф ягымлы елмайды:

—Молодец! Җиренә җиткереп эшләгәнсең. Реклама мировой булачак! Теге "Мерседес"ым синеке хәзер. Әйткәнемчә, егерме биш мең долларны шушы атнада алырсың. Ә бу егет озак яши алмас кебек күренә...

—Кем белгән инде...—Ярый, анысы язмыш кулында. Иллә дә мәгәр талантлы егет икән. Андый ук рекламаны өмет итмәгән идем. Иртәгә үк Казаннан югалт бу егетне. Уфадан кайткач, "генерал"ына керерсең, хәлне аңлатырсың. Әле бит аңа да шактый әҗер каралган. Сөенер бер, ичмасам! Тик... тик... тик... башка сыеп бетми, чит илдән килгән компонентлардамы бу агу, әллә үзебезнекеләрдәме?.. Ярый, болары белән соңрак кызыксынырбыз. Хәзергә файда юк. Чөнки бөтен базарларыбыз яңа продукция белән тулган. Рекламаны ике-өч көн әйләндерү белән товар ташкынын дөньяга чыгарырга кирәк. Миллиард долларлык товар бит ул! Ә товар ул, сөйгәнен көткән егет кебек, базар көтә, иптәш әфәндем!.. Ярар, бар, юлга жыен!

* * *

Кабат өч-дүрт көннән экраннарга яңа реклама чәчрәп чыкты. Халык чын могҗиза күргәндәй булды: урында үлле-мәлле ятучы карт, күзгә күренеп соклангыч яшь, матур егеткә әверелде дә, урыныннан калыкты һәм, кояштай балкып, түгәрәк мускулларын уйнатып, шигырь әйтеп алды:

Бу дөньяда күп интектем...
Рәхмәт, "Сафлык", кеше иттен!

Әнә, терекөмештәй бу егет, аргамакта чабып килде дә, яллары тузгып торган ат башы өстендә кылыч уйнатып алды һәм, чиксез бәхеткә ия булгандай, гүзәл табигатьне шаулатып, яңа шигырь сөйләп бирде:

Үлә идем, гүя, утта янып...
Кеше булдым сина таянып!!!
Рәхмәт, рәхмәт, изге "Сафлык",
Син булганда бетмәс шатлык!

Шушы гаҗәеп тамаша ялт-йолт килеп торучы сихри нурлар яктысында балкып-балкып торган арада, арттан өзек-өзек көр тавыш бәреп торды:

—Күрегез: кем иде?.. Кем булды!!!

—"Сафлык" фирмасы шундый могҗизага иреште!!!

—Сәламәт, чибәр буласыгыз килсә, "Сафлык" фирмасы товарларын эзләгез!!!

Унҗиде секундлык бу рекламада "Сафлык" маркасы сугылган дистәләрчә товарны да күрсәтеп өлгерделәр.

Аны әзерләгәндә кадрларның киредән ялгануын, соңгылары—иң алга,

беренчеләре ахырга монтажлануын, Ирбулатның бу минутларда булнистә ашказаны җәрәхәтен дәвалатып ятуын гади тамашачы башына да китермәде әлбәттә, базарларга, кибетләргә чыгып йөгерде...

## Изге шайтаннар

Мин сезгә океан артындагы илләрнең берсендә моннан ун еллап элек ишеткән вакыйганы сөйләп үтмәк булам. Шунысын да алдан ук әйтеп куям: вакыйга шулкадәр хәтәр ки, мондый хәлнең бездә булуы мөмкин түгел. Булган сурәттә дә язмас идем. Чөнки, сүз ирекгә тыелган шартларда, аны матбугатта чыгарырга җөрьәт итүче мөхәррир табылмас иде. Хәер, сүз озайтып торуның кирәге юктыр...

... Текә ярлы елга буенда сакал-мыегы чаларган бер кеше кармак салып утыра. Йөзендәге бихисап җыерчыкларына, каш төкләренең картларга хас булып озаюына һәм аларның, күзләрне капларга теләгәндәй, бөгелеп торуына игътибар итсәң, ул инде пенсия яшендә булырга тиеш. Ләкин джинсы костюмы, шул костюм киелгән җинел гәүдәсе аны яшәртеп җибәрә. Кармагын ераграк салу өчен әледән-әле аякларына басканда да җиргә таянмый—егетләр кебек җинел кузгала. Хәтта, сикереп тора, дисәң дә, арттыру булмас кебек. Башында бу якларда рәхимсез кыздыручы кояштан саклый алырдай ковбой эшләпәсе. Тик бу очракта эшләпәнең кирәге дә юктыр сыман. Аркасына терәлердәй булып тезелгән куе ябалдашлы агачлар аркылы ана ялгыз нур да төшми.

Ул инде бер эше дә калмаган, ашыгыр җире бөтенләй беткән затны хәтерләтә. Иң беренче булып игътибар иттергәне, мөгаен, карашыдыр. Җылы нур сибеп торучы бу монсу күзләр сине сихерли дә, иркәли дә шикелле. Әйтерсең лә каршында газиз онигы утыра һәм ул әледән-әле шуна карап ала... Һәркемне сокландырырдай карашының тагын бер хикмәте бар: сиңа таба бер генә сирпелеп алса да, гамьнәрен, борчылуларың гына түгел, кара кайгыларың да юкка чыга.

Менә ул яртылаш янган сигарасын ашыкмый гына үләнгә куйды, калкавычы күренмәс булып суга чумган кармак таягына тотынды, салмак кына тартты... Кармак таягы калтыранып бөгелде һәм, су астының кырык тарафына тартылып айкалган җеп унаена чайкалгалап торганнан сон, әкрен генә күтәрелә башлады. Кармак хуҗасы балыкны чыгарганда яр буена төшеп өлгергән өч машинага да күз төшерергә өлгерде. Алар, тавышсыз-тынсыз диярлек, балыкчының шактый искергән "Ниссан"ы янына тезелештеләр. Икесе—чем кара "Мерседес", өченчесе вак балыклар арасына адашып кергән чуртанны хәтерләтүче "Линкольн". Өч машинадан төп-төгәл тугыз кеше төште. Төп-төгәл диюнең хикмәте шунда, машиналарның һәркаюсында олы яшьтәге ир, яшь-яшь гүзәл кыз, пәһлеван гәүдәле шофер килгән.

Шоферлар һәм кызлар машиналар тирәсендә калдылар, ә өлкән яшьтәгеләрнең өчесе балыкчыга якынлаштылар.

—Йә, сэр, балык бармы елгада?

Балыкчы алар тарафына борылды да, иң кадерле танышларын күреп сөенгәндәй, мөлаем елмаеп, кулларын як-якка җәйде:

—О-о! Илебезнең иң могтәбәр кешеләре килгән!.. Балык бар, әфәнделәр. Караңгы төшкәнче тотарга өлгермәсәгез, ятыр корсакка мин тотканнары да житәр.

Өлкәннәрнең уртадагысы—килеш-килбәте белән орлык кыярына охшаганы—як-ягындагы юлдашларына мәгънәле генә карап алгач, балыкчының үзе кебек мөлаем елмаерга тырышып:

—"Могтәбәр" дидегез әле, сэр. Безне белгән шикеллерәк әйттегез.

—Сезне белмәгән кеше бар микән соң безнең илдә! Газеталарда атна саен диярлек сурәтләрегез чыгып тора. Телевизордан тапшырылып торучы нотыкларыгыз, әнгәмәләрегез күпме тагын! Картаябыз, әмма хәтерне югалтып бетермибез әле. Өчегез дә министр. Кирәк тапсагыз, исемнәрегезне генә түгел, нинди тармак башында утыруыгызны да әйтеп бирәм!

Тегеләр көлешеп алгандай иттеләр. Ябык йөзле юан корсаклысының көлүе сыкрауга охшаса, нечкә гәүдәле, ләкин көнбагыш табагыдай түгәрәк битлесе эт өргәндәй хахылдады.

—Һы. Мәгълүмәтле кеше син,—диде Орлык кыяры.—Синең белән янәшә балык тоту да шикләндерер...

Шуны гына көткәндәй, өч әзмәвер тавыш-тынсыз гына хуҗалары янына килеп җиттеләр.

—Бәлки аны икенче урынга күчерергәдер... Ял итәргә комачауласа, дип әйтүебез... Үзе дә каршы килмәс, бәлкем.—Орлык кыярының шоферы балыкчыга да сүз катып өлгерде.—Шулай бит, сэр?

Балыкчы, тыйнак кына елмаеп, иннәрен сикертте:

—Шулайдыр, бәлкем. Олуг шәхесләрнең теләген бик теләп үтәргә ризамын. Ихлас күңелдән риза! Мин әнә теге борылышка китәрмен. Сезгә берниндидә комачау тудырмам, джентльменнар.

—Рәхмәт,—диештеләр министрлар.—Безнең хөкүмәт эшләре турында сөйләшәсебез бар. Үзебез генә белергә тиешле дәүләт серләре дә бардыр. Сезнең киң күңелле булуыгыз сокландыра безне, сэр.

—Зинһар, үпкәли күрмәгез,—диде шоферларның берсе нәзакәтлелек белән.— Министр әфәнделәр шушында ял итәргә күнектеләр.

—Балыкларны калдырыргадыр, бәлки,—дип, рәхимле елмайды балыкчы, кармакларын урагандa.—Кичкә таба бик сүлпән чиртә башладылар.

—Еракка күчмисез бит.—Көнбагыш битле министр хәйләкәр көлде.—Нужа кушса, мөрәҗәгать итәрбез.

Балыкчы, машинасын да кабызып тормыйча, җәяүләп кенә китеп барды.

Беразга сузылган тынлыктан соң, Орлык кыяры кызларга да, егетләргә дә әмер бирде:

—Тегендә, аланда ял итә торыгыз. Трейлер янында. Барлык хәстәрне күрә торыгыз. Кирәгегез чыкса, үзебез дәшәрбез. Машиналарны да шунда алыгыз.

Янәшә утырышып кармакларын салгач, ябык йөзле министр карлыкканрак тавыш белән әйтә куйды:

—Сәер кеше булды әле бу. Кимсенү галәмәте дә чыкмады йөзенә. Беркатлы бала сыман китте дә барды. Мондый тынлаучанны балалар арасыннан да табу кыен хәзер.

—Табигате шундый инде, күрәмсең.

—Маклер яки укытучыдыр. Шулай тоела.

—Ә сез бер нәрсәгә игътибар иттегезме?—дип, капыл гына сорау бирде Орлык кыяры.—Аның йөзе кемнекенә охшаган? Уйлап карагыз әле.

Бер минут чамасы тын да алмадылар кебек. Соравына җавап ишетмәгәч, Орлык кыяры үзе телгә килде:

—Ниндидер изге затка, фәрештәгә охшаттым мин аны. Ул китәргә килешкәч, үзебез белән калырга да димләмәкче идем үзен. Тик, сезнең фикерне белмәгәч, кыймадым.

—Фикер дип соң инде... Монда әллә ниләр сөйләшергә килмәдек бит. Утырыр иде әле гөрләшеп...—Көнбагыш чырай, кинәт кенә башын артка ташлап, кытыклангандай көлергә кереште.—Җанашлар куенына кергәч тә сөйләшерлек сер юк инде су буенда. Җитди сөйләшүләрдән эштә дә туйган... Ярый, еракта түгел ул, чакырырбыз. Йөгерә-йөгерә килер.

... Тотканнары сыңар балыктан артмады. Күз бәйләнә башлаганда Орлык кыяры уртак кинәшкә нәтиҗә ясагандагы тавыш белән катгый тәкъдимен бәян итте:

—Чакыртыйк, булмаса. Ни сәбәптер, бүгенге көннең бөтен мәгънәсе шул кешедән генә торадыр кебек.

* * *

Балыкчы, ничек киткән булса, шулай тиз генә килеп тә җитте. Аны дәшкән шофер иптәшләре янына китеп баргач, Орлык кыяры салмак кына янган учак ялкыны аша:

—Сезне чакырырга исәп иттек әле, сэр. Сүз тыңлап килүегезгә рәхмәт,—диде.

Балыкчының сүзе министрларның берсе дә көтмәгәнчә булды.

—Чакырмасагыз, мин үзем дә килми калмаячак идем.

Анын тавышы, сөйләшү кимәле көндезгедән бөтенләй үзгә иде.

—Гажәп!—диештеләр учак хуҗалары.

—Бер дә гажәп түгел!—дип кистерде балыкчы.—Бүген булмаса да без барыбер каядыр, кайчандыр сөйләшергә тиеш идек. Чөнки без төп гамәлләребез, яшәү рәвешләребез буенча коллегалар. Бүгенге төнне Ходай үзе насыйп итте безгә. Яхшылап аңлашырбыз, ичмасам.

Балыкчының йөзендә дә, күзендә дә баягы балкыш бөтенләй юк инде хәзер. Һәр сүзе коры, һәр җөмләсе төгәл! Шиккә кала башлаган Орлык кыяры, аның яна сыйфатларын сизмәмешкә салышып, җилне икенче тарафтан истермәкче булды.

—Әле бая сезнең хакта сөйләшеп утырдык, сэр. Сезнең йөзегездән сихри игелек бөркелә, фәрештәгә тартымлык бар сездә.

—Менә шул күренешем дистәләрчә бәндәләрнең җанын кыйды да инде! Бал дип беләләр, агуга тап булалар. Кемгә капканнарын теге дөньяга китәр алдыннан гына аңлыйлар шул бичаралар. Юк, сез дөрес аңлагыз, минем төп максатым һич тә үтерү түгел. Иллә дә мәгәр кайчак үтерергә дә туры килә.

Министрларның берсе көчәнеп кенә көлеп җибәрде:

—Сез әле бик оста артист та икәнсез.

—Әйе, сез хаклы. Андый осталыктан башка минем һөнәрне башкару, у-ңыш-лы башкару бик кыен булыр иде. Сез ул сәләтемне көндез күрдегез инде.

—Сез бая үзегезне безнең коллега итеп таныткачы идегез. Берәр вакыт министр вазифасын тарттыгызмы әллә?

—Юк, бер кабинетта да утырганым булмады, коллегалар.

—Менә тагын шул ук сүз...

—Мин әле бу төндә ул сүзне тагын берничә мәртәбә кабатлаячакмын. Кем икәнемне дә белгәч, үзегез дә килешерсез минем белән. Без—коллегалар!

Шикләнә калган Көнбагыш чырай, тавышына нәзакәтлек өстәргә тырышып, кул сузды:

—Сер ясап утырмыйк, алайса, сер. Үзегез дә телисез сыман—танышыйк, булмаса.

—Кул бирешеп тормыйк!—диде "Коллега".—Минем белән сез болай да таныш. Исемемне дә әледән-әле ишетеп яшисез. Мактанып әйтүем түгел, минем даным сезнекеннән дә югарырак бу дөньяда. Исемне берәүләр шомланып кабатлый. Президент исеме дә минекедәй үк популяр түгелдер.

Әле һаман да бу әңгәмәне шаяруга санап, дөресрәге, аның шаяру икәненә үз-үзен ышандырырга маташып утыручы Орлык кыяры мескенлек авазлары да иңгән тавышы белән кеткелдәде.

—Ул популяр исемне ишетергә иде!

—Мин аны сер итеп сакларга да уйлыйм. Рәхим итегез, исемем...

Исемен ишетүгә барысы да кыбырдашып куйды. Сүз кыстырырга берсе дә әзер түгел иде әле. Инде "Коллега"ның шаярмавы да аңлаганга аңларлык булды кебек. Әйткәне хак булса, исеме һәм кылган куркыныч гамәлләре легендаларда йөри торган атаклы талаучы бу! Дистәләрчә миллионерларны бер бакырсыз калдырган, бронялы сейфлардан килограммлап—асылташлар, ил саклагычларыннан кирпече-кирпече белән алтын эретмәләре талаган куркыныч зат! Мондый кыйсса да таныш иде учак янында утыручыларга: шушы рецидивист бервакыт башкалага ашыгыч илтелергә тиешле акча төягән хәрби самолетны кулга төшерә. Очкан чакта, максаты гамәлгә ашмасына инангач, самолетка шартлаткыч куеп парашют белән сикерә. Сәер яклары да телдән-телгә, колактан-колакка йөри. Имеш, бөтен талаганын ярлыларга, эшсез калганнарга, ялгыз аналарга өләшә икән...

Каршыда утыручы бу адәмнең шул Бөек Талаучы булуы хак икән, ни өчен ул бөтен серен тиктомалга түгә? Һәр җинаятьченең изге шарты—конспирация ләбаса!

—Алдан ук әйтеп куям, үзегез тәртипле булсагыз, чәч бөртегегезгә дә зыян китермәм. Сездән сорарга теләгән бер генә нәрсәм бар. Ул—ярты сәгать буена бары тик минем сүзләремне игътибар белән тыңлау. Реплика ясарга рөхсәт. Теләгемә каршы килергә җөрьәт итсәгез, талап итәчәкмен!

Чәч бөртегенең дә сакланачагын белгәннәрнең берсе—күбрәк сүзсез утырган Чәндер чырай сорау бирүне кирәк тапты:

—Ә сез каршыгызда утырган бу әфәнделәрнең берсе нәкъ менә эчке эшләр министры икәнен беләсез бит, сэр. Болай чишелеп китүегез, үз чәчегезнең коелуына китермәсме?

—Юк!

—Без дә чишелеп алыйк, булмаса. Безне монда ике дистәдән артык полисмен саклый.

—Әйе, алар егерме өч кеше. Вакытлыча барысы да богауланган. Зур түземлек белән безнең сөйләшүнең бетүен көтәләр. Шоферларыгыз "Линкольн" салонында кәрт сугалар. Сөяркәләрегез, повар белән берлектә, сез килүгә табын әзерлиләр... Аңлыйсыздыр, мин сезнең вакытында ашавыгызны да кайгыртам. Үз иминлегем турында да онытмыйм, дип әйтеп торуның кирәге дә юктыр. Кайсыгыздадыр корал булуы ихтимал. Анысы да борчымый мине. Чөнки сезнең һәр хәрәкәтегез сизгер күзәтеләдә. Минем егетләрнең берничәсе, бәлки, менә шушы кул җитемендәге куаклар эчендәдер. Теләгегез булса, үрелеп карагыз, генерал. Аларның кыштырдау авазы да чыгармыйча хәрәкәтләнү сәләтенә үзем дә сокланам кайчак...

Түгәрәк чырайлы ябык министр—полиция генералы, каядыр үрелү түгел, җиргә таянган кулларын да тиз генә тезләренә куеп, шым булды. Бары тик Орлык кыяры гына, тулаем буйсынганлыкларын расларга теләгәндәй, сүз кыстырды:

—Сез, хөрмәтле сэр, нәрсәдер сөйләмәкче идегез. Коллегаларым да тыңларга әзер кебек...

—Ярый, коллегалар, кереш сүз тәмам. Сез мине кимендә йә президентыгыз, йә премьер-министрыгыз дип уйлагыз да, күндәм генә тыңлагыз... Коллегалар дип мөрәҗәгать итүемнең хикмәтен сез инде аңладыгыз булса кирәк. Чөнки без монда дүртебез дә—талаучылар. Тик рангларыбыз белән генә аерылып торабыз. Әйткәнемчә, мин кырык елдан артык таладым. Ихтыяри-мәҗбүри шактый кешеләрне үтерергә туры килде. Тилмереп караган күзләре дә, соңгы сүзләре дә, нишләптер, онытылмый, хәтердән чыкмый. Кызганам мин аларны! Ләкин үзләрен исән калдыру мөмкинлегеннән мәхрүм иттеләр мине: карыштылар, чыр-чу күтәрделәр, мылтык төбәп маташтылар... Шулай итеп, мин үз корбаннарымның трагедияләрен үз күзләрем белән күрдем. Үкенә, шулар өчен сызлана торгач, үз йөрәгемнең дә тузуын шәйли башладым. Кырык җиде кеше үтте минем кулдан! Аңлыйсызмы?! Авыр миңа, коллегалар, бик авыр!..

Ул сыкрап куйды һәм үксүен тыярга тырышып, бермәлгә тынып калды. Эченә алган сулышы, кинәт кенә ярылган камераның һавасы бәреп чыккандай, тышка агылды. Бу сулыш тыңлаучыларга учак ялкыныннан да кайнаррак тоелды. Сызлангандай, тагын сүзсез калды "Коллега". Шул форсаттан файдаланып, Орлык кыяры сүз кыстырырга өлгерде:

—Авырдыр шул. Намусыгызда биш дистәгә якын кеше гомере икән бит...

Ишетте дә сыман бу репликаны "Коллега", юк та кебек. Тирән итеп кабат сулыш алгач, дәвам итте:

—Ә сезгә, коллегалар, җиңел! Югыйсә, сез бит миңа караганда йөзләрчә тапкыр күбрәк талыйсыз, кешеләрне көн саен меңләп үтерәсез. Шулай да сезгә җиңел! Чөнки сез үзегезнең аркада җан бирүчеләрне күрмисез. Сезнең корбаннарыгыз белән зиратлар тула, яңалары ачыла. Сез исә һаман типтерәсез, берни булмагандай, парламентларда утырган буласыз...

—Без таламыйбыз да, үтермибез дә. Без ил белән идарә итәбез,—дияргә кыюлык тапты кайсыдыр министр, кыяр-кыймас кына.

—Ярый, әфәнделәр, бу ялганыгызны бүтәннәргә сөйләрсез. Мин һәркайсыгызның гамәлләрен белеп яшим. Менә син, мәсәлән, финанс министры. Әйт миңа, экватордагы—Канар утрауларындагы резиденцияң күпмегә төште? Ул бит үзе бер шәһәрчек! Телисең икән, дәшмә, үзем әйтәм: алты йөз дә егерме миллион доллар ул! Әле бит бу президентыгызныкына караганда пүчтәк! Белеп торам, вәкаләт срогы чыгу белән ул шунда качачак. Швейцария банкындагы акчасы да егерме буын нәсел-нәсәбенә җитәрлек аның. Димәк, нәселе 500 ел бәйрәм итәчәк. Ә халык нишли? Беләсеңме син халыкның нишләгәнен? Ай буена алган хезмәт хаклары ун көн ашарга да җитми аларның. Ризык җитмәүдән сабыйлар

кырыла, гүзәл кызлар фәхишәгә әйләнә. Алар, гафу итегез, сезнең кебек милли айгырлардан балага узып, корсак төшереп, ана булу бәхетеннән мәхрүм калалар. Әле менә монда да алып килгәнсез берничәсен. Әллә сезне яратудан шат күнелле дип беләсезме аларны? Кулыгызда власть булмаса, сезгә алар төкереп тә бирмәсләр иде. Сезгә ләззәтле минутлар китергәндә үпкән, назлаган кебек кыланалардыр әле! Ә чынлыкта җирәнәләр алар сездән. Ул мескеннәрне сез биргән фатирлар, кыйммәтле киемнәр, затлы бүләкләр тыеп тора йөзегезгә төкерүдән. Бу кызыйлар кырык ел производствода бил бөккән эшчеләрдән дә баерак яши хәзер... Мин кешеләрне пистолет яки пычак белән генә үтердем. Алар, күп дигәндә, бер минут газапландылар. Ә сез еллар буе газаплап үтерәсез. Миллиардларны, триллионнарны сез банкларда "әйләндерәсез", үзегез өчен яңа миллиардлар сыгасыз—эшчеләр, игенчеләр исә еллар буе хезмәт хакыннан мәхрүм. Менә сез, генерал әфәнде, үз чыгышларыгызда минем кебекләрне бандит дип бәялисез. Анысы—дөрес. Ләкин сез барлык бандитларга караганда да бандитрак бит! Халык файдасын түгел, мафияләр ихтыяҗын кайгыртуыгыз кемгә сер? Әгәр мин шушы төндә өчегезне дә асып үтерсәм, мона кадәр җыйган гөнаһларымны Ходай бер минутта кичерәчәк. Ләкин бу гамәлдән халыкка күпме генә җинеллек килер икән? Сездән бушаган кәнәфиләргә яңа бандитлар, яңа талаучылар килмәс дип иман китерә аламмы мин?! Менә шунын өчен дә исән каласыз, әфәнделәр.

Мона кадәр тораташтай утырган министрлар, сүз куешкандай, иркенрәк сулап куйдылар. Берсе, хәтта, оеган аякларын сузып, кат-кат тамак кырды, "Коллега" исә, сөйләүләрем барыбер бушка бит, дигәндәй, сүрәнләнеп китте. Шактый тын утыргач, иренгән кыяфәт белән өстәде:

—Минем бөтен максатым шушы сүзләрне әйтү иде, коллегалар. Әлбәттә, бер файдасы да булмас бу нотыкның. Әмма күңелемне, эчемне бушатасым килде. Шулай да, әз генә булса да, уйлап карагыз әле сез: акыл ияләре, язучылары, сәнгать әһелләре ач-ялангач калган, киләчәк буынны тәрбияләүче педагоглары бер ашарлык ризыкка тилмергән милләт кая бара? Үз нәфесегезне ун, егерме процентка гына тыйсагыз да, аларның тормышлары бераз рәтләнер иде бит. Үзегез ашаганда этләргә дә калдык-постыкларыгызны ташларга онытмагыз, балалар, дия торган иде әткәй мәрхүм... Сезнең аркада эт көненә калган халыкка да җан сакларлык ризык каптырыгыз, коллегалар...

Тагын бер мәртәбә авыр сулады да урыныннан торды "Коллега". Чалбарын каккалап алгандай иткәч, сүзен түгәрәкләде:

—Ярый, сау булып торыгыз, даһи талаучылар. Сакчыларыгызның кулын чишкәнче сабыр итегез дә, ялыгызны дәвам итегез. Тәмле ризыкларыгыз, ләззәт китерәчәк кызларыгыз сезгә шатлык, юаныч өстәсен.

Ул, чираттагы сигарасын күмергә терәп кабызды һәм әкрен генә караңгылык кочагына чумды...

## Буйдак тәвәккәллеге

Насыйп ризык тешне каерып керер, ди торган иде Идриснең әбисе. Туктале, тукта!.. Шуңа тарта түгелме соң бөтен подъезд ирләрен кыбырдаткан бу яңалык? Фатирларның берсенә күчеп килгән шул кызны Ходай үзе җибәрмәде микән Идриснең бәхетенә дип? Булмас, димә, булгандыр. "Идрис атлы бу колым тәки кырыкка җитеп тә өйләнми йөри бит,—дигәндер Ходай Тәгалә.—Искиткеч бер гүзәлне юлына чыгарып куйыйм әле, ичмасам".

Бу гүзәлнең исеме дә нәкъ менә Гүзәл икән. Күрше әби-сәбиләрнең әйтүенә караганда, яше белән дә Идрискә дип сакланган кебек: утыздан үтеп киткән. Тәзәмичә генә атып тидерү сыман булды бит әле бу, әй!

Башка ирләрнең кызыгуы файдасыз. Ник дисәң, һәркайсының үз кубызына гына биетеп яши торган хатыны бар, ә Идриснең дүрт ягы кыйбла—күз аткады белән күрешергә, серләшергә хакы бар.

Шөпшәдәй нечкә билле, зур кара күзле, кыйгач кашлы чибәрне күздән ычкындырмаска күнекте Идрис шушы ике атнада. Тычкан тишеген саклаган мәчедәй, иртән дә, кичен дә подъезд төбендә уралырга тырышты. Тегене карашы белән эшкә озатып куйгач кына үз хезмәтенә йөгерә, соңрак кайтамы, иртәрәкме—

гомуми ишек төбендәге эскәмиягә кунаклап, пенсиядәге эшсез абзыйлар белән уртак тел тапкандай, тегенең кайтыр юлын күзәтә.

Тик менә Ходай насыйп ризыкны авызга ук тыкмаган: кайчандыр Идрисне ошбу йортның беренче катына урнаштырган булса, Гүзәлне үзенә якынрак катка—тугызынчыга менгереп куйган. Әзрәк мәшәкатьләнсен, әзергә-бәзер генә куанмасын, диюедер. Әле лифт дигәне дә эшләми бу көннәрдә...

"Ничауа, мондый кыз артыннан күк гөмбәзенә менү дә артык булмас", дип нәтиҗә ясады Идрис. Иллә дә мәгәр сәбәп кирәк. "Менә син миңа ошадың, шуңа күрә мендем әле иң югары катка",—дип әйтмәссең бит инде. Нининдирәк йомыш табарга икән? Кайбер сәрхушләр кебек бурычка акча сорап керә алмый егет—беренчедән, акчасыз яшәми, икенчедән, хәмерне дә айга бер, кайда бер генә капкалый. Карчыклар кебек суган, борыч сорап та ишек шаку килешмәс...

—Эх, сүзләр сүзгә ялганса, җәннәт булыр иде бу дөнья! Бәлки үзе дә Идриснең менгәнен көтеп торадыр әле. Янынnан узып киткәндә ул да бик назлы карап ала бит. Бергә яшәү, кавышу тәкъдир тактасына язылган булса, уртак түшәктә йоклауга да күп калмагандыр. Менәчәк Идрис, менәчәк өске катка! Җилле генә йомышын да тапмый калмас. Тик шунысы, әгәр менеп-менеп тә һавалык күрсәтсә, киштәсен бик югары күтәрергә маташса, борынын чөйсә?.. Чөймәскә тиеш. Ул ханбикә түгел, Идрис хаерче түгел! Менү хәйләсен тапсын әле башта. Эһе, өченче көн үтүге янды Идриснең! Булды бу! Бер-ике сәгатькә үтүгенне биреп тор әле, чибәркәй, диясе дә вәссәлам. Аннан соң инде сүзне сүзгә ялгау бер дә кыен булмас. Ни дисәң дә, кызлар күңеленә хуш килердәй кәнфитле сүзләрне күп туплады егет буйдаклык елларында.

Кадергә тота торган кәчтүмен киде, чама белән генә француз хушбуен сиптерде һәм... тәвәккәлләде.

Икенче кат баскычының беренче басмасына аяк басуга, тәнендә, күңелендә илаһи җинеллек сизде. Ирек белән Диләнекеннән дә ким булмаган туй ясарлар. Һай, күңелле дә үтте шул туйлары. Өч көн буе барды. Бөтен кунаклар, кода-кодагыйлар сокланып туймады бу парга. Иллә шунысы... авылга кайтып килəм дип ике көнгә киткән Диләсенең элек йөргән егетендә "кунак булуы" сизелде. Ярты ел торуга ук аерылыштылар...

Өченче катка омтылганда елмаеп куйды Идрис: бетмәс монда ямьсез уйлар. Күңеллерәк фикер йөртергә кирәк. Гүзәл белән өйләнешсәләр, бер подъездагы ике фатир уртак булачак. Бүген Гүзәл аска төшсә, иртәгә Идрис өскә менер. Күңелле бит, ә: бер көн—аста, бер көн—өстә, тагын аста, тагын өстә!.. Берсендә ашарлар, икенчесендә йокларлар. Кушарга уйласалар фатирларын, өч бүлмәлесен йөгерә-йөгерә китереп бирәчәкләр. Әнә бит, Айдар белән Җәүһәр нәкъ шулай иттеләр. Ләкин... ләкин шунысы... балалары тугач, тагын берме, икеме ел үткәч, Җәүһәре "тещаны" да үз яннарына китертеп, пропискага кертеп, нинндидер хәйләмәкерләр табып, Айдарны урамга кудылар. Тапталып беткән иске башмагы, юылмаган күлмәге белән чыгып китте мескен...

Өченче катка менә-менә өр-яңа хискә чумып алды егет. Өйләнсә, зуррак акчалы эшкә керер. Бик кызык бит ул тормыш: өйләнешкәнче кызның да, егетнең дә акчасы үзенә бик җитә. Өйләнешкәч, ни хикмәттер, ике җитү бер җитмәскә өйләнә дә куя. Якын дусты Әмирҗан да шулай итте өйләнгәч: мондагыдан өч-дүрт мәртәбә күбрәк түли торган җиргә—Төмәнгә китте. Унбиш көн эшләп кайта да, унбиш көн Василәсе янында ял итә. Тагын китә. Әллә ниләр алып бетерделәр өч-дүрт елда. Машина яки бик хәтәр видик дисеңме, күн пәлтәләр, затлы туннар, гектарлы-гектарлы келәмнәр дисеңме!.. Кассадагы акчалары да патша сарае салырлык булган иде, ахры. Иллә дә мәгәр... Әмирҗан бахыр... җил тотып калды. Василәсе, хаерсез, бер әфисәр белән әллә Украинага, әллә Белоруссиягә чыгып качты. Бөтен байлыкны акчага әйләндереп бит әле, җитмәсә! Хәзер инде Әмирҗан кая? Үле дисәң, гүрдә юк, тере дисәң, җирдә, ягъни Казанда юк...

Дүртенче... Юк-ла, алтынчы кат баскычыннан менгәндә тагын бер мәртәбә канатланып алды буйдак кавалер. Бик тә назлы кызга охшаган бу Гүзәл. Рәҗәп хатыны Рәмзия назлары бардыр, билләһи. Рәҗәп уңга борылса да—"пәп", сулга караса да "пәп"—Рәмзиясе кәнфит суыргандай үбеп кенә тора тегене. Хәер,

торды диярга кирәк. Чөнки бик тә көнче булган ул Рәмзия. Рәҗәбеннән көнләшеп йөргән-йөргән дә, бер төнне, йоклап яткан иренең башын балта белән чабып өзеп, сигезенче каттан асфальтка сикергән... Ике яшьлек балалары ятим калды... Татлы йоттырып, ачы костыручылар да бар бу дөньяда!

Сигезенче, тугызынчы катларга менгәндә Идрис йодрыгы белән баскыч култыксасын төйгәләп куйды. Юк, диде ул катгый карарга килеп, сигезенче катта да, тугызынчыда да яшәмәсләр алар Гүзәл белән. Әле сикерү түгел, саграк йөрсәң дә мәтәлеп төшүең бар. Җитми беренче белән икенче катта яшәүгә! Җитми! Китсәң, кайтсаң да җайлы, артың сузылганчы, тының капланганчы менәсе юк, төшкәндә башың әйләнгәнче бөтереләсе юк. Беренче катта яшәрбез, Алла боерган булса. Хәниф белән Фәридә өйләнгәннән бирле беренче катта көн итәләр. Тик менә... хактырмы-юктырмы, Хәниф командировкадан төнлә кайтып ишек шакуга, тәрәзәсеннән нииндидер ят ир сикереп төшеп кача икән. Күлмәге белән чалбарын да күздән югалгач кына кия, имеш. Шулай инде ул тормыш— анасын ормыш. Әйтүен-әйтәләр ул, буйдак кеше адәмчә яшәсә дә, эт үлеме белән үлә, дип. Ләкин өйләнгәннәрнең бөтен тормышлары эт тормышы түгелмени?! Әле үлүләренең кешечә булуына да иман китерәм димә. Сабир үлгәч, җеназага килгән дуслары мәет янында аптырашып утыралар икән: "Һай, исән чакта битләрс түп-түгәрәк иде бит әле, хәзер янагы сөягенә ябышып каткан монык",— дип. Соңыннан мәгълүм булган: Сәкинәсе, Сабир җан тәслим кылуга ук, куелган алтын тешләрен казнасы-ние белән каерып алган, ди имансыз.

Идрис авыр сулап куйды. Авызыннан тын түгел, ялкын чыккандай хис итте егет. Ләкин уң кулының урта бармагы хуҗасының акылыннан башка хәрәкәт итте (шул урта бармак, ни хикмәттер, башка гамәлләр вакытында да сабырсыз була)—Гүзәлнең ишек кыңгыравына басып өлгерде. Әчтә житез адымнар ишетелеп алды да, чибәркәй үзе дә Идриснең каршында пәйда булды. Нурлы елмаюы салкын кышны "ә" дигәнче язга әйләндерерлек кояштай иде кызның.

—И-и, күрше төгелме сун?! Әйдә, уз!.. Нәстә катып калдың, әдә кер дим бит, әкият!

Идрис, басып торырга хәле җитмәгәндәй, коридор стенасына сөялде дә, янә авыр сулап, моңсу, томанлы карашын аяк астына юнәлтте һәм... бөтен тәвәккәллеген бер учка кысып, әйтәсе сүзен әйтте:

—Юк-юк, чибәркәй, үтүгең үзенә булсын! Кирәкми миңа синең үтүгең! Ки-рәк-ми!..

Җил-җил генә аска төшеп барганда, аңлашылыр-аңлашылмас мыгырданып куйды:

—Торсам—ашым, ятсам—башым... үземнең үтүкне төзәтермен әле...

Кызның киң ачылган, әмма елмаюы чигенеп бетмәгән биниһая аптырашлы күзләрен күрмичә төшеп китте...

*1996—1998.*
*Казан.*

# ПУБЛИЦИСТИКА



# ТАТАРНЫҢ ҮЗ МИССИЯСЕ БАР



***Күренекле шагыйрь, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Равил Бохарай инде байтактан Лондонда яши, дөньяга мәгълүм Би-Би-Си радиосында эшли. Англиядә танылып килүче сәясәтмән һәм журналист булу белән бергә ул татар шагыйрьләренең әсәрләрен инглиз һәм башка чит телләргә тәрҗемә итү, аларны бастырып чыгару буенча да шактый күп эш башкара. Күптән түгел якташыбыз Казанда булып китте. Журнал укучылар игътибарына танылган шагыйрь Гәрәй Рәхимнең аның белән үткәргән әңгәмәсен тәкъдим итәбез.***

**Гәрәй Рәхим:** *Равил әфәнде, синең туып-үскән җирең Казан. Балалык һәм яшьлек елларың монда үтте, монда урта белем алдың, монда Казан дәүләт университетының физика-математика факультетын тәмамладың. Иҗаттагы тәүге адымнарың да Казан белән бәйле. Урыс телендә язган беренче шигырьләрең дә матбугатта монда басылды, беренче шигырь китабың да монда дөнья күрде. Аннары син Мәскәүгә күчеп киттең, әмма татар дөньясы, татар әдәбияты белән элемтәләрең кимемәде генә түгел, тагын да ныгый төште дисәм, ялгышмамдыр. Чөнки син Мәскәүдә торып та байтак татар шагыйрьләренең әсәрләрен урыс теленә тәрҗемә итеп чыгардың һәм безнең күпләребезне гаҗәпләндердең. Хикмәт шунда, урыс телендә иҗат итүче кайбер татар язучылары гомерләре буенча Казанда, татар арасында яшәсәләр дә, татар телендә язу түгел, хәтта татарча сөйләшә дә белмиләр. Ә син, киресенчә, урыс телендә иҗат итүче шагыйрьләр арасында һәм урыс әдәбиятында киң танылгач, татар телендә яза башладың. Моңа нәрсә сәбәп булды? Татарча иҗат итә башларга сине нәрсәләр этәрде? Һәм мондый ихтыяҗ нилектән туды?*

**Равил Бохарай:** Моннан бер егерме еллар элек мин үземне татар шагыйре дип күз алдына да китерә алмый идем. Бу бөтенләй мөмкин түгел бер хәл булып тоела иде. Чөнки мин мәктәптә урыс телендә укыдым, аннан соң университетта математик белгечлеге алдым. Дөресен генә әйткәндә, миңа татар әдәби телен янабаштан һәм үзлегемнән, татар әдәби классикасыннан өйрәнергә туры килде. Шулай булу әйбәт тәдер әле, чөнки безнең урам теле, Казанда без сөйләшергә маташкан тел ул инде саф, чиста, пакь тел түгел. Ул урыс һәм татар телләренең катнашмасы. Хәтта җөмлә төзелеше

урыслаша башлаган иде бит. Иң саф, пакь тел чишмәсе ул безнең классик әдәбиятыбызда. Әнә шул чисталыкка, борынгы телнең гүзәллегенә соклану алар белән урыс укучысын да таныштыру теләгеннән уятты да инде. Шулай итеп, мин татарчадан урысчага турыдан-туры тәрҗемә итә башладым. Моннан егерме еллап элек синең белән очрашуым әле дә хәтердә. Ул чакта без Тельман урамында әдәбият сөючеләргә яхшы таныш бер өйдә сөйләшеп утырган идек. Ялгышмасам, минем иң беренче тәрҗемәләрем дә синең шигырьләрең булды бугай.

**Гәрәй Рәхим:** *Әйе, ул чакта "Сиңа татарчадан юлга-юл тәрҗемә, ягъни подстрочник, кирәк булырмы?" дип сораган идем. Ә син баш тарттың, "Миңа подстрочник кирәкми, татарчадан турыдан-туры тәрҗемә итәсем килә",—дидең.*

**Равил Бохарай:** Чишмә башы шундадыр ахрысы, мин татар телен чынчынлап, ныклап өйрәнә башладым һәм озакламый классикага күчтем. Башта Тукайны тәрҗемә итәргә омтылыш ясап карадым, аннары Дәрдмәнд, Хәсән ага Туфан, Сибгат ага Хәким. Бу шагыйрьләр мине чын татар теленә өйрәттеләр. Хәзер инде минем телем тагын алай ук саф түгел. Хәзер, үзең белгәнчә, мин Лондонда яшим, туган телдә аралашыр даирә юк. Бу бик комачаулый. Шулай да, Аллага шөкер, телне онытмадым.

**Гәрәй Рәхим:** *Ярый, татар теле, әлбәттә, синең туган телең, ватаныңның теле. Туган тел белән туган ил аерылгысыз төшенчә. Әмма син менә инде, үзең дә әйтеп киттең, хәзер дистә елга якын Англиядә, Лондон шәһәрендә яшисең. Синең урыс һәм татар поэзиясе үрнәкләрен инглизчәгә турыдан-туры тәрҗемә итүең турында да яхшы беләбез. Шунысы кызыксындыра, бөтенләй чит-ят мохитта яшәп, бөтенләй чит-ят телне ничек шул дәрәҗәдә өйрәнергә мөмкин! Моңа ничек ирешә алдың? Тагын, син инглиз телендә бары тик тәрҗемә белән генә шөгыльләнәсеңме, әллә иҗат та итәсеңме?*

**Равил Бохарай:** Өйрәнү дигәннән, телгә хирыс кешегә телләр үзләштерү артык кыен түгелдер дип беләм. Ә иҗатка килгәндә, хәзер мин турыдан-туры инглизчә дә язам. Менә быел, күз тимәсә, ике китабым чыгасы.

**Гәрәй Рәхим:** *Лондондамы?*

**Равил Бохарай:** Әйе, Лондонның үзендә "Курзон" дигән нәшрият бар. Анда "Рәсәйдә ислам дине" дигән монографиям, тарихи планда язылган киң күләмле эзләнүтикшеренүләрем чыгарга тора. Аны мин турыдан-туры инглиз телендә яздым. Аннан соң Лондон университетының танылган профессоры Дэвид Мэтьюс белән икәүләп шигъри антология төзеп ятабыз...

**Гәрәй Рәхим:** *Әллә татар антологиясеме?*

**Равил Бохарай:** Әйе, татар поэзиясе антологиясе. Ул чит ил укучыларын халкыбызның бик борынгыдан башлап бүгенгә кадәрге булган гаять бай әдәбияты үрнәкләре белән таныштыру максатында эшләнә. Үзем, әйткәнемчә, инглизчә дә шигырьләр язам, алар басылып та чыга. Тел белүем белән мин яшьлегемә бурычлы. Урта мәктәпне тәмамлаганда мин инде инглиз һәм алман телләрендә шактый йөгерек аралаша ала идем. Әмма гомерләр үтеп алар онытыла башлаган иде инде. Англиягә килгәч инглизчәнең урам теле вариантын яңабаштан өйрәнергә туры килде.

**Гәрәй Рәхим:** *Моңардан тыш син бит әле бераз Венгриядә дә яшәп алган идең. Анда син мадьяр телен камил өйрәндең, хәтта мадьярчага поэзия әсәрләрен, шул исәптән, минем шигырьләрне дә тәрҗемә дә итеп бастырган идең. Венгр телендәге иҗатың турында тәгәлрәк әйтеп китик әле.*

**Равил Бохарай:** Венгрча иҗатым ул тормышымдагы аерым бер истәлекле сәхифә. Мин бит венгр телен утыз алты яшьлек чагымда өйрәнә башлаган идем. Кем әйтмешли, яшь чак, егет чак. Яшьлегем белән димме, бик тиз өйрәндем мин аны, хәтта шигырьләр яза башладым. Аннан, мадьяр теле белән татар теле арасында кайбер уртаклыклар, охшашлыклар да байтак. Ул да ярдәм иткәндер.

**Гәрәй Рәхим:** *Венгриягә махсус рәвештә тел өйрәнү өчен барган идең түгелме соң?*

**Равил Бохарай:** Әйе. Мин Будапештта алты ай яшәдем һәм бик нык

тырышып укыдым, аннары Мәскәүгә кайттым да турыдан-туры венгр теленнән урысчага тәрҗемә итә башладым. Ул вакытларда Мәскәүдә венгрчадан дистәгә якын тәрҗемәче бар иде. Аларның көнләшүе дә булгандыр инде. Янәсе, әллә кайдан килгән, үзе татар, үзе тагы урысча яза... Җитмәсә мадьяр теленә тыгыла. Шуңа күрә алар миңа эш бирдермәделәр, димме...

**Гәрәй Рәхим:** *Ул чакта венгр телендә шигырьләрең басылып чыктымы?*

**Равил Бохарай:** Берничә тапкыр. Венгрлар мине шул шигырьләр өчен Язучылар Союзына да алдылар. Мин хәзер венгр Язучылар Союзы һәм венгр ПЕН-клубы әгъзасы. Шигырьләрем Венгриядә дүрт мәртәбә чыкты—бер мәртәбә китап булып, өч мәртәбә бик танылган журналларда. Минем өчен бу бик мөһим нәрсә булды. Чөнки венгрча шигырьләр язганнан соң уйладым, мин әйтәм, ярый венгрча язам, испанча да бераз язып карадым, итальянча бер-ике шигырь иҗат иттем инде, вакыттыр татарча да язып карарга. Менә шуннан башлап әкрен генә татарча яза башладым. Туган телемдә иҗат итмәү минем мәңгелек сызлануым булды. Вакыт-вакыт әле хәзер дә уйлап куям, эх, минәйтәм, моннан егерме-егерме биш ел элегрәк татарча әйбәт белгән булсам, бәлки, хәзер яхшы татар шагыйре булыр идем, дим.

**Гәрәй Рәхим:** *Замана чире, шул чорның шаукымы иде инде ул. Казанда туган телдә эшләүче бер бөртек мәктәп калган иде бит. Хәзер, Аллага шөкер, бу өлкәдә эшләр җайга салынып бара, алга китеш тә күзгә күренә башлады. Ничек кенә булмасын, бүгенге көндә син берьюлы берничә телдә иҗат итә алучы бердәнбер татар шагыйре. Үзең туган илдән еракта, Лондон каласында яшәсәң дә, туган телне, ватаныңны онытмыйсың. Бу безнең татар кешесенең гомер буена күңеленә сеңгән туган җирне сагыну, җирсү дигән мәңгелек бер хиседер инде. Дөнья ул хис кенә дә түгел бит әле. Туган җир, ватандашлар, татар әдәбияты белән бәйләнешләрең ничегрәк? Практик бәйләнешләрең турында әйтүем. Бу җәһәттән ниндидер эшчәнлек алып барасыңмы, әдәбият белән бәйланышлар, халкыбыз белән бәйланышлар ничек?*

**Равил Бохарай:** Чынында мин рухым белән Казаннан беркайчан да китмәдем... Күңелем һәм йөрәгем монда. Кайда гына булсам да Казан турында уйлыйм һәм татарча дога кылам, мөселман булып яшим. Читтә сөйләшергә кеше булмаса, Алла бар, дим, Алла белән туган телдә—татарча сөйләшеп була. Кулымнан нинди эш килә, барысын да—тәрҗемәмә ул, башкасымы—Татарстан өчен дип, туган халкым өчен булсын дип тырышам. Менә Лондонда "Казан" дигән альбом чыгардык, татар поэзиясе антологиясен чыгарырга торабыз. Ә кайбер татар шагыйрьләренең аерым әсәрләрен инглизчәгә тәрҗемә итеп инде элегрәк тә чыгаргалап тора идем. Сезгә мәгълүм, мин Би-Би-Си радиосында эшлим, ә ул бөтен җир шарына сөйләүче гаять зур корпорация. Шул радио дулкыннарында Татарстан турында сөйләргә тырышам, татар көйләрен эфирга җибәрәбез. Менә, мәсәлән, Илһам Шакиров җырларын инде берничә мәртәбә Би-Би-Си дулкыннары аша бөтен дөньяга яңгыраттык.

**Гәрәй Рәхим:** *Равил, без икебез дә шагыйрьләр, бер чор шагыйрьләре, әдәбиятка да бергә килдек. Синең белән әдәбият турында, бигрәк тә аның поэзия жанры турында сөйләшәсе килә. Син дөньяны күп күргән кеше, күп илләрдә булдың, төрле әдәбиятлар белән аралаштың. Хәзер көнбатыш илләре тормышы даирәсендә яшисең. Һәм, табигый ки, безнең поэзияне дә, көнбатышныкын да якыннан беләсең. Аларның теге яки бу якларын чагыштырып буламы? Әгәр дә булса, алар арасында нинди уртаклык һәм аерымлыклар бар?*

**Равил Бохарай:** Язучыга, шагыйрьләргә бүгенге заман, гомумән, авыр заман ул. Шулай да Англиядә яисә Америкада, яки Австралиядә (мин анда күптән түгел генә булып кайттым)—аларда бездәгедән дә читенрәк. Чөнки анда әдәбият дигән нәрсә, бигрәк тә шигърият дигән нәрсә беркемгә дә кирәкми. Бездә исә син язучы яисә шагыйрь булсаң, җәмгыятьтә язучы-шагыйрь дигән зур исем йөртәсең. Чөнки аның бездә гаять зур һәм тирән традициясе бар. Ә Англиядә шагыйрь яисә язучы ул кешенең чын иҗтимагый хәле түгел, ул бары тик бер хобби сыман нәрсә итеп санала. Шигырьләрне беркем дә укымый. Шигърият бөтенләй башка, анда рифмалар да юк. Андагы шигъриятнең моңы юк, минемчә. Моң булмаган шигърият ул инде чын шигърият тә түгел. Шуңа күрә мин инглизчә егерме-утызлап шигырь яздым да шул җитеп торыр

дип йөри бирәм. Анда шигърият белән, әдәбият белән генә шөгыльләнеп тамак туйдырып та, матди яктан яшәп тә булмый. Бөтен Англиягә бер утызлап модный язучы-романчы бар, шул романнары өчен алар акчаны умырып ала инде. Ә шигърият үги бала кебек. Бездә дә шигъриятне шул хәлгә төшермәскә иде. Ул безгә ярамас... Бу юл киләчәгебез түгел һәм булмасын да.

**Гәрәй Рәхим:** *Күптән түгел безнең Казанда да халыкара ПЕН-клубның татар ПЕН-үзәге төзелде. Хәзер анда утызлап татар язучысы берләште. ПЕН-клубның халыкара штаб-квартирасы Лондон шәһәрендә, анда безнең татар ПЕН-үзәген теркәү эшләрендә синең ярдәм итеп йөрүләреңне дә беләбез һәм форсаттан файдаланып моның өчен рәхмәт тә әйтәсем килә. Лондондагы ПЕН-клубның эшчәнлеге, аның эшендә синең үзеңнең ничегрәк катнашуың турында берничә сүз әйтеп китсәң, безгә бик кызыклы булыр иде.*

**Равил Бохарай:** Бая әйткәнемчә, мин үзем Венгриянең ПЕН-клубы әгъзасы һәм күптән түгел Американың ПЕН-клубына да кабул ителдем. Ә ниндидер эшчәнлек дигәннән, аның иң зурысы итеп инглиз телендә классик татар поэзиясе антологиясе чыгаруны әйтәсем килә. Ул басылып чыккач Англиядә дә, башка илләрдә дә күрсәтербез аларга Татарстандагы әдәби тормышны. Төзик әле бер әдәби делегация, килик әле Лондонга, залда татарча музыка уйнатып бер-ике күргәзмә оештырыйк. Менә бу чынлап та бер вакыйга булыр иде. Инглизчә антология татар шигърияте нәрсә икәнен, татар шагыйрьләренең кемнәр икәнен дөньяга танытуның бер чарасы ул.

**Гәрәй Рәхим:** *Инде, Равил, соңгы сүз итеп сиңа тагын бер сорау бирәсе килә. Бүгенге көнбатыш Европа тәҗрибәсеннән чыгып, безнең бүгенге Татарстаныбызга, аның сәяси, иҗтимагый хәленә, гомумән татар халкына, аерым алганда, аның әдәбиятына, шагыйрьләренә карата нинди теләк әйтә алыр идең?*

**Равил Бохарай:** Теләгем бер генә. Ул теләк миннән генә килми. Бөтен тарихыбызга бәйле нәрсә дә ул. Сабыр булырга кирәк. Эшчән һәм сабыр булырга... Чөнки дөньяда әле безнең бик күп казанышларыбызны белмиләр. Әкрен генә аларны да өйрәтербез әле, иншаллаһ. Шуны онытырга ярамый—цивилизация өлкәсендә без дөньяда беркемнән дә түбән түгел. Кешенең иң зур байлыгы ул—йөрәге һәм оста кулы, акылы һәм сабырлыгы. Бөтен нәрсәгә ирешү өчен менә шушылар җитә. Минем теләгем бар: ул юлны сиратыл мөстәкыйм диләр, тугры юл, менә шул тугры юлдан барырга кирәк. Нәрсә булса да, нинди дәвер килсә дә. Безнең, татарларның, дөньяда ниндидер миссиясе бар, шул миссияне аңларга һәм аның өчен эшләргә кирәк.

**Гәрәй Рәхим:** *Равил, татар халкының дөнья, мәңгелек каршындагы әнә шул миссиясен сез ничегрәк күз алдына китерәсез?*

**Равил Бохарай:** Татар халкы һәрвакыт сабыр булып, эшчән булыпниләр эшләгән? Ул моның белән кешеләргә бер үрнәк күрсәткән. Менә шул холкы аны эшчәнлеккә этәргән, мәгърифәткә этәргән, безнең халык белемгә омтылучан халык бит ул. Кая барса да пакьлекнең, чисталыкның үрнәген күрсәтә белә. Бигрәк тә бүгенге Рәсәйдә. Камчатка булсын ул, Магадан булсын... Анда да татарларның кем икәнлеген бик яхшы беләләр. Татарлар чиста, эшчән һәм акыллы халык диләр. Менә шуны сакларга кирәк. Хәзер безнең тарафка төрле яктан бик күп начар үрнәк килә. Тик аларны өлге итеп алырга ярамый. Кызганычка каршы, соңгы вакытта без үзебезнең югары дәрәҗәбезне оныта барабыз, яки аңлап бетермибез. Яңадан тарихка таянып, Аллага таянып алга барасы иде һәм яңадан татар үрнәген бөтен дөньяга күрсәтәсе иде. Гомумән, Татарстан шул юлдан барырга тырыша да. Мин Лондонда Татарстан турында бик күп ишетәм, ул хәзер ничектер бөтен дөньяга үрнәк булып күренә, минемчә. Безнең төп миссиябез дә шуннан гыйбарәт.

**Гәрәй Рәхим:** *Рәхмәт, Равил әфәнде. Без синең киләчәктә дә ватаның, туган телең, туган халкың, туган әдәбиятың белән горурланып, алар хакына иҗат итеп яшәвеңне һәм, әлбәттә инде, үзең белән, китапларың белән, әсәрләрең белән әледән-әле очрашуларны теләп калабыз.*

**Равил Бохарай:** Рәхмәт яусын!

Марсель Зарипов

# ГЕНЕРАЛ БУЛУ РӘХӘТМЕ?

Татарстан Җөмһүрияте дөнья илләре вә халыклары арасына матди байлыклар җитештерүче буларак кына түгел, ә тигез хокуклы, эшлекле, сәяси партнер—бергәләп эш алып барырлык тиңдәш буларак та керергә тырыша. Әмма сәүдә эше—җитди эш-шөгыль. Базарлар, нигездә, бүленеп беткән. Берсендә дә сине: "Рәхим итегез!"—дип ишек ачып көтеп тормыйлар. Кунакханә түгел. Дөнья базарларындагы икътисади мәйданнар, әйткәнебезчә, үзләштерелеп бетерелгән, шуңа күрә, үз матди мөмкинлекләреңне күрсәтеп, югары техник-технологик ачышларыңның башкалар белән ярышырлык икәнлеген дәлилләп, кирәк булса, терсәк белән төрткәләшә-төрткәләшә дә хәрәкәт итәргә, эш йөртергә туры килә. Әлбәттә, товарың яхшы сыйфатлы, бәясе дә килешерлек булырга тиеш. Бары тик шундый абруй-дәрәҗә казанып кына дөнья базарында лаеклы урын яуларга була.

Татарстан мөстәкыйльлек-бәйсезлек игълан итеп, хөкүмәт делегацияләре чит илләргә чыгарга мөмкинлек алды.

Мин алар булган илләр-шәһәрләрне картада билгеләп барырга яратам. Максаты ни-нәрсә соң бу сәяхәтләрнең? Башкаларны күреп танышу, үзебезне күрсәтеп таныту—максат әнә шундый. Менә безнекеләр соңгы елларда барып йөргән ерак чит илләр: Америка Кушма Штатлары, Куба, Һиндстан, Малайзия, Мисыр, Франция, Англия, Германия, Италия, Австрия, Венгрия, Польша, Төркия... Элекке Совет республикалары, бүген якын чит илләр дип йөртелүче илләрнең башкалалары—Киев, Алма-Ата, Баку, Минск, Вильнюс...

Гадәттә Татарстанның рәсми делегацияләрен йә Президентыбыз Минтимер Шәймиев, йә Дәүләт Советы рәисе, йә премьер-министр җитәкли. Инде алар бара алмаганда вице-премьерлар, министрлар һ.б. бара. Һәр делегация составында, кагыйдә буларак, "Татнефть" вәкилләре катнаша, алар нефтьчеләребез мәнфәгатен якларга тиешләр. Үз мәнфәгатьләре өчен нефтьчеләр үзләре йөрү—бер нәрсә, ә инде алар мәнфәгатен хөкүмәт, парламент, президент кайгырту, үз өсләренә җаваплылык алу—бөтенләй башка нәрсә. Моның дәрәҗәсе үк икенче! Шул рәвешле, "кара алтын" белән сәүдә итүдә ышанычлы базар булдырыла, бергәләп алыш-биреш итәрлек эшмәкәрләр тәгаенләнә.

Татарстан нефтьчеләренең башка төбәкләргә караганда уңайрак шартларда эшләүләренең тагын бер сәбәбе—һөнәри закон булдыруда, нефть сәнәгатенең анык үзенчәлекләрен исәпкә алып, дәүләт тарафыннан нәтиҗәле-уңышлы юнәлеш бирә белүдә.

Ни өчен һәрвакыт, һәр илдә табышлы булган нефть сәнәгате Россиянең башка төбәкләрендә таркалу-таралу алдында тора? Чөнки Россия законнары нефть эшенең үзенчәлекләрен исәпкә алмый. Барлык нефть ятмаларын да бер калыпка салып, бер икътисади нормативлар буенча эшкәртергә мәҗбүр итәләр. Әле нефть бар, әйдә ку! Дәүләткә акча кирәк, валюта кирәк. Һәм, аракыга салган шикелле, "кара алтын"га да акциз салымнары белән бергә башка салымнарны да тондырдылар. Әле ничек кенә!

Икътисадчылар ничек уйлый? Россия нефть скважиналарының

---

Ахыры. Башы журналның 1 санында.

мөмкинлеге, янәсе, елына 500 миллион тонна "кара алтын" бирерлек. Бу бит Иран, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Сөгуд Гарәбстаны, Кувейтларның барысының мөмкинлекләренә тиң! Башка исәпсез-хисапсыз салымнар өстенә нефтьнең һәр тоннасына тагын җитмеш дүртәр мең (иске акча белән) акциз җыемы тондырдыкмы? Тондырдык! Бу ич дәүләт казнасына өстәмә триллионнар дигән сүз! Санап карасаң, 288 триллион сум килеп чыга. Сызгырырсың, кодагый! Чубайс-фәләннәр урлап бетермәсә, бу кадәр акча реформалар үткәрергә дә, балалар бакчаларына-мәктәпләргә дә, фән-мәгърифәткә, сәламәтлек саклауга да, оборонага, милициягә дә... һәм инде болай да чамасыз күп үрчегән эреле-ваклы түрәләрне тагын да ишәйтергә дә җитәрлектер, валлаһи!

Нефть сәнәгатендә акциз салымнары куллану бер бүген генә башланган һәм бүген генә бетәчәк эш түгел.

Атаклы галим Дмитрий Менделеев (Аның турында "Казан утлары" журналының 1998 елгы 3 санында без инде тәфсилләп язган идек. М.З.), үзенең барлык фәнни эшләрен бер якка куеп, нефтькә акциз салымнары мәсьәләсендә көрәшкә кушылып китә. Ул иренми, һәртөрле исәпләүләрдән соң бер нәтиҗәгә килә: акциз салымнары нефть сәнәгатен һәлакәткә илтәчәк. Менә галимнең Россия сәнәгате һәм сәүдәсенә булышлык итү җәмгыяте утырышында әйткән сүзләре: "...Шулай итеп, елына сигез миллион доллар керем бирсә дә, Америкада нефтькә бу салымны туктаталар. Статистик мәгълүматлардан күренә ки, шул вакыттан башлап нефть сәнәгате бик тиз үсеп китә... ... Акциз салымын вакытлыча гына түгел, ә бөтенләй—гомерлеккә алып ташлау эшмәкәрләрне тынычландырыр, зур файдалар бирер. Бу файдалар нефть эшенә яңа эшмәкәрләрне җәлеп итәр, яңа капитал китерер. Нефть эшендәгеләр гадел табыш алганда гына бу эш ныклап аягына басачак. Нефть эшендә аны чыгаручы-табучылар башлангыч пружина булып торалар һәм аларга хаклы табышларын алмыйча һич ярамый."

Әйтерсең, бүгенге хәлне күреп кисәткән Дмитрий Менделеев! Ә бит бу сүзләр 1886 елда ук, моннан бер гасырдан артык элек әйтелгән! Ул вакыттагы Россия икътисадчылары хәзергеләр кебек сай акыллы булмаганнардыр шул: галимнең сүзләренә колак салып, акциз салымнарын бетергәннәр, нефть сәнәгате үсеп, чәчәк атып киткән.

Менә шулай. Уйлансаң, уйланырлык хәлләр бар.

Россия нефте реформаның беренче елларында ук бик кыйммәткә төшә иде. Һәр нәрсә чыгымнар сорый: электр энергиясенә, материалларга, техникага түләргә кирәк, технологик процессларны әйткән дә юк. Җитмәсә, шуның өстенә хөкүмәт "кара алтын"га акциз салымын күтәргәннән-күтәрә бара. Бу чыгым-салымнарга урындагы җирле хакимиятнең берниндн чикләү-тикшерүләрсез басып кала торган суммаларын да өстәгәч, нефть эше бөтенләй табышсыз-файдасызга әйләнә дә кала. "Новое время" журналы шундый кызыклы мәгълүматлар китерә: 1997 елның башына "Юганскнефтегаз" акционерлык җәмгыяте дәүләт бюджетына 1 триллион 715 миллиард сум (иске акча белән), "Ноябрскнефтегаз"—1 триллион 361 миллиард сум, "Нижневартовскнефтегаз"—1 триллион 63 миллиард сум, "Кондпетролеум"—643 миллиард сум бурычлы булып калган...

Хәзер күп кенә скважиналарны, аларны эшләтүнең икътисади файдасы булмаганлыктан, туктатып, томалап куярга мәҗбүрләр. Әле 1993 елда ук Татарстан нефть промыселларында ун меңнән артык скважина шулай томаланды, чөнки базар дигәнең шуны таләп итә—файда-табышсыз эшнең хаҗәте юк. Биредә берниндн фәрман-приказлар ярдәм итә алмый. "Үле" скважиналар саны артканнан-арта бара, "кара алтын" алу кими, нефть сәнәгате тирән кризиста. Хәер, ил тулаем үзе дә тирән кризиста...

Советлар Союзы чорында, сиксәненче еллар азагында, нефть чыгару үзенең иң югары ноктасына җиткән—елына 630 миллион тоннан

"җир мае" алына иде. Шуннан соң кискен кимү башланды. 1990 елдан алып бу күрсәткечләр түбәндәгечә аска тәгәрәде: 1990 ел—96,7 %, 1991 ел—90,9%, 1992 ел—84,9%, 1993 ел—72,8%, 1994 ел—63,9%, 1995 ел—62,6%, 1996 ел—61,3%... Шулай итеп, җиде ел эчендә Россия нефть промыселларында нефть чыгару елына 250 миллион тоннага кимеде!

Татарстан нефтьчеләренең җиденче генералы Ринат Галиевкә менә шундый күңелсез һәм аяныч хәлләрдә җитәкчелек итәргә туры килә. Ә нефть кирәк, бик кирәк!

* * *

Ринат Галиев бүгенге авыр шартларда үзен ничек хис итә соң? Аңа бит хәзер "кара алтын" ташкыннарына куанып утырырга мөмкинлек юк. Дистә меңнәрчә нефтьчеләрнең язмышы, промыселларның исән калу-калмавы өчен җаваплылык аның җилкәсендә. Нинди стратегик алымнар сайларга, отышлы тактик адымнар ясарга икән?

Кешенең холкы-табигате йөзендә чагыла, диләр. Ринат Галиевне күзәткәндә, аның кәефенә карап йөзендәге үзгәрешләргә игътибар итсәң, шатлык-куанычларда балкып китүен, уңышсыз-күңелсезлекләрдән сүрәнләнеп-сүнеп калуын күрәсең дә, бигрәк хисчән кеше инде: башта йөрәгенә буйсына, аннары гына акылга ирек бирәдер бу, дип уйлыйсың. Хәтта аны ничектер яклыйсы, кирәкмәгән күңелсезлекләрдән саклыйсы килә башлый.

Әмма тормыш Ринат Галиевне сабырлыкка-саклыкка өйрәткән, нинди генә хәлләргә тарымасын, кайнар хисләре ничек кенә ташып чыкмасын, ул аек, салкын акыллы булып кала белә.

Әгәр дә югарыда, хакимият башында утыручылар күтәрә алмаслык салымнар белән кыса икән, меңнәрчә скважиналарның эшләвеннән эшләмәве артык, нефть алуга тотылган чыгымнар аны сатудан килгән табыштан күпкә артыграк икән, димәк, нефть сәнәгате белән идарә итүнең ышандырырлык башка юлларын табарга кирәк. Нинди юллар табарга?

Салымнар—үлем-китем шикелле үк, алардан котылып булмый. Әмма, котылып булмаса да, аларны билгеле бер тәртипкә китерергә мөмкиндер бит. Салым—җәза түгел, ул идарә итүдә отышлы бер корал, табышны акыллы һәм файдалы итеп куллану чарасы. Дәүләт казнасын тутыруның ике юлы бар. Беренчесе—салымнарны һаман арттыра бару, мөмкин булган һәр нәрсәне түләүле итү. Рим императоры Веспасиан хәтта җәмәгать бәдрәфләренә керүне дә түләүле итеп эшли. Иң көлкесе шул: хәзер Рәсәйдә дә бу "файдалы гамәл" казнага акча китерә! Бюджетны тутыруның икенче юлы—салым салынырдай җитештерү көчләрен арттыру, халыкка хезмәт күрсәтүне үстерү һәм башкалар. Монысы да халыкның меңәр еллык тәҗрибәсенә таянып эшләнә. Әмма ул бүгенге Россия хакимияте тарафыннан онытылган. Бездә хәзер, бер генә илдә дә булмаганча, һәр бер сум табыштан бюджетка җитмеш-сиксән-туксан, хәтта туксан биш тиененә кадәр басып калына. Милекчеләрнең төп катламы булырга тиешле урта сыйныфны үстерү өчен җаваплы Ирина Хакамада күптән түгел генә ачынып әйтте: "Һәр эшмәкәр тир түгеп тапкан бер сумының туксан алты тиенен салымнар итеп түләргә мәҗбүр,"—диде. Салым җыючылар саны хәзер илдә кырык меңнән артып киткән. Салымнар күп җыела (түрәләр һаман "аз! аз!" дисәләр дә), ләкин казна барыбер... буш! Чөнки җитештерү кими, табыш юк, икътисад үлем хәлендә. Ә бит дәүләтнең салым системасы, киресенчә, икътисадны үстерүгә, җәмгыятьнең мул-имин тормышта яшәвен тәэмин итүгә юнәлтелгән булырга тиеш. "Деловой мир" атналык газеты язганча: "Ач-ялангач кеше салым түли алмый".

Бу хакта күп сөйләргә, күп язарга була. Тагын бер генә мисал. Реформаларның беренче җиде елында Россиядә нефть чыгару елына

250 миллион тоннага кимеде, дидек. Дөнья базарында ул чорда бер тонна "җир мае" 100 доллар тора иде. Димәк, күпме миллиард долларлар җилгә очты?! Шуның яртысы гына дәүләт казнасына керсә дә, ә?! Аннары сәнәгатьтә житештерү кимүдән, авыл хуҗалыгы таркалудан күпме югалтабыз? Без, җыелган салымга куанып утырып, мең сумын югалткач биш тиен табып шатланган ахмакка тиңләшәбез түгелме соң?

* * *

Татарстан нефтьчеләренең "кара алтын"нан табыш алулары кимүе реформаның беренче башлангыч елларына туры килде. Промыселларда скважиналарны туктата башладылар.

Нефть генералы Ринат Галиев нәрсә эшләргә тиеш иде бу очракта? Мин мөмкин булган берничә ысулны фараз итеп карадым. Әйтик, берсе шундый. Хәлнең хәтәрлеген, скважиналарның туктап калуларын иң өскә—министрга, Татарстан һәм Россия Президентларына хәбәр итәргә дә, бер җаен табарлар әле дип, кул кушырып көтеп утырырга мөмкин. Бер заман гаепләнене эзли башласалар, әйтәсең: мин бит хәбәр иткән идем, дисең.

Әмма җаваплылыкны һәрвакыт үз өстенә алырга күнеккән Ринат Галиев андый юлга барамы соң? Скважиналарның барысы да туктап, промыселлар ябылып бетсә, нефть төбәгендәге йөзләрчә мең эшче куллар эшсез калса... Нефтьче һөнәрен гомерлеккә сайлаган кешеләр кая барырга тиеш булыр? Кемгә әрнүле-ачулы сүзләрен җиткерер, кемне гаепләр алар? Юк, Мәскәү түрәләрен түгел, беренче чиратта, әлбәттә, Ринат Галиевне гаепләячәкләр. Аны бит, ышанып, акционерлар җыелышында җитәкче итеп, "Татнефть"нең генералы итеп сайлап куйдылар, җөмһүриятебезнең Дәүләт Советына депутат та итеп сайладылар. Ә ул шул нефтьчеләрнең өметләрен акламады булып чыгамы? Юк, юк, һәм янә дә бер тапкыр юк! Болай һич ярамый, булмый болай!

Бу четерекле төенне чишүнең тагын бер юлы, армия генераллары теле белән әйткәндә, көч кулланып чишү юлы да бар: салым җыючылар белән маңгайга маңгай бәрелешеп, нефть үткәргеч торбаларны ябасың да, катгый шарт куясың: нефть промыселларын дәүләт күләмендә талауны туктатырга, алынган "җир мае"на намуслы, гадел бәяләр билгеләргә, муенга салынган салым элмәген, бераз тын алырлык итеп булса да, бушата төшәргә, бер тиенгә яраксыз ваучер кәгазьләренә ия булганчы, үз хезмәтеңнең җимешләрен үзең татырга мөмкинлек бирергә, дисең. Чынлап та, "Татнефть"нең акционерлары-хуҗалары без, дип мактанып йөрүнең ни мәгънәсе бар: эшләгәнеңнең бар булганын диярлек кырып-себереп ала баралар ич! Иң симез калҗа—Мәскәүгә, аннары—Казанга, аннары—җирле хакимияткә, аннары, аннары, аннары... Аннарымы? Аннары эшчеләреңә хезмәт хакы түләү өчен югары процентлы бурыч—кредит аласың. Әнә, хезмәт хакы түләүне таләп итеп, күпләр ачыктан-ачык көрәш юлына басты. Шахтерлар, энергетиклар, тимер юлчылар, елгачылар-диңгезчеләр, завод-фабрика эшчеләре... Аларга түрәләр тарафыннан мыскыллап "бюджет хәерчеләре" дип йөртелүчеләр—галимнәр, укытучылар, табиблар, студентлар кушылды... Ил буенча забастовкалар, пикетлар, демонстрацияләр... Кемнәрдер ачлык игълан итә... Хәтта кемнәрдер үзенә-үзе кул сала... Ә нәтиҗәсе? Нәтиҗәсе—нуль! Хөкүмәт ишетми дә, күрми дә. Түрәләрнең тамагы тук, өсте бөтен...

Менә шундый шартларда һәрвакыт ераккарак карап эш-гамәл кылучы Ринат Галиев нишләде, дисез? Юк, ул хакимиятне каһәрләп, лаф орып, ах-вах килеп утырмады. Бер караганда бик гади, әмма гаять эшлекле, мин әйтер идем, бөек бер фикергә килде—шундый компромисс-килешү тәкъдим итте: финанс әһелләре промыселлар өчен һәлакәткә тиң салым кысуларын киметә, нефтьчеләр исә салымга биреп җиткермәгән

сумнарын өстәмә "җир мае" чыгарып, шуның белән каплый баралар. Нефть күбрәк алынган саен табыш та күбрәк, димәк, табыштан бюджетка керәчәк сумнар да арта барачак.

Ринат Галиев һәм аның фикердәшләре-мәсләктәшләре тәкъдим иткән бу ысулның әһәмияте нәрсәдә иде? Дәүләтнең ярлы казнасыннан бер тиен дә алмыйча, нефть промыселларын да һәлакәттән коткарып, димәк, нефтьчеләрне дә эш белән тәэмин итеп, бюджетка да зыян китермәүдә иде. Әйе, тормышта иң мөһиме—икътисад, хуҗалык итә белү. Кешеләрне кызыксындыру юлы бер генә: синең хезмәтең сиңа файда китерәчәк. Нефтьчеләр скважиналарны ябып түгел, ә, киресенчә, күбрәк ачып, үз мәнфәгатьләрен табарга тиешләр. Нефть чыгару өчен тотылган һәр сум табыш-файда китерсен. Менә шулай.

Әмма түрәләрнең аңы шулай калыпланган ки, алар бер чыгымнарсыз табыш алу мөмкинлеген күз алларына да китерә алмыйлар. Ринат Галиев моны бик яхшы белә. Шуңа күрә дә ул, үз фикерен югарыдагы түрәләргә җиткергәнче, җиде кат үлчәп, бер кат кисәргә булды. "Татнефть"нең баш штабында махсус үзәк—эксперт-анализ бүлеге оештырылды, аның башлыгы Валерий Матвеевка бердәнбер ашыгыч бурыч куелды: нефть скважиналарын эшләтүне икътисади яктан нигезләп-дәлилләп бирергә кирәк. Промыселлардагы һәр скважинаны исәпкә алып, меңнәрчә скважиналарның һәрберсен!

Исәпләү-хисаплау эшләре чиксез иде. Иң әүвәл һәр нефть ятмасының геологик хәлен, аның мөмкинлекләрен, тау токымнарының үткәрүчәнлеген, нефтькә никадәр бай булуын, ул байлыкның күпмесен алып булачагын, күпмесе катламнардан катламнарга агып төшәчәген һ.б. һ.б. исәпләп-өйрәнеп чыгарга кирәк булды. Нефтьне эше бик күп электр энергиясе сарыф итә. Димәк, анысын да, кем әйтмешли, энәсеннән җебенә кадәр хисаплап-санап, нинди чыгымнарга китерәчәген белү зарур иде.

Компьютерлар озакламый барлык тиешле мәгълүматларны исәпләп бирделәр. Инде кешеләргә шуларның иң файдалы-табышлысын сайлап алырга гына калды. Татарстан җирләрендә кырык меңгә якын скважина бар һәм алар арасында үзенчәлекләре белән бер-берсенә охшашларын таба алмыйсың. Кайберләре тәүлегенә 50-60 тонна "кара алтын" бирергә сәләтлеләр, ә кайберләренең суга изреп чыккан "җир мае" бер-ике проценттан да артмый, күз алдына китереп карагыз: бер тонна нефть алу өчен туксан тугыз тонна су кудырырга кирәк!

—Менә шундый чуар манзара,—дип сөйли исәп-анализлар буенча баш компьютерчы Валерий Матвеев.—Өч мең скважина берәр тонна бирә, уртача күрсәткечләр һәр скважинага биш тонна чамасы туры килә. Америка Кушма Штатларында ярты миллионнан артык скважина бар, һәр скважина көнгә ярты тонна нефть бирә алса, ул табышлы санала. Ә бездә, барлык чыгымнарны чигереп исәпләгәндә,—әлбәттә, иң зур чыгымнар—салымнар!—ике тоннадан ким "кара алтын" суыртучы скважиналарны эшләтүнең мәгънәсе калмый.

Шуңа күрә, иң ярлы мәйданнардан да нефтьне азмы-күпме алуга йөз тотабыз, ул гел көнгә берәр тонна чамасы гына булсын—барыбер алачакбыз. Андый скважиналар меңнәрчә бит, димәк, тамчылардан күл җыелачак.

Компьютерлар исәпләп биргән дистәләрчә вариантлардан дүртесен сайлап алалар. Беренчесе—нефтьчеләрне акциз түләүләреннән тулысынча азат итү, өстәмә бәягә салымның Татарстан өлешен яртылаш киметү, юл салымын бетерү, табыштан алына торган салымны 13 % ка киметү һ.б. Калган вариантлардагы күрсәткечләр дә шушы тирәдә, бары тик теге яки бу салымны бөтенләй алып ташлау, киметү мәсьәләләрендә генә аерма бар.

Салымнар киметелгәндә нефть чыгару арта бара, дәүләт бюджетына нефть сатудан килгән керем дә ишәя. Иң мөһиме—авыр эшкәртелә

торган катламнарда эшләү дә файдалы, табышлы булып кала.

Әлбәттә, Ринат Галиев шундый ысулны сайлый, зур түрәләр белән шуның өчен көрәшә, төпле дәлилләр китерә. Әмма туң маңгайлы Россия түрәләрен алай гына җиңәрмен димә! Өсте-өстенә яңадан-яңа салымнарны уйлап чыгара гына торалар. 1996 елда, мәсәлән, нефтьчеләребез аз да түгел, күп тә түгел—утыз өч төрле салым түләделәр, утыз өч төрле! Акцизлар өчен генә дә алардан 500 миллиард сум каердылар, табыштан янә шул кадәр... Явыз Иван патшадан калган бу koточкыч мирас—салымнар белән җелегеңне суыру гасырдан-гасырга шулай дәвам итә килә. Гасырдан-гасырга!

* * *

Татарстан нефтьчеләренең акыллы тәкъдимен Мәскәүдә ишетмәделәр түгел, ишеттеләр. Хәтта Россия хөкүмәте "өйрәнергә", "тикшерергә", "чара күрергә" диган вәгъдәләрен дә кызганмады. Тик, гадәттәгечә, буш вәгъдәләр җилгә генә очтылар.

Ә Татарстанның үзендә, бик авырлык белән генә булса да, җирле түрәләребезнең аңында үзгәреш сизелә башлады. Президент Минтимер Шәймиев тә, хөкүмәт тә нефтьчеләр фикеренә колак салдылар. Бик озак бәхәсләр, кат-кат исәпләүләрдән соң, ниһаять, үзара шундый килешүгә ирешелде: табышсыз дип саналган скважиналардан алынган нефтькә Татарстан өчен акциз түләүләрен бетерделәр, андый скважиналардан алынган нефтькә өстәмә бәя өчен салымны да бер чиреккә киметтеләр.

Әлбәттә, ярым-йорты гына эшләнгән бу чаралар барлык икътисади мәсьәләләрне хәл итеп бетерә алмады. Ә шулай да "кара алтын" чыгаруны күпмедер дәрәҗәдә арттыру мөмкинлеген бирде.

Әлегә кадәр томалап куелган меңнәрчә скважиналар яңадан эшкә җигелде. Әйе, тамчылардан күл җыела башлады, нефть суырту бер ел эчендә ике миллион тоннага артып, 1995 елда нефтьчеләребез 25 миллион тоннадан артык "кара алтын" алдылар.

Беренче елда нефтьчеләргә салымда җиңеллек Президент Минтимер Шәймиев һәм хөкүмәт күрсәтмәсе белән эшләнгән булса, икенче елны ул инде, Дәүләт Советында тикшерелеп, закон көченә ия булды.

Япан кырда ялгыз солдат сугышчы була алмый, дигән гыйбарә бар. Әгәр дә ул "япан кыр" бурыч һәм намус эше булса, нефтьчеләребез генералы Ринат Галиев—сугышчы!

* * *

Шулай итеп, унтугыз ел дәвамында туктаусыз түбән тәгәрәгән һәм республикада нефть чыгару биш мәртәбәгә кимегән бер заманда, промыселлар "кара алтын"ны ике миллион тоннага арттырдылар. Ә Россия нефть чыганаклары һаман үлә баралар, ил елына янә биш миллион тонна нефтен югалта килә.

1996 елда, ниһаять, Татарстан Дәүләт Советы да салымнарны киметү турындагы карарга кул куйды. Бу инде закон иде. Көз көне исә "Татнефть" Америка финанс компаниясе "Эксимбанк" белән килешү төзеде. Нәтиҗәсе—томаланган скважиналарны тергезү өчен 84 миллион доллар валюта алынды.

Россия нефть компанияләренең чит ил биржаларында кыйммәтле акцияләр белән сату итүгә өзерленүләре өч елга сузылды. 1993 елда "Татнефть" акционерлык җәмгыяте булып оешкан иде. Ә инде 1996 елда алар үз акцияләре белән Россиядә беренче булып чит ил биржаларына юл ярдылар.

Чит ил фирмалары—Англиянең "Прайс Уотерхаус"ы һәм Американың "Миллер энд Ленц"ы бик төпченеп Татарстан нефтенең запасын тикшерделәр. Безнекеләр "бер миллиард тоннадан артык байлыгыбыз

бар" диген исәпләүләр китереп чыгарган иде, әмма чит ил белгечләре, һәр кәгазьне энә күзеннән үткәреп, һәр скважинаны капшап караганнан соң, үз нәтиҗәләрен әйттеләр: "Кара алтын" запасыгыз 841 миллион тонна." Бу—33 елга җитәрлек запас иде. Мондый запас әле дөньяда тагын кайда гына бардыр? Гадәттә, егерме, ун, биш ел белән чикләнәләр. "Лукойл"ның, мәсәлән, тикшерелгән запаслары 18 елга җитәрлек икән.

Чит ит биржаларында беренче сату итү "Татнефть"кә 130 миллион доллар табыш китерде. Ә акцияләрне сораучылар, алырга теләүчеләр мөмкинлекләрдән алты тапкыр артыграк иде!

Ринат Галиевкә табигать, күрәсең, тумыштан шундый сәләт биргән: җирдән, чынбарлыктан аерылмаска, буш хыяллар белән мавыкмаска! Әмма кирәк урында, реаль чынбарлыкка таянып, тәвәккәлли белергә дә зарурлык зур.

1997 елда "Татнефть" акционерлар җәмгыятенең отчет җыелышында Ринат Галиев мондый саннар китерде: "Салымнарны киметү 355 миллиард сум табыш һәм аз табышлы скважиналардан да "кара алтын" алырга мөмкинлек бирде. Республика бюджетына шулай итеп нефть алудан кергән табыштан 1 триллион 174 миллиард сум салым гына бирелде." (Саннар иске акча белән).

Директор вазифасы—һәрвакыт киеренкелек диген сүз. Өстән түрәләр кысса, астан эшчеләрең—хезмәт коллективы кыса. Җитәкчелекнең нәтиҗәле-уңышлы булуы эш стажыңа да, тиешле күрсәтмә-фәрманнарны биш бармагыңдай белеп, үтәп баруыңа да карамый, ул тулысы белән сәләтеңә, җитәкче һөнәрен яратып һәм оста башкаруыңа бәйле. Ринат Галиев җитәкче абруе белән уйнамый, кем белән һәм кайчан ничек сөйләшергә икәнен нечкә сиземли-тоя ул: үз дәрәҗәсенә тиңнәр белән тиңнәрчә, үзеннән югарырак түрәләр белән, ялагайланмыйча, үзен түбәнсетмичә, әмма итагать-әдәп саклап сөйләшә белә.

* * *

Әйткәнемчә, Рәсәйнең нефть сәнәгате упкынга тәгәрәгәндә "Татнефть" өчен дә авыр, бик авыр көннәр килде.

Ринат Галиев,—тынгысыз җан!—һаман да бу гарасатлардан исән-сау чыгу юлларын эзләде. Шундый эзләнүләренең берсендә ул нефть промыселларына, хәзерге тел белән әйткәндә, презинтация үткәрергә булды. Ягъни нефть эшен тәкъдир итү, күрсәтеп, аңлатып бирү, шулай итеп яңа партнерлар табу иде аның нияте, алар белән хезмәттәшлек итү хаҗәт иде. Әмма кемнәргә күрсәтергә, кемнәрне чакырырга? "Җир мае"на буялып йөрүнең бик тә файдалы-табышлы булуына ничек ышандырырга? Уйлашкан-киңәшкәннән соң Татарстандагы хәрби-сәнәгать комплексы генералларын дәшәргә булдылар. Килү-килмәү ирекле, әмма хөкүмәт телефонограммасы белән ныгытылган иде. Сер түгел: республикабыздагы хәрби заводларның да "көймәсе комга терәлгән", алар да табышлы заказларсыз калган заман бит. Ә нефтьчеләр аларга кызыксынырлык хезмәттәшлек тәкъдим итәләр. Әлеге завод цехларында бораулау станоклары, скважина вышкаларына төрле арматуралар, горизонталь катламнарны җир астында күрә белә торган навигация җайланмалары һ.б. һ.б.—кыскасы, нефть эшенә кирәкле бихисап күп әйберләрне ясап булыр иде. Хезмәттәшлек очраклы, кыска вакытка гына түгел, озакка—җир астыннан соңгы тамчы "кара алтын"ны сыгып алганчы дәвам итәчәк. Бу эшләргә "Татнефть" елына 80-90 миллион доллар бүлеп бирергә дә әзер. Эш һәркемгә җитәрлек булыр: заводларның җыю конвейерларында эшләүчеләргә дә, конструкторлык бюроларында сызым сызып утыручыларга да, лабораторияләрдә теоретик тикшеренүләр алып баручыларга да җитәр.

Завод генераллары алай кыстатып тормадылар, килделәр.

Промыселларны карап йөрделәр, заводларда ясалырга тиешле кирәк-яракның үрнәк-өлгеләре белән таныштылар, кунакчыл хуҗаларның сый-нигъмәтләреннән дә авыз иттеләр, матур-матур теләкләрен, тостлар әйтә-әйтә, мактый-мактый хуҗаларга ирештерделәр һәм... нефтьчеләргә нәрсә булса да эшләп бирүдән баш тарттылар!

Әлбәттә, нефтьчеләр мондый хәлне һич көтмәгән иде. Мондый уңышсызлык йомшаграк-җебегәнрәк кешеләрне аяктан егар, өметсезлеккә салыр иде. Әмма Ринат Галиев "егылмады", ул, җөмһүрият җитәкчеләренә ниятенең барып чыкмаганын кыска һәм төгәл генә җиткерде дә, озын-озакка сузмыйча, нәкъ шул ук тәкъдиме белән Ижау машина төзүчеләренә мөрәҗәгать итте. Әйтәсе дә юк, бик тә тәвәккәл адым иде бу. Татарстанында эшсезлек арта барганда, чит республикага эш тәкъдим ит әле! Әмма Ринат Галиев шунысын да бик яхшы аңлый иде: Татарстан икътисадының умыртка баганасы булган нефть сәнәгатен ничек кенә булса да саклап калырга кирәк. Һәм ул оттырмады— "Татнефть" бар, эшли, яши!

* * *

Ринат Галиевнең гадәти эш көне 14-15 сәгатькә сузыла. Инде кая да булса барып кайтасы көннәренә,—әйтик, Казанга йә Мәскәүгә,— янә дә бер ике-өч сәгатьне өстәргә кирәктер.

Күрәсең, ата-бабаларыннан күчкән авыл гадәтедер—Ринат Галиев таң белән торырга күнеккән. Ул инде иртәнге бишто—аяк өстендә: салкын суда коенып-юынып, хәләл җәфәте Гасимә ханым әзерләгән ризыкны тиз-тиз генә капкалап алыр да, рәхмәтен әйтеп, эшенә ашыгыр. Кичке караңгыга кадәр. Еш кына берничә көнгә ераккарак та сәфәр чыгарга туры килә.

Аның көнлек эш сәгатьләре минутына кадәр кичтән үк исәпләп куелган: кемнәр белән очрашасы-сөйләшәсе, нинди кичектергесез чаралар күрәсе бар—һәммәсе минутына кадәр билгеле. Көнлек расписаниесеннән тыш атналыгы, айлыгы да мөмкин кадәр төгәлрәк итеп төзеп куелган. Әле болардан башка тагын еллык һәм берничә еллык стратегик программалар да тәгаенләнгән булыр. Һәм, ниһаять, Ринат Галиевнең хәтта мендәренә дә ышанып сөйләми торган хыяллары-серләре, уй-хисләре дә бар әле.

Промыселларда көн дә нинди дә булса яңалыклар булып кына тора. Әнә, тагын бер катламны эшкәртә башлаганнар. Менә беренче нефть эшкәртү заводын сафка бастырганнар. Ул арада чит ил инвесторлары килеп җиткән, алар белән очрашасы-әңгәмәләшәсе, күрсәтәсен күрсәтеп йөрисе бар: бәлки, ышаныч казанып булыр, кабынып китәрләр, хезмәттәшлек итә башларга теләрләр.

Нефть—ул җир асты хәзинәсен алу гына түгел. Ринат Галиев өчен нефть—бу төбәкләрдәге халыкның барлык көнкүреше, яшәеше. Шулай булгач, нефтьчеләр тырышлыгы белән кечкенә генә татар авылы Кичүчатта атаклы мәгърифәтче мулла һәм галим Риза Фәхретдингә музей, йә булмаса Әлмәттә татар гимназиясе, чуаш авылы Суркинода милли чуаш мәктәбе, "Победа" бистәсендә урыс мәктәбе ачыла икән—ничек итеп аларга бармыйча, бер-ике авыз җылы сүз әйтми калырга мөмкин? Әлмәттә яшәп, шигырьләрен һәм йөрәген нефтьчеләргә калдырып фани дөньядан киткән шагыйрә Саҗидә Сөләймановага һәйкәл куелу үзе бер зур вакыйга түгелмени?

Нефть генералы Ринат Галиевнең әле бит "кәгазь боткасын да ашыйсы бар"! Мин, мәсәлән, юри генә бу "ботканың" 1995 елгысын исәпләп караган идем. Болай килеп чыкты: Ринат Галиев шәхсән үзе укып-карап хәл итәргә тиешле кәгазьләр елына 1310 булган икән. Шуларның 120 се—Татарстан Президенты указлары, Министрлар кабинеты карарлары-күрсәтмәләре. Россия министрлыгыннан—60 фәрман-боерык.

"Роснефть" концернынннан, республикабызның Дәүләт Советыннан, төрле административ оешмалардан янә 300 фәрман, карар, күрсәтмәләр. Боларны укып-карап чыгу гына җитми, ә үтәргә, башкарып чыгарга да кирәк бит әле. Болардан тыш тагын һәртөрле түрәләрдән—өстән төшкән бихисап кәгазьләр...

Менә шулай җыела ул "кәгазь боткасы"! Ринат Галиевнең эш көннәреннән бәйрәм-ял көннәрен, читкә чыгып йөргәннәрен—җәмгысе 96 көнне чигерсәк, 220 көне кала. Димәк, генерал һәр көнне,—һәр минуты тыгызлап-дыңгычлап эш белән тутырылган һәр көнне!—әле алтышар эш кәгазе белән дә танышырга, аларны хәл итәргә тиеш. Дөрес, арада бик кыска язылганнары да бар ул кәгазьләрнең. Ә бар дилбегә буедай озыннары да, берәр аспирантның диссертациясе шикелле калын, күңелсезләре дә.

Боларга радио-телевидение, газет-журналлар аша кергән мәгълүматларны да өстик тә, үз хезмәткәрләре ирештереп торган көнлек яңалыкларны кушыйк. Штабның бер бурычы һәр урында эшне яхшы итеп оештыру, генераль директорны вак-төякләр белән борчымыйча, аңа тәүлеклек нефть алуның торышын кыска гына итеп җиткерү булса, икенче бурычы—һәр тармакның, һәр идарәнең эшчәнлеген, хәл-әхвәлен аңа үз вакытында ирештерү, Россиянең башка нефть төбәкләрендәге хәлләр ничек, "кара алтын"га дөнья базарындагы бәяләр нишли, алга таба нәрсә көтәргә—ул бәяләр күтәрелерме-төшәрме?—барысын да фаразлап бирергә кирәк.

Мин Ринат Галиевнең чит илләргә чыгып йөрүләрен дә исәпләп-санап карадым: Америкага, Канадага, Германиягә, Англиягә, Мисырга, Иранга, Гыйракка, Сәгуд Гарәбстанына, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә һ.б. һ.б.—һәр өч эш көненең берсе шул сәфәрләрдә үткән!Һәр өч көннең берсен "Татнефть" генерал күзеннән башка да гадәттәгечә эшләп тора. Чөнки шулай көйләнгән, әйбәт, сау-сәламәт организм ул "Татнефть"!

Шулай итеп, елның йөз көне ерак сәфәрләрдә, йөз көне нефть промыселларында, Татарстан шәһәрләрендә йөреп үтә Ринат Галиевнең. Ә калган йөз көне—эш кабинетында. Эштән соң, өйгә кайткач, тагын эш! Көн азагында аның кулына: "Галеев. Домашнее задание" дип урысча язылган зәңгәр тышлы папка тоттыралар. Нефть генералы кичләрен шул папкага салынган кәгазьләрне укып, янә кичектергесез мәсьәләләрне хәл итеп утыра.

Бер көнне, җай чыгып, ул папканы миңа да актарып карарга туры килде. Шактый калын, саллы иде ул. Укучыны ялыктырмас өчен андагы кәгазьләрнең эчтәлегенә тукталып тормыйм, шуны гына әйтә алам: аларны йөгертеп укып чыгу өчен генә дә берничә сәгать вакыт сарыф итәргә кирәк. Һәр кәгазь кирәкле, һәркайсы мөһим. Аларны укып чыгу гына җитми бит әле. Уйланырга, баш ватарга, хәл кылырга да тиеш син.

Менә шундый ул нефть генералы Ринат Галиевнең эштән соңгы бер киче!

* * *

Гадәттәге ыгы-зыгылы эш атнасына күңелле ыгы-зыгылар—бәйрәм хисләре дә килеп кушылган иде. Ул атнаның бер-ике көнен шәрехләп күрсәтсәм, үзегез дә аңларсыз.

Менә пәнҗешәмбе.

Иртәнге якта бер-бер артлы ике яңа мәктәп ачу тантанасында булырга кирәк иде Ринат Галиевкә. Һәр ике мәктәп тә, әлбәттә, нефтьчеләр акчасына салынган. Бу тантанага авылларның олысы-кечесе җыелган. Нефть генералы кызыл тасмаларны кисеп, кыска гына, әмма бик матур, мәгънәле сүзләр әйтә. "Буш мәктәп—шул ук эшләми

утырган буш скважина ул,"—ди генерал. Ир-атлар хуплап көлеп җибәрәләр, тырышырбыз, янәсе! Хатын-кызларның да күзләрендә шаян очкыннар кабына, алар сиздермичәрәк кенә татлы елмаеп куялар: ирләр тырышса, бездән эш калмас анысы, диюләре.

Ул арада төш тә җиткән икән. Аяк өсте генә бер-ике пәрәмәч капкалап, берәр чынаяк чәй эчеп алгач, Ринат Галиевнең "джипы" янә юлга чыкты. Сөгать өчкә Баулыга барып җитәргә кирәк иде. Ара—йөз чакрым. Нәкъ менә Баулыда илле ел элек беренче девон нефте ачылган иде—1946 елның сентябре иде ул. Бүген әнә шул легендар скважина янына ветераннар—"җир мае"на төүге юл ачучылар җыела. Исән калганнары... Атаклы Ромашкино нефть ятмаларының чишмә башына тиң булган скважина бу.

Әлбәттә, "Татнефть" генераль директорының эшләре болай да муеннан. Бирегә ул үзенең җиде урынбасарының берсен җибәреп тә котыла алган булыр иде. Әмма халык белән, үз эшчеләре белән күзгә-күз очрашу, сөйләшү-фикерләшү Ринат Галиев өчен изге бер гамәл ул.

Кичке якта мин генерал "джипы"ның спидометрына күз салдым: 320 километрны әйләндергәнбез икән. Аз түгел бит!

Ә җомга көнне нефтьчеләр башкаласы Әлмәттә яңа татар гимназиясен ачу тантанасы булды. Гимназия гаять зур—700 укучыга исәпләнгән. Йөзү бассейны, ике спорт залы, махсус компьютер класслары бар. Балалар дүрт тел өйрәнәчәкләр: татар, урыс, гарәп һәм инглиз телләре.

Аннары көн уртасында яңа медицина үзәге ачу тантанасы иде. Монысы турында аерым тукталып сөйләргә кирәктер.

Күпкатлы биек бу бинаның эчендә нинди кабинетлар, лабораторияләр, медицина җиһазлары барын шуннан аңларсыз: йөрәк-кан тамырлары хирургиясенең "алласы" булган америкалы табиб Майкл Дебейкиның Техас штатындагы Хьюстон шәһәрендә нинди атаклы клиникасы-хастаханәсе булса, Әлмәттәге яңа медицина үзәге дә нәкъ шулай җиһазландырылган, аннан һич тә кайтыш түгелдер.

Ничек итеп бөек кардиохирург Майкл Дебейки Татарстан нефтьчеләре белән бәйләнешкә кергән соң әле? Ничек итеп Әлмәттә әкияттәй бу үзәк пәйда булган?

... Ринат Галиев һәм аның командасы Хьюстон шәһәренә нефть эше өчен кирәкле җиһазлар юнәтү максатыннан барып чыккан иде. Америкада эшлекле кешеләрне яраталар. Безнең нефтьчеләребезгә үз мөмкинлекләрен ачып, конструкторлык бюроларын, төрле машиналар-аппаратлар җыю конвейерларын, "үле" скважиналарны "терелтә" ала торган химик чараларны һ.б. һ.б. күрсәтәләр. Аннары, шәһәребезнең башка күренекле урыннары да бар әле диптер инде, кунакларны шул атаклы Майкл Дебейкиның кардиологик клиникасына алып баралар.

Хәзерге кардиохирургиянең "алласы", туксан яшьлек Майкл Дебейки кунакларны клиникасының ишек төбендә үк каршы ала. Баксаң, бу хуҗа үзе түгел, аның бронза һәйкәле икән! Хуҗа нефтьчеләрне үзенең эш бүлмәсендә кабул итә.

Ринат Галиев биредә күргәннәрен үзләренең хастаханәләре белән чагыштырып, уйланып йөри. Әлбәттә, нефтьчеләр дә төшеп калганнардан түгел: аларның үз поликлиникасы, үз хастаханәсе, дистә ярым шифаханә-профилакторийлары бар. Табиблары да яхшы белгечләр. Әйтик, оста табибә Хәмдия Гарифуллинаның бер кешенең кисеп алынган борынын тегеп куюы үзе генә дә ни тора! Ә шулай да, шулай да...

Ринат Галиев тәвәккәлләргә була. Ул Майкл Дебейкиның һәр сүзен сеңдереп йөри-йөри дә, соңыннан аңардан нефтьчеләргә шушындый медицина үзәге салу нинди бәһагә төшәр икәнлеген сорый. Бәһасе, әлбәттә, зурдан буласы икән—25 миллион доллар! Димәк, шуңа бәрабәр нефтьне артыграк чыгарырга һәм сатарга кирәк булачак. Әмма генераль директор куркып калмый. "Әгәр без шундый зур эшкә

тотынсак, Майкл әфәнде ярдәм итәргә алынмасмы икән?"—дип сорый. Нәрсә беләнме? Әйтик, киңәшләре белән. Һәм... могҗиза! Майкл Дебейки ризалык бирә бит!

Һәм менә—мәһабәт клиника бинасы безнең күз алдында, Әлмәт шәһәрендә!

Егерме биш миллион долларны, нефть чыгарып һәм аны сатып, табарга да була. Әмма аны әллә нинди клиника салу өчен исраф итәргә нефть генералының да хакы юк. Нефтеңне чыгар, сат, дәүләткә табыш бир—менә синең төп бурычың!

Бу медицина үзәгенең нинди кыенлыклар белән төзелүе турында аерым бер китап язарга кирәк булыр иде. Бары тик шуны гына әйтә алабыз: клиника бар! Хәзер нефть төбәгендә яшәүчеләр, сәламәтлекләренә бер-бер хәл була калганда: "Дебейкига барам әле!"—дип кенә җибәрәләр. Бу клиникада 570 белгеч эшли. Алар авыруларны нәкъ Майкл Дебейкиның Хьюстондагы клиникасындагы ысуллар белән дәвалыйлар.

Клиниканың беренче чираты гына да 96 миллиард сумга төшкән. Гадәттә җиһазландыруга чыгымнарның 25% ы тотыла, ә биредә 75% лык җиһаз кайтартканнар.

Халык яхшыга тиз күнегә шул. Әллә кая, диңгез артларына барып йөрисе юк, "Дебейки клиникасы" Әлмәтнең үзендә хәзер!

* * *

Нефть генералы Ринат Галиевнең эш-гамәлләре турында сөйләгәндә аптырап калган чакларым да булды. Әллә янә бер көн эчендә нефтьчеләрнең өч зур вакыйгага шаһит булулары—промыселларга Президентыбыз Минтимер Шәймиев тә килгән көн турында сөйлисеме? Ул көнне башта яңа нефть эшкәртү заводын ачу тантанасы булды. Башка төбәкләргә ярты гасыр буе чи нефть җибәреп, күпме табыш югалтылган бит, ә хәзер моңа чик кую юлларын эзлиләр. Нотыклар сөйләнде, музыка уйнады, ал тасма киселде: бензин, солярка, төрле майлар үзебезнеке булачак!

Икенче вакыйга—Оренбур юлы өстендә финнар катнашында төзелгән бензин белән тәэмин итү станциясен ачу тантанасы иде. Анысын ничек телгә алмый каласың? Бу әле беренче станция. Алга таба Татарстан юлларының һәркайсында, аннары инде Россия һәм башка илләрдә дә шундый станцияләре булыр әле "Татнефть"нең!

Өченче тантана Кичүчат авылында Риза хәзрәт Фәхретдингә музей ачу булды. Йә, моны укучы белән уртаклашмый буламы соң? Нефть нефть инде ул, әле бит халыкның рухи байлыкларын сакларга да кирәк.

"Кара алтын" осталарының җәйге Сабан туйларыннан тыш кышкы Сабан туйлары да бар әле. Анысы да Ринат Галиев "җимеше".

Ә ат чабышлары?! Әйе, әйе, алары да бәйрәм төсендә уза. Менә шул ат чабышларының берсе тәмамлангач, Ринат Галиев ничектер ачылып китеп, миңа тулы бер нотык сөйләп ташлады. Болай диде ул:

—Кеше якты дөньяга кайгы-хәсрәтләр кичереп, михнәт күреп яшәргә килми. Ул тормыштан тәм табып, яшәвенә куанып, бәхетле булырга яратылган. Барысы да әйбәт, мул-имин, көйләнгән булганда, әлбәттә, яшәве җиңел-рәхәт. Әмма авырлыклар килгәндә дә, инде түзеп булмас дигәндә дә күңел төшермичә яши белергә, әле, Аллага шөкер, исән-сау мин дип куанырга кирәк. Без—нефтьчеләр үз һөнәребез белән горурланабыз, аның әһәмиятен аңлыйбыз: без булмасак, нефть булмаса, хәзерге заманда тормыш итүне күз алдына китерүе дә кыен. Әмма безнең көндәлек тормыш-көнкүрешебез, рухи таләпләребез бер нефтькә генә терәлеп калмаган бит. Кешегә тән азыгы өстенә җан азыгы да кирәк ич! Шуңа күрә, хезмәт ул җир астыннан "кара алтын" суырту,

мәгъдән кою, калалар төзү, юллар салу, иген игү һәм маллар үрчетү белән генә чикләнми. Болар барысы да, ахыр чиктә, шул ук кешеләр бәхете өчен эшләнә. Димәк, тормышны акыллы уйлап оештыра белү зарур: кешеләрнең көчә-җегәре хезмәт итәргә дә җитсен, күңелле ял итәргә хисләре-дәртләре дә ташып торсын! Хезмәт һәм ял—аерылгысыз юлдашлар. Ашар өчен яшәмибез, яшәр өчен ашыйбыз, диләрме әле? Дөрес, төрлечә яшәргә була: берәүләр хәләлме-хәраммы байлык туплый да, гомере буе шуны югалтудан куркып, кан калтырап яши, андыйларның төн йокылары кача; икенчеләре, бәйрәмнәрдән дә тәм таба алмыйча, һаман сыктап-сукранып гомер кичерә, андыйлар куана да белми; ә өченчеләре җир җимертеп эшли дә, гөрләтеп бәйрәм дә итә—тормышы түгәрәк! Гаиләсендә дә татулык, бәхет... Мин менә шундыйларны хөрмәт итәм. Бәлки, мин тирә-юнемдә күз яше булмасын, кешеләрнең бәхет-шатлыгы ташып торсын өчен яшимдер дә бу якты дөньяда, шуның өчен "җир мае" чыгарамдыр. Башкаларга куаныч китерә алмасаң, яшәп, көрәшеп тә торырга кирәкми, минемчә. Әлбәттә, тик торганнан сикергәләп, шаркылдап көлеп йөрү гайре табигый булыр иде. Халык бит тамашалар-бәйрәмнәрне алдагы көннәрдә тир түгеп эшләрлек көч-җегәр җыю өчен уйлап тапкан да инде. Бәйрәм итү хокукын хәләл хезмәтең белән яулап алырга да кирәк бит әле. Хәләл хезмәтең белән!

* * *

Хәләл хезмәтен илене-халкына багышлаган нефть генералы Ринат Галиевкә 1999 елның гыйнварында алтмыш яшь тулды. Димәк, рәсми сүзләр белән әйтсәк, лаеклы ялга да китәргә мөмкин аңа. Әмма, ай-һай, нефтьчеләре, нефть төбәгендә яшәүчеләрнең яше-карты Ринат Галиевне алай тиз генә җибәрерләрме икән әле? Узган елның җәендә аны яңадан "Татнефть" акционерлык җәмгыятенең генераль директоры итеп сайлап куюлары үзе күпне аңлатадыр.

Нефть генералы, җиденче генерал Ринат Галиевкә: "Генерал булу рәхәтме?"—дигән сорауны бирмәдем мин. Ул һаман да илгә-халыкка хезмәт итмәктә. Изге теләктә булыйк без аңа, хөрмәтле укучым!



## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Кешелек җәмгыяте өчен гаять мәгънәле дата—2000 нче ел якынлашып килә. Бу дата тормышыбызның төрле тармаклары турында җитди уйлануларга этәрә, үткән чорга нәтиҗәләр ясауны, киләчәк елларга күз салуны сорый.

Шул уңайдан "Казан утлары" журналы редакциясе язучыларга һәм киң катлам укучыларга, әдәбият сөючеләргә гасырыбызны йомгаклаучы туксанынчы еллар әдәбияты турында түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә:

**—Соңгы ун-унбиш елда басылган кайсы әсәрләрне (проза, поэзия, драматургия, публицистика) әдәбиятыбыз казанышы дип саныйсыз? Ни өчен?**

**—Сезнеңчә, туксанынчы еллар татар әдәбиятында нинди уңай сыйфатлар бар? Ә кайсы яклар Сезгә ошап җитми? Киләсе гасырга Сез кайсы әсәрләрне алып керер идегез һәм татар әдәбиятында нинди сыйфатларның өстенлек алуын теләр идегез?**

**—Әдипнең җәмгыятьтәге урынын киләсе гасырда ничек итеп күз алдына китерәсез?**

## Тәүфикъ Әйди:

Туган әдәбиятыбыз, милләтебез язмышының көзгесе буларак, табигый ки, заманыбызның кырыс чынбарлыгын чагылдырырга тырыша. Сиксәненче еллар ахырында, мәгълүм тарихи-иҗтимагый үзгәрешләр нәтиҗәсендә, аның сулышын буып, күзен томалап торган киртәләр какшый төште.

Әсир халыкның фаҗигале тормышын бар булганынча тулы канлы, оста һәм куркусыз чагылдырган әсәрләр бер-бер артлы әдәбият мәйданыбызга чыкты. Аларның бер өлеше ажгырып торган милли изү, рухи хөрриятне рәхимсез чикләү, җәмгыять үсешен ялгыш юлга кертеп җибәргән кара көчләрнең терроры шартларында язылган, әмма укучыга вакытында җиткерелә алмаган, яшереп тотылган иде. Нурихан Фәттахның "Кичү", Ибраһим Салаховның "Тайгак кичү", Гурий Тавлинның "Афәт" романнары нәкъ менә шундыйлардан булды. Тиздән аларга Мәхмүт Хәсәновнең "Язгы ажаган", Аяз Гыйләҗевнең "Балта кем кулында?" романнары өстәлде. Дөрес, аларның дөнья күрүе шушы ук эзлеклелектә генә бармады.

Бу әсәрләрнең беренче өчесе үзгәртеп кору дәвере башланганчы ук язылганлыгы, мине каләмдәшләрем өчен аеруча горурландыра—татар язучылары арасында нинди авыр чорда да намуслылар, кыю һәм тәвәккәлләр, замана саташтыруларына бирешмәүче фидаилар, "палач балтасына башны куеп" Моабит төрмәсендә генә түгел, совет "лагеренда" да иҗат итүче каһарманнар булган икән. "Казан утлары" журналында басылган бу әсәрләрнең байтагын редактор буларак укыганлыктан, авторларына хәлдән килгәнчә ярдәм дә күрсәткәнлектән, миңа аларның отышлы яклары ачык билгеле. Н. Фәттахның туган ягы (Янавыл төбәге) сөйләшен шагыйранә матур һәм төгәл чагылдыруы, баш каһарманының күңел дөньясын тирән һәм тәэсирле гәүдәләндерүе, А. Гыйләҗевнең ирония һәм сарказмны,

нәфрәт һәм кызгану хисләрен әсәре тукымасына оста сеңдерүе мине әле дә сокландыра. И. Салаховның әдәби осталыгы, тел байлыгы Фәттах һәм Гыйләжевнекеннән калышса да (миңа аның урысча язылган кайбер диалогларын тәржемә итеп бирергә туры килгән иде!), "Тайгак кичү"дәге вакыйгаларның кырыслыгы, образларның үзенчәлеге тормыштагыдай чын һәм калку ачылуы белән әсир итә. Турысын әйткәндә, Салахов әлеге әсәрен әүвәл җанын җәфалап, тир-кан түгеп, имгәнеп-яраланып, коточкыч шартларда гомере белән "язган", аннары гына шуны кәгазьгә төшергән иде. Романның зур уңышы—авторның җәһәннәм газапларыннан исән-аман котылып, үзендә тормыш хакыйкатен сәнгать хакыйкатенә әйләндерерлек көч табуында. Әйтергә кирәк, А. Гыйләҗев, Г. Тавлин да сталинчылар вәхшәтен бик мул татыган язучылар, шунлыктан аларның романнарыннан да җанлы тормыш сулышы бөркелеп тора.

Кыскасы, югарыда аталган әсәрләр, минемчә, туган әдәбиятыбызга чын хакыйкатьне кайтарды, катлаулы тормыш материалын сәнгатьчә үзләштерү ягыннан алга таба зур адым булды, бу исә башка әдипләребезгә дә сизелерлек йогынты ясады, таләпчәнлекне арттырды.

Соңгы ун-унбиш елда прозабыз М. Мәһдиев, Ә. Баянов, М. Юныс әсәрләре хисабына да бөтәйде, аларның һәркайсы укучыларның күңел дөньясын үзенчә баетты. Мәһдиев татар авылын, галимнәр дөньясын импрессионистик ысулда матур гәүдәләндерсә, Юныс чынбарлыкның яңа катламнарына, яңа географик һәм этник киңлекләренә иркен атлап керде, укучыларын милли аңлы фикер иясе итеп тәрбияләү хакына рухланып язды, Баянов исә Аурупа һәм Америка әдәбиятлары традициясендә символлар куллану, әдәби форманы, стильне төрләләндерү юлында эзләнүләр алып барды.

Инде күптән сыналган стильдә язу ышанычлы, гарантияле була. Тәҗрибәләр ясау кыюлык, зур әзерлек таләп итүдән тыш, еш кына абындырырга да мөмкин. Ә. Баянов прозабызда, яңа самолетларны сынаучы пилот кебек, язу палитрасын төрләләндерү, әдәбиятыбызны тагын да заманчалаштыру, иҗатта дөнья әдәбияты казанышларын кыюрак үзләштерү буенча әһәмиятле эш башкара. Шунысы кызганыч, аның бу фидакарь тырышлыгы, чын мәгънәсендә матур һәм үзенчәлекле повестьлар язуы нигәдер тиешенчә югары бәяләнми—Тукай бүләген, депутатлык-түрәлек терәүләренә таянып, иҗади яктан аңардан шактый калышкан әрсезләр алып тора. Заманында шундый лилипутлар "гулливер" Салих Батталны да типкедә йөрткән иде—шигъриятебездә әллә кайдан "мин—Баттал!" дип кычкырып торган әсәрләр калдырган шагыйрь, ышанам ки, кайбер лауреатлардан, әлбәттә, озаграк яшәр, әмма аны докладларда "һ.б." дип кенә телгә алган затларның оятсызлыгы барыбызга да кара күләгәсен төшерде. Бу хурлыкны тагын кабатламыйсы иде!

Әдәбиятыбызга яңа дәрман өстәүчеләр арасында Фоат Садриев, Айдар Хәлим, Марсель Галиев, Зөлфәт Хәким исемнәрен дә атыйсым килә. Садриевның "Адәм әүлиясе", Хәкимнең "Агымсуда ни булмас" повестьлары юмор-сатирабызны җанландырып җибәргән тансык әсәрләр. Галиевнең сурәтле фикер йөртүе, туган телнең тәмен тоеп иҗат итүе, Хәлимнең иҗтимагый хәрәкәтебезне рухландырып һәм азыкландырып торган сугышчан публицистикасын иҗат итүе сәламәт әдәбиятыбыз барлыгына дәлил.

Минемчә, гасырыбыз башында чын реалистик татар прозасы нигез ташларын Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимовлар салды, аларга Мәхмүт Галәү килеп кушылды. Коммунистик идеология терроры 1917 елдан соң татар әдәбиятын сәламәт үсештән мәхрүм иткәнлектән, байтак каләм ияләрен рухи сытып кына түгел, физик яктан да үтереп бетергәнлектән, әдәби дөньябызны болганчык нәрсәләр каплады. Табигый ки, бу дәвердә дә көчләүгә, диктатка карышырга тырышкан, аерым уңышлы әсәрләр иҗат иткән әдипләребез булды. Әмма иҗат өчен чын хөррият гасырыбыз ахырында гына ачыла башлады, шуның нәтиҗәсендә мәгълүм калыплардан, ясалмалыктан, ялганнан арынган әсәрләр заманы килде. Аларны башка телләргә дә оялмыйча тәржемә итәргә мөмкин.

Туксанынчы еллардагы әһәмиятле казанышыбыз—прозабызның күп буяулы, күп стильле булуы, иң яхшы әсәрләребезнең сәнгатьчә камиллеге, игътибарны җәлеп итәрлек образлар тудырылуы (Мисалга, А. Гыйләҗевнең "Яра" повесте).

Ә кимчелекләребез күпме соң? Бик күп! Минемчә, иң зур җитешсезлек—күп

сүзлелек. Без кино, телевидение гасырында яшәвебезгә, киләчәктә аларның тормышта тагын да зуррак урын биләячәгенә тиешенчә игътибар бирмибез. Көнбатыш әдәбиятларында күпчелек романнар 150-200 биткә калганчы югарды, ә без һаман 400-500 битле, хәтта аннан да калынрак "кирпечләр" сугабыз. Икенчесе—колоритлы зур шәхесләр образы иҗат ителмәве. Бөек әсәрләр шуннан башка барлыкка килми. Өченчесе—безнең әсәрләрдә кешенең физиологик көнкүреше артык зур урын алуы, фикер, фәлсәфә көрәше сыеклыгы. Дүртенчесе—персонажлар телен тиешенчә бирә алмавыбыз, яшьрәк буын иҗатчыларның әдәби теле тулаем фәкыйрьлеге. Бишенчесе—яшь прозаикларыбызның санаулы гына булуы һ.б.

Гасырыбыз татар прозасына тулаем күз салганда, анда һәм тема, һәм форма төрлелеге житәрлек бай булмавына да уфтанырга туры килә.

XXI йөздә әдәбиятыбыз хакыйкатьне ачудан бер карыш та читкә тайпылмасын иде. Безнең гасыр мирасыннан аермалы буларак, ул укучыларга милли тәрбия бирүне үзәккә куярга, бу юлда, әйтик, поляк әдәбиятыннан үрнәк алырга тиеш. Әгәр шуңа ирешми икән, ул үзен үлемгә хөкем итәчәк.

Әдәбиятыбызның киләчәге аның сыйфат ягыннан күтәрелүенә бәйләнгән. Әгәр ул башка әдәбиятлар белән ярышырлык дәрәҗәдә булмаса, тиз арада укучыларын югалтып бетерәчәк, чөнки татар хәзер кимендә ике телне иркен белә. Аның сайлап уку мөмкинлеге киң.

Сыйфат сикереше өчен исә туган әдәбиятыбызның иң яхшы үрнәкләре белән мәктәп дәверендә үк танышу, бер үк вакытта дөнья әдәбияты җәүһәрләре белән дә азыклану шарт. Тоталитар совет режимы безгә чит ил әдәбиятларын да идеологик иләктән иләп кенә укытты, бу хәл исә безне чын кыйммәтләрнең байтагын күрми-белми яшәргә хөкем итте. Мисалга, Ф. Кафка, К. Һамсун, М. Пруст, Джойс һәм бүтән зур язучылар күләгәдә калдырылды, Т. Драйзер, Р. Роллан, С. Льюис, Хемингуэй, Стейнбек, Голсуорси кебекләр чамасыз күпертелеп тәкъдим ителде. Язучы булырга җыенган яшьләребезнең дөньякүләм танылган бөек язучыларның әсәрләре белән мөмкин кадәр яшьрәк чакта туган телебездә яки асыл нөсхәдә танышулары зарур. Моның өчен аларның студент дәверендә үк Париж, Берлин, Лондон кебек үзәкләрдә кайнап алуын Татарстан хөкүмәте кайгыртырга тиеш. Анда милләткә әллә ни бирмәячәк бай балалары укып маташкан шартларда, минем бу фикерем берәүгә дә "мөгез чыгару" тоелмасын. Менә шундый тыгыз аралашу булмау, телләр белмәү аркасында, татар язучылары дөнья әдәби процессында күзгә күренми, үз кабыгына бикләнгән хәлдәрәк гомер итә. Шунлыктан алар Көнбатыш әдәбиятлары үсешеннән 40-50 елга калышып яши, язганнары Көнбатыш өчен генә түгел, (анда инде без хәзер күтәрә торган мәсьәләләрне әллә чәйнәп туйганнар!), зирәк татар укучысы өчен дә кызыгын югалткан була. Калышу аермасын киметү әдәбиятыбыз үсешен, аның йогынтысын саклау өчен хәлиткеч әһәмияткә ия. Моның өчен исә дөнья әдәбияты җәүһәрләрен елдамрак тәрҗемә итеп бастырырга, яшь язучыларыбызга чит телләр үзләштерүдә булышырга кирәк. Шул очракта әдәбиятыбыз психологик тирәнлеккә, фикри байлыкка, теләсә кайсы теманы камил яктыртуга тизрәк ирешер.

Татарның куәтле сүз сәнгате үссен өчен, язучының хакимияткә, акча капчыгына бәйсез, намуслы һәм куркусыз булуы, күпчелек мәнфәгатен яклавы шарт. Моның өчен аның көч-куәте физиологик яшәешен тәэмин итүгә китеп бетмәве зарур. Тик якын елларда язучы булырга теләгән татар баласына моңа ирешү ихтималы бик үк күренми. Әгәр Татарстанда әдәбият, сәнгать, фән үсешенә мөнәсәбәт үзгәрмәсә, ярдәм артмаса, безнең әле бүген ирешкән югарылыктан да түбән тәгәрәвебез мөмкин. Җитәкчеләрнең нинди "кабул итү"ләрендә мәдәниятне үстерү хакында төче сүзләр, юмарт вәгъдәләр янгырый, гамәлдә исә хәл көннән-көн начарлана бара. Түрәләргә куштанланырга түгел, аларның икейөзлелеген, вак җанлылыгын, бурлыгын фаш итәргә, киләчәк буыннарга аларның күңел кайтаргыч образларын гәүдәләндереп калдырырга кирәк!

Милләтне аның әдәбияты, сәнгате, гыйльми казанышлары күтәрә. Әгәр Татарстан җитәкчелегенә киләчәктә шуны аңларлык затлар килсә, әдәбиятыбыз да көчәеп китәр. Һәрхәлдә халкыбыз шуңа мохтаҗ, ул моңа ирешми калмас, дип өметләник.

## Рафаэль Сибат:

1. Соңгы елларда басылган әсәрләрдән шәхсән үзем Мөхәммәт Мәһдиевнең повесть һәм язмаларын, Аяз Гыйләҗевның "Йәгез, бер дога" романын, Гариф Ахуновның Тимерхан турында әдәби-документаль повестьларын, Фоат Садриевның "Таң җиле" романын, Тәбриз Мөбәрәковның "Хәтер аланы" повесть-кыйссасын, Ринат Мөхәммәдиевның "Утлы таба өстендә" дигән репортаж-хроникасын, Марсель Гали эсселарын, Зөлфәт Хәкимнең "Гөнаһ" романын әдәбиятыбызның казанышы дип саныйм.

Боларга Миргазыян Юныс, Зәки Зәйнуллин, Шәүкәт Галиев каләменнән төшкән иҗат чагылышларын да өстәү—дөреслеккә хилафлык булмастыр дим.

Яшьрәклрдән Факил Әмәк, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Ләис Зөлкарнәй, Зиннур Хөснияр, Равил Сабыр, Мансур Шаһимәрдән, һичшиксез, кызыклы каләм әһелләре һәм аларга зур өметләр баглыйм. Әле, минемчә, алар төркеменә Илфак Шиһапов дигән юморист та килеп кушылды. Юмор дигән бик тә четерекле жанрның тәмен беләә, каләме үткен, язганнарыннан шаянлык-җорлык очкын булып чәчри, әйтер сүзе бар һәм ул сүз—үз урынында. Шушында бер лирик чигенеш ясыйк әле. Аксакалларыбыз—90 яшьлек Әмирхан Еники, йөзьяшәр Гомәр Бәширов бу—олуг әдипләр исемен атамау үзе үк әдәпсезлек булыр иде. Алар—тере классиклар...

Мөхәммәт Мәһдиев... Соңгы елларда авыл татарының җанын чын һәм төгәл ачуда аның кадәр җентекләп, барлык әдәби нечкәлекләргә ирешеп яза алган тагы берәр прозаик булды микән? Андагы моңсу юмор, сагышлы лиризм—бер Мәһдиевнеке генә. Башкалар алай язмый, дөресрәге—яза да алмый.

Мәһдиевнең әдәби быргысы кисәтеп килде: хәзер чын мәгънәсендә саф татар авылларда гына калып бара. Ләкин...

Аларда да татарлык коелган-уңган, милли аң үтерелгән, горур баш идерелгән. Бигрәк тә бу яшь буында сизелә. Авылны һәм аларны эчкечелек басып киткән, һәр нәрсәгә битарафлык чолгап алган. Үз культураңны санламыйча, читнекенә иярү, туган телеңә илтифатсызлык, чын милли тарихны белмәү—менә татар деградациясенең кайбер билгеләре. Бу бит һәлакәт үк булмаса да, фәлакәт! Милли инкыйразга илкүләм бару. Гаяз Исхакыйдан соң Мөхәммәт Мәһдиев беренчеләрдән булып (әле партия, "социализм шартларында" "совет халкы" әмәлләп маташканда) әнә шулай кисәтүле чаң сукты.

Аяз Гыйләҗев... Тормышның төпләрен күргән, ачысын-төчесен татыган, күп авырлыкларны үз башыннан кичергән әдип. "Язгы кәрваннар" повестында гыйбрәтле бер күренештә—симәнә орлыгы ташучы ике төркем очрашуда—системаның череклеген күп еллар элек ачып салган язучы.

Соңгы елларда язылган "Йәгез, бер дога" романын шәхсән үзем шушы прозаикның да, әдәбиятыбызның да зур казанышы дип саныйм. Төрмә—илнең кечерәйтелгән моделе ул, ватанда ни бара, төрмәдә дә шул. Вакыт-вакыт натурализмга җиткән сурәтләүләр, кискен вә ачы реаль кырыслык, рәнҗетелүләргә корылган тормыш һәм... Һәм төрмә шартларында да кешенең чын-горур кеше булып кала алуы, саф мәхәббәт, дуслык хисләре. Әле тагын зарланмау. Әйе, зар елап язмышыңны каргап утырмау. Гинзбург, Шаламов, Аксенов, үзебезнең Ибраһим Салахов язганнарда ул зар әсәр тукымасына кыерсытылу мотивы булып кергән, укучы аны сизә, күңеле белән тоя, ә Гыйләҗевта—юк!

Романның беренче җөмләсен генә искә төшерик:

—И-и, төрмәнең сөенечле мизгелләре! —Бу җөмләне язар яисә әйтер өчен олуг талант кына җитми, титан рухлы, кояш җанлы, галәмдәй иксез-чиксез күңелгә ия, тормышны вә яшәүне яратучан, дөньяга гашыйк инсан булу кирәк.

Гариф Ахунов... Инде сигезенче дистәсен ваклап килсә дә, ифрат җор җанлы, тормышчан, оптимист кеше. Язучылар арасында шундый аксакал булу—әдәбиятыбызның аклыгына да даими ишарә ул. Моңа аның иҗат энергиясен, көйләнгән автомат кебек, төрле жанрларда бертуктаусыз актив иҗат итүен искә төшерсәк, "Язучы—язарга тиеш!"—дигән тәгъбир канатлы күбәләк булып җаныңа, йөрәк түренә кунар.

Әлеге автор мине күп еллар элек "Чикләвек төше" повесте белән әсир иткән иде. Кыска гына, китапта 60 битле генә, әсәр. Ә тыгызлык, матурлык, кеше

күңелен ачу!? Аннан ул эпик планда язылган “Идел кызы” романы белән күңелне яулады.

Прозаик Ахуновның әсәргә материалны тормышның үзеннән күрәп алганы күренеп тора. Бу турыда аның “Ардуан батыр”ы һәм йөзләрчә очерклары үзе үк сөйли ич. Бездә бер алама фикер яшәп килә:

—Имеш, язучылар “модный тема”ларга ияреп, партия кушканга ләббәйкә диеп, нефть чыгару, КамАЗ төзелеше турында әсәрләр яздылар. Соң Әлмәттә нефть чыгармасалар, “Хәзинә” романы да тумас иде, шәһәр дә төзекләндерелмәс, асфальт юллар да салынмас иде. Тормыш нинди—язучы шуны күрсәтә.

Күпкырлы талант иясе, киң колачлы әдип Гариф Ахунов соңгы елларда Тимерхан турында гади генә язылган повестьлары белән күңелгә керде. Нигәдер, шундый публицистик рухтагы, бернинди шомартуларсыз язылган әсәрләргә күңел тарта башлады. Автобиографик яисә биографик, документаль алымда булсыннар—барыбер ошыйлар. Әхсән Баяновның “Су өсләрендә пароход”ын гына искә төшерик.

Фоат Садриев... Аның “Таң җиле” романы күңелләрне хушландырып исте. Язучының монда иң зур казанышы вә укучы алдында отышы—Ана образы. Дөрес, безнең әдәбиятта Изге Карчык, Акъәби, Ана, Җир-Ана образлары юк түгел. Әле Ак сихерчеләр дә бар. Мәсәлән, Нәбирә Гыйматдиновада. Инде Акъәбигә килсәк, аның иң матур вә бөек үрнәген “Әйтелмәгән васыять”тә Әмирхан Еники бирде. Ул хәзер дә әдәбиятыбызда өлге-образ булып тора. Гомумән, тәркиләр Ананы изгеләштерергә яраталар. Хатын-кызны да... Көнбатышта гына ул күбрәк секс, порно иясе.

Әдәбиятта булган Ана роленә Фоат Садриев ни алып килде, нәрсә өстәде соң? Ул да Нуриасманы шактый ук изгеләштереп бирә, ләкин аның “Ана”сы җиргә бик якын. Үзеннән балаларына милләтебезнең гореф-гадәтләрен, йолаларын калдырырга тырыша, иман-дан турында кайгырта, аналарның үз балаларын төрле юньсезлекләрен, яманлыктан кисәтеп, саклап торырга тиешлеген аңлап эш итә. Әлеге образ чын мәгънәсендә “татар хатыны” дигән зур төшенчәгә ия.

Тәбриз Мөбәрәков... Әдәбиятта берданбер күләмле әсәр белән чыгыш ясаган әдип “Хәтер аланы” повестын сызык аша “кыйсса” дип атавы да әсәрнең сулышына ниндидер сер, сихер, тылсым керткәндәй була. Әсәрдә кеше кадере идеясен, саф хисләр олылыгын җырлый автор. Унике яшьлек Тәүфыйк, Галимә белән Шура образлары да шушы уй-фикерләргә хезмәт итә.

Матур әсәр! Теле белән дә, сизелеп торган җылылыгы белән дә, яктылыгы белән дә...

Тәлгат Галиуллин... Әдәбиятыбызда тәүге әсәрләре белән үз урынын алган, беренче тапкыр татар мафиозларын (татар-урыс дисәң дә була) тормышчан вә ышандырырлык итеп күрсәткән әдип. Теле дә бай. Бары өсле-аслы эпитетларны киметергә дә, озын-озын җөмләләрне генә сирәгәйтергә кирәк. Чын бөеклек—һәрвакыт гадилектә!

Ринат Мөхәммәдиев... Үзенең Гыйлемханы, “кенәриләр”е, Солтангалиев турындагы романы белән зур популярлык алган прозаик. Ә инде “Утлы таба өстендә”—аның бүгенге көндә чын мәгънәсендә иҗат апогее. Мин аны бер мәшһүр әсәргә ымлап, ишарә ясап, “Репортаж с петлей на шее” дип атар идем. Ак Йортларны да Кара Сөрем басарга мөмкин. Әсәрдә шул Олуг Киная ята...

Марсель Гали... Эсселар остасы. Телнең бөтен үзенчәлекләрен, тәмен-ямен, нәфислеген, сыгылмалыгын, гүзәллеген, бөеклеген белеп яза. Бу язучыны гади укучыларга гына түгел, әдипләрнең үзләренә дә кабат-кабат укырга кирәк. Шәхсән үзем, мәсәлән, соңгы бер-ике елда гына да аның “Догалы еллар”ын ике (!) тапкыр укыдым инде. Чөнки... Әйе! Укыла Марсель Гали!!

Зөлфәт Хәким... Әдәбиятыбызның өмете, яшьрәкләрдән иң-иң талантлыларның берсе. Анда тирән психологизмны, Кафка сулышын ачык тоясың. Гөнаһ кылу—яманлык, ләкин кешегә Тәүбәгә килергә юл калдырылган. Пычрангансың икән, Чистарын! “Гөнаһ” романындагы эчке идея, бәреп торган көй-мотивлар әнә шулар. Бу—дөньяви, Галәмкүләм Идея, Иң Олуг Мәгънә.

Миргазыян Юныс—әдәбиятыбызга диңгез сулышы өргән язучы, анда миллилелек бик көчле.

Зәки Зәйнуллин—гомерен бер зур роман иҗат итүгә багышлаган элеккеге

полковник. Кыска-ачык җөмләләр, хәрби тәртипкә охшаган сюжет. Аның әсәрләрендә дә (алыйк "Идел"дә чыккан "Атом полигон"ын) милли хисләр, милли аң көчле.

Шәүкәт Галиев үзенең "Минем беренче гомерем" белән авыл халкына, ата-анасына, әби-бабаларына прозада мәдхия укыды. Онытмаска иде:

—Татарлык, милли хисләр, милли аң беркайдан да түгел, ата-ана, әби-бабайлар тәрбиясеннән килә. Шаян-җор телле, ачык фикерле әдип шуны тоеп язган.

2. Татар әдәбиятында уңай сыйфатлар:

—Әдипләребездә хәзер миллилек бик нык чагыла. Татарлык, Татар Идеясен күтәрү омтылышлары бар;

—Тарихи әсәрләр күп языла башлады. Монда Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Җәмит Рәхимов, Рабит Батулла, Флүс Латыйфи, Вахит Имамов исемнәрен генә дә атау житәдер дип уйлыйм.

—Тормыш дигән Олуг Бинаның парад ишекләреннән генә кереп, "нык алга киткән социализм"га мәдхия яудырулар бетте. Хәзер язучылар арткы-бикле-кара ишекләрдән кереп, подвалларны, притоннарны, чүплекләрне дә төшеп карый алалар, ә бит бу чын дөреслекне язуга нык якынаю дигән сүз. Ни генә димә, Максим Горькийның "Тормыш төбендә" ("На дне") драмасы ил буенча трагедиягә әверелеп бара ич;

—Әдәбиятыбызда омтимизм, Кеше Көченә ышану, Матурлык—яхшылыкка чакыру яшәп килә. Болар—бик матур, гуманистик тенденцияләр;—Дөньякүләм проблемаларны яктыртуга Омтылыш, Космос, Галәм, Аллаһыны тоярга теләү дә—Жан-Рухның, Калеб-Күнелнең изге башлангычлары булып тора.

Ошап житмәгән яклар:

—Тезгеннән яисә тышаудан ычкындырылган ат бераз нишләргә белмичә як-ягына каранып тора. Ул әле үзенең иреккә—иркенлеккә чыкканын да тоймый-аңламый. Хәзер язучылар белән дә эш шулайрак. Ирек дәгъва кылып килсәләр дә, аны алгач, кулына бомба тоттырылган бәндә баласыдай, каушап калдылар;

—Кирәкме бу нәрсә? Куркыныч түгелме бу?? Чөнки болай яз, тегеләй яз дип, өйрәтеп торучылар булганда, өстендә бер җаваплылык та тоймыйча, басым-идеологиягә яраклаштырып язу рәхәт иде бит;

—Безнең әдәбиятка һаман әле кырыс тормыш дөреслеге, психологизм, ихласлылык, сөйләп чыгу түгел—сурәтләү (!) житешми;

—Оп-озын, кирпеч калынлыгындагы буш-сыек, хиссез романнар бетмәсә дә, һич югы нык кына кимесен иде. Алдагы гасыр—тагы да ныграк информация ташкыны ул, вакыт аз булачак, шуңа дилбегә буе, төче су тулган әсәрләрне укымаячаклар. Шәхсән үзем повесть 80, 100, 120 биттән, ә роман 150-200, 300 саннарыннан да артмаска тиеш дип саныйм. Дөрес, бик талантлы язылган әсәрләр өчен—укыганда—бу күләм азрак тоелырга да мөмкин;

Агач тел әдәбиятны яулый бара. Кая Галимҗан Ибраһимов, Марсель Галиләр теле? Татар теленең илаһилыгын, олуглыгын язучылар күрсәтмәсә, кем күрсәтер?!

Теләк:

—Киләсе гасырда әдәбиятта миллилек һәм тарихилык тагын да ныгысын иде. Кеше жанының иң тирән төпләренә төшеп эзләү тагы да көчәйсен иде. Жанрлар күплеген тоярга язсын, эстетик дәрәҗәсе югары булган әсәрләр күбәйсен һәм телгә булган сак караш, аңа изге күренеш итеп карау үзен бик нык сиздереп торсын иде. Мөхәммәт абый Мәһдиев үзенең бер хатында миңа: "Язучы көчле һәм өстен, үз көчен сизә торган кеше булырга тиеш", дип язган иде. Аның шушы фикере васыять рәвешендә барыбызның да аңына сеңсә, бер дә начар булмас иде кебек.

Әдип—әдәп иясе, тел сакчысы, милли трибунаның ораторы, Иман-дин, Матурлык-Яхшылык мөнбәренең вәгазьчесе, тормыш көзгесе, киләчәкне алдан күрүче пәйгамбәр ул. Менә аның җәмгыятьтәге иң чын вә дөрес урыны. Әгәр ул шушы урынын ташлый икән яисә кемнәргәдер, икенче бер төркемгә, социаль катлауга бирә калса—ул инде әдип түгел, ә гариn. Сүз Җан-Рух гариплеге турында бара. Димәк, мондый очракта язучы көчсез...

Кабат Мәһдиевкә кайтыйк. Аның сүзләре колак төбемдә гел яңгырап тора:

—Язучы көчле һәм өстен...

*Әдәбият тарихы*

# СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВ ҺӘМ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

Сәгыйть Рәмиевнең Гаяз Исхакый белән тәүге очрашуы 1902 елның көзендә "Мәдрәсәи Хөсәения"дә була. С. Рәмиев мәдрәсәне тәмамлар алдыннан Г. Исхакый, Татарская Учительская школаны бетереп, бирегә мөгаллим булып килә.

Г. Исхакый, мәдрәсәгә килү белән, аны үзгәртергә керешә. Бу хакта Сәгыйть Рәмиев һәм Габдрахман Хөсәенов Г. Исхакыйның 1907 елда чыккан "Зиндан" китабына кереш мәкаләдә язып чыгалар. Моңарчы "хакыйкатьне күңелләрендә яшереп" йөргән мөгаллимнәрдән Гаяз әфәнде "хакыйкатьне хакыйкать көенә сорый башлый" һәм шәкертләр тормышының төрле өлкәләрен үзгәртергә тотына. Моңа җавап рәвешендә С. Рәмиев һәм башка шәкертләр "чын күңелдән Гаяз әфәндегә ихлас куялар" *(С. Рәмиев, Г. Хөсәенов. Мөхәммәтгаяз әфәнде.—Мирас.—№ 6.—1992.—Б. 28—33.)*. Шуннан соң Гаяз Исхакый шәкертләргә яңа фәннәр, яңа китаплар укытып, әдәбият ахшамнары ясап, рус театры белән дуслаштырырга омтылып, барысының да мәхәббәтен яулый. Г. Исхакый бу хакта үзе дә, инде эмиграциядә яшәгән вакытында "Шималь төрекләренең әдәбиятына бер караш" дигән хезмәтенең Сәгыйть Рәми иҗатына багышланган өлешендә болай дип язып үтә: **"Сәгыйть Рәми бу яңа хәрәкәткә кушылып китә һәм, яңа мөгаллимнең киңәшен тотып, урыс әдәбияты белән кызыксына башлый, урыс театрларына йөри торган булып китә, каләм тибрәтә башлый"**. Әмма "Хөсәения" хәлфәләре Г. Исхакый керткән яңалыклардан, аның шәкертләр тарафыннан сөелүеннән куркып, икенче елга Г. Исхакыйны китермәскә уйлыйлар һәм теләкләренә ирешәләр: 1903 елның көзенә ул инде "Мәдрәсәи Хөсәения"гә килми.

Шулай да Г. Исхакый өргән яңа сулыш мәдрәсә шәкертләренә һәм алдынгы карашлы мөгаллимнәренә үз тәэсирен ясаган була инде. Мәдрәсәне бүләкләү белән тәмамлап чыккач, С. Рәмиев биредә фарсы теле, геометрия һәм алгебра фәннәреннән мөгаллим итеп калдырыла. Ләкин мәдрәсә тәртипләре белән килешмичә, аларга каршы баш күтәреп, 1905 ел азакларында шәкертләр белән бергә мәдрәсәне ташлап чыга. Бу хәлне Г. Исхакый түбәндәгечә аңлата: **"Сәгыйть Рәми ... мәдрәсәдә күңеленә хуш килердәй эш таба алмый, тәкъдим ителгән имамлыктан баш тарта һәм әдәбият белән шөгыльләнә башлый"**. С. Рәмиевнең тормыш юлын һәм иҗатын җентекләп өйрәнгән галим Ш. Садретдинов та С. Рәмиевнең мәдрәсәне үз теләге белән, протест йөзеннән ташлап чыгуы турында яза. Икенче бер галимебез М. Гайнетдинов исә, Г. Исхакый да, С. Рәмиев тә "Хөсәения"дән хурлыклы рәвештә куылдылар дигән фикер әйтә.

С. Рәмиев бу чор вакыйгаларын 1907 елда язылып бетеп, 1908 елның февраль азакларында аерым китап булып басылып чыккан "Низамлы мәдрәсә" комедиясенә нигез итеп ала. Бу комедия хакында Г. Исхакыйның Пинегада сөргендә булган җиреннән (1908 елның март ае) рецензия язуы да очраклы түгел: "Низамлы мәдрәсә"дәге хәлләр аңа бик яхшы таныш, үз башыннан кичкән. "Мисалы да үз тормышымыздан, үз өемездән" алынганга күрә, Г. Исхакый бу әсәрне (пьесаны) "беренче татар көлкесе" исемен алырлык дип күрсәтә. *(Гаяз. Татар матбугаты. Низамлы мәдрәсә; (Сәгыйть Рәмиев.—Казан мөхбире. 1908, 24 март).*

1906 ел башында С. Рәмиев Казанга килә һәм "Таң йолдызы" газетасын чыгару хәстәрлегендә катнашып, аның беренче саннарыннан башлап хезмәт итәргә керешә. Әмма Гаяз Исхакый язуынча, Сәгыйть Рәмиев инде 1905 елда ук "революцион хәрәкәт башланыр-башланмас "таңчы"лар хәрәкәтенә кушыла, аларның Оренбург комитетының мөһим бер әгъзасы булып китә".

Замандашы, шагыйрь М. Укмасый "Сәгыйть Рәмиев иҗтимагый-сәяси көрәш

мәйданына журналист һәм публицист буларак килеп керә",—дип билгели. "Таң йолдызы" газетасының фактик житәкчесе, ана рух биреп торучы кеше Г. Исхакый була. Ләкин мөхәррирлек вазифаларын үз өстенә алырга мөмкинлеге булмау сәбәпле, газетаның рәсми мөхәррире һәм нашире башта М. Путиляков, аннары Ф. Туктаров һәм С. Рәмиев исәпләнәләр. Шулай итеп, 1906 елның 30 маенда С. Рәмиев "Таң йолдызы" газетасын бөтен күләмендә редакторлык итү жаваплылыгын үз өстенә ала. Революцион-демократик характердагы мәкаләләрендә ил, халык язмышы кебек зур мәсьәләләр күтәрә, трибунадан-трибунага, мәдрәсәдән-мәдрәсәгә барып, ялкынлы речьләр сөйли, үз имзасы, төрле псевдонимнар белән кайнар политик мәкаләләр яза, шигырьләрен бастыра.



*Сәгыйть Рәмиев «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте*

Әмма, озак та үтми, Г. Исхакый житәкләгән "Таң йолдызы" газетасын һәм аның жаваплы редакторы С. Рәмиевне эзәрлекли башлыйлар. С. Рәмиев берничә мәртәбә суд жаваплылыгына тартыла, 21 июльдә исә кулга алына: аз гына вакыт булса да бер кешелек төрмә камерасында утырып чыга. 1906 елның 5 августында цензор Н. Ашмарин газетаның 25 нче санын конфискацияли. С. Рәмиевне судка бирү турында сүз алып барыла. Шундый эзәрлекләүләргә карамастан, С. Рәмиев үзенең эшен дәвам итә. Хәтта яшәргә дә редакциягә күчеп килә. С. Рәмиев "жинаятен" тикшерү өч ай ярымга сузыла. Суд 1906 елның 1 ноябренә билгеләнә. "Таң йолдызы" газетасында (№ 60) "Казан хәбәрләре. Чәршәмбе" дигән баш астында 1 ноябрь көнне түбәндәге беллерү чыга: "Өченче көн 30нчы октябрьдә гәзитемезнең редакторы С. Рәмиевнең квартирында тентү булып, Сәгыйть әфәнде һәм гәзитемезнең беренче язучыларыннан һәм татарларның беренче мәшһүр мөхәррирләреннән Мөхәммәтгаяз Исхакый жәнаплары арестовать ителеп, төрмәгә ябып куйдылар. Сәгыйть әфәндене исә бераз тоткач та чыгардылар. Шуның өчен сишәмбе көн чыгачак номерымыз кичегеп бу көн чыкты". Гаяз Исхакый бу хакта үзенең "Зиндан" повестенда бик тәфсилләп яза. Качып йөргән вакытта көндезләрен Сәгыйть әфәнде фатирында мәкаләләр язып үткәргән, бер көн шулай Сәгыйть Рәмиевтә кунып калгач, тентүгә эләгә ("Сәгыйть әфәнденең фатиры безнең редакциямез хисапланганга") һәм аларның икесен дә кулга алалар. Билгеле булганча, Сәгыйть Рәмиевне тоткынлыкта озак тотмыйча, чыгаралар. Гаяз Исхакый моңа бик шат була: "Чөнки Сәгыйть "Таң"ның редакторы булганга, ул ябылу берлән газета туктала иде. Ул чыккач газета, соңга калса да, чыгачак иде" *(Г. Исхакый. Зиндан.— Казан, 1997).* Эзәрлекләүләр нәтиҗә-сендә, 16 ноябрьдә "Таң йолдызы" газетасының соңгы 65нче саны чыга һәм икенче көнне газета басыла торган И. Ермолаева типографиясе ябыла.

"Таң йолдызы"ның дәвамы буларак, Г. Исхакый идея житәкчелеге астында "Таң мәжмугасы" һәм "Тавыш" газеталары чыга башлыйлар. Ләкин аларның да гомерләре озын булмый. Гаяз Исхакый сөргенгә озатыла, башкалар да кайсы кая таралып бетәләр. Бары тик С. Рәмиев кенә (ә ул әлеге газеталарны чыгаруда да якыннан торып катнаша) Казанда кала, ярым легаль хәлдә йөри. Замандашы Вафа Бәхтияров "Сәгыйть абзый бик кызганыч, бик авыр хәлгә төшә..." дип яза бу хакта *(В. Бәхтияров. Г. Тукай турында кайбер истәлекләр. 1948, 20 декабрь.—Г. Ибраһимов ис. ТӘСИ архивы, ф. 9, оп. 4, сак. бер. 35.).*

Бу вакыйгалар С. Рәмиевнең 1914 елда "Ил" газетасында Г. Тукай үлүенә бер ел тулу унае белән язылган "Икенче апрель көне" мәкаләсендә дә чагылыш тапкан.

"Г. Тукай турында истәлекләр" дигән китапта (1986 ел) бу мәкалә бик киселгән рәвештә "Беренче очрашулар." С. Рәмиев истәлекләре" дип бирелгән бирелүен, әмма Г. Исхакый телгә алынган җирләре, әлбәттә инде, төшереп калдырылган. 1907 елда Г. Тукай Казанга килә һәм С. Рәмиевне эзләп "Болгар" номерларына китә. Әгәр моңарчы бу истәлекләрдән Тукай килгәндә Сәгыйть Рәмиевнең нигә кәефсез булуы аңлашылмый калса, "Ил"дәге мәкалә ачыклык кертә. С. Рәмиев бу көн турында болай дип искә ала: "Гаяз әфәнденең Казан төрмәсендә тоткын чагы, шул мөнәсәбәт белән безнең дә бик кайгылы көннәремез иде.

Числосы хәтеремдә юк, бер көн, Фуад Туктаров, Ш. Мөхәммәдъяров, Хөсәен Әбүзәров һ. б. иптәшләремез мөшавәрә (киңәш) итеп, Гаяз әфәнде хакында бер төрле хәрәкәттә булынырга карар кыйлган идек. Минем өлешемә дә бер вазыйфа төште". Шуннан соң С. Рәмиев үз вазыйфасын башкарганда зур хурлык, кимсетүләр күреп кайтуы турында сөйли. Мәкаләнең бу кереш өлешендә, гомумән, вакыт төшенчәсе Г. Исхакый белән бәйле вакыйгалар белән үлчәнә: "Бер ун-унбиш көннән *(Г. Тукай—Ч. З.)* тагы әйләнеп Казанга килде. (...) Бу дәфга (тапкыр) килгән көннәрс—Гаяз әфәндeнең Казан төрмәсеннән сөргенгә озатылган көннәре иде.

—Гаяз әфәндене күрә алмам микәнни инде,—диде.

—Булмас шул инде...—дидем *(С. Рәмиев. Икенче апрель көне. "Ил", 1914, 2 апрель № 23).*

С. Сүнчәләй 1906 елның көзендә "Таң йолдызы" идарәсенә кергәләп (хәтта кунгалап) та йөрүен искә алып, "Сәгыйтьне идарәдә бик сирәк очрата идем. Сәгыйть "таңчы"лар арасында шагыйрь генә һәм киpәксә рәсми редактор булып Г. Исхакыйга ияреп кенә йөри булгандыр",—дип яза һәм "әмма ул да таңчылык әмәлләренә инанган вә күнел куйган бер таңчы иде, әлбәттә",—дип өсти *(С. Сүнчәләй. Истәлекләр. Г. Ибраһимов ис. ТӘСИ архивы).* Шагыйрьнең үзен-үзе төзәтеп куюы кызыклы гына килеп чыга. С. Рәмиевнең "таңчылар" арасында шагыйрь генә һәм рәсми редактор гына булып йөрмәве көн кебек ачык: Рәмиев үзе "ата таңчы", "таңчы"ларның иң көчлеләреннән дип үз замандашлары һәм соңрак галимнәр тарафыннан да танылган факт. Г. Исхакыйга ияреп йөрде диюе дә дөрес булмас: ул Г. Исхакыйның фикердәше, көрәштәше; һәм публицист, журналист буларак, әлбәттә, аның йогынтысы астында формалаша. Язмыш бу ике олуг әдипне бер очраштырып, инде ахыргача (Г. Исхакый илдән чыгып киткәнче) күзгә күренмәс җепләр белән бәйләп тота һәм янәдән-янә очраштырып тора.

С. Сүнчәләй әлеге истәлекләрендә **"С. Рәмиев 1907 елда бөтенләй әдәбият вә театр кичәләре төзү эшенә генә бирелгән кебек күренә иде"**, дип яза. С. Рәмиевнең театр вә әдәбият кичәләре үткәреп йөрүләре (бу чорда да, соңрак та)—аерым бер тикшеренү темасы. Ләкин сүз башлаганбыз икән, "Әльислах" газетасының 1907 елны чыккан 5 санына күз салыйк. Бирeдә Ф. Әмирханның "Дамелла" имзасы белән басылган кызыклы гына мәкаләсе бар: **"Г. Исхакый җәнабларының иң гүзәл тасвирларыннан булган бу хикәя иң тәэсирле сурәттә кызларымызның гаҗизин вә аларга татар мәгыйшәте һәр юлны вә һәр якты төшерә торган тәрәзәләрне каплаган икәнене күрсәтәдер. Гаяз әфәнденең ... фикриясе вә ... каләмиясе белән бөтен зал тулысы халык ләззәтләнгәндә, шул ук нәрсәләрнең нәтиҗәсе аңар икенче төрле иде—ул, 40 градуслы суыкта боз диңгезе ягына сөрелеп, әллә никадәр газаплар күрергә мәхкүм** (хөкем ителгән) **иде! Укучы Сөбектәгин әфәнде"**. "Сөбектәгин" имзасы белән матбугатта С. Рәмиев чыккан. Г. Исхакый сөргендә булганда да, С. Рәмиев аның әсәрләрен пропагандалауда актив катнашкан. С. Рәмиевнең сәхнәдән оста укуына һәм спектакльләр куйганда үтә дә оста итеп карчыклар ролен уйнавына замандашлары бигрәк тә басым ясыйлар. Шагыйрьнең хатыны Бану Әюпова-Рәмиева истәлекләренә караганда, С. Рәмиев 1914 елда Әстерханнан Уфага күчеп киткәч тә әдәби-музыкаль кичәләрдә һәм спектакльләрдә катнашуын дәвам итә. Мәсәлән, приказчиклар клубында хәвәскәрләр көче белән куелган Г. Исхакыйның "Өч хатын берлә тормыш" спектаклендә катнаша.

1907 елның июнь башыннан С. Рәмиев трибунасыз—матбугатсыз һәм эшсез кала. Шул трибунасызлык, акчасызлык аны, үз принципларыннан баш тартып, "Бәянел-хак"ка ялланугa китереп чыгарган, диләр. М. Гайнетдинов шактый материаллар тупланганнан соң кыйммәтле нәтиҗә ясый: "1908 елда ук, февраль башларыннан, "Бәянел-хак" гүя гомумән "таңчы"лар газетасына әйләнә, ягъни бу газетага ("Бәянел-хак"ка) С. Рәмиевтән алдарак (ул биредә 1909 елның беренче көннәреннән эшли башлый) Г. Исхакый килеп керә. Аның Архангельдә сөргендә язган әсәрләрен тагын

шул ук "Бәянел-хак"та иректә калган Х. Әбүзәровләр, С. Рәмиевләр чыгарып торалар.

С. Рәмиевнең "Бәянел-хак"ка урнашуын хурлаучылар да, аклаучылар да үз заманында ук шактый булды. Кайбер замандашлары һәм кайбер галимнәр моның сәбәбен бер тиен акчасыз, эшсез калганлыктан дип күрсәттеләр. С. Сүнчәләй, мәсәлән, С. Рәмиевнең "Бәянел-хак" кебек кирелеге, каралыгы белән танылган, әмма зур гына газетаны кулга алып, аның мәсләген, йөзен үзгәртеп җибәрү кебек яхшы нияте дә булгандыр",—дип уйлана. Безнең көннәрдә М. Гайнетдинов хакыйкатькә иң якын версия тәкъдим итә: "танчы"ларга актуаль, программ әсәрләрен—тоткынлыктагы Г. Исхакыйның яна тәнкыйть мәкаләләрен, шау-шусыз, мыштым гына, бераз "томан артындарак" рәвештә, кичекмичә мәйданга чыгару кирәк. Алар "Бәянел-хак" вариантын сайлыйлар. С. Рәмиев үз иҗат планнарыннан баш тартып, намуслы исеменә юылмас тап төшереп, "Сәйдәш бабайларга" ялчылык итеп "танчы"лар бурычын түләргә мәҗбүр була" *(М. Гайнетдинов. Җаектан килгән "таңчы" һәм Сәгыйть Рәмиев.— "Мәдәни җомга"— 1996, 23 май, 31 май).*

1913 елның 22 октябрендә Петербургта йорт-җир файдасын күзәтүче татар газетасы—"Ил" чыга башлый. Р. Әмирхан язуынча, бу газета "чын мәгънәсендә Г. Исхакыйның иҗат вә йөрәк җимеше", чөнки ул беренче тапкыр Г. Исхакыйның үз редакторлыгында чыккан басма. *(Р. Әмирхан. Иманга тугрылык. Казан.—(1997.—198-318 бб.).* Биредә Й. Акчура, М. Бигиев, Ә.—З. Вәлиди, Ш. Мөхәммәдъяров, Ф. Туктаров һ. б. күренекле җәмәгать эшлеклеләре белән С. Рәмиев тә катнаша. Ягъни биредә дә Г. Исхакыйның "иске гвардиясе"—"таңчы"лар эш итә. С. Рәмиевнең 1914 елда Тукайның үлүенә бер ел тулу унае белән чыккан "Ил"нең махсус санында инде өстә телгә алынган "Икенче апрель көне" дигән Тукай турында истәлекләре басылып чыга. Бу мәкаләдә С. Рәмиевнең Тукайны "татар җәмгыятенең вакытсыз бер корбаны" итеп бәяләве һәм үзен мәрхүмнең иң якын иптәше, җан дусты дип тәкъдим итүе, Тукайның шәхси кимчелекләрен дә читләтеп үтмәве галимнәр тарафыннан (Г. Халит) тискәре бәяләнеп, тәнкыйтьләнеп киленде, яисә гомумән бу мәкаләнең барлыгына күз йомдылар. Югыйсә, мәкалә Тукайга каршы ук ату, аны кимсетү максаты белән язылган булса, Тукайны югары бәяләүче, аның исеменә пычрак атучыларга каршы чыгучы Г. Исхакый, мөхәррир буларак, С. Рәмиевнең бу мәкаләсен юбилей санында мәрхүм шагыйрьгә ихтирам хисе белән язылган мәкаләләр янына урнаштырыр идемени! Ш. Садретдинов язуынча, **"1912 ел башларында эчке эшләр министрлыгы Казан цензура комитетына "Таң йолдызы" газетын яңадан тикшереп чыгарга күрсәтмә җибәрә"** (Ш. Садретдинов. С. Рәмиев һәм патша жандармериясе.— *"Аргамак". 1994, № 6.*). Тикшерү нәтиҗәсендә газетаның 20гә якын санына арест салына, тыелган әдәбият исемлегенә кертелә, Казандагы суд һәм жандармерия органнары С. Рәмиевне эзли башлыйлар.

1914 ел башларында С. Рәмиев эшләгән "Идел" газетасы ябылып, шагыйрь Әстерханнан сөрелә. Яңа гына гаилә корган С. Рәмиев хатыны Бану Әюпова белән Уфага күчәргә мәҗбүр була.


С. Рәмиев Әстерханда "Идел" газетасында эшләгәндә дә "хөкүмәткә каршы характердагы" эшләр белән шөгыльләнә, мәкаләләр яза, "сөргенгә сөрелгән татарлар белән даими аралашып тора. Аның тарафыннан чыгарыла торган "Идел" газетасында үз тирәсендә сәяси ышанычсызлыгы белән танылган хезмәттәшләр җыя." Бану Әюпова-Рәмиева истәлекләренә караганда, алар өйләренә тентү килүен көтеп, С. Рәмиевнең кулъязмаларын, язышкан хатларын сайлап алып яндыралар. Яндырылган кәгазьләр арасында С. Рәмиев белән Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов һ. б. әдипләр, җәмәгать эшлеклеләре язышкан хатлар да бик күп була. Димәк, С. Рәмиев Г. Исхакый белән күрешә алмаган вакытта да даими язышып торган.

1916 елның январь башында С. Рәмиевкә жандармерия: **"Монда, Уфада, Г. Исхакый, Г. Терегулов, С. Рәмиев вә Г. Ибраһимовлардан оешкан бер инкыйлаб комитеты төзелгән, сез шуны беләсезме?"**—дигән сорау биреп, агент итеп алырга тырыша. Шул көннән алып С. Рәмиев исеме "провокатор" дигән атама белән пычрана. Октябрь революциясеннән соң, 1918 елның гыйнварендә, Уфада җыелган Милләт мәҗлесе әгъзалары бу мәсьәләне (С. Рәмиев провокатормы, әллә юкмы?) көн тәртибенә куялар. Мәҗлестә Г. Исхакый да катнаша һәм үз сүзен әйтә: **"С. Рәмиевнең "Таң йолдызы" мөхәррире булып торган вакытында газеттагы мәкаләләр өчен судка бирелгән чакларда да бөтен мәсъүлиятне** (җаваплылыкны) **үз өстенә алып, язучыларны судка тарттырмаганын сөйли. Шуның белән бергә Сәгыйть әфәнденең бер курыкса, кинәт кенә

**бик нык куркып китү гадәте дә бар, ләкин соңыннан исен башына җыеп ала ала",** ди *("Тормыш", 1918 ел, 18 гыйнвар).* Хәкимнәр хәйәте (суд коллегиясе) С. Рәмиевкә биру өчен төзегән сигез сорауга, Г. Исхакый "Инде бер нәрсә дә арттырылырга урын калмаган. Бу сөальләргә караганда, һәйәт каршында алды карарланган бер нәрсә бар кебек күренә", ди. Теге сигез сөаль өстенә үзеннән шундый бер сөаль куша: "С. Рәмиевнең гамәлендә милләткә хыянәте бармы?" Аннан соң мәсьәләнең икенче ягына күчеп: "Бу мәсьәләне күтәрүчеләр бигрәк Сәгыйтьнең әдәбият вә матбугаттагы хезмәтләрен игътибарга алып башлаганнар иде. Бинаэн галәйһи (шуңа күрә) ул хакта һәйәт бик ачык җавап бирергә тиешле. Шуның өчен мин тагын шундый сөальләргә җавап бирергә тиеш дип беләм: әгәр С. Рәмиев гаепле табылса:

1. Матбугат галәменә кайтырга аның хакы бармы, юкмы?

2. Булмаса, китапларда аның шигырьләре калырга ярыймы, әллә себереп түгелергә тиешләрме?" *("Тормыш", 1918 ел, 19 гыйнвар).*



*«Таң йолдызы» газетасы хезмәткәрләре. Сулдан уңга: Ш. Мөхәммәдьяров, А. Дәүләтшин, Х. Әбүзәров, С. Рәмиев. ( Матбугатта беренче мәртәбә басыла)*

С. Рәмиев үзе сүз алып, сораулардан канәгать икәнлеген бәян итә. "Бу хакта сөальләр була торган булса, нәкъ менә шул хөкемнәр һәйәте сөальләре булырга гына мөмкин,—ди". Суд С. Рәмиевнең милләтенә хыянәт нияте булмаган, дип таба. "Шуның белән бергә С. Рәмиев табигате шигъри вә хыялый булуы, хакыйкый хәяттән ерак торуы, җисмани авырулыгы, хезмәткә көчләнеп кертелүе, вөҗданы газап чигүе, управлениягә һичбертөрле мәгълүмат бирмәве—һәрберсе гаепне җиңеләйтүче сәбәпләрдән саналырга тиеш дип тапты". Әмма С. Рәмиев турында төрле имеш-мимешләр, дәлилсез гаепләүләр 20 елларда да күренгәли. Гасим Мансуров 1925 елда язылып, 1926 елда басылып чыккан "Беренче революция елларында татарлар" дигән китабында Г. Исхакыйны, "таңчы"ларны тоташ каралтып, татар эсерлары "провокатор булдылар" дип, шул исәптән бернинди аңлатмасыз С. Рәмиевне дә шулар рәтенә кертеп яза.

1918 елда С. Рәмиевне аклауда, көрәсең, Г. Исхакыйның да өлеше зур булган. Гасим Мансуров юкка гына, үпкә белдергән кебек, "революция булгач, татар буржуа ирләре милләт өчен файдасы тиярлегрәк провокаторларны тәүбә иттереп, аклап маташтылар. С. Рәмиевне, Г. Исхакый тәкъдиме буенча, милләт мәҗлесе aклады", дип язмыйдыр.

Сәйфи Кудаш хаклы: С. Рәмиевкә Г. Исхакый йогынтысы бик көчле була һәм февраль революциясеннән соң алар тагын да тыгызрак бәйләнешкә керәләр *(С. Кудаш. Онытылмас минутлар. Уфа, 1962.).* 1917 елның 23 мартында Мәскәүдә янә "Ил" газетасы чыга башлый. "Февраль революциясе көннәреннән башлап, 1918 елның урталарына хәтле дәвам иткән милли буржуа газеталары арасында иң алдынгысы, аларга тон биреп баручы газет шушы булды, (...) Советларга каршы бик каты язды,

(...) малай-шалай комиссарлар, эш башына менгән көтүче, каравылчы, зимагур, рабучи товарищлар һәм башкаларны (...) каргады. Большевиклар үзләре дә, аларның хакимиятләре дә өч көнлек, диде"—дип яза бу басма хакында "Вакытлы татар матбугаты" альбомы (1926). Һәм "фикереннән, тел, имлясеннән үрнәк урында" дип өстәп куя. Милли-патриотик рухтагы бу каһарман газетаның гомере 1918 елның урталарында большевиклар хакимияте тарафыннан өзелә.

С. Рәмиев 1918 елда "Ил" газетасында актив язышa башлый. Газета да үз чиратында С. Рәмиевкә игътибарлы: провокаторлыкта гаепләнеп, суд аклаганнан соң, "Сәгыйть әфәнде Рәмиев акланды" (идарәмезгә телеграм) дигән белешмә бастыралар *("Ил", 9, 27 гыйнвар).* Шул вакыйгалардан соң күнеле сүрелеп, рухы рәнҗеп калган шагыйрь "Талдым" дигән шигырь яза һәм бу шигырь "Ил"дә басылып та чыга *(1918, 15 февраль, 12).*

1918 елның 9 мартында (24 февраль) С. Рәмиев "Алар" дигән шигырь яза һәм аны "Ил" газетасының 23 санында бастырып чыгара. Бу шигырьнең исеме астына С. Рәмиев "Гаяз әфәндегә һәм аның максатташ иптәшләренә багышлана" дип язган һәм эпиграф итеп "Коръән"нең 48нче "Җиңү" сүрәсеннән аять китерә. Әлбәттә инде Гаяз Исхакыйга багышланган шигырь буларак, 1918 елдан соң дөнья күргән С. Рәмиевнең шигырь җыентыкларына "Алар" шигыре кертелмәгән.

Г. Тукайның үлүенә биш ел тулу уңае белән С. Рәмиев Әстерхандагы "Сарай" газетасында *(1918, 3 (17) апрель)* "Мәктүб" дигән мәкалә бастыра. Биредә ул якын дустының рухына мөрәҗәгать итеп, илдә барган сәяси үзгәрешләр белән уртаклаша, хөррият һәм иреклең бары тик сүздә генә хөррият булуын, чынлыкта исә илдә коточкыч вакыйгалар баруы турында ачынып яза. Г. Исхакыйның эмиграциягә китүен алдан белеп, шул хакта да (исемен атамыйча гына) язып үтә: **"Теге кысынкылык заманында: хөррият! хөррият! дип янып йөргән, хөррият юлында (...) таптап, Архангель сазлыкларын киптереп бетергән каһарманлар (...), хөррият килгәч, бары хөррият белән тәбрик кенә ишетеп калдылар, хөрриятнең үзен алмадылар. Алар тагы яңадан башлап, шул хөррияте эзләү юлына, яңадан башлап озын сәфәргә керешәчәкләр кебек күренәдер".**

Гаилә белән бәйләнгән, әле яңа провокаторлыкта гаепләнеп, көчкә акланган С. Рәмиев үзенең остазы Г. Исхакый белән бергә илдән чыгып китү турында уйлый да алмый. Ләкин алдагы тормышын күз алдына бик ачык китерә: өметләнер нәрсә юк.

Г. Исхакыйның илдән чыгып китүе С. Рәмиев өчен шәхси фаҗига була дип әйтә алабыз. Моңарчы гел Исхакыйның киң җилкәсен тоеп, аның ярдәмен күреп яшәгән С. Рәмиев, Г. Исхакый эмиграциягә киткәч, тагын кызганыч хәлгә төшә: бер кызыллар ягына чыгып карый (хәтта большевиклар партиясенә керә, һәм бу хакта соңыннан **"С. Рәмиев революция вакыйгалары дәвамында үзенең контрреволюция ягына чыккан элеккеге дусларыннан читкә китеп, советлар ягына күчте"** дип язып чыктылар *(С. Кудаш, 84 б.)*, бер урталыкта чайкала, соңыннан барыбер партиядән чыгарыла һәм җанына тынычлык, иҗатына илһам ала алмаган килеш тилмереп вафат була.

Шагыйрь үлгәч, күрәсең аны "кызыл" итеп күрсәтү теләге белән, язучылар—замандашлары бер дәлилсез, С. Рәмиевнең үләренә озак калмаганда, Г. Исхакыйга мөнәсәбәте үзгәрүе турында язып чыгалар. 1925 елда Г. Исхакый турында төрек матбугатыннан алынган бер материал, имеш: Г. Исхакый ниндидер бер төрек газетында большевикларны сүгеп бер мәкалә язган һәм төрек газеталары зур гауга куптарып, Төркия белән Советлар Союзы арасындагы дуслыкны бозарга йөри дип, Гаяз ише контрларның Төркиядән сөрелүен таләп иткәннәр. Имеш, С. Рәмиев шул хакта укып: **"Бу Гаяз дигән ахмакка мин әле булса бераз ихтирам саклап йөридер идем, чыннан да бик зур подлец булып чыкты бит бу кеше, йә соң инде, революциянең тугызынчы елында, большевиклар тоткан юлның дөреслеге бөтендөнья алдында исбат ителеп торган бер вакытта шундый ахмаклык сатып йөрү буламы соң"** инде, ди. Гаязга һәм аның язганнарына үзендә ифрат түбән һәм начар бер караш туганлыгын сөйли, имеш *(С. Кудаш. Онытылмас минутлар. Уфа, 1962, 84 б; Г. Касыймов. Сәгыйть үлеме турысында. "Яңа авыл", 1926, 20 март, № 32).*

Кинәт кенә, үләр алдыннан, Сәгыйть Рәмиевнең Гаяз Исхакый турында фикере үзгәрүе шикле, әлбәттә. Нигә соң шагыйрь, әгәр бу чынлыкта шулай икән, шул хакта матбугатта язып чыкмый, акланыр өчен мен дигән форсат бит югыйсә?! Аннары, С. Рәмиев большевиклар алган юлны дөрес юл дип таныды микән, дигән сорау туа. Бу очракта җавап бер генә төрле була ала: әлбәттә, юк. Инде 1918 елда ук, шагыйрьләргә

генә хас үтә сизгерлек белән С. Рәмиев илдә барган вакыйгаларның кайда китерәсен күрә белгән һәм бу хакта ачыктан-ачык язып чыга. *("Сарай" газетасы. 1918, 3 (17) апрель).* Революцион комитетларда эшләп, төрлесен күргән, ачлык елында үле гәүдәләр җыеп йөргән һәм бу вакыйгаларга багышлап "Иблис тә дердерәде" дигән әсәр язган, партиядән чыгарылган шагыйрь советларны мактап сөйләр микән? Әгәр шагыйрь советлар ягына чыккан булса, нигә соң аның совет чорында, үзе исән чакта, бер китабы да дөнья күрмәгән? Нигә соң аның өч томга җыелган әсәрләре, М. Гайнетдинов язуынча, вәхшилек, шәхес культы чорындагы кебек юкка чыгалар һәм бүгенге көнгә кадәр табылмаган килеш кала бирәләр? Һәм, ниһаять, нигә соң совет хакимияте заманында шагыйрь илдәге вакыйгаларга дан җырлап, бер генә шигырь дә иҗат итмәгән? Д. Юлтый хаклы, төрле совет эшләрендә йөрсә дә, **"С. Рәмиевнең эчке рухы бу яңа дәвергә үзләшә алмады. Бу дәвер аның шигъри талантына көч бирә алмады"** *(Д. Юлтый. Сәгыйть Рәмиев үлде. "Эшче", 1926, 20 март, № 53).* 1923 елда "Башкортстан" газетасының 11 гыйнварда чыккан санында Г. Касыймовның "Сәгыйть агага" дигән мәкаләсе басылып чыга. Ул С. Рәмиев турында: "Хәзерге эшче-крестьян диктатурасы дәверендәге икътисади мөнәсәбәтләрдән туган яшь әдәбиятнең шагыйре булыр өчен ул диктатураның сөелүе һәм аңа иҗади карау шарт. Сәгыйтьтә бу юк, биш ел дәвам иткән бөек революциягә дә, аның нәтиҗәсендә туган әдәбияткә дә ул хаос дип, аңлашылмау дип карый. Шулай булгач, аның хәзерге әдәбият шагыйре һәм аны тудырган идеологиянең тәрҗеманы була алу ихтималы юк",—дип яза. С. Рәмиев бу сүзләргә каршы үзенең "Сүзем һәм үзем" дигән шигырен яза. Бу—аның соңгы шигыре дип санала. С. Рәмиев үзенең сүз кылычы турында түбәндәгечә язып, элеккеге идеалларына тугры калуын тагын бер кабат раслый:

Җиһадында ләшәй* аңар атар ук та,
Юл өстендә ятар дәрья, янар ут та,
Вәләкин ул әрәм җиргә, ялтрау бирми
Буш һавада, әзерләнгән зәмин юкта.

Моңа каршы Г. Касыймов үзенең мәкаләсендә С. Рәмиевкә: "Сезгә нинди зәмин кирәк, сезнең кылычыгыз өчен шушы зәмин дә тармыни? Менә сез хәзерге көндә Париж буржуаз ...ларында лакейлык итү дәрәҗәсенә төшеп хур булган Гаязлар шикелле Русиянең элекке—1917 елның 7нче ноябренә чаклы булган шомлы, караңгы жандармнар зәминен сагынасызмы?"—дип, шагыйрьне "биш ел буена әллә ничаклы кыйммәтле корбаннар биреп, низагларга каршы торып дәвам иттерелгән канлы көрәш вакытында тик торганы, сүз кылычын кынасыннан чыгармаганы" өчен гаепли һәм "ни өчен... әле дә чыгармыйсыз?",—ди.

Г. Исхакый С. Рәмиевнең соңгы көннәреннән хәбәрдар булган, күрәсең, чөнки "Большевиклар революциясе вакытында ул Мәскәүдә большевиклар дошман күргән Г. Исхакыйның "Ил" газетасы мөхәррире була һәм шуның аркасында большевиклар хәрәкәте бу шагыйрьгә дә үги итеп карый. Ул хәерчелеккә төшә һәм, ниһаять, 1926 елда үпкә авыруыннан вафат була",—дип яза *(Г. Исхакый. Шималь төрекләре әдәбиятына бер караш. "Татарстан", 1993, № 9).* Әгәр дә С. Рәмиев советлар ягына чыгып хезмәт иткән булса, бәлки ул хәерчелектә үлмәгән булыр иде һәм вафатыннан соң аның хатыны Бану Әюпова-Рәмиева өч баласын алып, Уфадан Мәскәүгә, татарлар азрак булган җиргә китәргә мәҗбүр булмас иде. Ә бит нәтиҗәдә шагыйрь балалары рус мохитендә тәрбияләнеп, башка милләт вәкилләренә кияүгә чыгып, үзләренең ана телннән һәм татар мәдәнияте казанышларыннан, үз аталарының әсәрләрен оригиналда укудан мәхрүм калалар!..

Сүз башына әйләнеп кайтып шуны әйтәсе килә: С. Рәмиевнең жандармерия вакыйгаларыннан соң да тернәкләнеп китәргә үзендә көч табуы—Г. Исхакый хезмәте булгандыр, мөгаен: үзе судка килеп чыгыш ясый, соңыннан С. Рәмиевне үзе белән "Ил"гә эшкә тарта. Шуңа күрә үз канаты астына алып, нинди авыр, дәхшәтле чорларда да яклап, ярдәм күрсәтеп, шигъри талантын югары бәяләгән бер кешегә С. Рәмиев алай тел тидермәс, кул күтәрмәс, гәрчә 20—30 елларда андый тенденция (үз башыңны саклап калу өчен Г. Исхакый белән булган дуслыктан, аралашудан баш тарту) барлыкка килсә дә. Бу тенденция бигрәк тә 20 еллар ахырында, 30 еллар

* Л ә ш ә й —берни түгел.

башында көчәя, шуна күрә С. Рәмиевкә 1926 елда "рәхәтләнеп", гаиләсеннән аерылмаган килеш, үз үлеме белән үләргә насыйп була. Соңгы көннәрендә, Гаяз Исхакый белән дуслыгыннан бик теләп, бик каты баш тартып караса да, акланып бетә алмас иде: аларның яшьлекләре, язмышлары артык тыгыз үрелгән...

Әлбәттә, С. Рәмиев белән Г. Исхакый арасында бер-берсенен карашы белән килешмәгән, бәхәсле моментлар да булган. Мәсәлән, латин алфавитына күчү мәсьәләсендә Исхакый Рәмиев белән һич кенә дә килешми: "Уфада үзара булган бер мәҗлестә С. Рәмиев үзенең латин хәрефләре ляихәсе (проекты) кабул ителүе тиешлеген куәтләп сөйләгәндә, Г. Исхаков зур ирония белән көлеп, "Бәлки шулайдыр, ләкин латин кабул ителсә, сез әйткән файдалар артыгы белән булачактыр, ләкин, ... ләкин тел вә әдәбият мәсьәләләрендә революция мөмкин түгел!.. Менә шушы хәл сезнен ляихәгә каршы җиңелмәс бер маньйг (киртә) булачак...",—ди (*"Аң", 1915 № 18-19.*). Г. Исхакый бу мәсьәләдә дә сизгеррәк, зирәгрәк, "шәкертенә" акыл бирер дәрәҗәдә оста булып кала. Бүгенге көндә дә хакимият башында торганнарга колак салырлык киңәш бу.

Г. Исхакый С. Рәмиев турында, Г. Тукай турында кебек үк, эмиграциядә дә кайгыртып яши. Инде үзләре өчен түгел, тарих, әдәбият өчен. "Шималь төрекләренең әдәбиятына бер караш" дигән хезмәтендә Г. Исхакый, И. Нуруллин язуынча, "беренчелек пальмасын Тукайга бирә бирүен, ләкин үзенең сәяси яктан фикердәше С. Рәмиевне Тукайдан да өстен куярга тырыша". С. Рәмиевкә "Хөсәения" мәдрәсәсендә үзенең йогынты ясавын, соңрак С. Рәмиевнең "Таң йолдызы" газетасында мөхәррир булып торуын һәм "үзенең фикерләре, каләме белән таңчыларның нәшрият эшендә якыннан катнашуын" белдерә. Гомумән, "шималь төрекләре телендә чыккан шигырьләр арасында С. Рәмиевнекенә тиңләнердәй, аларның ише булырдайлары юк"—дип яза.

Чыннан да, Г. Исхакый язмышында һәм С. Рәмиев язмышында мөһим бердәмлекләр, уртаклыклар аз түгел: икесе дә иске тәртипләр белән килешә алмыйча, "Хөсәения" мәдрәсәсен ташлап чыгып китәләр, икесе дә "Бәянел-хак"ка килеп керәләр, "Әльислах"та юлаучылар гына, ә "Шура" битләрендә бер мәртәбә дә күренмиләр, икесе дә туктаусыз эзәрлекләнеп шәһәрдән шәһәргә куылып йөриләр (С. Рәмиев Казаннан качып китеп, Әстерхан, Уфа, Чиләбе якларында гомер кичерергә мәҗбүр була. Г. Исхакый да Казаннан качып йөреп, гомерен Петербургта, Мәскәүдә, чит илдә үткәрә); икесе дә "Г. Тукайның талантын формалаштыруда, аңа юнәлеш бирү, юлга салуда "Таң йолдызы" була алганнар" (*М. Гайнетдинов. Г. Тукай һәм С. Рәмиев. Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары. Казан 1997*). Ләкин шулай да бу ике бөек шәхесне берләштереп торган нәрсә—ул фаҗигалелек. Икесенең дә язмышына хурлау-әрнүләр муллан язган була. Үзләре исән чакта да, инде мәрхүм булганнан соң да озак вакытлар аларның исемнәре һәм иҗатлары дөрес бәя алмаган килеш калды.

Шулай да, С. Рәмиевнең иң якты, иҗаты чәчәк аткан чор булды һәм ул—Г. Исхакый кул астында "Таң йолдызы" газетасында хезмәт иткән вакыт иде. Д. Юлтый: "С. Рәмиев 1905 ел революциясе соңында үзенең шигыре белән дә, "таңчы"лыгы белән дә татар дөньясы, үз гасырдашлары тарафыннан нык сөелгән кеше иде",—дип яза. М. Укмасый да: "Рәмиевнең әле бу чорларын бүгенгедәй хәтерлим, ялкынланып янып торган күңел ташуын кайда куярга белмәгән бер шагыйрь иде",—дип искә ала. (*М. Укмасый. Истәлекләр. 1940. Г. Ибраһимов ис. ТӘСИ архивы*). "Таңчы"лар дигәч тә, иң беренче чиратта бары ике кешене—Г. Исхакыйны һәм С. Рәмиевне күздә тотулары, Г. Тукайның да Казанга шуларның икесен күрер өчен килүе—болар зур мәгънәгә ия.

Шөкер, С. Рәмиевнең 1907 елда: "Гаяз әфәнде кебек сирәк бер әдипнең, Гаяз әфәнде кебек сирәк бер мөхәррирнең, Гаяз әфәнде кебек сирәк бер кешенең һәрвакыт бар булып торуы безнең татар халкы өчен минут саен кирәк булганга, без бөтен татар күңеле белән Гаяз әфәндененң күп елар яшәмәгән телимез вә аның, яшәгән сурәттә, һичбер арымыйча, һәрвакыт халык файдасына тырышып хезмәт итәчәгенә чын-чынлап ышанабыз",—дип язуы рас килә бара. Әмма язмыш монда да үз төзәтмәләрен кертә: Г. Исхакый С. Рәмиев үлеменнән соң әле 28 ел яшәячәк һәм һичбер арымыйча, әмма халыктан еракта халык файдасына тырышып хезмәт итәчәк һәм аның бу хезмәте үлгәннән соң 33 ел үткәч кенә халкына кайта башлаячак.

**Чулпан ЗАРИПОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

*Фән һәм дин*

**Адлер Тимергалин**

# ПӘЙГАМБӘР




Өлкән яшьтәге укучылар хәтерли булыр, моннан утыз еллар элек "Казан утлары"ның берничә санында язучы Гариф Гобәйнең "Коръән серләре" дигән китабының журнал варианты дөнья күргән иде. Матбугатта дингә каршы көрәшнең беренче зур дулкыны узган булса да, ярты гасыр буена "коммунизм төзүчеләр" агыннан Иман тамырларын йолкып бетерә алмыйча гаҗиз булган хакимиятләр, кабат җиң сызганып, яңа һөҗүмгә күчкән чор иде бу. Аннан соң әлеге хезмәт җимеше Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып та чыкты, соңыннан журнал редакциясе укучылар язган күпсанлы хатларга авторның шактый күләмле җавабын да урнаштырды.

Кызганычка каршы, каләмдәшләре һәм якыннары Гариф аганың үзенә бу китабы хакында тискәре сүз кузгатырга базмадылар шикелле, ә бит, турысын әйткәндә, җәмәгатьчелек (мин монда тулаем халыкны күздә тотам, партия һәм номенклатура әһелләрен түгел) фикере һич тә уңай түгел иде... Атеистик темага лекцияләр укып көн күргән берничә шома кәсептене исәпләмәгәндә, мәдәни ядкяр буларак кына да изге саналырга тиешле Коръәнгә тел ягу Иман кәлимәсенең әлифен таяк дип тә белмәгән, ошбу дөньядагы һәр нәрсәне материалистик күзлектән карап аңлатып була, бүген булмаса иртәгә булачак дип ышанган (ә мондый ышануны логик дәлилләү мөмкин түгел, чөнки ул өмет кенә) самими матдиюннарны (материалистларны) да сагайтты бугай. Акыллы кешеләр дәшмәде, куркаклар ләммим, әлбәттә. Миңа бер танышым, мәчет әһеле, әле ул вакытларда яшь кеше, "Коръән серләре" китабын кухнясында яндыруы турында сөйләгән иде. Аның гадәттә тыныч күзләрендә шул мизгелдә кабынган зәһәр ут шәүләсен күреп, мин хәтта сәерсенебрәк тә киткән идем...

Гариф Гобәй үзенең ни дәрәҗәдә хаксыз һәм гөнаһлы булуын белмәгән көенчә китте. Инде нәшрият планына кергән китабының яңа басмасын әзерләп җилкенеп йөргәндә, кинәт кенә сәяси җилнең башка якка авышып, "Коръән серләре"н дөньяга чыгару эшенең туктатылуы аның өчен авыр булгандыр. Ул заманнарда татарның чит илләр белән элемтәсе юк чамасында булса да, Ислам дөньясының бездәге вәзгыять һәм матбугат белән кызыксынып торуы сизелә иде. Мәсәлән, могтәбәр К. З. Хәмзин һ. б.лар төзегән "Гарәпчә—татарча—русча алынмалар сүзлеге" басылып чыккач *(Татарс-*

*тан китап нәшрияты, Казан, 1965)*, бу уникаль китапның Шәрекъ илләрендә уңай бәяләнүе безне—нәшрият хезмәткәрләрен, әлбәттә, куандырмый калмады. Ә менә "Коръән серләре" белән башкачарак килеп чыкты.Хәтерем ялгышмаса, Мәскәүдәге Алжир илчелегеннән, ихтимал, башка мөселман илчелекләреннән дә булгандыр, протест сүзләре кремльдәге иң югары даирәләргә ирешеп, алар безнең куштан өлкә комитетына әлеге китапны кабат басмаска дигән катгый күрсәтмә биргәннәр дип ишеттек. Шул рәвешле, Коръәнне пычратырга дип әзерләгән легет лагуныныи кирәге калмады... Ләкин "Коръән серләре" китабы барыбер татар күңелендә бер төер булып калды.

Бу китаптагы тәнкыйтьтә, асылда, яңа нәрсә таба да алмыйсың, ул Коръәнне инкяр итүче башка хезмәтләрдән фәкать җирле шартларга яраклаштырылып, татарча усал сүзләр кулланылуы, урам бәхәсенә якын өслүбе һәм тональлеге белән генә аерылса аерыла торгандыр. Шуңа күрә "Коръән серләре" китабына анализ ясап, андагы "хакыйкатьләрне" фаш итү бүген артык эш булыр иде дип саныйм.

Мин, егерменче гасыр азагында, гади татар язучысы, мәчет манаралары киселүнең Шаһиты, дини белем алудан мәхрүм калган буыннар вәкиле буларак, Мөхәммәд Пәйгамбәр турындагы уй-фикерләремне шушы ук "Казан утлары" журналына тәкъдим иткәнче озак кына икеләнеп йөрдем: Рәсүл турында, аны ничек күзаллавым турында язарга минем хокукым бармы? Мин бит ана бик әйләнеч юллар белән килдем. Моннан бер-ике ел элек Пәйгамбәрнең балачагы турында әдәбиләштерелгән әсәр язарга тәкъдим булгач, мин: "Ай-һай, моңа минем хакым юктыр",—дип баш тарткан идем. Мин бик ихтирам итә торган могтәбәр бер затның, күзләремә карап: "Бар, бар..."—дигән сүзләре дә мине какшатмаган иде. Мин бүген дә Рәсүл турында роман язуны кирәксез бер эш, гөнаһ дип саныйм һәм, гомумән, тарихи роман дип атала торган җилбәзәк жанрга, чынбарлыкны бозганы, исәпсез-сансыз яңа мифларны җилдән тудырганы өчен, тискәре карыйм.

Бу эшкә җөрьәт итүемнең иң төп сәбәбе, ихтимал,башкадыр... Ил тагын болгавыр чор кичерә. Алай гына да түгел, Идел-йортта бүген тагын өрәк йөри—коммунизм өрәге... Ельцин әфәнденең ярым-йортылы демократиясе ул кызыл өрәкне мәңге баш калкытмаслык итеп күмеп ташлый алмады. Өлкә комитетлары ишегенә йозак элеп кенә миллионлаган коммунист Шариковлардан котылып булмады. Асылда алар үз позицияләрен бирмәделәр, иң мөһим житәкче постларын саклап калдылар, хәтта демократия жимешләреннән беренче нәүбәттә алар авыз итте. Хосусыйлаштырудан безнең кесәләр такырайган вакытта аларныкы калынайды, хәтта диссертацияләр яклап, доктор, академик булып беттеләр. Алар кабат хакимияткә үрмәлиләр... Менә шунда инде без коммунистларнын билгеле бер идея тарафдарлары булудан бигрәк, билгеле бер психологик тип әһелләре—ертлач, хәйләкәр һәм мәкерле кешеләр булуын ачык күрдек. Коръән андыйларны "адәми шайтаннар" дип атый. Коръән белгече,"Тәфсир Ногмани"ның соңгы басмасын әзерләп дөньяга чыгарган Мөфлихун Арыслани хәзрәт Адольф Һитлер, Владимир Ульянов, Иосиф Жугашвили кебек тарихта яман эз калдырган бәндәләрне шундый адәми шайтаннар исемлегенә кертә һәм ул хаклы.Бүген безгә адым саен эреле-ваклы шайтани шәхесләрне очратырга туры килә һәм, аянычка каршы, бүген алар гадәттә күчлерәк...Тормышлар авырайган саен аларныкы җиңеләя, һәрхәлдә алар шушы тормыштан ләззәт табалар. Шунысы аяныч, әле кичә генә коммунистларны хөрәсән ялкавы гына сукми иде, бүген исә совет чорындагы мәҗбүри хезмәткә һәм хәтта концентрацион лагерьлардагы миллионнарча кол хезмәтенә нигезләнгән авторитар системаны сагынып искә алучы беркатлы адәм балалары күбәйде.Алар дөньяны рәтләргә тырышкан демократларны "дерьмократлар" дип сүгәләр, ә коммунистлар, астыртын елмаеп, аларны өстереп тора...

Гөнаһ дигәннән. Кешеләр үзләре уйлап чыгарган җинаятьләр һәм аларны кылган өчен янә үзләре тапкан җәза турында төшенчән булу гына җитми бу дөньяда. Борынгы китапларда—Библиядә, Инҗилдә, Зәбурда һәм, беренче нәүбәттә, Коръән Кәримдә ачык әйтелгән мәңгелек васыятьләр идарә алмашынган саен үзгәреп тора торган җинаять кодексларыннан яки әлеге дә баягы коммунизм төзүченең мораль кодексыннан олырак һәм югарырак, чөнки гөнаһ төшенчәсе чынлыкта әсаси төшенчә. Әсаси дигәндә мин аның табигый, илаһи, төп нигез булуын, түрәләр уйлап чыгарган канун түгеллеген күздә тотам. Гөнаһ төшенчәсе булган бәндә иманга һәм әхлакка бер адым якынайган була. Коммунистлар—адәми шайтаннар—"гөнаһ" дигән төшенчәне белмиләр, алар һич тә гомуми бәхет өчен көрәшүче изге җаннар түгел, һәркайсы

үзен генә кайгырта, үз файдасын гына каера торган бәндәләр алар. Хакимият башына менә калсалар, тагын мәчетләрне тартып алып, халык яшь аралаш әйткәнчә, янә "сөннәткә утыртачаклар" алар.

Аларны кем тыяр? Нәрсә тыяр? Ничек тыяр?

Ислам философиясенә эчкәрс кераә барган саен, Мөхәммәд пәйгамбәрнең бөек шәхес булуына, чыннан да җир йөзенә аның бик вакытлы—адәмнәрне гөнаһ баткагыннан йолу һәм пакьлау өчен килгәнлегенә ныграк ышанасың.

Минем бу язмаларым, әлбәттә, мөкаммәл түгел. Алар,мәгълүм дәрәҗәдә, минем кул астымдагы чыганакларның һәм тормыш тәҗрибәмнең каршылыклы булуын да чагылдыралар. Мин теге яки бу фактны бәяләүдә сукыр хискә бирелмәскә тырыштым, чөнки нәрсәнең булса да хакыйкый дөреслеген тикшерүче мөхәкъкыйклар шикелле иманның хаклыгына берсүзсез инанган һәм гакълый дәлилләргә мохтаҗ булмаган кешеләрдән түгелмен.Мин диндә дә гакыл дәлилләренә таянып сөйләүчеләргә-мөтәкәллимнәргә якынрак торам, әмма бу юнәлешләрнең тегесенә дә, бусына да ихтирам белән карыйм, чөнки фәндә дә гакълый дәлил җитмәгәндә, илһам килеп, интуитив ясалган ачышларны атлаган саен очратырга мөмкин. Фән белән дин арасында үтеп чыккысыз каршылык булмавын күптән тоемлаган булсам да, аларның кушылып китүе, "фәнни дин" яки "дини фән" дигән синтезның бүгенге мәгънәсендә мөмкин түгеллеген анлыйм мин. Алар—фән һәм дин яки, әгәр теләсәгез, дин һәм фән—бер медальнең ике ягы гына, һәм, баксаң, алар бер-берсеннән башка яши дә алмыйлар. Фән—кара пессимист, ул бу дөньяның максаты һәм мәгънәсе юк дип саный, дин исә—якты оптимист, ул дөнья яратылышында олуг максат күрә һәм хәтта шушы принцибы белән генә дә фәнне яңа эзләнүләргә этәрә, асылда фәннең яшәешенә мәгънә бирә. Ихтимал, материя белән рухны капма-каршы куюның дөрес түгеллеген исбат итүгә дә ерак калмагандыр инде. Рух төшенчәсе, әйтик, тереклек ярлу, фикерли белүче адәм кауменең килеп чыгышы, илһамлану, төштә фәнни ачыш ясау һәм пәйгамбәрләргә вәхи килү һ. б. кебек бүгенге материалистик фән теше үтми торган мәсьәләләрне җиңел хәл итә.Тәкъдир (язмыш һәм ихтыяр) турында Ислам философиясе белән материалистлар арасында барган бәхәсләргә дә урын калмаска охшаган...

Әйе, болар хакында шактый сүз куертып булыр иде, әмма урыны бу түгел,бүген минем сүзем Пәйгамбәр турында, аның шәхесе турында.

XX гасыр азакларына миллиардтан артык мөселманны үз канаты астына алган Ислам диненә нигез салучы, Аллаһы тәгаләнең илчесе (Рәсүле, ягъни Рәсүлулла) буларак танылган Мөхәммәд бине Габдулланың тормыш юлы турында ышанычлы мәгълүматлар күп тә, аз да дип әйтергә була.

Күп—чөнки Пәйгамбәргә назил булган, ягъни күктән иңгән Коръән сүрәләре аның рухи үсешен ачык итеп күзалларга мөмкинлек бирәләр, ә йөз меңләгән хәдисләрдән без Пәйгамбәр тормышындагы кечкенә генә вакыйгалардан да хәбәрдар һәм һәр очракта аның нинди эш-гамәл кылганын, нинди сүзләр әйткәнен, соңыннан кануни (дәстүрелгамәл) булып киткән нинди кагыйдәләр төзеп биргәнлеген беләбез.

Аз—чөнки Пәйгамбәрнең сәхабәләреннән, яраннарыннан, көрәштәшләреннән, гомер юлдашларыннан, аннары, сәхабәләр вафат булып беткәч, ул сәхабәләрне белгән затлардан (тәбгы табигыйннәрдән—иярченнәргә иярүчеләрдән) килеп ирешкән риваятьләр дингезендә адашып каласың: бу риваятьләрнең кайберләре үзләренең чынлыгына карата шик уята. Кайчагында Пәйгамбәрнең сөекле җефете хәзрәти Гайшә сүзләренә дә тәнкыйди якын килмичә булмый (бу хакта алдарак сүз булыр).

Исламияттә кабул ителгәнчә, Мөхәммәд бине Габдулла миляди белән 570 елның 27 апрелендә (12 рабигыль-әүвәлдә) дүшәмбе көненә каршы Мәккә шәһәрендә дөньяга килә. Кайбер риваятьләрдә Мөхәммәднс әнисе Әминә сахрада таба дип тә сөйләнә. Баланың киндеген өзү өчен Аллаһы киндек әбисе итеп бер козгын җибәргән, имеш.

Бу Мәүлид кичәсе бөтен дөньяда әһле Ислам өчен мөбарәк кичәләрдән исәпләнә. Беренче тапкыр Мәүлид-шәрифне миляди белән 1207 елда Гыйракның төньягындагы Әрбил шәһәрендә билгеләп үткәннәр. Ләкин Мөхәммәд пәйгамбәр үзе исән чагында бу көнне бәйрәм итү гадәткә кермәгән һәм принципта кераә дә алмаган, чөнки Пәйгамбәр аерым шәхесләрне артык олылауны Аллаһыга ширек катыштыру, ягъни күп Аллага ышану, мәҗүсилек була дип исәпләгән. Дөрес, аерым авторлар сабый вакытында ятим калган Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең туган көнен хәтерләрлек булмаган

дип тә язалар, ләкин ул заманнарда ук инде гарәпләрдә шактый төгәл кояш календарьлары гамәлдә йөргәнлеген һәм кабиләләрдә туганлык җепләренең ныклыгын исәпкә алсак, аның туган көнен абзыйсы һәм бабасы яхшы хәтерләгән булырга тиеш.

Кыскасы,Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көнен һәм урынын билгеләүдә төрле чыганакларда чуарлык күзәтелә. Нишләмәк кирәк, ихтимал, әгәр исән чагында Пәйгамбәр Мәүлид көнен бәйрәм итүне тыймаган булса, бу мәсьәләдә бүген бәхәсмазарга урын калмаган да булыр иде. Шуна күрә, күпчелек фикере белән, Мәүлид бәйрәме Мөхәммәд пәйгамбәрнең вафат булган көнендә—рабигыль-әүвәлнең 12 сендә үткәрелә. Моның фәлсәфи нигезе бар, чөнки кешенең вафат булу көне аның фани дөньядан бакый (мәңгелек) дөньяга күчү, ягъни мәңгелек өчен туу көне дип карала.

Соңыннан Мәүлид көнен билгеләп үтү иҗмаг, ягъни иҗтимагый җыен тарафыннан бидгать хәсәнә дип,—ягъни хуп күрелә торган яңалык дип игълан ителгән. Мәүлид Мисырда XII гасырдан, Гыйракта XIII гасырдан, ә Госманлы мәмләкәтендә 1588 елдан башлап тантаналы төстә бәйрәм ителә.

Пәйгамбәр туган 570 ел гадәттән тыш вакыйгаларга нисбәтән Фил елы дип аталган. Бу елны Йәмән хакиме Әбрах Кәгъбәне яулап алу нияте белән Мәккәгә гаскәр белән юнәлә. Гаскәрендә сугыш филе дә була.Мәккәгә житәрәк, фил капыл туктап кала, бер адым да атламый. Гаскәр кире борыла, күпләр күктән яуган ташлардан яраланып һәлак була.

Мөхәммәд ибн Муса әл-Хәрәзминең "Тарих китабы"нда исә Мәүлид көне бераз башкача күрсәтелгән. Анда Пәйгамбәр Мәккәгә фил белән яу килеп илле көн үткәч, атап әйткәндә, Анушираван патшалыгының кырык икенче елында унҗиденче дей-махта дүшәмбе көнне яки Искәндәр эрасының 882 елында егерменче нисанда (яңа эраның 571 елы 20 апрель көнне) дөньяга килә диелгән. Әл-Хәрәзми Пәйгамбәр туган көнне Кояшның (Шәмс) Үгезбозау йолдызлыгында 1°та Айның (Камәр)— Арыслан йолдызлыгында 18° 10 минутта, Сатурнның—(Зөхәл) Чаян йолдызлыгында ахыргы хәрәкәтенең 9° 40 минутында, Юпитерның (Мөштәри)—Чаянда ахыргы хәрәкәтенең 2° 10 минутында, Марсның (Мәрих)—Кыслада 2° 50 минутта, Венераның (Зөһрә) Үгезбозауда 12° 10 минутта булганлыгын исәпләп чыгара (Хәрәзми Кояшның һәм планеталарның озынлыгын зодиак тамгаларының градусларында һәм минутларында күрсәтә. Бу градусларны эклиптика градусларына күчерү өчен Үгезбозау градусларына 30 градусны, Игезәкләр градусларына—60, Кысла градусларына—90, Арыслан градусларына—120, Кыз градусларына—150, Үлчәү градусларына—180, Чаян градусларына—210, Укчы градусларына—240, Кәҗәмөгез градусларына—270, Сукояр градусларына—300, Балыклар градусларына—330 градус кушарга кирәк).

Югарыда китерелгән саннарның тарихи даталарны ачыклау һәм төрле чыганаклардагы каршылыкларны, үзара ярашмаучылыкны ачыклау өчен әһәмияте бар. Хәзерге вакытта хас иткән кешегә, тәвәккәлләп, беренчел чыганакларны ныклап өйрәнгәннән соң, әлбәттә, махсус астрономик программалар яки "Интернет" ярдәмендә бу мәсьәләне компьютерда тикшерү әлләни кыен булмаса кирәк ("Күк картасы" дигән астрономик һәм "Прима", "Уранус" дигән астрологик компьютер программалары миңа беркадәр таныш, ихтимал, көчлерәкләре дә бардыр). Шул ук вакытта әлеге саннар астрологик юрауларның дөрес түгеллеген дә күрсәтәләр, чөнки, әйтик, Хәрәзминең хисаплауларына караганда, Мөхәммәд галәйһиссәламнең "пәйгамбәрлек итүгә хокукы булмаган" икән, ә чынбарлык, күргәнебезчә, мең ярым ел буена моның киресен раслый. Укучы югарыдагы саннарга игътибар итсә, бу мизгелдә Зөһрә йолдыз белән Мөштәринең бер-берсеннән ерак урнашканлыгын күрер. Мәгълүм булганча, шәрекъ мөнәҗҗимнәре (йолдыз багучылар, астрономнар) бу ике йолдыз (планета) бергә туры килгән (бер йолдызлыкта кушылышта) чакта дөньяга килгән кеше бәхетле була дип исәпләгәннәр һәм аны бәхет йөзлеге белән—"күлмәкчән" туган, сахиб кыйран зат дип йөрткәннәр. Мондый эпитет монгол ханнарына, Искәндәр Зөлкарнәйгә һәм Тимерләңгә (Аксак Тимергә) бирелгән. Тарихта бу исемне төрек солтаны Явыз Сәлимгә карата куллану да очрый. Ләкин, минемчә, әлеге очракларда сахиб кыйран эпитеты үзенең асыл мәгънәсендә кулланылмаган, ул чорлардагы шәхес культының чагылышы гына булган.

Мөхәммәд галәйһиссәлам туган көнне күктә бер "Кызыл йолдыз" пәйда булган дип тә сөйлиләр. Йолдызчы-мөнәҗҗимнәргә билгеле булганча, күк йөзенә Кызыл йолдыз чыкса, бу—пәйгамбәрне озата йөрүче йолдыз булып, ул аны хәвеф-хәтәрдән саклый икән. "Кызыл йолдыз"ның кызгылт Марс планетасы булуы ихтимал, чөнки бу

планета гарәпләргә яхшы мәгълүм булган (Мәрих планетасы) һәм урта гасыр гарәп астрологиясендә Сатурн белән Марс бәхетсезлек китерә торган йолдызлар исәбенә кертелгәннәр. Ләкин бу дәвердә күктә яңа йолдыз кабыну яки комета (койрыклы йолдыз) күренү факты да бүгенге фәнгә билгеле түгел.

Кайбер чыганакларда Мөхәммәд пәйгамбәр Искәндәр Зөлкарнәйн вафатыннан 688 ел соңрак, Дауд пәйгамбәр заманыннан 1800 ел кичкәч, Муса галәйһиссәламнән соң 2300 ел, Ибраһим пәйгамбәрдән соң 3000 ел, Нух галәйһиссәлам заманыннан 4490 ел, Адәм пәйгамбәрдән соң 5750 еллар узгач Мәккә шәһәрендә Бәниһашим сарае дип танылган йортта дөньяга килде дип бәян ителә. Әлбәттә, бу саннарны фәнни нигезләү мөмкин түгел.

Мөхәммәд пәйгамбәр чыгышы буенча гарәпләрнең корәиш кабиләсеннән була. Атасы—Габдулла, аның атасы—Габделмоталлип, аның атасы—Һашим, аның атасы—Габделманаф, аның атасы—Кусай, аның атасы—Киләп, аның атасы—Моррәт. Мөхәммәд галәйһиссәламнең егерме буынга кадәрле нәсел шәҗәрәсе билгеле.Аның анасы—Әминә Ваһаб кызы, Ваһаб—Габделманаф улы, Габделманаф исә Зөһрәнең улы булган.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең нәселе турыдан-туры төньяк гарәп кабиләләреннән берсенең башлыгы Ильяс ибн Мударның хатыны Ләйлә бинт Гыймранга барып тоташа. Бу хатынны хөрмәт иткәннәр һәм корәишларның анасы дип атаганнар.

Татарча әдәбиятта Пәйгамбәрнең исемен Мөхәммәт рәвешендә язу да еш очрый. Коръәндә һәм борынгырак Ислам әдәбиятында ул Рәсүл Әхмәд исеме белән телгә алына. Хәдисләрдә исә Пәйгамбәр үзен Мөхәммәд дип тә, Әхмәд дип тә, Мәхмүд һәм Хәмид дип тә атый. Русча әдәбиятта Мухаммад, Мухаммед, Магомет вариантлары бар.

Булачак пәйгамбәрнең балачагы һәм үсмер еллары турында мәгълүматлар аз. Шулай да, ул вакыттагы гадәт буенча, Мөхәммәднең Мәккә тирәсендәге бер авылда Хәлимә исемле бер хатында тәрбияләнүе турында хәбәрләр бар.Мөхәммәднең сөт анасы Хәлимә баланы бик ярата, чөнки аны имезергә алгач өйләренә бәрәкәт керә, малларының сөтләре арта башлый. Мөхәммәд алты айдан тәпи йөри, тугыз айда теле ачыла. Ул дүрт яшенә кадәр шушы авылда тәрбияләнә, аннары аны Мәккәгә алып килеп, үз әнкәсе хәзрәти Әминәгә тапшыралар.

Мөхәммәднең әтисе Габдулла хәзрәт улы туганчы ук үлеп китә, ә әнкәсе хәзрәти Әминә Мөхәммәдкә алты яшь чагында дөнья куя. Шуннан соң аны бабасы Габделмоталлип тәрбиягә ала, әмма ике елдан соң ул да вафат була. Ятим баланы Мөхәммәднең әтисе ягыннан абзыйсы Әбү Талиб тәрбияләп үстерә.Мөхәммәд бабасы Габделмоталлибка һәм агасы Әбү Талибка гомере буена рәхмәтле була.

Унике яшендә ул агасының озак вакытка сузылган сәүдә сәфәрендә катнаша һәм ерак Сүриягә—Шамга сәяхәт кыла. Риваятьләргә караганда, Мәккә сәүдәгәрләренең кәрваннары Бостра шәһәрендә яшәгән христиан монахы (раһиб) Бәһира өе янында туктый торган булганнар. Әбү Талиб кәрваны шунда тукталганда, Бәһира Мөхәммәдне күреп, болытларның, кояшның һәм агач ботакларының хәрәкәте буенча аның киләчәктә пәйгамбәр булачагын белеп, бу хакта Әбү Талибка сөйли. Ул ана малайны Дәмәшекъка алып бармаска киңәш бирә, чөнки анда Мөхәммәдне йәһүдиләр үтерергә мөмкин икән. Боларны ишеткәч, Әбү Талиб малларын сатып, кире Мәккәгә кайтып китә.

Шушы сәяхәте вакытында Мөхәммәд үзе үскән мәҗүси ыруг-кабилә мохитеннән аерылып торган нәсранилар (христианнар), йәһүдиләр һәм башка дин җәмәгаләре белән аралаша. Яңа дөнья белән очрашу яшь Мөхәммәдкә бик көчле тәэсир итә, аңарда рухи эзләнүләргә омтылыш уята һәм ул аңарда бөтен гомере буена саклана. Шул рәвешле ул өр-яңа дингә нигез салу фикеренә килә һәм аны тормышка ашыра.

21 яше тулганда мәккәлеләр Мөхәммәдне, ышанычлы һәм тугрылыклы кеше буларак әмин дип хөрмәтли башлыйлар. Агасы Әбү Талиб аны Һөвәйлид ибн Әсадның кызы Хәдичә исемле тол хатынга сату-алу эшләрен алып баручы сыйфатында эшкә урнаштыра. Бай Хәдичәнең сәүдә эшләре буенча Мөхәммәд тагын Сүриягә сәфәр кыла, Халебта һәм Дәмәшекътә була. Бу сәфәре вакытында ул нәсранилар һәм йәһүдиләр белән тыгыз аралаша, аларның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре һәм дини идеологиясе белән якыннан таныша.Нәсраниларның һәм йәһүдиләрнең бер генә Аллага табынуы, шөбһәсез, Мөхәммәдтә монотеистик (бер аллалык) идеясе туута һәм формалашуга ярдәм иткән. Шул ук вакытта Мөхәммәд нәсранилар белән йәһүдиләрнең үзара низагларына, бер-берсен хаталануда гаепләүләренә игътибар итә. Соңыннан Мөхәммәдкә иңгән Коръән аятьләрендә әлеге ике дини тәгълиматның нәкъ менә шушы бәхәсле

яклары беренче нәүбәттә тәнкыйть ителә дә.

Хәдичәнең хезмәтчесе Мәйсәрә (кайбер чыганаклар буенча—Мисрә) Мөхәммәднең сәүдә сәфәрләрендә ияреп йөри. Сәүдәдән кайткач, ул Хәдичәгә Мөхәммәднең намуслы һәм тугрылыклы кеше булуын сөйли. Миляди 595 елда Мөхәммәд һәм Хәди-чә өйләнешәләр. Бу вакытта инде Хәдичә кырык яшьләргә житкән һәм аның элекке ике иреннәнике улы һәм бер кызы калган була.

Хәдичә Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә беренчеләрдән булып ышана һәм аның изге иманы хакына көчен дә, байлыгын да кызганмый. Мөхәммәд Хәдичәгә тирән мәхәббәт һәм ихтирам хисе белән жавап бирә һәм аларның бәхетле никахы 25 ел дәвам итә. Шушы вакыт эчендә Мөхәммәд үзенә хәләл жефетлеккә башка бер генә хатынны да алмый. Хәдичә анардан ике угыл һәм дүрт кыз бала таба. Өлкән угыллары Касыйм ике яшьлек чагында үлеп китә һәм Мөхәммәд, борынгы гарәп йоласы буенча, Әбү әл-Касыйм дигән хөрмәтле кушамат ала. Икенче угыллары Габдулла да берничә айлык кына вакытында вафат була.Зәйнәб, Рокыйя, Өммегөлсем һәм Фатыйма исемле кызларыннан фәкать соңгысы—Фатыйма гына Мөхәммәднең нәселен дәвам итә.

Баласы туганда Рәсүлулла:"И Аллаһы тәгалә, Син аны ата-анасына игелекле, изге гамәлле, Исламда күркәм сыйфатлы итеп үстер",—дип әйтә торган булган.

Кырык яшьләрендә Мөхәммәд галәйһиссәлам буш вакытын дини уйлануларга һәм эзләнүләргә багышлый, аның эчкәреге рух киеренкелеге көчәйгәннән-көчәя һәм кайчакларда ул илһам халәте кичерә, ниндидер томанлы сурәтләр күрә һәм аңлаешсыз авазлар ишетә башлый. Гадәттә (еш кына төнлә) ул Мәккәдән өч миль ераклыгындагы Хира тавы мәгарәсенә барып ялгыз гына уйга чума һәм өчәр көн өенә кайтмыйча гыйбадәт кыла торган була. Шундый мизгелләрнең берсендә Мөхәммәд үзенә кешеләргә Аллаһ сүзләрен житкерергә боерган Жәбраил фәрештәне аермачык күрә (46 нчы сүрә). Мөхәммәд курка кала һәм озак кына вакыт буена рухи төшенкелеккә бирелә. Пәйгамбәргә өч ел буена Аллаһыдан вәхи килү киселеп торган ара фитрәт заманы дип атала. Аннары вәхи килү тагын янарган. Жәбраилнең Мөхәммәд пәйгамбәргә Аллаһыдан вәхи китерми торуының сәбәбе Пәйгамбәребезне сабырлыкка өйрәтүгә, аның тугрылыгын һәм намус камиллеген сынауга бәйле булган дип исәпләнелә. Бу төшенкелектән чыгарга аңа янә шушы өн ярдәм итә, бу юлы да Мөхәммәдкә Аллаһы сүзләре белән кешеләр катына барырга әмер бирелә (73, 74 нче сүрәләр).

Риваятьләрдә бу вакыйгалар тәфсилләп сурәтләнә. Рамазан кичәләренең берсендә Мөхәммәд каршысына кулына язулы төргәк тоткан бер зат (Жәбраил) килеп баса да:"Укы!"—дип әмер бирә. "Мин укый белмим, "—дип жавап бирә Мөхәммәд. Бу зат Мөхәммәднең күкрәген кыса, хәтта аның чак кына сулышы өзелми кала. Аннары тагы:"Укыгыл!"—дип боера. Мөхәммәд янә:"Мин укый белмим",—ди. Жәбраил тагын аның күкрәгенә баса. Куркуга калган Мөхәммәд:"Нәрсәне укыйм соң мин?"—дип сорый. "И Мөхәммәд, Коръәнне укы Раббың исеме илә! Ул хәлык кылды (юктан бар итте) кешене оешкан каннан",—дигән жавап ишетелә. Һәм Мөхәммәд язылган сүзләрне кабатлый.Аңына килгәч ул бу сәер сүзләрне үзенең йөрәгенә язылган кебек итеп тоя. Мөхәммәд мәгарәдән чыккач, күктән: "И Мөхәммәд, син—Аллаһының илчесе, ә мин—Жәбраилмен",—дигән тавыш ишетә. Мөхәммәд пәйгамбәр күрә: Жәбраил фәрештәнең аяклары жирдә, ә башы күккә ирешкән, канатлары мәгъриб белән мәшрикъкә житә. Аның аяклары сары, канатлары—яшел, йөзе—нурлы, тешләре—ак һәм чәчләре кызыл мәржән төсендә икән. Кайбер хәбәрләрдә Жәбраил фәрештәнең алты йөз мең канаты, башында тажы булуы дә әйтелә. Мөхәммәд пәйгамбәр кая таба гына борылмасын, аның каршысына Жәбраил килеп баса.

Мөхәммәд пәйгамбәр Мәккәдә вакытта, аңа 52 яшь чагында, һижрәттән ел ярым элек, рәжәбнең егерме жиденче кичәсендә (егерме алтынчы рәжәбтә кояш баеганнан соңгы кичә) хәзрәте Рәсүл күкләргә менү вакыйгасын күргән (Жәбраил фәрештә алып килгән канатлы Буракка атланып Мәккәдән Бәйтелмөкатдәскә—Иерусалимга, аннары, Буракны шунда калдырып,Аллаһы янына сәяхәте.Бурак—"ялтыр" яки "яшендәй житез" мәгънәсендәге әл-Бурак сүзеннән. Кайбер чыганакларда ат яки качыр дип тә атала. Мөхәммәд пәйгамбәргә кадәр Бурак башка пәйгамбәрләргә дә, хосусан, Ибраһим галәйһиссәламгә хезмәт иткән дип исәпләнелә. Урта гасырлар ахырында Буракны адәм башлы ат сурәтендә күзаллый башлаганнар. Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, кыямәт көнендә Мөхәммәд пәйгамбәр шушы Буракка атланып жәннәткә керәчәк).Күкләргә менгәч, Рәсүл әүвәлге пәйгамбәрләрнең жаннарын күреп, алар

белән сөйләшкән. Бу кичәдә ул фәрештәләрне вә җәннәтләрне, Аллаһуның күкләрдәге төрле гаҗәеп вакыйгаларын да күрә. Биш вакыт намазның фарыз булуы да Аллаһы тәгалә тарафыннан аңа шушы кичәдә җиткерелгән.Ахырда Мөхәммәд галәйһиссәлам Мәккәгә кайтарыла. Бу кичә "Ләйләт әл-Мигъраҗ", Мигъраҗ төне дип атала.

Мәккә халкы Мөхәммәд Пәйгамбәрнең Мигъраҗ төне турында сөйләгән сүзләренә тиз генә ышанмаган.Шул чагында Аллаһы тәгалә Пәйгамбәргә Иерусалимне кабат күрсәткән һәм Мөхәммәд галәйһиссәлам, ул шәһәрдән Мәккәгә таба килә торган кәрванны күреп, кәрванның биш көннән Мәккәгә керәчәген алдан хәбәр итә. Бу вакыйга рамазанның унөченче кичәсендә, шимбәгә каршы булган. Шуна күрә ошбу кичә дә мөбарәк кичәләрдән санала һәм Исраил кичәсе дип атала.

Исламият гыйльмендә Мигъраҗ төне турында бәхәс әледән-әле калкып чыга. Мөхәммәд пәйгамбәр күккә рухы белән генәме, әллә тәне белән бергә ашканмы дигән сорау бәхәс кузгата. Коръәннең 17 нче сүрәсен хәрефкә-хәреф аңлату яклы галимнәр бар. Бу аятьтә: "Үзенең колы Мөхәммәд галәйһиссәламне бер кичтә Мәккә шәһәрендәге мәсҗид Хәрамнан Коддус шәһәрендәге мәсҗид Әксагә йөретеп кайтаручы Аллаһы Тәгаләне һәр кимчелектән пакь дип белегез!" диелгән ("Тәфсир Ногмани" буенча). Мондагы "кол" сүзенә нигезләнеп, әлеге галимнәр:кол—тере зат, аның җаны вә тәне бар һәм, димәк, Мөхәммәднең җаны күккә тәне белән ашкан, диләр.

Дөрес, моңа каршы килә торган хәдисләр дә бар. Аннары Пәйгамбәрнең җәмәгате Гайшәнең:"Аның тәне минем тәнемнән аерылмады!" дигән сүзләре билгеле. Хәдисләр җыючы мәшһүр әл-Бохари, әт-Тирмизи һәм ән-Нисаи, Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәхабәләре Ибн Габбас белән Мөгавия Гайшә сүзләренә таянганнар һәм Рәсүлуллаһның күкләргә төшендә ашканлыгына шикләнмәгәннәр, дип язалар.

Әмма кайбер галимнәр хәзрәти Гайшә сүзләренә шик белән карыйлар, чөнки, диләр алар, Гайшә Һиҗрәдән соң, ягъни Мигъраҗдан соң гына Мөхәммәд пәйгамбәр белән никахлаша, димәк, ул Мөхәммәднең күккә ашуын белә дә алмаган.

Мигъраҗ кичәсендәге хәлләр турында урта гасырларда гарәп телендә бик бай халык әдәбияты туган. Бу китаплар Европага да мәгълүм булган һәм алар, мәсәлән, Дантеның "Илаһи комедия" әсәренә чыганак булып хезмәт иткән дип уйланыла.

Югарыда әйтелгәнчә, хатыны Хәдичә Мөхәммәднең Аллаһы рәсүле булуына беренче булып ышана һәм тиздән аңа туганнан туганы Гали бине Әбү Талиб һәм Мөхәммәднең тәрбиягә алган улы Зәед бине Харис кушылалар.Аннары атаклы Мәккә сәүдәгәре Әбү Бәкер әс-Сиддыйк, әз-Зөбәер, Тәлһа, Сәгыйть бине Гауф, Госман бине Гаффан һәм Габдрахманнар Мөхәммәд Рәсүлулла тәгълиматына иман китерәләр. Башта Пәйгамбәрнең сәхабәләре 50 кешедән артмый һәм аларның күбесе аның туганнары һәм якыннары була. Әмма Мәккә җәмәгасе, бигрәк тә йогынтылы корайшитлар яңа тәгълиматка һәм аның тарафдарларына ачыктан-ачык дошманлык белдергәннәр, шуның аркасында унбер сәхабә гаиләләре белән бергә ашыгыч төстә Хәбәшстанга (Эфиопиягә) күчеп китәргә мәҗбүр булган.

Ирдәрлыклары, гайрәтләре һәм Пәйгамбәргә ихлас күңелдән бирелгәнлекләре белән танылган Хәмзә һәм Гомәр яңа дини җәмәгагә кушылгач, аның сафлары ныгый төшә, ләкин корайшитларның яңа тәгълиматка һәм имам Мөхәммәдкә карата дошманлыгы да көчәя. 610—620 елларда бер аллалыкны гына таный торган Ислам белән мәҗүсилек арасында туктаусыз көрәш бара.

620 елда Мөхәммәд пәйгамбәрнең ышанычлы таянычы булган Хәдичә дөнья куя, ике ай үткәч Әбү Талиб вафат була һәм Пәйгамбәргә дошманнары белән көрәшү тагын да кыенлаша. Әбү Талибтан соң ыру башлыгы булып саналган Әбү Ләхәб Мөхәммәдне үз химаясенә алудан баш тарта.Кабиләсе тарафыннан кире кагылган Пәйгамбәр Мәккәдән 100 чакрым чамасы көнчыгышка таба урнашкан Таифтә үзенә таяныч эзләп карый, ләкин уңышка ирешми.

Аңа ярдәм бөтенләй көтелмәгән тарафтан—Мәккәдән 400 чакрымнар төньяктагы зур игенчелек оазисы булган Йасрибтән килә. Андагы мәҗүси һәм йәһүд дине кабул иткән төрле гарәп кабиләләре үзара низаглардан тәмам туеп, абруйлы Мөхәммәдне битараф мәхкәмәче сыйфатында үзләренә чакыралар.Мәккәгә мәҗүси хаҗ кылырга килгән 70 ләп Йасриб кешесе Мөхәммәдкә ышаныч белдереп, аның тәгълиматын үзүзләрен аямыйча якларга ант итәләр. Соңыннан алар моның өчен әнсарлар—Мөхәммәднең ярдәмчеләре, сәхабәләре дигән дәрәҗәле исемгә лаек булганнар.

Мөхәммәд галәйһиссәламнең үз туганнары арасында да дошманнары була.

Мәсәлән, аның атасы белән бер туган агасы Габдел Гоззә бин Габдел Моталлиб тарихка Әбү Ләһәб кушаматы белән кереп калган. Ул үзе дә, хатыны да Пәйгамбәрнең явыз дошманнары булганнар.Риваятьләрдә аларның хәзрәти Рәсүлгә һич тынычлык бирмәүләре, намаз укый башласа, өстенә пычрак нәрсәләр ыргытулары, йөри торган юлына чәнечкеле чыбыклар китереп салулары тасвир ителә.

Коръәндә "Сүрәи Мәсәд"нең ("Бау сүрәсе":111) аятьләрендә Әбү Ләһәбнең һәлак булачагы, тәмуг утына керәчәге, ә хатынының шунда утын ташучы булачагы әйтелә (әбү Ләһәб—ут атасы).

Риваятьтә сөйләнгәнчә, Әбү Җаһил (ата надан мәгънәсендә) дигән бер йогынтылы кеше, әгәр Мөхәммәднең сәҗдә кылганын күрә калсам, әлбәттә, сәҗдәдә аның муенын өзәрмен, дип яный. Бер көн Пәйгамбәр намаз укыган вакытта Әбү Җаһилгә бу хакта хәбәр кылалар һәм ул ашыгып шунда юнәлә. Ләкин ул Пәйгамбәр янына ук килеп җитә алмый, кире дүнә, үзенең барча әгъзалары калтырый."Сиңа ни булды?"—дип сорыйлар анардан.Ул:"Мөхәммәд белән үземнең арамда уттан бер дивар күрдем, аз гына янмыйча калдым,"—дип җавап бирә.Бу хәбәр килеп ирешкәч, хәзрәти Мөхәммәд: "Әгәр минем яныма килеп җиткән булса иде, фәрештәләр аны парә-парә кылып ташлаган булырлар иде,"—дигән.

Шулай да бу вакытларда Мөхәммәдкә һәм аның тарафдарларына Мәккәдә дошманнары кулыннан үлем куркынычы яный һәм ул Йасрибкә күчеп китәргә карар кыла.

Мөхәммәднең сәхабәләре гаиләләре белән Йасрибкә вак төркемнәр булып, корайшитларга сиздермичә генә качып китәләр. Моңа Мәккә кешеләренең, бигрәк тә түрәләрнең, Пәйгамбәрне һәлак итәргә ниятләве сәбәп була. Мәккә аксөякләре һәр кабиләдән берәр кеше сайлап алалар, ул кешеләрнең һәрберсе Мөхәммәд галәйһиссәламгә таяк белән сугарга тиеш була.Әмма Пәйгамбәр моны белеп ала һәм үзенең тугрылыклы сәхабәсе Әбүбәкер белән өеннән чыгып китә һәм алар Мәккә тирәсендәге Тәүр (Сәүр) дигән тауда бер мәгарәдә яшеренеп яталар.Эзәрлекләүчеләр һәр тарафны тентеп йөриләр, мәгарә авызын да килеп карыйлар. Ләкин алар мәгарә авызына үрмәкүч пәрәвез сарганын һәм оясында утырган кыргый күгәрченне күргәч, монда кеше аягы басмаган дип уйлап, борылып китәләр. Аллаһы тәгалә Пәйгамбәрне һәм аның сәхабәсен шулай коткара.Өч көннән соң, кяфирләр арасында шау-шу тынгач, Пәйгамбәр белән аның сәхабәсе, мәгарәдән чыгып, Мәдинәгә юл тоталар. Алар Мәдинәгә килеп җиткән көн миляди 622 елның 17 сентябренә туры килә дип исәпләнелә, ләкин 24 сентябрь дигән ихтималлык та бар.

Гомәр хәлифә заманында Пәйгамбәрнең Мәдинәгә Һиҗрә кылу (күчү) вакыты яңача ел хисабының башлангычы итеп алына (дөрес, Пәйгамбәрнең Мәдинәгә килеп җиткән көне түгел, бәлки шул елдагы мөхәррәм аеның беренче көне, ягъни 622 елның 16 нчы июле). Шул көннән һиҗри ел исәбе башлана.

Шул рәвешле Йасрибтә Мөхәммәд Пәйгамбәр тирәсендә тупланган мөселманнар җәмәгатьчелеге (өммәт) барлыкка килә. Бу тәшкиләтнең (оешманың) дини, дөньяви, милли һәм хәрби җитәкчесе Мөхәммәд Рәсүлуллаһ була. Соңгы дистә елларда совет хакимияте шартларында тәмам таушалып, беренчел мәгънәсен җуйган "җитәкче"(куллан тотып алга алып баручы) сүзе бу урында нәкъ үзенең асыл мәгънәсенә туры килгәнлеген әйтеп китмичә булмый. Бирердә ул гади вәгазьчедән чын мәгънәсендә Аллаһының илчесенә әверелә, кешеләргә бу тормышта кулланылырга тиешле илаһи канунnarны өйрәтә башлый. Яңа диннең төп йола-мәрасимнәрен һәм мөселманча яшәү рәвешенең төп кагыйдәләрен баян итү Пәйгамбәрнең Йасрибтә яшәү чорына туры килә. Никах йоласы һәм җәмәгать ихтыяҗлары өчен акча-мал җыю тәртибе, мирас алу, мөлкәтне бүлү һәм кредит бирү кагыйдәләре шушы вакытта эшләнә. Шуңа күрә Йасрибне соңыннан Мәдинә-и ән-Нәби, ягъни Пәйгамбәр шәһәре дип атый башлыйлар. Аның бүгенге рәсми исеме әл-Мәдинә, яки кыска гына—Мәдинә шәһәре.

Һиҗрәнең икенче елында Мөхәммәд галәйһиссәлам кыйбланы үзгәртеп, гыйбадәт кылганда Иерусалимга түгел, бәлки Мәккәдәге гыйбадәтханәгә—Кәгъбәгә карап укырга куша. Моның стратегик әһәмияте һәм максаты шунда ки, инде хәзер бөтен Көнбатыш Гарәбстанның төп дини үзәге булган Мәккә шәһәрен буйсындырырга кирәк була.

Мөхәммәд галәйһиссәлам мәккәлеләр белән көрәш башлап җибәрә, иң әүвәле аларның кәрван куып сәүдә итүенә комачау тудыра. 624 елда Бәдер янындагы сугыштаМөхәммәд пәйгамбәр җитәкләгән мөселманнар үзләреннән шактый күбрәк

сандагы мәккәлеләрне җиңүгә ирешәләр. Бу сугышта Пәйгамбәрнең дошманы, югарыда телгә алынган Әбү Җәһил үтерелә. 625 елда исә мәккәлеләр Мәдинә шәһәренә һөҗүм итәләр.Өхөд сугышы дип атала торган бу бәрелеш мөселманнар өчен уңышсыз тәмамлана, Мөхәммәд пәйгамбәр яралана. Икенче елны мәдинәләләр, фарсы кешесе Сәлмән киңәшен тотып, мәккәләләр юлына чокыр ("хәндак"—ур. траншея, окоп; Гариф Гобәй һәм Мәҗит Гафури кулланган "канау" сүзе бу урында туры килеп бетми шикелле) казыйлар һәм аларның яңа һөҗүмен кире кайтаралар (Хәндак янындагы сугыш).

Мәдинәдәге эчке оппозициянен Мәккә белән элемтәсенә каршы Мөхәммәд пәйгамбәр хәлиткеч чаралар күрә. Пәйгамбәрнең дошманнары үтерелә, йәһүд кабиләләре шәһәрдән куыла.

628 елда мөселманнарның зур гаскәре, Пәйгамбәр җитәкчелегендә, Мәккә ягына яу белән чыгып китә, ләкин эш сугыш хәрәкәтләренә тикле барып җитми. Ходайбийа бистәсендә мәккәлеләр белән сөйләшүләр нәтиҗәсендә солых төзелә. Бер елдан соң Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның сәхабәләренә Мәккәгә килеп хаж кылырга рөхсәт ителә. Пәйгамбәрнең хакимлеге ныгый, күп кенә мәккәләләр аның ягына чыгалар. 630 нчы елда Мәккә сугышсыз гына Мөхәммәд пәйгамбәргә бирелә. Егерме беренче рамазанда булган бу җиңү көне, ягъни Мәккәи Мөкәррәмәне кяферләр кулыннан алган көн мөбарәк санала һәм Фәтех Мәккә көне дип атала.

Туган шәһәренә аяк баскач, Мөхәммәд пәйгамбәр Кәгъбәгә сәҗдә кыла, биредәге пот-санәмнәрне җимертеп, Кәгъбәи Мөгаззәмәдән чыгарта, фәкать "Кара таш"ны ("Әл-хәҗәр әл-әсвәд"ны) гына калдыра.Моннан соң да Мөхәммәд Мәдинәдә яшәвен дәвам итә. Һиҗрәтнең тугызынчы елында ул Әбүбәкер хәзрәтне баш кылып, Мәккәгә хаж (гомрә) кылырга җибәрә. Менә шушы хаж иң беренче кылынган хаж дип исәпләнә. Һиҗри унынчы елда изге Зөлхиҗҗә аеның сигезенче көнендә (632 елның мартында) Мөхәммәд Пәйгамбәр үзенең бөтен гаиләсе белән бергә"Олуг хаж" ("әл-хаҗ әл-әкбәр") кыла. Беренче һәм соңгы тапкыр кылынган бу тулы хаҗны "Хушлашу хаҗы" ("Хәҗҗәт әл-вәдаг") дип тә атыйлар. Тугызынчы зөлхиҗҗәдә Пәйгамбәр Гарәфәттә хотбә укый, аннары "Әлйәүмә әкмәләтү" аятен укып, өммәтенә гомеренең аз калганлыгына ишарә кыла һәм васыятен сөйли.

Моннан соң Мәккәнең Ислам мәркәзе буларак роле тагы да ныгый.Мөхәммәд пәйгамбәр "Хушлашу хаҗы" вакытында биргән хаж гамәлләре моннан соңгы гасырларда һичбер үзгәрешсез һәм каттый төстә башкарылып килә.

Мәдинәдә мөселман мәзһәбләре барлыкка килгән чорда (622—632) имам хезмәтен Мөхәммәд галәйһиссәлам үзе башкара, кайчакта имамлыкны Әбү Бәкергә яисә Гомәргә тапшыра.

Гарәбстанда Мөхәммәд пәйгамбәрнең абруе ныгый. Төрле гарәп кабиләләренең вәкилләре килеп, әчың белән берләшү турында сүз куешалар, Ислам динен кабул итәләр. Шулай итеп, Гарәбстанның шактый өлеше Мөхәммәд пәйгамбәр җитәкләгән дини-сәяси тәшкиләткә кушыла. Дөрес, сакиф һәм һәвазин кабиләләре Мөхәммәд пәйгамбәр тарафдарларына каршы кораллы көрәшкә дә кузгалып карыйлар, әмма Хунайн үзәнендә тар-мар ителәләр. Бу җиңүдән соң, мөселманнар кыенлыксыз гына Таиф шәһәрен алалар да, беренче эш итеп җирле әл-Лут алиһәсе потханәсен җимерәләр.

Мөхәммәд пәйгамбәр бу берлекнең хакимлеген төньякка, Фәләстыйнга һәм Сүриягә дә җәелдерергә хәзерләнә, ләкин 632 елда вафат була. Әхмәдһади Максудиның "Гыйбадәте Исламия" китабында бу дата "Тарих милядиның 631 елында 8 июньдә вә тарихе һиҗриянең 11 елында уникенче рабигыль-әүвәл дүшәмбе көн өйлә вакытында" (Мәҗит Гафурида "төштән элек") дип күрсәтелгән.Җан биргәндә Пәйгамбәрнең янында сөекле хатыны Гайшә була. Пәйгамбәрнең җәсәден юууда аның кияве Гали һәм агасы Габбас катнашалар. Мөхәммәд галәйһиссәлам Мәдинәдәге мәчеттә җирләнгән.Пәйгамбәрнең кабер шәрифе "Рәүзаи мотаһһәрә" ("Изге бакча") дип атала.

Коръән Кәрим Мөхәммәд пәйгамбәр инсаниятькә калдырган Ислам диненең нигезен тәшкил итә. Аллаһы тәгалә Коръәнне үзенең пәйгамбәренә 23 ел буена диярлек хәбәр итеп килгән (610—632 миляди еллар), ә Мөхәммәд галәйһиссәлам илаһи вәхиләрне килгән мизгелдә үк кешеләргә тапшырган яки элек ишеткәннәрен халыкка кабатлаган.

*Ахыры киләсе санда*

*Хәтер*

Фуат Маннапов

# БАБАЕМНЫҢ ТОРМЫШ ФӘЛСӘФӘСЕ: КЕШЕ ХАКЫ

ИСТӘЛЕК



*Рәсемдә: әдип Әмирхан Еники белән Фуат Маннапов.*

*... Мәскәүдә яшәүче күптәнге дустым Фуат Маннапов миңа бик кызыклы язмасын җибәргән. Укый башлагач, язма гаять җитди бер мәсьәләне күзгатуы белән мине бик мавыктырды. Фуат гади-садә генә итеп, бала чагында бабасыннан ишеткәннәрен яза. Бабасы Троицкида гомер сөргән гади татар карты, исеме Хәкимҗан—бүрекче Хәким дип йөрткәннәр...*

*Троицкий ул татарның элек шактый зур дан тоткан сәүдә һәм мәдәни үзәге булган. Анда яшәүче безнең халык та, ничек дим, әдәплерәк тә, инсафлырак та булган шикелле—бабай сүзләреннән дә шулайрак сизелә. Дустым Фуат та шул шәһәрдә туып үскән—аңа карап та моны әйтеп була: бик татар җанлы, бик инсафлы кеше ул...*

*Әмма бүрекче Хәким картның 5-6 яшьлек оныгы Фуатка сөйләгәннәрен мин, үзе бер бик гыйбрәтле тормыш фәлсәфәсе дияр идем... Сез язманың башына куелган "Кеше хакы" дигән сүзгә игътибар итегез әле! Хәзерге заманда күп илләрнең конституциясенә төп маддә булып кертелгән гаять кирәкле бик зур сүз ул "Кеше хакы!"... Минә ул "Кеше хакы" дигән төшенчә, бактың исә, безнең татарларда бик борыннан ук сакланып килгән әхлакый яшәү кагыйдәсе булган... Хәкимҗан карт "Кеше хакы"ның адәм балалары өчен күп яклы әхлакый бер зарурият булуын оныгына аңлатып бирә... "Күрше хакы", "Бала хакы", "Туган хакы" кебек төшенчәләрне дә "Кеше хакы" үз эченә ала, ди ул... Минә шул әхлакый таләпләрне иманлы татарлар борын-борыннан ук үзара мөнәсәбәтләрендә һәрвакыт исләрендә тотарга һәм үтәргә тырышып яшәгәннәр.*

*Фуат Маннапов бабасын сагынып язган шушы истәлегендә моңарчы бездә ничектер юньләп телгә алынмаган, әмма халкыбызның рухи дөньясын аңлау өчен гаять мөһим булган бик кирәкле бер мәсьәләне кузгаткан... Әйткәнемчә, гади-садә генә язылган истәлеген укып чыккач, табигый рәвештә үзеннән үзе бик урынлы бер сорау туа: "Кеше хакы" дигән әхлакый кагыйдә безнең хәзерге заман кешеләрендә бармы ул?! Әллә инде бөтенләй онтылды, юкка чыктымы?.. Укучы күңелендә шушы борчулы сорауны уятуы белән бик әһәмиятле дә Фуат Маннаповның бу истәлек язмасы!..*

**Әмирхан ЕНИКИ**

* * *

Бабаем... Минем бабаем бар иде. Ул бик ат ярата, ат тотарга рөхсәт итмәгәннәренә гомере буе өзгәләнеп яшәде... Ул 1953 елның суык февралендә көтмәгәндә вафат булды.

Әтием исә горисполком рәисен йөрткән, шәһәрнең иң яхшы атын сорап алды. Мәчеткә кадәр бабаемның җеназасын күтәреп илттеләр, мәчеттән зиратка бабайның яраткан, сагынып яшәгән атына салып алып бардылар. Әти атны көчкә тотып барды. Зиратка бик күп халык җәяүләп тә килгәннәр иде.

Безнең Тройцкий шәһәрендә күп кешенең кушаматы бар иде. Кара Ибрай, Сучы Йосыф, Күркә Шәрип дип йөртәләр. Безнең бабайны Бүрекче Хәким диләр. Бабайны озатырга Сәгыйт башкорт та килгән. Аның өе шәһәрнең иң читендә, яр кырыена кәздән сылатып эшләнгән. Ат тотам дип, налогтан таланып, бөлеп беткән. Өендә самавыры да, биш тиен бакыр белән ямалган казанынннан башка әйбере калмаган. Җәй буе лесхозда печән чаба. Өенә барган кеше кerә алмый азаплана. Өй ишегенең тоткасы юк. Сәгыйт абзый көлеп утыра. Газраил килсә, бу бәндәнең эше бетмәгән икән дип борылып китәр иде.

Ул атын бабай белән саубуллашырга алып килгән. Мич янына казакълар һәм кыргызлар кия торган колакчынсыз кышкы бүреген—томагын тез астына кыстырып утырган. Карт әкрен генә елый: "Хәкимҗан агаем, телең кешегә, камчың атыңа тимәде. Инде минә ялгыз мин генә торып калдым. Ничек була инде бу? Мине ятим иттең дә үлдең дә киттең..."

Сәгыйт абзый үзе 1961 елны дөнья куйды. Ярый әле Хрущевның тагын бер яманлыгын күрә алмый китте. Зур заводларның эшчеләренә ашатырга ит беткәч, колхоз атларын суйдырып, ашханәләрдә ат итеннән күп итеп күмәч кушкан котлет ашаттылар. Сәгыйт абзыйның атын да, үзе үлү белән, фининспектор түләнми калган салым өчен, иткомбинатына, колхоз атларының соңгы юлына алып китте.

Бабаем кол түгел иде. Ул заманаңың явызлыкларына теше-тырнагы белән каршы, кеше хакын саклау, кеше булып яшәү өчен бөтен көчен куеп яшәде. Гитлер кем дә? Ленин, Сталин кем? Туган ил нәрсә? Сатылу, коллык нәрсәдән килеп чыга? Әхлак кагыйдәләре, дини кагыйдәләр турында бабаем миңа аңлатып сөйләп утыра. Миңа нибары җиде яшь. Бабаем искиткеч матур әкиятләр дә белә. Аларны мавыктыргыч итеп сөйли. Бу әкиятләрне үскәч бер китаптан да таба алмадым. Кызганычка каршы, язып куймаганмын.

Бөек Ватан сугышы башланган елны җәй бик коры, янгырсыз булып аптыратты. Дала көя, яна. Миңа инде 8 яшь. Ике тәгәрмәчле кечкенә арбаны өстерәп, елга буендагы инкел җирләрдән үлән эзләп, бабай белән унбер-унике чакрымга китәбез. Шулай йөреп көн аралаш сыерга үлән җыябыз. Комнан арба тартып кайтуы бөтенләй хәлне ала. Бабай арттан таягы белән арбаны этеп кайткан була. Иң кызыгы—су буенда ашап утыру, яки бабайны тыңлау. Кояш эссесенә күперә башлаган катыкны барып житү белән бабай чишмә суына тыгып куя. Елга буенда бабай гына белгән чишмәләр күп, сулары да боз эченнән чыккан төсле салкын, тешкә тия. Сөйләгәндә бабаем бер кешене каргамый да, ачуланмый да. Ул һәр эш-гамәлнең ялгышлыкларын, кеше хакының бозылган җирләрен аңлатып, сөйләп утыра. Мин сабыйга җитди итеп сөйли.

Бабай үлгәч, читкә укырга киттем, хәрби хезмәткә эләктем. Ел саен, берничә көнгә булса да кайтып, бабаем зиратына барам, кырык елдан соң кайтканымда

бабаем чишмәләрен эзләп карадым. Троицкида, Европаның иң зур электростанцияләреннән берсен төзегәннәр, мәһабәт буа-плотина эшләгәннәр. Елга буендагы чишмәләр су астында калганнар, ә урмандагы чишмәләр кибеп беткәннәр.

Безнең өйдә иң матур нәрсә стенага эленгән, шкаф кадәр зур борынгы сәгать иде. Һәр өйдә стена сәгате, самавыр, казан була. Бабай үлү белән сәгатебез туктады. Сәгатьче Шиһаб абзый да рәтли алмагач, аны чоланга чыгарып куйдылар. Кайсы вакытта эш шул сәгатьтән генә торган шикелле булып куя. Сәгатьне җибәрсәм, бабаем сөйләгән тормыш, кеше хакын саклап яшәү, бабаемның матур кагыйдәләре кайтыр төсле була. Кибетләрдә эленеп торган сәгатьләрдән аерыла алмый уйланып азаплана торган гадәтем калды.

Бабаем... Бабаем миңа кеше хакы нәрсә ул һәм аны бозудан нәрсәләр килеп чыкканын өйрәтте. Ул хак сүзенең мәгънәсен бик киң итеп аңлый: чын, дөрес, нәкъ үзе, изге, гадел, кешенең өлеше, хокук, вәкаләт, бәя, эш хакын түләү, шәхси милек, Алла, Тәңре, Ходай...

Бабаем дөньяда яшәгәндә ике төрле төп кагыйдәләрне саклап яшәргә кирәк дип исәпли иде.

Беренчесе, Аллаһы Тәгалә, безгә акыл, сөйләшү сәләте һәм ихтыяр көче биргән. Ирекле ихтыяр, көчле акыл ияләре җәмгыятьтә аралашып яшәсеннәр һәм үз чамаларын югалтмасыннар өчен аларга дини кагыйдәләр бирелгән. Адәм галәйһиссәлам яратылганнан бирле җыелып килгән шушы әхлакый кагыйдәләр белән әдәп, вөҗдан һәм оятның нәрсә икәнен белгән кешеләр генә җир йөзендә гадел хөкемгә лаек и::саннар була алалар. Болар—Аллаһы Тәгаләдән иңгән дини кагыйдәләр.

Икенчесе, кеше хакын саклап яшәү кагыйдәләре. Бер яктан, кеше хакы, ул чит кеше хакы кебек. Икенче яктан, ул минем кеше хакым. Кеше хакы нәрсә соң ул?

Кеше хакы ул Ходайдан куелган, кешеләрнең бер-берсенә булган кара каршы бурычы.

Уралдагы Уй дигән елга буенда Россиянең башка шәһәрләренә дә үрнәк булырлык итеп төзелгән бик матур кала тора. Ул минем туган калам—данлыклы Троицкий каласы. Аның ярминкәләрендә Россия Азия илләре белән сәүдә иткән. Шәһәрнең бер-ике катлы өйләрен, челтәрләп чуеннан коелган коймаларын, капкаларын, зур ташлар җәелгән урамнарын матурлап эшләткән булганнар. Революциядән соң 1953 елга кадәр шәһәрдә бер йорт та салмадылар. Мәктәп укучыларыннан матур челтәрле чуеннарны җыйдырып, металлоломга илттерделәр. Мәчетләрен, чиркәүләрен дә ваткаладылар. Шәһәрдә ике монастырь, биш чиркәү, католиклар чиркәве, синагога, җиде мәчет бар иде.

Татар мәдәниятенең үзәге! Троицкиның үзендә Рәсүлия, Мөхәммәдия һәм Галия мәдрәсәләре булган! Дәрелмөгаллимәт мәктәбендә татар кызларын, Казан белән Уфадан алдарак, урысча укыта башлаганнар. Анда Мәҗит Гафури укыган, Крылов, Даль, Плевако, Атилла Расих торган. Кыскасы, бик күп зыялылар чыккан шәһәр ул.

Анда кояшның радиация көче дә Кавказ белән Кырымнардан көчлерәк. Әйләнәтирәдә үскән бодайлары гомер-гомергә чит илләргә китә барды.

Революциягә кадәр Троицкида сәүдә һәм тынычлык хөкем сөргән. Әле сугыштан соң да, һәрберсе 500-600 сыердан торган биш-алты көтү чыгадыр иде. Яшелчә, мал, ит, печән, иген, такта, он...—толкучка базарлары гөрләп торыр иде. Кибеттә азыктөлек булмый дисәң дә ярый. Халык бар нәрсәне базардан ала. Урта Азия кешеләре дә күренгәлиләр. Базарлар 25-30 гектар җирне биләп торалар. Хөкүмәт бик күп көч түгеп, җирен бетереп кенә, базарны туктатты, юк итте. Хрушевның сыер тоткан өчен салган налогы дөньяны бөтенләй үзгәртте, харап итеп ташлады.

Мәчетләрнең дә иң матурларын сугыштан соң ваттылар.

Шәһәр башкарма комитеты урнашкан борынгы Шәһәр Думасы йортына каршы бик матур чиркәү бар иде. Башындагы тәреләрен революция вакытында кәкрәйтеп бетергәннәр. Шулай да Троицкига килгән бер кеше аңа сокланмый китми иде. Чиркәү янында бакча. Коймасы матур, челтәрле чуеннан. Ленин бакчасы дип йөртәләр. Монда Ленинга куелган һәйкәл бар (бюст). Постаменты Николай патшаныкы. Абзыйлар бу һәйкәл яныннан узганда: "Николайның к...нә Ленин башын куйганнар"—дип җырлап узгалыйлар.

Алтмышынчы елларда матур чиркәүне шартлаттылар. Ленин бакчасын бетереп, урынына өч катлы йорт салдылар, горисполком белән горкомга. Шәһәрнең иң матур җире юкка чыкты.

1950-1951 елларда бабай белән әти, сыер утлыгының кырыена утырып, сөйләшеп утыралар. Бабайның: "Ул Урта Азия, Казакъстан, Украина, Кавказ китәр, Россия 11 кисәккә бүленер",—дигән сүзләре мине аптыраткан иде... Арттырып җибәрде, дигәнмендер. Бу сүзләр Империя ярым таркалгач искә төште.

НЭП бетү белән бабай бодай җыя башлаган. Аты бар. Базардан сатып алып кайтканын кеше күрми кала. Ларларны утын, печән астына яшереп куйган. Озакламый бабай ике таш алып кайтып кул тегермәне ясап куйды. Ул арада сугыш башланды.

Машиналар чыгу белән Троицкий урамнарының рәте китте. Урыны-урыны белән урамнар үтә алмаслык пычрак була. Мин чүпрәктән сырган читектән, агач калып бәйләп йөрим. Барыбызның да әтиләребез сугышта, ә минем әле бабаем бар. Мин бай малаймын. Башка балаларга ашарга талон бирәләр, алар барып солы боткасы ашап кайталар. Ләкин без ачлык күрмибез. Бәрәңге, тарткан бодай боткасы, сөт бар. Кайсыбер көнне бүген күмәч юк диләр. Кечке ашка 18 җан булып утырабыз: дәү апайлар, җиңгиләр, туган апайлар. Уллары, ирләре сугышта. Алар барысы да бабайга киләләр. Капканы ачу белән: "Абый җаным",—дип дәшеп керәләр.

Әбием кечкенә генә буйлы, нәзек гәүдәле бер карчык иде. Ишек алды тулы бер көтү бала, ә әбинең чәе дә, ашы да бер минутка да соңга калмый. Бабай да ашны көттерергә яратмый. Ашны да, ботканы да җәен казанда, кышын мичтә пешерәләр. Кечкенә балалар да, зурлар да икешәр тәлинкә аш ашыйбыз. Кысыр ашны ашап туеп булмый. Зур, ике чиләк сыйган казан. Астында кояшта кипкән кизәкләр яна. Өйгә черки керә башласа, әбием янган кизәк кисәген читек табага салып идәнгә куя. Өйгә төтен чыга, черкиләр качып бетә.

Безнең йорт базардан ерак түгел. Бабай базарга ат җикми чыкмый. Кырыгынчы елны ул налогтан котылмак булып атын сатты, сыер гына калды.

Без торган йортның күршеләрен бабаем ихтирам итә. Күрше хакы өчен. Күршедә бер байның ике катлы йорты. Һәр катында урамга дүрт тәрәзә чыга. Таякка таянып йөргән карчык, Фатыйма апа, шушы йортта тора. Аның ике улы бар. Фатыйма апа Исрафиле белән икенче катта бер бүлмәдә тора. Исрафил революциядән сон каланың башы булып йөргән. Урлап, төрмәдә утырып чыккан. Исмәгыйле гаиләсе белән беренче катта, бер бүлмәдә тора. Ул аклар ягында сугышкан. Исрафилен ата коммунист дип йөртәләр. Көтү каршы алырга барган картлар, шул ике туганның, ничек итеп бер-берсенә каршы сугышканнарын сөйләтеп утырырга яраталар. Бу ике туган өч хәрефкә дә (КГБ га), бу тормышка да, берәүгә дә кирәкмиләр булып чыкты. Фатыйма апа үлгәч, әкренләп үлеп беттеләр.

Революция вакытында, Троицкига бер мулла гаиләсе күчеп килгән. Татар революционерлары шул мулланың гаиләсенә ябышканнар, җәберләгәннәр. Мулла абзый чыдамыйча, бер көнне: "Әһәмиятле сүзем бар",—дип, тегеләрне чакырып алып бәддога укыган. Шул ук елны, дога тыңлаган революционерлар да, мулла абзый белән аның гаиләсе дә кырылып үлгәннәр. Башка революционерларны чехлар кырып киткәннәр.

Бабай кеше каргаганны гына түгел, ачуланганны да яратмый. Каргыш белән ачулануны янәшә торган гөнаһ нәрсә итеп карый. "Каргыш дөрес булса, икесенә дә: каргаучыга да, каргалучыга да төшә, каргыш ялгыш булса, каргаучының үзенә генә төшә",—ди. Яман уйлар әйләнеп кайталар, шуңа күрә һәр кешенең эше генә түгел, уе да саф булырга тиеш дип исәпли.

Беренче катта, бик кечкенә генә бүлмәдә, ярлы, ятим карчык тора. Кәҗә тота. Кәҗә тотучылар бик аз, алар хәлсез кешеләр. Туксанынчы елларда Мәскәү тирәсендә, мул тормышлы кешеләр кәҗә тота башлаганнарын күреп, күршедәге ятим карчык искә төшкән иде.

Татар мәктәбендә укыйм. Урысчаны юньләп белмибез. Безгә "колхозник" белән "хәерче" охшаш сүзләр. Ишек алдына килгән хәерчегә: "Колхозник килде",—диябез. Колхозникларның кием-салымы хәерчеләрнекеннән дә сәләмәрәк була.

Безнең бабай елда Коръән укыта. Башта барып бер аяксыз Җәмил хәлфәне чакыра. Аннан, зиратка барып, сакчы картны. Аны агач хәлфә дип йөртәләр. Аннан соң мин абыйны чакырып кайтам. Абыйдан соң күршеләрне чакырабыз. Каршыдагы ике карчыкны, Исмәгыйл белән Исрафилне. Кунакка алар киенеп керәләр. Исрафиле генә Коръән укыганда башына кими, дога кылмый утыра.

—Бабай, нигә мондый кешеләр чакырасың?

—Аларда өч хак бар. Кеше хакы, милли дини кардәшлек хакы, күрше хакы. Абыеңда да өч хак бар.

Хәзерге заман үлчәве белән әйтсәң, милли дини кардәшлек хакы икс хак булырга тиеш шикелле. Ләкин бабай милли дини кардәшлек хакын бер хак итеп саный.

Кеше хакы, туганлык хакы, милли дини кардәшлек хакы, күрше хакы дигән сүзләрнең мәгънәсен бабай миңа болай аңлата:

—Беренче дәрәҗә булып кеше хакы тора. Ул Ходайдан куелган, кешеләрнең бер-берсенә булган бурычлары.

Икенче дәрәҗә булып туганлык хакы тора. Ул туганнар арасындагы бер-берсенә булган бурычлары.

Өченче дәрәҗә булып милли дини кардәшлек хакы тора. Ул бер милләт кардәшләре яки дин кардәшләре арасындагы бер-берсенә булган бурычлары.

Бабай милли кардәшләр белән дини кардәшләрне аермый, бер итеп карый. Төрки телле халыкларга бер итеп, бердәмлек тойгылары белән карый: уйгурлар, казакълар, кыргызлар, башкортлар, карачайлар, азәрбәйҗаннар... бер агачның ботагы, бер ботагын да сындырырга ярамый, берлек кирәк, ди.

Дүртенче дәрәҗә күрше хакы тора. Күршеләрнең бер-берсенә булган бурычлары.

Кеше хакын яки үз хакыңны бозу, күтәрү яки төшерү, ул харам нәрсәләрнең берсе.

Хакы синең үзеңнән әзрәк кешене мактап хакын күтәрү, ул үзеңне кимсетү, сатылу яки коллык билгесе була. Үзеңнән зуррак хаклы кешеләргә буйсынып яши белү яшүсмерләр өчен иң әһәмиятле нәрсә. Яшүсмерләр ата-бабаларына буйсынып яшәүне зур бәхет, бүләк итеп кабул итәргә тиешләр.

Үлгән кешеләр—икенче дөнья кешеләре. Аларның хакын терс кешеләр белән бергә куеп карау кешенең хакын бозу була. Гөнаһ нәрсә.

Бертигез хакны бозу коллыкка илтә, яки тынычлыкны боза. Бүгенге кулланылган атамалар белән әйткәндә, экстремизм, революция, фашизм, национализм, коммунизм, сатылу, коллык—болар барысы да, кеше хакын бозудан гына килеп чыгалар.

Бабай, Сталинның кем икәнен, аның бөтен яманлыкларын аңлап яши. Әмма халык аны үзенә хуҗа итеп сайлагач, аның хакы күтәрелеп китәргә тиеш дип карый. Шуңа күрә Сталин үлгәнче түзәргә кирәк, ди.

Зур хаким иләре халыкның вөҗданы, намусы булып торган кайсыбер шәхесләргә лаек дәрәҗәне мәҗбүри бирәләр, үзләрендә изге тойгылар барлыгын күрсәтеп яшәргә тырышалар, ди.

Мәктәптә укыганда, кем булыйм дип бабай белән киңәшеп утырам:

—Улым, бик серле, яшерен эшкә барма, кирәгең беткәч үтереп куюлары бар.... Боларга ышанып булмый. Күпне күрдем... Моның булуы бик мөмкин.

Бабай... Минем бабай! Әллә син тәкъдирдән хәбәр бирүче булдыңмы?

Әтием, бабайның сабакларын үзенчә кыскартып, өч нәрсәгә әһәмият бирә.

Беренчедән, һәр кеше үз исемен алыштырмый яшәргә тиеш. Кешенең исеме—аның туган иленең бер кисәге.

Икенчедән, анасын ихтирам итеп, анасын багарга тиеш. Ана, ул туган илнең тагын бер өлеше.

Өченчедән, үз авылын, туган җирен онытмый яшәргә тиеш.

Бу өч нәрсәгә хыянәт итү кешенең бөтен хакларына да зыян китерәләр, хыянәтчене сатлык җанга әйләндерәләр. Әти, бу өч нәрсәнең берсен булса да бозган кешегә сатлык җан итеп карый.

Бер сатылган кеше, ул дусларын да сатачак.

Тормышта, мин шушы васыятьләргә таянып яшәдем. Очраган юлдашларым саф, намуслы кешеләр генә булдылар, Аллага шөкер, мине бер кеше дә сатмады.

Хәким бабам каты авырудан терелгәч, мине—алты яшьлек кара малайны үзе белән алып йөри башлады. Ул шактый ябык, чандыр гәүдәле кешегә әверелгән. Аның күзләре зәп-зәңгәр, чәчләре коңгырт, сакал-мыеклары матур итеп кыркылган була. Башында кара түбәтәй, йә соры төстәге каракүлдән тегелгән түгәрәк бүрек. Өстендә якасын утыртып теккән, хас татарлар кия торган соры төстәге костюм. Таякка таянып йөри. Янында мин булмасам, очраган бер кеше:

—Хәкимҗан абзый, тайчыгың кайда?—дип теңкәсенә тияләр.

Брежнев заманында туган Троицкига кайттым.

Беренче этажлар җиргә кереп, тәрәзәләре күмелә башлаганнар. Өйләр җимерелеп ята. Көлеп торган туган шәһәрем археологик казылмаларга охшаш булып калган.

Зиратында биш буын булып бабайларым, әтием ята. Кайбер җирдә казармага охшаган 4-5 этажлы "хрущевкалар" салып куйганнар. Зиратына да "хрущевкалар" салырга җыеналар. Далада, әйләнә-тирәдә башка урын юк диярсең.

Туган шәһәрем, анда торган кешеләр, милләттәшләрем, кардәшләрем искә төшеп, "Фаҗигаи Казан" сүзләре күңелгә килә:

"Оҗмах җирләр күрделәр дә
гаҗәпләнеп тордылар:
"Җәннәт җирдә торган икән,
кабәхәтләр",— диделәр.

"Үзгәртеп коруны" куанып каршы алдык. Бу тамашадан без бәйсезлек, ирек көттек. Россия икътисады ансат кына күтәрелә алмаслык хәлгә килгәнен белә идек. Ике миллион киловат көчле электростанция—Идел буендагы ике миллион гектар иң матур җирне суга батырып эшләнгән. Кем бер гектар җирне бер киловат көчкә алыштыра соң?! Бу—Россия икътисадының мисалы. Һәрхәлдә "үзгәртеп кору" тоталитар системаны бетерә алмады. Янгырсыз күк күкрәү генә булды.

Кеше хакын таптарга яңадан усаллар килде. Алар Империянең күп кенә җирләрендә үз халкына каршы сугыш ачтылар. Ничә йөз меңләп картын, яшен, балаларын—чечен булсын, рус милләте кешесе булсын—кырдылар.

Мәскәүдә торучы "кара малайны"—мине кара булганым өчен, пенсионер кара бабай булуыма карамастан, урамында, метросында, вокзалында тентеп тикшерделәр. Халык кол. Ул сугышның ямanлыкларын чеченнардан гына күрә. Кеше хакы ирек аламы дип торганда усаллар хакы тагын җинде.

Бу янгырсыз күк күкрәүдән сулыш алыр өчен һава җиңеләеп калса да, халык өчен тагы бер авырлык килде—хәерчелек. Ельцин идарәсенең котсыз билгесе—хәер сораучы күбәйде: сугыштан кайткан аяксыз кешеләр, картлар, балалар.

Эчәргә өйрәтелгән халык, бу хокуксызлыктан, тәгәрәп эчәргә тотынды, әфьюнга ябышты. Ельцинның хакимлек иткән дүрт елында халыкның саны, дүрт миллионга кимеде. 1913 елны Россиядә 200 милләт булса, "үзгәртеп кору" башланганда 100 милләт калган иде. Совет заманында рус халкының эчеп кимүе башка милләтләрнең рус милләтенә күчүе аркасында күренми, беленми килде.

Халкымны аякка бастырыр ният белән бабаемның васыятьләрен искә төшерәм.

Кеше хакын сакларга өйрәнсәк кенә без цивилизациягә кире кайта алачакбыз.

Җир йөзендә яшәүче барча инсаннарның бер-берсенең хакын саклап яшәү кагыйдәләре, дин кагыйдәләре белән бергә, Ходайдан кусла килгәннәр. Халыкка үзебезнең мәдәниятне үстерү, әхлаклы тәрбияләү юллары бирелгәннәр. Ислам дине, мәгърифәт, һәр гаиләнең ныклыгы, сафлыгы, халыкның матур гореф-гадәтләре: тәртип, тәүфикъ, әдәп, вөҗдан, намус. Оятның нәрсә икәнен белгән абруйлы кешеләр генә башка инсаннар белән үз хакларын саклап яши алалар.

Безнең бабайлар киң мәгънәсендә югары мәдәниятле кешеләр булганнар. Хәзерге вакытта Россиянең милли сәясәте нигезендә һаман бөек державачалык коткысы ята. Онытыла башлаган үз гореф-гадәтләребезне искә төшереп, бабайларыбыз кебек яшәү генә татар халкын саклап кала алачак. Безнең бабайлар өчен кеше хакын саклап яшәү көндәлек тормышның киң кагыйдәсе булган. Икенче яктан, кеше хакыннан башка, бабайлардан килгән бердәмлек хаклары бар:

1. Милли дини кардәшлек хакы.
2. Туганлык хакы.
3. Күрше хакы.

Бу бердәмлек хаклары халыкны туплый, милләткә көч бирә, ныгыта һәм фикердәшләр булып яшәргә булыша.

Кеше хакын саклап яшәр өчен кешенең үзендә, күңелендә, рухында изге тойгылар булырга тиеш. Изге тойгы: Ходайга, дөньяга китергән анаңа, әби-бабайлар каберенә, үзеннең токымына, туган иленә... Кадерле исемнәргә: Татарстан, Болгар, Казан, Сөембикә кебекләргә.

Изге тойгыларны кешегә кайтару өчен яшьтән әхлакый тәрбия биреп, әдәп белән тәүфыйкны өйрәтергә кирәк. Әдәп, тәүфикънын башы—кеше хакына тимәү.

Башка чарабыз юк. Бабаем кушканча, кеше хакын саклап яшәп карыйк.

*Flyn Musinqa 60 jəş*

# TANЬLQAN QALIM

Fən keşesenen tormьşь nindi buluьn tulьraq bely ecen ixtimal yzenə də fən dənjasьnda qajnau kirəkter. Ber qaraqanda, fənni ezlənylər, acьşlar-tabьşlar qalimgə zur şatlьqlar kiterə, jana tikşerenylərgə ilhamlandьra, tirən qənəqətləny xislərе ujata. Mondьj caqlarda anьn kyzenə tormьş ьqьzьqьsь kyrenmi, xezmət xaqь camalь bulu da əlləni borcьmьj.

Əmma qalim xezmətenen ikence jaqь da bar. Fən keşese yzenen tabьşlarьn tykmi-cəcmi, tarixqa xьjənət itmi bəjan itkəndə, bik çitdi fənni həm əxlaqi taləplər belən bergə, zamanьnьn terle şəxeslərе, içtimaqi xərəkətlər qaraşlarь basьmьn da tojьp tora. Bu kəclər belən sanlaşmau da, sanlaşьp eş ity də—hər ikese—ana zur bəlalər kiterycən, qanьn qorьtucan bula. Sanlaşmьj eş itsə—dereslek, qədellek anьn juldaşь. Əmma, "turь əjtkən, tuqanьna jaramas", digəndəj, əlege rəweştə jazu da qajberəylərgə oşamьj, terle çənçallar kiterep cьqara. Cənki ajьrьm şəxeslərnen, içtimaqi terkemnərnen yz mənfəqətlərе, yz qaraşlarь bar. Alar ozaq jьllar dəwamьnda yzləren sizderep toralar.

Sanlaşьp eş ity də qalimne qьzganmьj, yzencə çəzalьj. Prinsipial'lektən, objektivlьqtan citləşergə məçbyr bulqan şəxesne yz zamandaşlarь da, kiləcək buьnnar da tybənsetələr. Şunьn estenə, fənni mənfəqətlərdən jьraq bulsalar da, fən keşelərе arasьnda da jəşəycən xesetlek, "cьь urьn", dərəçə-isem, bylək h. b. ecen tartьşu da bar bit əle. Menə bolarnьn barьsьn iskə alqanda, qalim-gələmənen (həm şundьjraq eşkə alьnqan keşelərnen) eşe-tormьşь şaqtьj katlaulь həm ceterekle ikənlege acьqlana. Bu ujlar tarixьbьz səxifələren üzganda da, bygenge dus-işlərebez, xezməttəşlərebez eşe-tormьşь turьnda fiker jərtkəndə də qabat-qabat kynelgə kilə. Ykeny, borcьlu, xislərе bulьp, təzəlməgən jara bulьp üşi alar. Kypme ägaltular, nindi ajanьc xəllər şunьn nətiçəsendə...

Əlege jazmamnь başlaqanda bu ujlar, xislər qabat janarьp kitte. Ədəbiatcь qalim Flyn Məslax ulь Musin—fən dənjasьnda məqlym şəxes. Ul SSSR Fənnər Akademiəsenen G. Ibrahimof isemendəge Tel, ədəbiat həm tarix institutьnda 1963 jьlda eşli başlьj, xəzer də (1987 jьldan başlap) şunda ədəbiat beleme bylege çitəkcese. Dimək, 36 jьldan artьq tьnqьsьz qemer fəngə birelgən. Şul jьllarda ədəbiat dənjasьnda nilər genə bulmaqan da, nilər genə jərək aşa uzmaqan...

Fən keşese bulqancь da tormьş anь bik irkələp tormaqan. Ixtimal, balacaq cьnьqularь ana zur kirtələrne, çitdi qarşьlьqlarnь çinep ytərgə kəc-cьdamlьq birəder.

Tərçeməi xəlennən mizgellər: bulacaq qalim 1939 jьlnьn 23 fevralendə Tatarstannьn Məslim rajonь Iske Qaramalь awьlьnda krestiən qəiləsendə tua. 1941 jьlnьn çəjendə alarnьn qəiləse "bəxet ezləp" Jьraq Sebergə dip kitə. Əmma Cita şəhərenə barьp çitkəndə suqьş başlana. Şul kənnərdə yk ətise Məslax armiəgə alьna. Su astь kejməsendə xezmət itkəndə ul "xəbərsez" juqala. Dimək, kyplər kebek, Flyn də ətisenen qəberenə cəcəklər qujudan məxrym qala.

Ənise Məsəwərə apa ike jəş balasь belən Seber jaqlarьnda bylenep qalqac, ozaq həm awьr jullar ytep, tuqan awьlьna qajtьp jьqьla. Bu mixnətle səfərdə awьrulardan sawьqa almaqan keckenə qьzcьqьn çirli.

Tol xatьn çilkəsenə təşkən 40-50 jьllar awьrlьqlarьn ulь Flyn keckenədən yk tatьp ysə. Qьrda uzqan jьldan qalqan eşegən bərənge-kəlçemə cьju, ylən-

qьсьtqan belən çan saqlau kebek nərsələr aŋa tormьşnьŋ acьsьn-təcesen tatьtalar. Kiləcəktə tatar awьlь turьndaƣь əsərlərne bəjələgəndə, bu jьllar sulьşь turьnda sүz barƣanda, tarixi dereslek taləp itkəndə balacaq xatirələre aŋa ьşanьclь tajanьc bulьp qala.

Mondьj tormьşta, kүpne kүrgən awьl xalqь arasьnda cьnьƣu, үçətlənep çil-jaŋƣьrƣa qarşь baru anьŋ xolqьn, ixtьjar kecen nьƣьtqan dip tə əjtə alabьz.

1947 jьlda Flүn tuƣan awьlьndaƣь başlanƣьc məktəptə uqьj başlьj. Bişence klasstan Kүbək urta məktəbendə belem alub dəwam itə. 1957 jьlda anь təmamlap, juƣarь uqu jortь turьndaƣь xьjallarьn tormьşqa aşьrьrƣa teli. Əmma... Zamanasь nindi! Kolxoz rəise rəxsətennən başqa awьldan kitү, pasport alu juq! "Iple genə jeget, sin, kolxozda at çigep eşlərseŋ",—dilər aŋa.

Əje, ul jьllar "romantikasь" nindi bulubn jegetebez bүgen də bik jaxşь xəterli.



Flyn Musin

Tьrьşqan—tabar, taşqa qadaq qaƣar, digənnər borьnƣьlar. Çətməgə eləkkən balьq kebek, bu jegetebez də alaj-bolaj bərgələnə, үtenə, jalwara. Şulaj da rizalьq ala almьj. Tatarda təwəkkəllek bar bit ul! Belemgə, kiŋlekkə omtьlьş "jaramaƣan" nərsədən ostenrək bulьp cьƣa: Flүn awьldan rəxsətsez, pasportsьz-nisez taja. Pojezd biletьna kec-xəl belən aqca jүnətep, Məskəүgə (Qazan ƣьna jaramaƣan diərseŋ) barьp cьƣa. Ƣadi tatar awьlьnnan dokumentsьz kilgən abiturientqa Məskəү aƣajlarь ni diərgə belmi aptьrap qalalar. "Ølgergənlek attestatь şəp. Əjdə, imtixannarьn birep qarasьn əle",—dip, kire bormasqa bulalar. Jegetebez sьnatmьj. M. V. Lomonosov isemendəge məşhүr universitetnьŋ filologiə fakultetьna, ƣajət zur konkursnь үtep, uqьrƣa kerə.

Məskəү universitetь, beten ildən, donjadan çьjnalƣan studentlar donjasьnda, kecle uqьtucьlar joƣьntьsьnda jegetebez jaŋadan tuƣandaj bula. Qaraşlarь үzgərə, awьl bolьnnarь, çьr-moŋnarь, ƣəçəp "romantikasь" jaqьn da, jьraq ta bulьp, tatlь xatirələrgə əwerelə. Tuƣan xalqьnьŋ ruxi donjasьn, mədəniəten başqa millətlər belən caƣьştьru momkinleklәre acьlu student Flүngə kүp nərsə birə. Soŋьnnan alar ədəbiatcь-ƣalim, tənqitce Flүn Musinnьŋ məqələlərendə, monografiəsendə ezlekle ber mohim sьjfat bulьp formalaşqan kiŋ qolaclьlьq, terle xalьqlar ədəbiatьndaƣь urtaqlьq həm milli ajьrmalьq məs'ələləren tirən analizlau bulьp nьƣьjlar. Anьŋ Үzək matbuƣat bitlərendə jьş kүrengən məqələlərе ənə şundьj bululаrь belən otьşlь ide. Moŋa dəlil itep anьŋ "Tormьş sьnawь aşa" (Qazan, 1969), "Tarix həm zaman" (Qazan, 1974), "По координатам жизни" (Məskəү, 1976), "Связь времен" (Qazan, 1979), "Tormьş үzəgennən" (Qazan, 1987), "Kemeş kezge" (Qazan, 1989), "Ƣajaz Isxaqi tormьşь həm eşcənlege" (Qazan, 1998) h. b. xezmətləren kүrsətergə momkin.

... Məskəү universitetьn təmamlaganda Flүn Musin belən anьŋ keşelek asьlьn bilgeləүce ƣibrətle ber xəl bula. Jəş belgeclərne eşkə bilgeləgəndə F. Musinƣa ul waqьtta bik dərəçəle keşelərneŋ də uƣьl-qьzlarьn konləştererlek abrujlь eş—cit illərneŋ bersenə universitet uqьtucьsь bulьp baru təqdim itelə. Jьraq ber tatar awьlьnnan kilgən tatar balasь Flүnneŋ ataqlь Məskəү universitetьn təmamlawьn sotsializmnьŋ milli səjəsət qazanьşlarьna ber misal itep kүrsətergə niətlilər kүrəseŋ. Ə inde tuƣan çirenə kire qajtu turьnda xьjallanƣan jegetneŋ əlege bik dərəçəle eştən baş tartuь universitet çitəkceləren şaqqattьra. Alar moŋa awьl balasьnьŋ berqatlьlьƣь digəndəj səjersenep qarьjlar. Tuƣan jaƣьna qajtu teləge F. Musinnьŋ ul waqьtta şulaj uq bik mərtəbəle bulƣan ikence ber rəsmi təqdimnən—Məskəү universitetьnda

aspiranturada qaludan da baş tarttъra həm bu xəl də başqalarnъ səjersenderə.

Şunъꞑ ɵstenə anъ partiə ɵlkə komitetъ da Qazanƣa qajtarunъ sorъj. Şulaj itep, ul 1962 jъlda Qazanƣa çibərelə. Başta "Sotsialistik Tatarstan" gazetasъnda ədəbi xezmətkər bulъp eşli. Əmma tirən filologik əzerlek, ədəbiat tarixъna analitik qaraş, jəşlərcə qъjulъq anъ çitdi fən dɵnjasъna tarta. 1963 jъlda ul SSSR Fənnər Akademiəseneꞑ Qazan filialъ Ƣ. Ibrahimof isemendəge Tel, ədəbiat həm tarix institutъna eşkə kycə. 1970 jъlda filologiə fənnəre kandidatъ dərəçəsen ala, 1983 jъlda Məskəydə A. M. Gor'kij isemendəge Dɵnja ədəbiatъ institutъnda doktorlъq dissertatsiəsen jaqlъj.

Əjtergə kirək, bu dərəçələr aꞑa çiꞑel genə birelmi. Ber jaqtan, ul jъllarda hər jaꞑa fiker ideologik taləplərneꞑ "enə kyzennən" ytkərelə. Ikence jaqtan, prinsipial' bəjlənylərne kyplər kytərə almъj. Ɵcencedən, traditsion xɵsetlek, kɵnləşy də mondъj ƣalimnərgə jul birergə teləmi. Əmma Flyn iptəş barъber bireşmi, dulqъnnarnъ jarъp maqsatlarъna ireşə. Ənə şundъj sъjfatlarъ həm kiꞑ qolaclъ fənni həm pedagogik eşcənlege aꞑa jaꞑa uꞑъşlar, dərəçəle isemnər kiterə. 1991 jъlda aꞑa "Tatarstannъꞑ atqazanƣan fən eşleklese" digən maqtaulъ isem birelə, 1995 jъlda ul Rossiə Gumanitar Fənnər Akademiəseneꞑ xaqiqi əƣzasъ itep sajlana. Dəresleklər jazu, aspirantlarnъꞑ fənni çitəkcese bularaq aktiv eşləy uqъtucъlarnъꞑ belemen kytəry institutъnda kafedra mɵdire wazifalarъn başkaru anъ əjdəp barucъ professor itep tanъttъ.

Ədəbi tənqit eşcənlegen altmъşъncъ jъllarda başlaƣan F. Musin 1970 jъlda SSSR Jazucъlar berlegenə əƣza itep alъna. 1987 jъldan başlap ul Ƣ. Ibrahimof isemendəge Tel, ədəbiat həm sənƣət institutъnъꞑ ədəbiat beleme bylegen çitəkli. Ojъştъru eşləre belən bergə, ul altъ tomlъq "Tatar ədəbiatъ tarixъ"nъꞑ tɵp avtorlarъnnan berse də.

Tatar xalqъnъꞑ baj ədəbiat tarixъn kiꞑ planda həm tirənten ɵjrəny kirəklege ƣɵmumən ədəbi mirasъbъznъ xalъqqa qajtaru həm jaꞑa zamanda jaꞑaca bəjaləy zarurlъƣъn aꞑlauƣa kiterə. Şul jynəleştə eş ity ɵcen 1987 jъlda Ruxi miras komissiəse tɵzep, F. Musin anъꞑ eşendə çitəkcelek itə. 1991 jъldan Tatar "Miras" fondъnъꞑ prezidentъ bula, ələge fond oeştъrƣan "Miras" zurnalъnъꞑ berence baş mɵxərrire itep sajlana. Bu fond bɵtendɵnja tatarlarъn berləştery jynəleşendə də zur eş başqara. Ələge fondnъꞑ çitəkcese sъjfatъnda F. Musin 1992 jъlda Berence Bɵtendɵnja tatar kongressъn həm 1997 jъlda Ikence Bɵtendɵnja tatar kongressъn əzerləydə həm ytkərydə aktiv katnaştъ. Ələge kongresslarda Başqarma komitet rəise urъnbasarъ həm bjuro əƣzasъ itep sajlandъ.

Distədən artъq fənni kitap avtorъ, tanъlƣan ƣalim həm çəməƣət eşleklese Flyn Mɵslax ulъ Musin ənə şulaj nъqlъ adъmnar belən atlap, şəkertləren iərtep həm xalqъna bik kirəkle məsələlərne xəl itə barъp, yz julъn jara.

**Nazъjm XANZAFAROV,**
filologiə fənnəre doktorъ.

*Jьlmajьp-kөlep kenə*

# Ilham Fəjzraxmanof

PARODIJƏLƏR

## Tujdan qajtqanda

*Jalqъş qajьnnь qocqanmьn,*
*Min anь sin dip toram...*

Robert Minnullin.

Uram bujlap berəy bara,
"Tuqta!"—diep qьcqьram.
Tuqtarqa ujьnda da juq,—
Min anь sin dip toram.

"Tuqta, minəjtəm,—juqijsə
Qolaq şərifen boram!"
Tuqtadь da kөtep tora,
Min anь sin dip toram.

"Не залезай!"—dip jazьlqan,—
(Ax, kyzennen qarasьn!)—
Jalqъş barьp qocqanmьn bit
Elektr baqanasьn.

Pogon taqqan berəy şunda
Mina kilep bəjlənə.
Nigə ikən bəjlənə ul?—
Bolaj da baş əjlənə.

Əjt əle, əjt sin şunarga
Əjt əle, qajьnqajьm.
Keşegə bəjlənələrme
Baqana qocqan sajьn?!

Nigə mina bəjlənə ul?—
Ajaqъmda nьq toram.
Ul da, qajьn da ber tөsle—
Ajьralmьj tik toram.

## Qatьşmьjm!

*Berkən tөnlə qajtьp baram,*
*Kemder tibə ecemə.*
*Şunda qъna ьşandьm min*
*Mafijənen kөcenə...*

Niaz Akmal.

Teşkə suqsьn, başqa suqsьn,—
Suqsьn başqa təşemə,—
Anьsьna—ber syzem juq,
Nik tibə ul ecemə?

Şulaj itep tibələrme
Ber gənahsьz keşegə?—
Bəlki yc saqlaqannardьr
Şiqer jazqan өcen, ə?

Xəzer inde min qatьşmьjm
Mafijənen eşenə,—
Eckə kiterep tibylərе
Kөn də kerə təşemə.

## Tərəz sajьn nicə gəl ysə?

*Tərəz təbem minem bernicə,*
*Tərəz sajьn jaran gəl ysə...*

Rezeda Wəlieva.

Tərəz təbem minem bernicə,
Şunь sanap jərdem min kicə.
Tərəz təbe sajьn gəl ysə,
Gəl sawьtь sajьn buş şeşə.

Jannarьma ƣьna kilsə iden,
Tərəzəmne sanap birsə iden.
Tərəz təbem minem son nicə?—
Anƣьrajdьm şunь belmicə.

## Əbienə sələm əjt!

*Kətmə sin kətmə, ypkələmə,*
*Aradan çillər ytte.*
*Səjygə susaƣan iren*
*Inde başqanь ypte.*

Fənis Gərəjef.

Juqqa ypkələp jərden sin,
Juqqa ypkələp kitten.
Menə taƣьn çil iste də,
Taƣьn başqanь yptem.

"Ytkən ƣəmer—iskən çil",—dip,
Əjtələr də, juƣisə,—
Çil iskəngə ypkələmim,
Çil ul kən sajьn isə.

Aradan çillər ytkəngə
Inde çilgə ypkələ.
Juq, çilgə də ypkələmə,—
Yzen kilep kitkələ.

Əje, ypkələmə çilgə,
Ytkən eşkə—salawat.
"Əbienə sələm əjt!"—dip,
Çьrlar, juqsa, Salawat...

*Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## КАЗАКЪСТАН ҖИРЕНДӘ

20 гыйнварда Казакъстан башкаласында республиканың яңадан сайланган Президенты Нурсолтан Назарбаевның ант итү тантанасы булды. Шул уңайдан Астана шәһәренә чит илләрдән һәм БДБ дәүләтләреннән 18 рәсми делегация килде. Чакырылган олы кунаклар арасында Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев та бар иде. Шәхси очрашулары вакытында ул Н. Назарбаевны яңадан Президент итеп сайлануы белән чын күңелдән котлады, Казакъстанда яшәүче күпмиллэтле халыклар файдасына аңа нәтиҗәле эш теләде.

## ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ ИНТЕРНЕТТА

Шушы елның 12 гыйнвареннан башлап, Интернеттан файдаланучы барлык кешеләр Татарстан Республикасы Президенты турында мәгълүматлар белә алалар. Анда Шәймиевка кагылышлы махсус сәхифә ачылды. Интернет сәхифәсе әледәнәле яңартылачак һәм өч телдә—татар, рус, инглиз телләрендә чыгачак. Аның инглизчә варианты февральдә пәйда булса, татарчасы шушы елның мартында күренергә тиеш.

Интернет аша Татарстанның дәүләт төзелеше, икътисады, тарихы, сәясәте, мәдәнияте h. б. турындагы күп төрле мәгълүматлар белән дә танышырга мөмкин.

## МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ—БЕЛАРУСЬ МИНИСТРЫ

Беларусь Республикасының тышкы эшләр министры итеп Урал Латыйпов билгеләнде. Заманында Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлаган татар егете—юридик фәннәр докторы. Ул моңарчы Беларусь Республикасы Президентының киңәшчесе булып эшләгән иде.

## Р. ФӘХРЕДДИН ЮБИЛЕЕ

22 гыйнварда Әлмәт төбәгендә мәшһүр әдип, галим, журналист һәм дин әһеле Ризаэддин Фәхреддиннең (1859—1936) тууына 140 ел тулуга багышланган күп төрле чаралар уздырылды. Анда катнашучылар бөек мәгърифәтченең туган авылы Кичүчаттагы музейда, мәдрәсәдә, мәчеттә булдылар. Әлмәт шәһәрендәге Ислам университеты эше белән таныштылар. Әлмәттә Р. Фәхреддиннең тормышына һәм күпкырлы эшчәнлегенә багышланган фәнни-гамәли конференция уздырылды.

Юбилей тантаналарында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстан мөфтие Госман хәзрәт, академиклар М. Госманов һәм Х. Миннегулов, галимнәрдән М. Әхмәтҗанов, Ә. Хәйри, язучылардан М. Хәбибуллин, Р. Вәлиуллин, Әлмәт шәһәре һәм районы хакимияте башлыгы И. Фәрдиев h. б. катнашты һәм чыгыш ясады.

## КУТУЙ ЕЛЫ

Пенза өлкәсенең Кузнецк районы Татар Кынадасы авылы музеенда фронтовик-язучы Гадел Кутуйның тууына 95 ел тулу уңаеннан күргәзмә ачылды. Әдипнең тормышын һәм иҗат юлын чагылдырган әлеге күргәзмә ел дәвамында эшләячәк.

## ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТЛАРЫ КОРЫЛТАЕ

18 декабрьдә Казанда—Матбугат йортының конференцияләр залында—Татарстан Журналистлар берлегенең XI корылтае булып үтте. Аның эшендә ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары И. Хәйруллин, Дәүләт Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча комиссиясе рәисе Р. Миңнуллин, Президентның матбугат үзәге җитәкчесе Ә. Хәсәнов, Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов h. б. катнашты.

Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова, Россия журналистлар берлеге генераль секретаре Ж. Яковенко бүгенге көндә матбугат өлкәсендәге кыенлыклар һәм алардан чыгу юллары турында сөйләделәр. Корылтайда "Журналистлар

этикасы кодексы" кабул ителде, яна житәкчелек сайланды. Журналистлар ижади берлеккә житәкчелек итүне яңадан Р. Ратникова ышанып тапшырдылар.

## "РУХИЯТ" БҮЛӘКЛӘР ТАПШЫРА

"Татнефть" Акционерлык җәмгыяте һәм "Рухият" фонды соңгы ике елда дөнья күргән иң яхшы әсәрләр өчен бүләкләр тапшырды.

Әдәбият өлкәсендәге беренче бүләк, "Догалы еллар" китабы өчен, язучы М. Галиевка бирелде. "Татар мифлары" дигән китабы өчен Г. Гыйльманов, "Канатлы елан" дигән тарихи очерклары өчен Д. Рәхмәти, "Татарстан референдумы" дигән әсәре өчен Р. Юныс төрле дәрәҗәдәге бүләкләргә лаек булдылар. Нефть төбәгенең рухи тормышына зур өлеш керткән шагыйрьләр Г. Афзал, К. Булатова, прозаик А. Хәсәновка махсус призлар бирелде.

Шундый ук бүләкләр театр һәм рәсем сәнгате, җыр-музыка өлкәсендә эшләүче сәнгатькәрләргә дә тапшырылды.

Иң зур бүләкне—Гран-прины—Казан дәүләт консерваториясенең Р. Халитов житәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры яулады.

## "ИЛҺАМ ЙОРТЫ"НДА ТАНТАНА

Мәскәүдә яшәүче милләттәшләребезнең рухи дөньяларын баетуга зур өлеш кертеп килүче "Хилал" фондының мәдәни үзәк концерт залына Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Илһам Шакиров исеме бирелде. Бу залда түләүле үткән һәр чарадан килгән керемнең 10 проценты аның исеменә күчерелачәк.

Күптән түгел бирелә үткәрелгән кичәдә И. Шакировка Россиянең Табигать фәннәре академиясенең (РИАН), Халыкара табигать һәм җәмгыять фәннәре академиясенең мактаулы профессоры тыныклыклары һәм меценат Третьяков исемендәге көмеш медаль дә тапшырылды.

Үзенә күрсәтелгән шундый игътибар-ихтирам өчен, "Хилал" фондына һәм аның рәисе—академик Рәшит Баязитовка чын күңелдән рәхмәт белдереп, халкыбызның мәшһүр җырчысы зур концерт программасы белән чыгыш ясады.

## АВЫЛ УРАМЫНА—ГАЛИМ ИСЕМЕ

Кәрәкәшле урта мәктәбе—Ютазы районында гына түгел, татар дөньясында мәгълүм белем үзәге. Аны тәмамлап, соңыннан төрле өлкәдә фән докторы булып үскән кешеләр байтак: академик Мирфатих Зәкиев, профессорлар Нуриман Хәҗипов, Фәһимә Хисамова, Кәүсәр Яхин, Мөкатдис Газизов, һ. б.—әнә шундыйлардан.

Кәрәкәшле мәктәбе шәкертләре башлыча филологиядә, инсани фәннәр һәм татар мәдәнияте өлкәсендә зур эшләр башкара. М. Зәкиев, Г. Шәрәфетдинов, И. Надиров, С. Ибраһимов, Ф. Хисамова кебек шәхесләрнең исемнәре күпләргә яхшы билгеле.

Үзенең 60 еллыгын билгеләп үткән Кәрәкәшле урта мәктәбе һәм авыл халкы алар белән хаклы горурлана. Академик М. Зәкиевка 70 яшь тулган көннәрдә шушы зур авылның үзәк урамына аның исеме бирелде.

## "ШИГЪРИЯТ ОСТАХАНӘСЕ"НДӘ

Татарстан Язучылар берлегенең "Шигърият остаханәсе"ндә соңгы вакытта бер-бер артлы ике шагыйрәнең—Казан шәһәреннән тәрбияче-мөгаллимә Флера Гатинаның "Сөю канатлары" һәм университет талибәсе, 17 яшьлек Луиза Янсуарның "Күзен ача умырзая" дигән беренче китаплары укып тикшерелде. Остаханә житәкчесе—Татарстанның халык шагыйре И. Юзеев, утырышта катнашучылардан Р. Гаташ, Ш. Маннап, Г. Рәхим, Зөлфәт, Н. Гамбәр, М. Вәлиев, М. Әгъләмов, Н. Сафина, Ф. Мөслимова, Ш. Мостафин һ. б. өлеге авторларның иҗат җимешләре турында фикерләре белән уртаклаштылар. Нәтиҗәдә, һәр ике шагыйрә Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим ителде.

## ЯЗУЧЫДАН БҮЛӘК

Язучы Фәнзаман Баттал туган авылы мәктәбенә (Минзәлә районы, Үрсу авылы) бүләк итеп, шәхси китапханәсеннән 200 китап җибәрде. Аларның 100гә якынын каләмдәшләренең автограф белән биргән китаплары тәшкил итә.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Президенты Указы нигезендә, театр сәнгате өлкәсендәге уңышлары өчен, Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театрының сәнгать житәкчесе **Фәрит Әхмәтҗан улы Хәбибуллинга** "Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

# ГАЛӘМ ХИСЕ

XX—гасыр азагы татар мәдәни анына, татар сәнгатенә хас ин калку сыйфатларнын берсе—тарихчанлык. Гасыр эчендә булып үткән гарасатлар: сәяси бәрелешләр, сугыш-инкыйлаблар, экологик югалтулар, тау-елгаларнын, урман-үзәннәрнен таушалуы, икътисади һәлакәт һәм әхлак зәгыйфьләнү кебек күренешләр иҗат кешесенен дөньяны күзаллавына аеруча киеренкелек өсти. Тарих сәхифәләрен идеаллаштыру, аларны тоташ җәннәт, татлы төш итеп сурәтләүче, ә киләчәкне фаразлаганда—фаҗигале буяулар белән нәгышьләнгән карангы-шомлы рәсемнәр туууга сәбәп була.

Уфада яшәп иҗат иткән татар рәссаме Ренат Минлебай—борынгыны беркатлы мәдхияләү, яисә киләчәкне каргау сыман вак гамәллләрдән югары. Ул вакыт катламнарында курыкмыйча сәяхәт итә. Моннан 2-3 мен ел элек туган, бары Кытай чыганаклары, яисә Геродот язмаларында гына телгә алынып үткән легендар мәдәниятләрне, дәүләтләрне, андагы каһарман-пәһлеваннарны, ырым-тоюларны, инану төрләрен һәм гүзәл сәнгать үрнәкләрен дөрес, объектив итеп, бөтен чынбарлыгы белән торгызып эш итүче шәхес. Анын иҗатын мөмкин кадәр тирәнгә, кешелекнен "тамырларына" төшү теләге сугара. Анын рәсемнәрендә— Евразиялә безнен эрага кадәр 2 меңенче еллар эчендә шау иткән арийлар чоры, берзаман Европа, Азия далаларын лу куптарган скиф кабиләләре иҗаты (б. э. кадәр беренче меңьллык). Инеш-кырларны, агач-яфракларны пот иткән борынгы угорлар, бөек төркиләр мәдәнияте һәм ислам цивилизациясе. Р. Минлебай офорт—ак кәгазьгә бакыр пластинадан төшерелгән мөһерсыман рәсем техникасында эшли. Үткән цивилизацияләрдән калган гүзәл табылдыкларга гашыйк рәссам үзе дә беркадәр археолог (ул Аркаимда барган казыну эшләрендә катнашкан)—тарих "кыйпылчыкларын" бербөтен итеп нәфис р:тон (мөгез формасында алтын касә), пектораль (алтын яссы муенса), төрки "тораташ"—балбаллар итеп торгызып, безнен алдыбызга узган чорларнын сәнаигъ мирасын әзлекле бер күренеш итеп китереп бастыра.

Авторнын игътибарга лаек иҗат тармакларынын берсе—борынгы төркиләр мәдәнитe. Ерак Көнчыгыш цивилизациясен Урта дингез дөньясы белән тоташтыручы—тарихка аерым бер динамика, тизлек, куәт, яна төсләр, буяу, материаллар, темперамент, хәрәкәтчәнлек, тизлек бирүче төркиләр.

Бу могҗизалар авторнын шактый офортларында урын табалар, анын композицияләренен үзәген тәшкил итәләр. Мәсәлән, Милли мәдәният музеенын диварына эленеп куелачак зур рәсемнен нәкъ уртасыннан төрки халыкларнын анасы саналган Ак бүренен тылсымлы түгәрәк йөзе карап торачак.

Ә инде журнал тышлыгындагы рәсемдә—бөек эфсен иясе, тау тишегендә бикләнеп калган төрки ыруг бәндәләренә тимер эрету хикмәтен өйрәткән һәм аларны тозактан чыгарган мифик Ак бүре. Тумышы белән монгол кабиләләреннән булып, төркиләшкән һәм төрки халыкларнын легендар ата-бабасына әйләнгән реаль прототибы ул. Татар экиятләрендә без кешегә ярдәмчел геройларны үзенә атландырып ерак араларга илтә, эфсене белән дошманнарга өреп, аларны тораташка әйләндерә торган "Ак бүре" образын беләбез. Анын безгә төбәлгән утлы-алтын күзләрендә тирән мәгънә, тирән уй, сагыш катнаш сагыну... Мифик бүре төнге пейзаж кодрәтенә индерелгән... Бу йолдызлы чем-кара күк гөмбәзеннән кавемнәрне, гавәмнәрне, милләтләрне, тарихларны, һәм, гомумән, дөнья хикмәтен үз эченә алган кодрәтле физик бербөтен галәм хисе анкып тора сыман.

Бүре дрессировкага бирешми, коллыкны сөйми, ул юлбашчы-әйдаман. Шунын белән дә бу образ бүген безгә якын һәм анлаешлы.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
*сәнгать белгече*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы, публицист Фәнзаман Баттал.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. **Сайланма әсәрләр.** IV том.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1998.—384 б. Тиражы 2000 данә.




Яңа ел алдыннан гына Равил Фәйзуллин Сайланма әсәрләренең чираттагы IY томы дөнья күрде. Бу томлыкка шагыйрьнең 50 гә якын әдәби-публицистик мәкаләсе тупланган. Аларның бер өлешен татар әдипләренә (Г. Тукай, М. Җәлил, Г. Кутуй, Х. Туфан, С. Хәким, Г. Афзал, Н. Арслан, С. Баттал, Г. Ахунов, М. Шабаев, Ш. Хөсәенов, Р. Даутов, Батулла. Рәш. Әхмәтҗанов, Р. Гаташ, Г. Рәхим, М. Әгъләмов, З. Мансуров, Ф. Зөлкарнәй, Мөдәрис Вәлиев, М. Галиев һ. б.) багышланган иҗади портретлар тәшкил итсә, калган өлеше әдәби процесска караган эссе-уйланулардан гыйбарәт.

Равил Фәйзуллин әдәбиятка яшьли кереп, соңгы өч дистәдән артык елда әдәби-иҗтимагый хәрәкәтнең үзәгендә кайнаучы әдип. Татарстанда, Россиядә, элеккеге СССРда, һәм шулай ук, чит илләрдә үткәрелгән югары дәрәҗәдәге конференция-съездларда, әдәбият атналыгы-декадаларда, халыкара форумнарда татар әдәбияты вәкиле сыйфатында актив катнашкан шәхес буларак, аның бу язмаларын XX гасырның соңгы чирегендәге әдәбиятыбызның үзенчә бер шаһитнамәсе, әдип күзаллавындагы бер елъязмасы дип бәяләп була.

Равил Фәйзуллин сайланма әсәрләренең элеккерәк елларда (I том—1992, II том—1993, III—1995) чыккан басмалары киң җәмәгатьчелектә хуплау табып, тиз арада таралып беткәннәр иде. Бу томлык—югары уку йортларында, мәктәпләрдә, милли гимназияләрдә бүгенге татар әдәбияты буенча укытучылар, студентлар, гомумән, әдәбият сөючеләр өчен файдалы кулланма булачак.

Алдагы елларда чыккан басмаларныкы шикелле, бу томлыкның да мөхәррире—Наис Гамбәр, рәссамы Д. Җәләлетдинов.

Китапны соратып алучылар игътибарына:

*420111, Казан, Бауман ур., 19.*
*Татарстан китап нәшрияты,*
☎ *92-27-62; 92-00-13.*

Индекс 73210



Фәнзаман Баттал

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)